


# КАЗАН УТЛАРЫ

12
ДЕКАБРЬ
1979

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**12**

ДЕКАБРЬ
1979

## Бу санда

**С. СӨЛӘЙМАНОВА. Сабыр канатларым.** Шигырьләр . . . 3
**Ә. ШӘМИН. Яңа язлар.** Повесть . . . 6
**К. ЛАТЫЙП. Яктылык тизлеге.** Шигырьләр . . . 67
**Ә. ГАФФАР. Бер йотым су.** Хикәя . . . 70

В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ ТУЛУГА, ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН ОЧЕРКЛАРДАН

**И. ЗАРИПОВ. Уренгойның ак боланы** . . . 79

**Р. ЗӘКИЕВ. Кояш иңгән аяз алан.** Шигырьләр . 98
**Ә. РӘШИТОВ. Талпыну.** Шигырьләр . . . 100
**Ә. МӘХМҮДОВ. Хезмәт яме.** Шигырьләр . . . 103
**Н. ӘМИНЕВА. Иң кирәклесе.** Шигырьләр . . . 105
**БАТУЛЛА. Яшенле яңгыр көткәндә.** Хикәя . . . 107

ПУБЛИЦИСТИКА

**М. РАФИКОВ. Суда балык йөзәдер** . . . 116

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 80 ЯШЬ

**Н. ИСӘНБӘТ. Татар теленең фразеологик әйтемнәрендә тарихилык һәм үткән белән хәзергенең чагылышы** . . . 124

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Х. ЗАКИРОВ. Өянкеләр шавы.** Хикәя . . . 142

ДӘРДМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

**Г. ХАЛИТ. Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе** . . . 146

ГАБДУЛЛА ШАМУКОВКА 70 ЯШЬ

**Г. ШАМУКОВ. Мәсәлләр** . . . 158

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**В. ХАНГИЛДИН. Әдәби телебезне тагын да камилләштерик** . . . 160

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ГОСМАНОВ.** Мираска ихтирам . . . . . . 166

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Яктылыкка — нурга илтә . . 170

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Х. ГАЙНЕТДИНОВ.** Төсләрдә — күңел яктысы. (Х. Якуповка 60 яшь) . . . . . . . . . . . 174
**Ә. РАХМАН.** Киңлек һәм кыюлык юлыннан. (Я. Абдуллинга 60 яшь) . . . . . . . . . . 176
Мәсәлчеләр мәҗлесе . . . . . . . . . . . . 178

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**С. ШӘЙДУЛЛИН.** Мәсәлләр . . . . . . . . . 180
1979 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр. 182
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** Баш редактор—3-07-60, баш редактор урынбасары—3-07-60, җаваплы секретарь—3-07-09, проза бүлеге—3-07-61, поэзия бүлеге—3-07-61, тәнкыйть бүлеге—3-07-63, сәнгать бүлеге—3-07-63, очерклар бүлеге—3-07-63, хатлар бүлеге—3-07-61, корректорлар—3-07-65, техник редактор—3-07-65, машинисткалар—3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

**Редколлегия:** **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 23/VIII-1979 ел. Басарга кул куелды 23/XI-1979 ел. ПФ 09053. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83300 экз. Заказ Ц-350. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

## Сажидә Сөләйманова

# САБЫР КАНАТЛАРЫМ

### Төшен—төшкә

Бераүгә дә багышламый гына
үзем өчен язам, җан өчен.
Башта уйлар, җанда көйләр чыңлый,
очын очка кирә ялгыйсым.

Җил иркенә чыгып, җилгәрәсем
төшен — төшкә, чүбен — кибәккә.
Арыш басуының алкышлары
җанга иңә, тынны киңәйтә.

Башакларның бардыр үз исәбе,
табаларымы берәр охшашлык? —
Уңыш туе өчен җилгәрелү —
ул, мөгаен, үзе бер шатлык.

Җиргә салган һәрбер бөртек тере,
яшәрерләр кабат язларын.
Башаклар бит алар тормыш өчен,
кеше өчен сала башларын.

Битне сыйпый арыш башаклары,
хатирәләр тынны киңәйтә.
Эш өстендә уйлар җилгәрелә
төше — төшкә, чүбе — кибәккә.

Яшь чакларым, алтын башакларым!..
Сорамадык хәтта кем өчен —
яшьтәшләрем янды яшәү өчен,
яшәү биргән туган җир өчен.

Үзем өчен генә җырлый алмыйм,
арышларым, сезгә багышлау.
Урган, чәчкән, яуда калганнарны
онытмасак, җырда ялгышмам.

●

Тау тарта мине, тау тарта,
туган якларга кайтарта.
Исәннәр әле, исәннәр
кыяда янәшә исемнәр.

Су тарта мине, су тарта,
җәйләрдә җирсетә, сусата.
Тәгәри чуер ташлары,
ярларга салып башларын.

Ай тарта мине, ай тарта,
тукталып, тотылып торганы,
безне бер янәшә күргәне
туган якларга кайтарта.

●

Җил исте дә, очтың, яфрак атлы
и, самими яшел тереклек,
һәм берәүнең күкрәгенә яттың,
син әсирме, әллә ирекле?

Охшагансың кеше йөрәгенә,
тармак-тармак тере тамырың.
Бер кыз сине үз учына салыр,
бит алмасы белән кагылыр.

Аннан куяр китап арасына...
Тамырың җирдә, төсең бизәктә.
Күккә очтың, яфрак, җиргә төштең,
җырга күчтем диеп исәплә.

Яфрак-яфрак яшел ямьгә чумса,
яшеннән соң күкрәп, һәр тараф,
чыклы таңда туган моңлы җырга
бер йөрәк тә калмас битараф.

●

Маңгай тирен сөртеп ала егет,
әнисенә оек кидерә...
Улын шулай киендергән чакта
ана бәхетлерәк иде лә!—

Сабыеның тәүге адымнары
хәтерендә олы бәйрәмдәй...
Сырхаудан соң ана җиргә басты,
җир әйләнә, дөнья әйләнә...

Сирәк бәйрәм, сәер бәхетләрнең
яңа аңлагандай мәгънәсен,
кыенсынып кына көлемсери,—
җитәкләгән улы әнкәсен.

Ана белән бала кулларының
бергәлеге янә яңаргач,
елмаюлар куна бар йөзләргә
яз кошы белән аралаш.

## Сабыр канатларым

Сабыр канатларым, сабыр канатларым...
Кулым сузып калдым, чапты пар атларым!
Тик ымсынып калдым, сулыгып карап калдым,
Сөйгәнемнән гүя нахак талак алдым.

Ыспай кунакларны, оста каракларны —
чыбыркылап куды чаптар пар атларны.
Янәр инде атлар сугармаган килеш,
төнгелеккә калыр тугармаган килеш.

Йөгерә-атлый китәм җәйләүләргә таба,
җәяүләргә кала, җәяүләргә кала.
Сыгылмагыз әле, сабыр канатларым,
бер йотымга сусап торадыр атларым.

Ир канаты аттыр, кыз канаты актыр.
Ак канатка атмас, булса ул чын батыр.
Бәлки эзләп тапкан чапкын туры атларны,
тугарылмый чапкан атлар яраткандыр.

Узалмыйдыр атлар камчы-авызлыксыз...
Тик ямьлерәк иде дөнья явызлыксыз.
Канга тузсын тезләр, егыла-тора атлармын,
тик сынмасын гына сабыр канатларым.
Сабыр, канатларым...

**Әбрар Шәмин**

# ЯҢА ЯЗЛАР

ПОВЕСТЬ

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### I



Еллар юллар белән башланды. 1947 ел, көз. Шәһәр урамнарында бүген иртәдән бирле ябалак-ябалак кар ява. Беренче кар.

— Әйдә, Әкрам!— диде Зиннәтша абзый, озын гына коридордагы беренче бүлмәгә керергә әзерләнеп.— Әйдә, оялып торма! Син хәзер авыл малае түгел. Әйдә, капчыкларны да үзебез белән алыйк!

Алар үткән айда гына төзелгән яңа трестның кадрлар бүлегенә килеп керделәр. Бүлмәдә чем-кара чәчле, чем-кара күзле яшь кенә бер кыз ялгызы гына утыра икән.

— Сез эшкә ялланып килүчеләрме?

— Әйе,— диде Зиннәтша абзый, өстәл каршына килеп.— Сез кем буласыз, сеңелем?

— Мин монда эшлим.

Абзый өстәлгә төрле-төрле документлар чыгарып куя башлады:

— Менә паспортлар. Менә колхоз кәгазе. Икебезнеке дә шунда. Менә минем хәрби билетым.

Кыз документларны алды, укыды һәм аларны кызыл папкага салып куйды.

— Бераз сабыр итегез! Озакламыйча начальник килер.

Абзый белән Әкрам, өстәл каршыннан китеп, шушы ук бүлмәдәге кыска эскәмиягә урнаштылар.

Өйлә вакыты иде. Кыз, үзенең өстәл тартмасын ачып, кәгазь төргәк чыгарды һәм тамак туйдырырга кереште.

— Рәхим итегез!

Абзыйның күзләре очлы: кыз өстәлендә бер телем күмәч, аз гына ак май һәм кечкенә генә балык кисәге пәйда булды.

— Юк, рәхмәт!— диде абзый, күмәч белән майга кызыгып карап.— Безнең тәгам бар әле болай...
Абзый капчыкны ачты, солы оны кушып пешергән ике кабартма алды һәм аларның берсен Әкрамга бирде.
— Аша, Әкрам!
Әкрам ачыккан иде.
— Абый! Минем капчыкта бәрәңге коймагы бар иде. Аны да ашыйк!
Сүзгә кыз да кушылды:
— Сез татарлар икәнсез, ә?
Абзый гаҗәпкә калды:
— Менәтерәк! Сез дә татар кызы икәнсез ләбаса? Кайсы якныкы?
Кыз никтер җавап бирмәде. Беләсе килә ич, Әкрам абзый баягы соравын кабатлады:
— Ник яшерәсез? Әйтегез инде! Кайсы шәһәрдән, кайсы яктан сез? Ихтимал Казаннандыр?— диде аннары абзый, елмаеп.— Без дә Казан ягыннан, сеңелем, Зөябашыннан. Танышсак зарар булмас: менә бу егет Әкрам, минем абыем улы. Пләмәнник, значет. Яшь әле, унсигезне тутырды гына. Зөябашында әнисе бар аның. Минем килен, значет. Әтисе фронтта югалды. Нишлисең бит, сугыш хәлләре. Мин дә тол хәзер. Хатыным мин фронтта чакта үлгән. Ә кыз Ташкент ягында — ирдә. Сездән ник яшерергә? Икебезнең дә ният Зөябашында матур йорт кору. Кем белә, бәлки монда да төпләнеп булыр әле.
Әкрам бу сүзләрне әчтән борчылып, әчтән көенеп тыңлап утырды.
— И абый!— диде кыз, урыныннан торып.— Сезнең дә, Әкрамның да кайгы-хәсрәтегез күп булган икән. Ләкин нишләмәк кирәк? Әх язмышлар, язмышлар...
Кыз әле абзыйга, әле Әкрамга җентекләп карап куйды.
Әйе, абзый соры шинельдән, погоннары юк, билендә солдат каешы, башында кер җыйган колаклы бүрек, солдат бүреге. Әкрам исә кыска гына калын пинжәктән, аягында олтан салынган итек... Малай буйга озын икән, әмма яшь әле, бик яшь.
— Мин техник, монда вакытлыча гына эшлим,— диде кыз, күз карашын абзыйга юнәлдереп.—Исемем—Мәрьям, ә русча Маша дип атыйлар мине. Әнием...
Мәрьям тагын нидер әйтмәкче иде, ләкин бүлмәгә бер ир килеп керде. Карап торырга нәкъ Зиннәтша абзый: керүченең киеме ярты-лаш хәрби.
— Менә яңа эшчеләр,— диде Маша, әлеге иргә карап.— Менә аларның документлары.
Абзый шунда ук аңлады: әлеге ир трестның кадрлар бүлеге башлыгы икән.
— Рәхим итегез!— диде ул, эшкә килүчеләрне үзенең бүлмәсенә чакырып.— Танышыйк! Сез дә фронтовик, ахры?— Кадрлар башлыгы абзыйның һәм Әкрамның документларын тикшерергә тотынды.— Яхшы, яхшы!
Абзый сүзгә бик юмарт кеше. Бигрәк тә мондый чакларда:
— Әйе, фронтовик. Өч елга якын фронтта булдым. Бер тапкыр — тыловой госпитальдә. Өлкән сержант идем мин. Сапер. Соңгы дәрәҗәм — старшина. Шинелегездән таныйм: сез офицер булгансыз икән?
— Әйе,— диде бүлек башлыгы, абзый белән Әкрамның документларын укып бетергәч.— Сез безгә кирәк кешеләр. Ә сезне, старшина, бригадир итәргә мөмкин. Сөйләштекме, бригадир?
Абзый елмаеп куйды:
— Күз күрер...
Аларны «Уралкоммунстрой»ның махсус трестына эшкә алдылар һәм шунда ук, кулларына икмәк карточкалары биреп, тулай торакка озаттылар.

Абзый һәм Әкрам әйбәтрәк баракка урнаштылар. Иркен, якты. Бүлмәдә биш кенә кеше. Икмәк кибете каршы яктагы иске барак белән янәшә генә икән. Яңа эшчеләрне шул барактагы кечкенә генә складка чакырып алып, эш киемнәре белән тәэмин иттеләр: брезент пинжәк, брезент чалбар, озын балтырлы резин итек.

— Ну, Әкрам, настоящий рабочий без хәзер,— диде абзый, эш киемнәрен култык астына төреп баракка кайтып кергәч.— Менә бу чал Уралдан баеп кайтып, икебезгә ике йорт саласы гына кала, шайтан алгыры, ә?

Нәкъ шул вакыт бүлмәгә бер хатын килеп керде. Кулларында юка гына юрганнар һәм житен простынялар.

— Исәннәрме, яңа эшчеләр?

— Исәнмесез?

— Менә сезгә юрганнар, простынялар. Тәртипле файдаланыгыз! Матраслар караватларда. Әнә ике урын буш.

Сүз рус телендә барды. Хатын һич көтмәгәндә татар теленә күчте:

— Сезне татарлар дип әйтәләр. Дөресме, юкмы?

— Бик дөрес!—диде абзый, куанып.— Кем сез, кайсы якныкы, ходай бәндәсе?

— Мин уборщица, бик ашыгам.

Хатын бүлмәдән тиз генә чыгып китте. Абзый һәм Әкрам бер-беренә карашып куйдылар.

— Менәтерәк!— диде абзый, әлеге хатын китергән постельләрне караватка җәяргә тырышып.— Рәхәттә ятыйк әле ичмаса, шайтан алгыры. Давай урын-жиреңне төзәт! Солдат булырга вакыт...

Көн кичкә якка авышты.

— Тамак туйдырыйк!— диде абзый, Әкрамга карап.

Бераздан алар бүген генә кибеттән алып кергән саф арыш икмәге белән тамак туйдыра башладылар: «Тәмлеме. Әй тәмле лә!» дип сөйләнделәр. Зур чәйнектә кайнаган су да табылды: бүлмәгә кергәч уңда, чуен плитә өстендә икән.

— Әкрам!— диде абзый, тамагы туйгач, үзенең караваты янына барып.— Карта уйныйкмы?

Әкрамның карта уйнаганы юк иде әле.

— Мин уйный белмим, Зиннәтша абый.

Абзый караватка ятты һәм никтер бик тиз йоклап та китте: хырр... хыр... хыр...

Мондый чакта нишләргә? Берничә секундтан соң Әкрам да үзенең караватына баш төртте, ләкин йокы килмәде. Әкрам кинәт үзенең туган якларын, әнисен күз алдына китерде.

Әйе, Әкрам Зөябашыннан чыгып киткәндә Бөек Ватан сугышы беткәнгә әле ике ел да тулып җитмәгән иде. Бер көнне Әкрамның әнисе күршеләр каршындагы тирән коедан су алып керде дә: «И... балам! Туган авылны ташлап, чит җирләргә ничек чыгып китәрсең?»— дип өзгәләнеп әйтте. Аның бу сүзләре кайчан булса да истән чыгармы? Зөябашы «Тау ягы» дип аталган чокырлы кырлар һәм яшел болыннар түрендә борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Әбиләр сөйли: Җәй көннәрендә челтерәп аккан салкын чишмәләр дә күп булган монда. Зөябашы ике генә урамлы авыл, ләкин аның яшелчә бакчалары һәм уйсу аланлыклары күрше авылның алма бакчасына ук барып тоташалар. Әкрам гаҗәпләнә: чит җирдә бик кызык икән, әмма туган як барыбер сагындыра. Әйтергә генә ансат, Әкрам җидене дә Зөябашында тәмамлады ич. Ә сабый чаклар, ә сугыш еллары: «Менә, улым, хәл кадәре май салып, кабак бәлеше пешердем бүген». Әни, әни! Әкрам аның миһербанлы күзләрен мәңге онытмас. Әни! Әнә ул, әнә; әйтерсең

хәзер монда килә: әнә өстендә мамык белән сырылган плүш пальто. Әнә әни һаман кайгыра: «Әй улым, улым! Әтиең тәки фронтта һәлак булды микәнни?» Әкрам әтисен хәтерли: түгәрәк йөз, кара мыек, урта буй. Ул җырчы булган. Зиннәтша абыйсы белән бергә, киң чанага утырып, авылдан чыгып киткән чакта Әкрам да җырлады:

> Сандугачлар килде, аккош кайтты,
> Син кайтмадың киткән җиреңнән...
> Аккош китәр урман күлләреннән,
> Син китмәссең минем күңелемнән.

Әкрам уйланды. Очсыз, кырыйсыз, киртәсез иде бу уйлар. Әйе, Зөябашыннан чыгып киткәч тә кырлар башланды. Аннары юллар һәм ерак авыллар... Төрле исемле, төрле милләтле, төрле байлыктагы авыллар... Күбесе таныш. Әнә Әкрамны кайчандыр зур белем алу турында хыялландырган Мөрле авылы. Зур авыл. Әнә Зөя үренә күтәрелгәндә әллә кайларга күренеп тора. Мәктәбе унъеллык аның. Әкрам бу авылга сабан туена килә иде. Ләкин сугыш. Сугыш гаепле! Гитлер гаепле!.. Менә инде сугыш тончыкты, бетте. Ә килгән юл һәм чана һаман онытылмый... Андагы коры печәннән әле дә хуш исләр аңкый төсле... Әнә әйтерсең тирә-юньдә көмеш кар һаман ялтырый. Ә чана җырлый, чана моңая: «Кыш... Кыш... Кыш». Әйтерсең ул яңа бер көйгә: «Кайда икән, кайда икән, без барасы ерак юл?» — ди.

Ниһаять, чана тимер юлы станциясенә килеп туктый. Сугыш елларында Зөябашыннан ашлык ташыган чакта бик күп мәртәбәләр булды монда Әкрам. Һәммәсе таныш: каршы якта таш вокзал, ә аннан арырак дәүләт складлары. Өйлә вакыты. Вокзал кешеләр белән шыгрым тулы. Моның сәбәбе Зиннәтша абыйга билгеле икән: «Сугыштан соң халык урнашып бетә алмый». Зиннәтша абый дөньяны гизгән кеше. Чувашча да шәп белә. Поезд көткән арада бер чуваш хатынына акрын гына:

> Айда, инкә, вырмана,
> Хура шырла пуштарма[1]...

— дип җырлап та бирде.

Әкрам йөзтүбән ята һәм уйлый. Уйлар, уйлар, уйлар... Әйе, юлда килгәндә ашау ягы, колхоз кырындагыдай, тиз күмәкләште: «Менә кәбестәгә төреп пешергән бәрәңге кәлҗемәсе, Зиннәтша абый, аша! Менә йомырка, менә бер тавык боты. Аша, Зиннәтша абый, аша! Һәммәсен дә юлга дип, әнием әзерләгән».

Поезд Казанда озак тормады. Мәскәү ягыннан килеп җитте дә Урал ягына китеп тә барды. Казан... Нинди матур, нинди зур, нинди дәһшәтле диләр бу шәһәрне! Әкрамның әле бер генә тапкыр да булганы юк иде бу зур калада. Анда эңгер-меңгер вакытлар иде. Шул чак кинәт утлар кабынды. Карап туймассың: әйтерсең Казан утлар диңгезе! Кызык иҷ, кызык. Абзый, Әкрамны нәртеп, вокзалның зур залына керде. Карт солдат абзый ни күзе белән күрсен, вокзалның буфетында сыра саталар! Тиз генә буфет каршына килеп: «Өч кружка!» — дип кычкырды абзый. Бирделәр, эчте. Әкрам эчмәде. Ул эчәргә кайчан һәм кайда өйрәнсен әле? Абзый буфеттагы икра, кызыл балык бәяләре белән кызыксына башлады, ләкин кесә ягы чыдарлык түгел икән. «Әйдә, селәгәйне агызмыйк, коммерческий ул,— диде абзый һәм вагонга ашыкты. — Әйдә, тимер алаша безне көтеп тормас, шайтан алгыры!» Абзый, вокзалдан вагонга кергәч, шактый гыйбрәтле бер вакыйга турында сөйләп бирде: «Казанда булды бу хәл, шайтан алгыры. Сугышка чаклы. Мин Пермьнән кайтып киләм, значет. Пароходта йөкче булып эшләдем. Егет чак. Кесә тулы кызыл червонец. Ни-

[1] Әйдә җиңги урманга,
Кура җиләге пешкән...

ят—өйләнү. Кызлар күзен шар итәрлек бик матур костюм эзлим. Казанда кибеткә кереп, кулны кесәгә тыксам: червоннар тү-тү! Менә сиңа өйләнү!

Әкрам елмаеп куйды һәм тагын уйларын дәвам итте: Урал... Нәкъ поездда абзый сөйләп килгәнчә — тезмә таулардан гыйбарәт икән Урал. Урал... Монда урманнар да күп. Кая гына карама ямь-яшел урман. Нарат урманы. Ул да түгел, караңгы тоннель. Ә тоннельне үткәч: янә урман, янә очлы кыялар, янә коточкыч текә ярлар, тирән чокырлар, аннары яшь наратлар, яшь чыршылар... Кем белә, бәлки бу тауларда кайчандыр ут вулканнары ыжгыргандыр?

Әкрам шулай уйланып ята бирде. Аның уйларын кинәт абзый тавышы өзде:

— Энем! Мин черем итеп алдым, ахры, шайтан алгыры? Ә кешеләр һаман эштән кайтмадылармы әле?

— Юк, — диде Әкрам һәм тиз генә урыныннан торды.— Иртәгә эшкә чыгабызмы, Зиннәтша абый?

Абзый да торды:

— Обязательно!

### 3

Эшчеләр кайтып кергәндә баракта инде ут кабынган иде. Абзый кыю кеше. Ул монда яшәүче эшчеләр белән үзе танышырга кереште:

— Ну, әйдәгез, таныш булыйк, егетләр! Кайсыгыз кайсы яктан? «Ат кешнәшеп табыша, кеше сөйләшеп таныша», дигәннәр ич. Мин Кәлимуллин Зиннәтша. Карт солдат, значет, шайтан алгыры.

Эшчеләрнең берсе Оренбургтан, берсе Уфадан, ә берсе — кыска буйлы, соры күзлесе Казаннан икән.

— Мин Казаннан.— диде ул, никтер бик горурланып.— Мин Ярмухаметов Гайни булам. Икенче төрле итеп әйткәндә — Гайнулла яки Гайка. Ә син нинди кеше, карт солдат? Синең белән дуслашып буламы, юкмы? Усал эт кебек, тешли торган гадәтең юкмы?

— Бар!— диде абзый, җитди төс алып.— Мин тешләсәм, ычкына алмассың, егет!

Оренбург егете кычкырып көлеп җибәрде:

— Кирәгеңне алдыңмы, Гайка?

— Күрәм, карт солдат, син иске шинелең белән масаясың, ахры? Әгәр алырга теләмәсәк, без сине монда сыйдырмаска да күп сорамабыз. Ишеттек: үзең белән бергә авызыннан селәгәе китмәгән яшь малай ияртеп килгәнсең. — Ярмөхәммәтов Әкрамга кулы белән күрсәтте. — Аның өчен без эшләрбез дип уйлыйсыңмы, солдат?

Абзый дәшмәде, түзде: «Карыйк әле, күз күрер».

Әкрам ачуыннан тешләрен кысты.

— Чебешләрне көздә саныйлар,—диде Зиннәтша абзый.—Карт солдатның нервылары какшаган, сез аны онытмагыз.

Бүлмәгә, бер кочак ваклап туралган утын күтәреп, мичкә ягучы хатын килеп керде. Абзый аны шунда ук таныды: татар хатыны, көндез юрган һәм простынялар алып килгән хатын. Чибәр, чем-кара күзләр... Сүз дә юк, сөйкемле хатын. Яшь ягыннан утыз биш-кырык тирәсе. Кием-салымы, барак халкыныкыдай, брезент пинжәк, ләкин аякта әйбәт киез итек, ә башта, иске булса да, оренбур шәле.

— Җылытыйм әле үзегезне, — диде хатын, кочагындагы утыннарны мич янына ташлап.— Җылытыйм әле, рәхәтләнеп йоклагыз!

Хатын елмаеп куйды, мичне ягып җибәрде. Абзый аның каршына килде һәм сүз башлады:

— Менә галәмәт! Бая әйтмәдегез, исемегез ничек?

— Фатыйма.

— Кайсы якныкы?
— Тамбовтан. Аннары — Үзбәкстан, аннары — Украина, аннары — фронт...
Абзый гаҗәпкә калды:
— Ничек инде ул? Мин аңлап житкерә алмыйм, Фатыйма сеңелем?
Фатыйма җитди төс алды:
— Ник аңлашылмасын? Мин Тамбовта туып, Тамбовта үстем. Тамбовта иргә чыктым. Мин, ирем белән бергә, Ташкентка күчтем. Аннары — Украина. Аннары — фронт... Мин чик сакчысы хатыны идем, ә монда эвакуация буенча килдем. Бердәнбер кызым Мәрьям дә монда. «Маша» дип атыйлар аны. Мактаныйм әле: кызым быел кечке техникум тәмамлады. Техник ул. Миннән зур инде. Хәзергә вакытлыча кадрлар бүлегендә эшли...
— Мин аны беләм, күрдем!— диде абзый, шатланып.— Кадрлар бүлегендә, значет. Чибәр кыз.
Абзый нииндидер уйга калды. Фатыйма дәшмәде. Ул мичкә салган утыннар дарыдай гөрләп яналар иде.
«Менә сиңа дөнья!— диде абзый, уйларны дәвам итеп.— Менә кешеләрнең язмышлары белән ничек кенә уйнамый, шайтан алгыры».
Фатыйма ашыга иде. Ул күрше баракка чыгып китте.



## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Эш иртүк башланды. Зур шәһәрнең Декабристлар урамы. Иске урам, әмма һаман әле көн саен чаң бирә торган чиркәүле урам, ә чиркәүгә якын гына — иске зират.
Бүген әллә ни салкын түгел. Хәтта кичтән яуган кар эри. Абзый канауда эшли. Кулда — көрәк.
— Иптәш Кәлимуллин!— диде аңа прораб.— Эшне дәвам итегез, ә мин башка участокларга барам. Сез элеккеге сапер ич, эшне аңлыйсыз.
Абзый — бригадир. Ул, үзенең бригадасындагы эшчеләр белән бергә, Декабристлар урамындагы канауларны төзәтә. Канаулар исә тәмам бозылган, урыны-урыны белән ишелеп төшкән һәм андагы су юллары өзелгән икән.
— Ярый, иптәш прораб,— диде абзый, маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртеп.— Эш бездән тормас, тик торбаларны гына тизрәк китертегез!
Урам... Киң урам. Кайчандыр ул вак таш һәм калын асфальт белән капланган булган. Каршы якта бер генә катлы агач яки таш йортлар һәм зәңгәр капкалар. Әкрам белән Зиннәтша абзый һәм башка эшчеләр менә шушы урамда яңа канау казыйлар. Табигый хәл, җир монда чуерга әверелгән, ә шулай да эш туктамый, эш кайный, кая гына карама — халык һәм көрәк тавышы. Әнә бүген иртәнге якта бульдозер пәйда булды. Әкрам кулында — көрәк. Кыска саплы, үткер көрәк. Брезент бияләй. Әкрам җир казый. Җирдән чыккан балчыкны иске тротуар буйларына ыргыта Әкрам. Җир тирәнәя, канау эчендә ташлар очрый. Әкрам, тимер көрәкне ташлап, җирне лом белән казый. Аннары ломны янә көрәккә алыштыра. Әкрам уйлана: «Карале, мондый эш ничек сагындырган!» Әкрам үзенең авылда чакта бәрәңге бакчасында эшләп йөргән көннәрен күз алдына китерде. Нәкъ шул минутта тротуар буйлап бер карчык үтеп бара иде. Карчык туктады: «Я рабби! Шундый яшь малай нинди авыр эшкә җигелгән?»

— Эти-эниең юк мәллә, улым?— диде карчык, Әкрамга карап.— Әтиең сугышта үлгәндер шул, бәгырем?
Әкрам дәшмәде, эшләвен дәвам итте. Сүзгә абзый кушылды.
— Ятим түгел ул, әби, эшләсен, эш сөякне сындырмый, шайтан алгыры.
Карчык китте. Канау каршына техник Мәрьям килде. Аңа саф һава тәэсир иткән күрәсең: болай да алсу бите комач кебек кызарган.
— Эшләр барамы, иптәш бригадир?
— Бара, техник, бик әйбәт бара!
Мәрьям, абый белән Әкрамга карап, елмаеп куйды:
— Бригадир абый! Эшчеләрне ике группага бүлсәк дөресрәк булмасмы? Әйтик, группаларның берсе җирне лом белән йомшартып бара, ә икенчесе аны канау эченнән көрәкләр белән әрчи.
Абзый уйланып торды.
— Дөрес!— диде ул бераздан.— Дөрес! Ни дисәләр дә яшь кыз акылы дөресрәк эшли бит, шайтан алгыры.
Мәрьям канауның киңлеген ике метрдан киметмәскә боерык бирде һәм тиз генә каядыр китеп тә барды.
Җир казучы эшчеләр белән бергә Ярмөхәммәтов Гайни дә эшли. Ул Мәрьям артыннан күзен акайтып карап калды да:
— Тьфу!—диде.—Маша да начальник, янәсе!
Моңа берәү дә игътибар бирмәде, эш дәвам итте. Аннары бригадир:
— Перекур!— дип кычкырды...

2

Вакыт эңгер-меңгер тирәсе иде. Әкрам белән абзый, эштән кайтышлый кибеткә кереп сигез йөз грамм күмәч, сигез йөз грамм арыш икмәге, бер кило шикәр һәм ике йөз грамм такта чәй алдылар.
— Иртәгә тары ярмасы була,— диде аларга кибетче хатын.— Карточкаларыгызны ашханәгә тапшырмасагыз, ашамлыкларны моннан гына алырга мөмкин.
Абзый солдат кашыгы, солдат боткасы белән элек-электән дуслашкан кеше. Кайчандыр, аз гына вакыт повар да булган.
— Без үзебез повар, сеңел,— диде ул кибетчегә.— Иртәгә, ярмадан башка, тагын берәр төрле ашамлык булырмы икән?
Кибетче хатын көттереп җавап бирде:
— Балык көтәбез.
Абзый тормышта чыныккан кеше. Кибеттән чыгып баракка кайткан чакта Әкрамга болай диде:
— Сизәсеңме, энекәш! Озакламыйча рәхәт яши башлыйбыз. Карале кулда нинчаклы ашамлык, ә? Значет дөнья төзәлә, тормыш рәтләнә. Шулай булмый хәле юк: сугыш тончыкты. Менә күрерсең: эшләр яхшырганнан-яхшыра барыр. Авылда корылачак өй кешеләр шаккатырлык булсын, шайтан алгыры...
Әкрамның ашыйсы килә һәм ул кулындагы күмәчкә карый, кызыга иде. Түзмәде, күмәчне кулы белән сындырып капты, комсызланып чәйни башлады:
— Әй тәмле лә, Зиннәтша абый!
— Иртәгә тары ярмасыннан аш пешерәбез, балык ашарбыз,—диде абзый.— Курыкма, ач булмабыз!
Алар баракка кайтып керделәр, эш киемнәрен салып, чөйгә элделәр. Абзый, чуен плитә өстендә торган зур чәйнеккә су салып, чәй кайната башлады. Баракка әле Гайни кайтмаган иде.

— Иптәшләр!— диде Уфа егете.— Әгәр дә аш әзерләсәгез, әнә миндә кастрюль бар, табак белән кашык бар, бәрәнге дә табылыр.
— Зур рәхмәт, якташ!— диде абзый куанып.— Ләкин бүгенгә кирәк булмас.
Абзый өстәлгә ак тастымал җәеп, икмәк турый башлады:
— Өч телем арыш ипие, өч телем күмәч житәрдер пока. Чәйгә шикәрне күбрәк салырбыз: сагындырган, шайтан алгыры.
— Ярый, Зиннәтша абый,— диде Әкрам, өстәлгә коелып төшкән икмәк валчыгын бармагы белән җыеп. — Менә, әрәм булмасын! Мондый ак күмәч төшкә дә керми иде.
Ниһаять, чәй өлгерде. Абзый үзе өчен дә, Әкрам өчен дә яшь балалардай шатлана иде.
— Менә бу күмәч — күмәч ичмаса! Исңә, Әкрам, нинди хуш исле бит, ә? Чәй дә хуш исле, мөгаен Грузия яки Сәмарканд чәедер ул. Күңел тарта, әх, тагын бер барасы иде шундый якларга!
Болар чәй эчеп бетерү алдыннан гына Гайнулла кайтып керде. Исерек. Әмма аякта нык тора. Ул кайдадыр егылган күрәсең: чалбарының тезләре җирәнерлек пычрак.
— Бригадир!— диде Гайни, күзен акайтып.— Нигә син безнең эш нормасын арттырдың? Мин синең медалең бар дип тормам.— Абзыйның түшендә дүрт медаль ялтырый иде.— Ә син, Зөя малае!— Гайни Әкрамга карады.— Нигә син эштә бик тырышасың? Әллә син техник Машага гашыйк булырга уйладыңмы? Белеп тор: әгәр дә Маша белән йөри башласаң, мин сине суям. Суям, подхалим, турыйм!
Әкрам кинәт кабынып киткәндәй булды:
— Әгәр хәлеңнән килсә?!
Абзый сүзне куертмаска тырышты:
— Ят, Гайнулла, ят, йоклап ал азрак. Яки кайнар чәй эч. Әнә кайнаган чәебез бар.
— Мин столовыйга йөрим, бригадир,— диде Гайни һәм өс-башын чишенми-нитми, караватка ауды.— Белерсең әле, белерсең минем кемлегемне...
Исерек йокыга китте.
Абзый чишенде, караватка урнашты, барак халкына хәерле йокы теләде, ә үзе йокыга китә алмыйча, озак уйланып ятты.
Әйе, сугышка чаклы абзыйның да хатыны бар иде. Гөлнур. Абзый Бөек Ватан сугышында бик каты яраланып, хәрби госпитальдә яткан чакта вафат булган. Йөрәк. Элегрәк тә саусызрак кебек иде шул. Кем белә, бәлки шуңадыр. Бала да бер генә булды. Кыз. Әх Гөлнур, Гөлнур! Чыпчык катып үләрлек салкын кышларда, эчең арканга ябышкан килеш, атны да, арбаны да алыштырырга туры килдеме, Гөлнур?! Ә кызыбыз? Кызыбыз нилләр турында уйлыйдыр? Хәер, үз тормышы үзендә инде аның. Унҗидене тутырмыйча иргә чыккан, шайтан алгыры. Баласы бар икән. Никтер хат язмый. Кирәгем юктыр. Йорт-җирне күршеләргә тапшырып, дусларына иярәп, Ташкент ягына китеп барган ул. Ташкент җылы як, җимешле як, ефәк оясы, имеш.
Абзый шулай уйланды. Уйланды да үзе үткән сугыш юлларын хәтерләде. Юллар, юллар... Коточкыч сугышка алып барган юллар...

### 3

Ярмөхәммәтов туңып уянды. Иртүк уянды.
— Салкын!— диде һәм тиз генә урыныннан торып, каядыр чыгып та китте.
Баракта чыннан да салкын иде. Ни булган? Ник салкын? Хәзергә әле берәү дә белми иде.

— Әкрам, тор!— диде абзый, үзенең караватыннан торып.— Эшкә җыенырга вакыт, шайтан алгыры.

Әкрам, юка гына юрган һәм пинжәк белән төренеп, әллә кайчаннан бирле инде уянып ята иде. Салкын. Тешләре тешкә бәрелә иде аның. Ул тиз генә урыныннан торды, ашык-пошык кына юынды, бик тиз киенде һәм чәй әзерли башлады: «Абыйны көттереп булмас — ул олы кеше».

Бераздан башка эшчеләр дә тордылар:

— Салкын!

— Ник салкын?

— Тезләрне иякка чаклы бөгәрләп ятарга туры килде. Әйтерсең бизгәк тота!

— Ник начар якканнар!

— Безобразие, жалоба язарга кирәк!

— Ә бригадир нәрсә караган?

Абзый да туңган иде, ләкин ул кинәт мич ягучы Фатыйманы яклый башлады:

— Мин үзем күрдем, мич яхшы ягылды, егетләр!

— Ә нигә салкын?

— Мич ягучыны эштән куарга кирәк!

— Салкын теңкәгә тисә эшләп буламы?

Абзый җәнҗалны туктатырга тырышты:

— Салкын окопта кунулар онытылдымыни?

Ихтимал тулай торакта яшәүче ирләр тавышын ишеткәндер, бүлмәгә Фатыйма килеп керде. Эшчеләр аны дәррәү теш кайрап каршыладылар:

— Ник салкын?

— Нигә сез мичне начар яктыгыз?

Фатыйма борчылган һәм борчыла иде.

— Нәрсә? Әллә мин сезне күлмәгем астына яшерергә тиеш идемме, оятсыз ирләр!— дип кычкырды ул, барак тәрәзәсенең ватык өлгесенә кулы белән күрсәтеп.— Әнә, ниндидер исерек яки хулигандыр тәрәзә пыяласын ватып киткән ич. Беренче этаж бит, исерекләр үткәндә тәрәзә төбенә килеп егылалар, кабахәтләр.

Эшчеләр бер-берсенә карашып куйдылар: «Ярмөхәммәтов түгелме икән?»

Фатыйма тынычлана төшкәндәй булды:

— Хәзергә тәрәзәне юрганнар белән каплыйм, аннары пыяла куючы тапмыйча булмас. Йөрисез шунда ир исеме күтәреп! Ә хулиганнар көләләр генә сездән.

Абзый шаркылдап көлеп җибәрде һәм үзенең иске чиркәүдә яшәгән чаклары турында сөйләп бирде:

— Хәзер инде ничего, Фатыйма. Менә элегрәк бар иде кызык заманнар... 1929 ел. Кыш. Мин яшь егет. Авыл егете. Теләк: капчык-капчык акча эшләргә. Без, авылдаш егетләр белән бергә, шушы Уралга килеп урнаштык. Урнаштык та дүртәр катлы яңа йортлар корабыз. Тору — чиркәүдә. Иске чиркәүдә. Тәреләре алынган, колоколлары да юк. Рәхәт! Иманга зарар килер дип, уйлаучы да юк. Эштән кайтып тамак туйдыргач, гармунга ябышабыз; җырлыйбыз, авыл урамында йөргәндәй итеп, чиркәү буйлап йөреп җырлыйбыз. Чиркәү — зур, әй яңгырый: гармун белән җыр тавышы әллә кайларга ишетелә. Бер мәлне скандал: иске чиркәү тәрәзәләре аша безнең башка кинәт таш ява башлый. Чыгабыз, чиркәүдән атылып чыгабыз! Ә чиркәү тирәсендә инде ник бер генә җан иясе күренсен?! Сызганнар, кай арададыр сызганнар, каһәр сукканнар. Менә бу хулиганство! Исерек кеше ялгыш тәрәзәгә орынса чепуха ич ул...

— Шулаен шулай да,— диде Фатыйма,— ә кешеләргә ничаклы күнелсезлек! Уйлап-уйлап торам да безнең Ярмөхәмматов эше түгел микән, гөнаһ шомлыгы?!

Абзый да уйга калды: «Булыр, булыр, шайтан алгыры. Но ничего, сабыр иткән морадына җиткән, дигәннәр».



## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Ярмөхәмматов Гайни егерме сигез-утыз тирәсендәге кеше. Әйе, бик үк яшь түгел инде. Ләкин ул буйдак. Ихтимал, шуның өчендер, Ярмөхәмматов үзен егетләр рәтендә йөртә. Бер вакытта да өйләнгәне булмагач, нигә егет булмасын? Гайни һәм Мәрьям кай вакытларда эшкә барышлый урамда очрашалар.

— Исәнме, Мәрьям?

— Исәнме, Гайни?

— Эшкәме?

— Эшкә!

— Бик җиңел киенгәнсең, салкын булмасмы?

— Булмас.

Мәрьямнең башында юка гына ак берет. Аның әнисенекедәй чемкара чәчләре маңгаена коелып төшкән. Өстендә төлке якалы кызгылт пальто. Аягында калын табанлы туфли.

— Мәрьям! Әллә син театрга җыендыңмы?

— Юк, эшкә.

Сүзләр ничектер ябышмый иде. Вакыт иртәнге сигез. Мәрьям тирәякка карады. Көн әле әллә ни салкын түгел. Шәһәр кырыендагы урыны белән такта, урыны белән таш җәелгән юл аяк басканда шыгырдамый. Шулай да күк, җир белән бергә кушылып, тәмам өшегән төсле. Урамда кая гына карама, халык — халык эшкә ашыга. Күбрәге: хатын-кыз. Аргы урам ягында бер-бер артлы ике тапкыр завод гудогы ишетелде. Бу тирәдә, әйтерсең авыл, агач өй морҗаларыннан көлтәкөлтә ак төтен балкый. Әнә чиркәү морҗасыннан да төтен күренә.

— Мәрьям!— диде Ярмөхәмматов.— Әйдә бүген циркка барыйк!

Кыз риза булмады.

— Циркны яратмыйм мин.

— Алайса киного барыйк!

— Кичер, Гайни, вакытым юк.

— Ник?

— Техникумны тәмамлау гына җитешми, абый кеше. Кыш әзерләнеп, көзгә институтка керәсе бар.

Ярмөхәмматовның төсе бозылды:

— Син минем белән йөрергә теләмисең. Киного да бер генә тапкыр, ялынгач кына бардың. Нәрсә, син миннән җирәнәсеңме? Карт егет, тюремщик, дисеңме? Нишлим? Яратам мин сине, Мәрьям! Яратам, яратам! Әйдә бүген ресторанда утырыйк!

— Юк, юк! Минем анда нәрсәм югалган?

Алар Декабристлар урамы чатына килеп җиттеләр һәм шунда абзый белән Әкрам очрады. Болар шушы урамда эшли башлаганга икенче атна иде.

— Хәерле иртә!

— Хәерле иртә!

Әкрам, участокка кешеләр җыелган арада, эш мәйданына карап торды.

— Әйе, монда ничаклы җир актарылган... Ничаклы канаулардан, ничаклы ватык торбалар чыгарылып, алар урынына ничаклы яңа торбалар китерелгән! Ә хәзер инде ничаклы иске тротуарлар буена, ничаклы яңа эш участоклары әзерләнгән?

«Яңа башлыйбыз!»— диде Әкрам эченнән генә һәм кызыл балчыктан әрчелгән яңа канау буена килеп туктады. Аңа шунда ук көтмәгәндә прораб очрады. Прораб олы яшьтәге кеше. Чандыр. Урта буй. Гадәттәгечә, әйбәт киенгән: соры каракүл бүрек, постау пальто, ә аягында, аучыларныкы кебек, зур балтырлы резин итек.

Прораб никтер бригадирны чакырды, халыкны җыйды.

«Иптәшләр!— диде прораб кычкырып.— Безгә тапшырылган участокларны йомгаклау ягына барабыз. Без яңа торбаларны яңа канауларга куярга тиеш хәзер. Аңлыйсыздыр, иптәшләр, эш көче җитәрлек бездә. Моңа өстәмә бүген студентлар киләчәк. Әнә безнең комсомолка техник Казембәтова үткән көн райкомда булды, аннары студентлар белән очрашты. Молодцы, егетләр, тырышып эшлисез. Менә,— прораб Әкрамга карады.— Менә бу егет аеруча тырыш. Әйдәгез, эш темпын тагын үстерик! Аңлашыламы, дуслар?

— Ник аңлашылмасын?— диде бригадир.— Эш бездән тормас. Тик сварканы гына ашыктырыгыз!

— Эшлибез, акча гына күбрәк булсын!—диде кайсыдыр.

Эш башланды. Әйтерсең кешеләр хезмәт явында! Кая гына карама — һәркайсы хәрәкәттә. Үнда — сварка утлары чәчри, сулда — яңа канау өлгерә. Табигый хәл: тирә-юнь шаулый, тирә-юньдә электр бораулары дерелди.

Әкрам шатлана: «Карале!»— ди ул эченнән генә.— Бая прораб мине дә телгә алды ич». Әкрам елмая, ул тагын да тырышыбрак эшли. Әкрам авыр эш үти. Әкрам монда бер төркем эшчеләр белән бергә торбалар ташый. Абзый аны кызганса да, кызганганын сиздерми.

— Давай, Әкрам, давай!— ди ул, Әкрамга карап.— Безнең нәселдә ялкау кеше юк.

Әкрам дәшми. Эш дәвам итә. Менә канау буена студентлар да килеп җитте. Нәкъ прораб әйткәнчә, Мәрьям каршылады аларны:

— Ура, иптәшләр, ура! Сүзегездә тора беләсез икән. Эш гади: барыгызның да кулына бирер көрәк! Калганнарыбыз яңа торбалар ташыйбыз, бозык юлларны, тротуарны тигезлибез!

Студентларның күбесе кызлар икән. Һәммәсе дә төзүчеләр техникумыннан. Кызык, алар килүгә эш мәйданында шау-шу, уен-көлке башланды. Аннары — эш, күмәк эш, күңелле эш!

Абзый бу тавышларны рәхәтләнеп тыңлый башлады: «Менәтерәк! Нинди генә егетләр, нинди генә кызлар бар икән монда. Әнә кайберләренең төс-битләреннән, киемнәреннән, телләреннән аңлыйсың: татарлар да, башкортлар да, чувашлар да бар икән монда. Күбрәге руслар, әлбәттә. Болар һәммәсе дә булачак төзүчеләр. Ярый, әйбәт ич, әйбәт! Тик менә мондый бәхетле яшьлек безнең буынга гына туры килмәделәр.

Канау тирәсендә эш кызганнан-кыза бара. Әйтерсең кешеләр арасында үзеннән-үзе нindидер ярыш туды. Мәрьям дә кулына көрәк алды һәм эшли башлады.

Ниһаять, халык төшке ялга туктады. «Юрганыңа карап аяк сузасың»: эшчеләрнең кайсы өенә китте, кайсы трест ашханәсенә, Әкрам белән абзый кебекләре, үзләре алып килгән ашамлык төенчеген чиштеләр. Ә студентлар үз ашханәләренә йөгерделәр.

— Эхх!—диде абзый үз-үзенә.—Эх рәхәт тә хатыны, гаиләсе бар кешеләргә!

Тәнәфестән соң эш участогына трест башлыгы килде. Ул Мәрьямне таный икән:

— Исәнме, иптәш Казембетова, эшләр барамы, прораб кайда?

— Хәзер килер, ә бригадир монда, әнә!— диде Мәрьям, Зиннәтша абзыйга кулы белән күрсәтеп.

Башлык бригадирга карады:

— Беләм, ишеттем сезнең хакта, мондагы эшне ничә көннән тәмамларга уйлыйсыз?

Абзый бер елмайды, бер җитди төс алды:

— Тиздән,— диде.— Тиздән! Но эшне тәмамларга өч секция бар әле.

Башлыкның чырае үзгәрмәде: белмәссең — әллә борчыла, әллә куана. Шулай да:

— Молодец, бригадир!— диде ул бераздан.— Ләкин эшнең сыйфаты турында онытмагыз!

Мондый чакта тик торамыни? Сүзгә Гайни кушылды:

— Сез сыйфат таләп итәсез, хуҗа, ә безнең хәл турында сорамыйсыз. Баракта эш киемен киптерү өчен махсус шүрлекләр эшләнмәгән. Чи киемне киптермичә ничек эшләргә? Ул гынамыни? Әнә безгә дигән азыкларны официанткалар урлый.

— Шулаймыни? — диде башлык. — Ярый, тиешле чараларны күрербез. Тагын берәр жалоба юкмы?

— Юк!

Мәрьям Гайнигә карады: « Эчкән, ләгънәт, борыны кызарган».

Прораб килде. Башлык, аны ияртеп, участокларны карый башлады.

Әкрам эш арасында әллә нинди уйларга батты: «Әнә башлык... Мөгаен, күп укыган, күпне сынаган кешедер ул. Ә миңа туйганчы укырга туры килмәде. Сугыш. Әти турында кайгылы хәбәр.. Әнә Зиннәтша абый... Ул әйтми генә: ул да кайгылы кеше. Өйләнми дә ичмаса. Хәер, нигә өйләнсен? Әнә Мәрьям... Нигә ул иргә чыкмый? Сөюярату бармы? Ничек була ул, ничек? Ә бәхет — бар... Ләкин Зиннәтша абый: «Аяк астында ятмый, — ди аны. — Эзләргә, табарга кирәк», — ди. Ә ничек табарга? Укыпмы? Күп итеп акча эшләпме? Кайда ул бәхет, кайда? Нигә кешеләрнең кайберләре һичбер кайгысыз яшиләр, ә кайберләре... Әллә чыннан да дөнья тигез түгелме? Бер кулдагы биш бармак та тигез түгел, диләр ич...»

Әкрамның уйларын бригадир бүлде:

— Энем! Янәшә секциягә күч, анда озын торбаны урнаштырырга кирәк. Ә-әнә Гайни янына!

Әкрам канауның аргы башына йөгерде.

Гайни, Әкрам килеп җиткәндә, тәмәке тартып утыра иде.

— Дускай! — диде ул, Әкрамны күргәч. — Син миңа үпкәләмә! Анనары Мәрьямне үз ягыңа аударма, яме? Аңла! Мин болай да бәхетсез кеше. Кыен миңа, гомер буена кыен! Үземне сүгәм, юкка гына мин бу якларда калдым. Син миннән ераклашма! Ни дисәң дә без якташлар ич. Ә главный, без хатыннар түгел. Син мине кичер! Тәнәфестә аз гына салдым. Исе киләме?

— Белмим,— диде Әкрам, шактый озын бер торбаны үзе генә этмәкче булып.— Әйдә күчерик, сварщиклар көтәдер.

Ярмөхәммәтов эшкә керешә, ләкин шул ук вакытта сөйләшүен өзмәде:

— Беләсеңме син, якташ? Миндә бер тәкъдим бар: бригадирга әйт, өйләнсен ул, өйләнсен! Хатыны юк икән аның. Безнең баракны җыештыручы Фатыймага өйләнсен. Шәп хатын! Ире, то-есть Мәрьямнең әтисе, фронтта үлгән. Мин үзем өчен кайгырмыйм: хатын-кыз

буа буарлык, любой сортын табарга мөмкин. Бәлки шәп квартиралысы да эләгер әле. Шәһәр зур. Бай хатыннар да күп диләр монда. Барасыңмы?

— Юк!— диде Әкрам, кырт кисеп.

Гайнулла дәвам итте:

— Әйе, өйләнү — түгел сөйләнү,— дигәннәр картлар. Аңлыйм, квартирга өйләнү — ир егет эше түгел димәкче буласыңдыр. Себер ягында йөргән чакларда минем дә ишеткәнем бар: ир кеше үзенең гомерендә иң кимендә бер нигез корырга тиеш! Но искерде инде мондый әйтемнәр. Ихтимал, ир егет хәзер иң кимендә бер шәп квартира алырга тиеш булыр? Ә мебель — чукынмас! Ни пычагыма мебель? Яшермим: минем бәхет юк, якташ. Әнием юрист иде. Үлде. Мин аннан унбер яшемдә калдым. Әти инженер иде. Өйләнде. Яшь хатынга өйләнде. Миңа көн бетте. Мин алар белән араны өздем. Миңа нибары ундүрт иде. Мин араны мәңгегә өздем. Нигә миңа шундый золым әни? Оятсыз әни? Тфү! Мин шулай уйладым. Кем белә, бәлки ялгышканмын... Соң инде. Әтидән киткәч, мин дөнья гиздем... Но кеше үтермәдем... Юк! Кызганыч, укып булмады. Барлыгы дүрт кенә класс. Вот нәрсә, Әкрам! Сиңа укырга кирәк! Укымаган кешеләр бер җирдә дә кирәкми икән. Берәр төрле әйбәт һөнәргә өйрән син, Әкрам! Кем белә: торабара нарком булырсың бәлки? Ато землекоп. Тфү! Йөрисең шунда солдат абыең бүреген киеп. Болай да күп андыйлар безнең трестта. Дөресме, малай?

— Син, исергәч, тел бистәсе буласың икән, Гайни абый,— диде Әкрам көлеп.— Эшлик инде, әйдә тизрәк эшлик!

Гайни тынды, участокта эш дәвам итте.

## 3

Абзый белән Әкрам, эштән соң кибеткә кереп, тары ярмасы, икмәк һәм балык алдылар. Аннан соң, гадәттәгечә, тулай торакка кайттылар. Әллә ни кыен эшмени, алар кайтып кергәндә инде торакның ватык тәрәзәсенә яңа пыяла куелган иде. Фатыйма Казембәтова мичләргә ягып йөри икән. Абзый аңа, кайтып кергәч тә, треска балыгын мактый башлады:

— Менә ул кылчыксыз була, Фатыйма. Көнбатыш фронтында без аны ашаштыргалый идек: азрак сасы булса да тәмле, шайтан алгыры. Менә пешергәч, сине дә сыйларбыз. Ярыймы?

Фатыйма балыкларны кулларына алып карады:

— Эреләр икән. Туктагыз, үзем пешереп бирим. Вакыт бар. Кызганам сезне.

Фатыйма тиз генә үзенең бүлмәсенә чыгып китте. Ул да түгел, әйләнеп керде. Кулында зур таба, үткен пычак, чирек шешә май.

— Бирегез, турыйм!

Казембәтова балык чистартырга кереште.

— Тары ярмагыздан шулпа да пешереп биримме әллә, ирләр?

— Пешерегез, рәхмәт яугыры!— диде абзый.— Әйтерсең мәрхүмә хатыным янына кайттым, билләһи.

Фатыйма елмаеп куйды.

Ярмөхәммәтов һәм Уфа егете бүлмәгә кайтмаганнар иде әле, ә монда яшәүче өченче ир, җиңнәрен сызганып куеп, бәрәңге пешереп йөри иде. Ул абзыйга бәрәңге тәкъдим итте.

— Күчерәм! — диде карлыккан тавыш белән. — Тамак ягын ашханәгә күчерәм. Туйдым. Карточкаларны ашханәгә тапшырам. Шуның белән эшең бетте — вәссәлам. Барыбер баеп булмас.

Абзый бәрәңге әрчи иде. Ул үзенең фикерен әйтте:

— Дөрес дөресен, егет, әмма тормыш рәтләнер. Ашханә дә шәбрәк эшли башлар, шайтан алгыры.
Оренбург егете Ярмөхәммәтов турында сүз кузгатты:
— Әнә Гайнинең яхшы ашыйсы килә, килсә — азрак салсын! Яна бит, аракы белән яна, каһәр.
Оренбург егете саран кеше түгел, күрәсең, тагын бәрәнге бирә:
— Минә шулпагызга бәрәңге күбрәк салыгыз! Куерак булыр.
— Рәхмәт! — ди абзый. — Бүгенге аш — настоящий аш булыр. Шәп бит, шәп!
Ниһаять, ашлар өлгерде. Абзый шат иде:
— Кил, Фатыйма, кил, үзең дә утыр, рәхмәт яугыры!
Фатыйма тәлинкәләр китерде, ашны бүлде, утырды, куырылган балыкны мактый башлады:
— Яхшы! Белугадан бер дә ким түгел...
Кичке аш әйбәт үтте.
— Менә мин дә сыйландым, — диде Фатыйма, урыныннан торып. — Кыен сезгә. Әкрамга аеруча кыен. Яшь. Рәхмәт сезгә. Чәйгә миңа керегез! Бөртек чәем бар.
Фатыйманың бүлмәсе шактый зур икән. Ишектән килеп кергәч тә үңда тимер караватъ. Сулда — шифоньер, ә каршы якта — аш-су өстәле.
Мәрьям, абзый белән Әкрам килеп кергәндә, каядыр чыгып китәргә җыена иде.
— Ой, кунаклар керә икән, ә мин киного җыенган идем.
— Син бар, кызым! — диде Фатыйма. — Үзебезнең клубка гынамы?
— Әйе.
Мәрьям Әкрамга карады:
— Әкрам! Әйдә киного бергә керик! Хәзер кызык фильм башлана.
— Әйдә! — диде Әкрам. — Абый! Без тиз кайтырбыз.
Яшьләр киного чыгып киттеләр. Фатыйма чәй китереп куйды һәм шикәр ваклады.
— Әйдәгез, утырыгыз, Зиннәтша абый!
Утырдылар. Абзый ашыкмый гына чәй эчәргә тотынды.
— Зиннәтша абый! — диде Фатыйма. — Сез элек офицер булгансыз икән? Дөресме, юкмы?
Абзый теләр-теләмәс кенә җавап бирде:
— Юк. Мин офицер түгел, старшина идем. Әйе, күп йөрергә, күп эшләрне сынарга туры килде. Заманында Ташкентта да булдым мин. Шул инде — читкә киту, акча эшләү, бәхет табу кайгысы. Монда, утызынчы елларда, хрусталь тавында эшләдем мин. Ташкентта озак тормадым...
— Ташкент, эх Ташкент! — диде Фатыйма, абзыйның сүзен бүлеп. — Мин Ташкентта унике ел яшәдем. Сагынам. Тагын шул якларга барасым килә. Әйткәнем бар ич: ирем чик сакчысы иде. Өлкән лейтенант. — Фатыйма урыныннан торды, шифоньерның аскы тартмасын ачты һәм аннан ниндидер фоторәсем чыгарды. — Менә, Зиннәтша абый! Ирем шул кеше иде. Польша чигендә һәлак булды. Ә мине, Мәрьямем белән бергә, эвакуация китерде монда. Нишлим? Язмыш шулай булгандыр.
Абзый фоторәсемгә карады. Аннан яшь кенә ир, чибәр ир елмая иде. Киеме — хәрби. Якасында — өч шакмак. «Әйе, өлкән лейтенант булган», — диде абзый эченнән генә һәм фоторәсемне Фатыймага кайтарып бирде.
Фатыйма кинәт Гайни турында сөйли башлады:
— Гайнулла бәхетсез егет, — Фатыйма чыраен сытты. — Миңа үзе сөйләгәне бар. Әнисе юрист, әтисе инженер булган. Әнисе үлгән. Әтисе бозылган. Гайни әле тик былтыр гына төрмәдән чыкты. Җиңү бәй-

рәме чыгарды аны. Куркам. Мәрьямемә бәйләнә, исерек баш белән әллә нишләр, дип куркам. Дөрес, бер караганда бик үк бозык та түгел кебек ул. — Фатыйма урыныннан торды: — Ой, Зиннәтша абый! Минем мичләрне ябасым бар.

Абзый да торды:

— Әйдә, әйдә, Фатыйма, эшеңдә бул! Менә озакламый Әкрам да кайтыр. Егет һаман әтисен көтә, бәлки пленддер, ди. «Билгесез югалды»дан башка бер хәбәр дә юк...

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Көн артыннан көн туа барып, төзелеш дәвам итте. Бүген дә абзый белән Әкрам, гадәттәгечә иртүк торып, эшкә баралар. Юл ерак түгел, вакыт җитәрлек, җәяү генә баралар. Абзый уйлана: «Әйе, Фатыймага бараклар складыннан чи утын җибәрәләр, ә аның белән мичне кабызу үзе бер газап түгелме? Фатыйма салкын тидерде, ахры, йөткерә. Шулай булмый хәле юк, аргы баракка су килеп җитми, суны һәр көн коедан ташырга туры килә. Ләкин дөнья төзәлер, һичшиксез төзәлер. Менә трест зурайганнан-зурая бара. Халык молодец! Кешеләр фронттагыча эшләргә тырышалар. Чөнки куллар кычыта, халыкны эш сагындырган, ләкин сугыш тудырган яраларны төзәтү җиңел эш түгел! Шулай да инде шәһәр урамнарында яңа машиналар күренә башлады. Менә Әкрам да тырышып эшли, тирли, пешә, әмма сер бирми. Молодец егет! Янә шунысы әйбәт, аракы эчми, тәмәке тартмый. Гармуны да бар иде аның, юкка гына авылда калдырып китте. Югалмасын, бозылмасын, янәсе. Әйе, энекәш чибәр, техник Мәрьям дә матур, нәкъ Фатыйма. Ә Фатыйманың энҗе кебек вак тешләренә, чем-кара күзләренә хәзер дә карап туймассың, билләһи! Әйе, прораб та бик әйбәт кеше. Ә теге...»

Абзыйның уйларын Әкрам өзде:

— Абый! Зиннәтша абый! Карале, әнә андагы агачларны нигә кисәләр икән?

Абзый урам буендагы кечкенә бакчага карады.

— Халык төрлечә сөйли, — диде. — Кайсы анда квартирлар корыла, кайсы зур больница булачак, диләр. Ә мин бу турыда бер нәрсә белмим, шайтан алгыры. Дөрес, кормыйча ярамый, конечно. Менә син дә өй корырсың, алла теләсә Суворов әйтмешли. Но эш өй коруда гына түгел бит, Әкрам. Егет кешегә сары туфли кирәкме? Кирәк! Хром итек кирәкме? Кирәк. Бостон костюм кирәкме? Кирәк! «Читтә йөреп малсыз кайтсаң — үз туганың ят була»,— дип җырлаганнармы элек? Җырлаганнар!

Әкрам кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Әйй... Минем авыздан алып әйттең бит, абый!

Алар Декабристлар урамына килеп җиттеләр. Урам чатыннан уңга борылгач, эш участогы башлана иде.

— Но Әкрам! — диде абзый, канау кырыена ашыгып. — Бүген мондагы эшнең ахыргы сәгатьләре. Бетерәбез, бетерәбез аны, шайтан алгыры.

Бераздан эш участогына техник та килеп житте:

— Хәерле иртә, Зиннәтша абый!

— Хәерле иртә, Мәрьям!

— Начар хәбәр бар, Зиннәтша абый.

Абзый сагайды:

— Нинди?

— Менә,— диде Мәрьям, кызгылт пальтоның кесәсеннән ниндидер кәгазь кисәге алып.— Менә эшне тәмамлыйбыз дип торганда гына бит, ә?

Абзый кәгазьне укый башлады: «Иптәш бригадир Кәлимуллин! Мин Тагилга киттем. Әнием үлгән. Эштә чатаклык чыга башласа, су каналы идарәсенә яки үзебезнең баш инженерга хәбәр бирегез. Хушыгыз!»

Абзыйның күз алдына кинәт үзенең мәрхүмә әнисе һәм мәрхүмә хатыны килеп басты. Әйе, прораб әнисе кебек алар да дөнья куйдылар. Нишләмәк кирәк? Кеше дөньядан киткәч, үзе берни дә белми, диләр, ә калучыга кыен! Абзый шулай уйланды-уйланды да Мәрьямгә карап:

— Аңлыйм, Мәрьям,— диде тавышын түбәнәйтә төшеп.— Аңлыйм, Мәрьям, но үлгән кешене кире кайтарып булмый, әйдә эш көтә, тәмамлыйк бүген.

Эшчеләр тиз җыелды. Ярмөхәммәтов та вакытлы килде. Ул аек иде.

— Гайни!— диде аңа абзый, хәрби сапер чагындагыдай ачык һәм калын тавыш белән.— Син, дускай, су канавының аргы башын ач! Хәйләсен беләсең: канауның аргы башы цементка катырылган. Ә болай әллә ни калын түгел ул. Син аны электр боравы белән ваттыр! Без анда яңа канауга — яңа юл ачабыз. Аңлашыламы?

Гайнинең күңеле күтәрелеп китте:

— Ник аңлашылмасын? Әллә син минем, аракы эчүдән башка, кулымнан берни дә килми дип уйлыйсыңмы, бригадир?

Гайни, тиз генә бер төркем эшчеләрне ияртеп, яңа канауның аргы башына китте.

— Егетләр!— диде абзый Уфа һәм Оренбург егетләренә.— Менә мондагы секцияне су кабул итү өчен әзерлик. Әзерлик тә, күрше урамдагы чиста сулы баш магистральга ялгыйк. Аңлыйсыздыр: мөһим эш, җаваплы эш, иптәшләр. Я җиңәбез, я хур булабыз, шайтан алгыры! Но алданмабыз, Суворов әйтмешли, алла теләсә. Әйдәгез, башлыйк!

Эш башланды. Тирә-юньдә яңадан шау-шу, яңадан сварка авазлары кабынды: «Чажж... Чожж... Чажж... Чожж...»

Мәрьям шат иде. Ул әле абзый янына килә, әле Гайнигә тапшырылган эшнең барышы белән кызыксына: «Кем белә? — ди ул эченнән генә.— Гайни бәлки эчүен ташлар. Бәлки төзәлер. Ялгышулар булмыйммыни дөньяда? Бәлки аны вакыт төзәтер. Бәлки...»

Минут артыннан минутлар үтте... Ниһаять, ниндидер ят аваз белән абзый кычкырды:

— Җиңдек, егетләр, җиңдек!

Нәкъ шул вакыт Декабристлар урамының аргы башыннан Гайни йөгереп килде:

— Готов, бригадир, готов!

Әйтерсең ниндидер могҗиза булды: әнә, яңа куелган калын торбалар буйлап искитәрлек көчле су шаулый башлады. Ә торбаларда ник бер генә ярык күренсен.

— Менәтерәк! — диде абзый, чын күңелдән куанып. — Менә егетләр! Димәк, бу тирәдәге ничаклы халык саф сулы булды бит, ә? Шәп, бик шәп, егетләр! Менә хәзер яңа торбаларны яңадан җир белән күмәргә мөмкин, значет. Ә хәзергә... — Абзый һаман әле хәрбиләрчә сөйләшергә ярата иде. — Ә хәзер перекур!

Озакламыйча канау буенда, борынны ярып, тәмәке исе аңкый башлады. Нинди генә тәмәкеләрнең исе аңкымый иде монда!?

— Әх сасы ла, каһәр! — диде абзый, бер читкәрәк борылып. — Ярый әле ташладым. Тәки ташладым, шайтан алгыры!

Гайни тарта. Бер-бер артлы өченче папиросын кабызды.

Ял көне иде. Абзый, иртән торып тамак туйдыргач, нәрсә эшләргә дә белмичә аптырап торды: кешеләр бүлмәдән кайсы кая чыгып киткәннәр. Әкрам исә әнисенә хат язарга утырды.

«Әх, шайтан алгыры!» — диде абзый эченнән генә һәм бүлмә буйлап, әле анда, әле монда йөри башлады. Абзый ни сәбәптәндер борчыла иде. Ниһаять, ул үзенең караватына барып ятты. Ятты да, гадәттәгечә, төрле-төрле уйларга чумды.

Әйе, менә Декабристлар урамына да су килде инде. Әллә кайлардан, Урал тавы итәкләреннән гөрләп ага торган салкын һәм саф су килде. Менә барак халкы да, шул җөмләдән Фатыйма белән аның кызы Мәрьям дә саф суга мохтаҗ булмаслар инде. Фатыйма... Әйе, Фатыйма тырыш хатын... Ә Ярмөхәммәтов? Хәер, Ярмөхәммәтов та бик начар кеше түгел, ләкин дилбегәсез егет ул. Җитмәсә Мәрьям артыннан йөгерә тагын! Өйләнергә тели, янәсе. Юк, Гайни Мәрьямгә тиң түгел. Мәрьям Әкрамга пар булыр иде, ләкин Әкрам яшьрәк әле. Әкрам армиядә дә булмаган бит. Әйе, Мәрьям чибәр, чибәр һәм сөйкемле кыз. Кыскасы, яшь егетнең төшенә керерлек кыз Мәрьям! Кызык, Мәрьямнең сөйгән егете булганмы икән? Әгәр булмаса, нигә ул шушы көнгәчә иргә чыкмаган? Хәер, сугыш, сугыш еллары... Әнә кемнәрне генә ирсез, кемнәрне генә хатынсыз калдырмадылар алар? Ә шулай да сиңа инде өйләнергә кирәк булыр, Зиннәтша. Кыен ич, кыен! Әмма өйләнү тагын да кыенрак. Моны кем генә белми? Хатын-кызларның да төрлесе була, шайтан алгыры! Но ничего! Эшләр рәтләнеп бара. Менә быел икмәккә карточка бетәчәк дип көн дә сөйлиләр. Ул гынамы? Әнә башка товарларга да һәр ел бәя төшә барачак, имеш. Төшәр, төшми хәле юк: сугыш ярасы ямалганнан-ямала бара. Менә Декабристлар урамындагы чуер ташка әверелгән каты җир тәки буйсынды, тәки җиңелде! Яңа канауга тәки яңа торбалар урнаштырылды...

Абзый шулай уйлана, Әкрам исә хат яза.

«Әни! Мин сиңа үземнең кайнар сәламнәремне чал Урал якларыннан җибәрәм. Мин исән-сау, минем өчен кайгырма! Мин, Зиннәтша абый белән бергә Уралга килеп, яхшы урнаштым. Эшлим. Бүген ял көне. Барагыбыз җылы. Безнең баракка Фатыйма исемле татар хатыны яга. Зур миһербанлы хатын.

Әни! Хатыңны көтәм. Сагынам. Зөябашында нинди хәлләр бар? Туганнар, дуслар, тирә-күршеләр исән-саулармы? Әти турында берәр яңалык юкмы? Монда әсирлектән кайтучылар бар диләр... Бәлки безнең әти дә әсирлектә булгандыр? Язар сүзләрем бик күп, әни, ләкин һәммәсен дә хатка гына сыйдырып буламыни? Укытучым Глафира Петровнага һәм авылдашларга миннән зур сәлам. Сау бул, хатыңны көн дә көтәрмен, әни. Әкрам».

Әкрам хатны конвертка салды. Абзый исә нәкъ шул вакыт урыныннан торды:

— Эч поша, — диде. — Җырла әле, Әкрам! Беләм, авылда син беренче җырчы идең, акыллы энем.

Әкрам уңайсызланды:

— Оят ич, абый?

— Ничего! — диде абзый һәм ниндидер көйгә акрын гына сызгыра башлады.

Әкрам берничә секундтан соң өзелеп тыңларлык моңлы тавыш белән рәхәтләнеп җырлап җибәрде:

Безнең Идел буйларында
Исә шифалы җилләр.
Нинди матур, нинди ямьле,

Нинди гүзәл ул җирләр,
Нинди гүзәл ур җирләр!?
Чит җирләргә, ят җирләргә,
Язмасын күнегергә.
Әллә ниләр бирер идем,
Илемне бер күрергә,
Илемне бер күрергә!
Яңгыры да, җилләре дә,
Ят икән чит җирләрдә.
Йөрәк елый:
— Илгә кайт! — ди,
— Илгә кайт! — ди җилләр дә,
— Илгә кайт! — ди җилләр дә.

Әкрам тынды.

— Зиннәтша абый! — диде ул баягыдай моңсу тавыш белән. — Беләсеңме? Минем мәрхүм бабам җырлый иде бу җырны. Яшь чагында, әсирлектә өйрәнгән. Германиядә. Ошыймы, юкмы?

Абзый янә арлы-бирле йөри башлады:

— Ошый, Әкрам, бик ошый. Бу җырны бабаңнан минем дә ишеткәнем бар. Йөрәк җыры!

Бүлмәгә Фатыйма килеп керде:

— Әкрам, син җырладыңмы?

— Әйе, Әкрам җырлады, — диде абзый, күңеленнән горурланып.— Менә безнең як егетләре ничек җырлыйлар!

Фатыйма үткән вакытлар турында уйлап алды:

— Эх... егет! — диде. — Гомереңдә рәтле хатынга тап бул! Бәхетле бул, Әкрам җаным.

Әкрам кинәт комач кебек кызарды. Шул секундта бүлмәгә Мәрьям керде:

— Әкрам! Син әйбәт җырлыйсың икән. Стена аша тыңлап тордык. Молодец! Ә безнең патефон бар. Әни уйната. Әйдә, тыңлыйкмы?

— Әйдәгез, тыңлыйк! — диде абзый һәм алар, дүртәүләшеп, Фатыйма бүлмәсенә чыгып киттеләр...

3

Ярмөхәммәтов кайтып кергәндә тулай торакның абзыйлар бүлмәсендә Оренбургтан килеп урнашкан егеттән башка бер кеше дә күренми иде. Нишләмәк кирәк? Гайни тагын исерек икән, ә Оренбург егете, кайдандыр кайтып, йокыга яткан.

— Бригадир кайда тончыккан? — дип кычкырды Гайни бүлмәгә килеп кергәч тә. — Ә Казан ягы малае Әкрам кайда?

Оренбург егете уянмады күрәсең, Гайнигә җавап бирмәде.

— Ашыйсы килә! — диде Гайни, тешләрен кысып. — Фатыйма түтәйдә мөгаен ашарга бардыр? Мәрьям сылу да өйдәдер бәлки? — Гайнине очкылык тота иде: — Ык... ык...

Гайни, адымнарын әлпеш-тилпеш китереп, Фатыйма бүлмәсенә омтылды. «Ык... ык... ык!» Гайни килеп кергәндә Фатыйма бүлмәсендә патефон уйный иде.

...Кайда гына барып төшә икән,
Ашыгып-ашыгып аккан агым су?
Рәхәт иде бергә торган чаклар,
Аерылышу бигрәк ямансу!

— Байлар күңел ачалар! — дип кычкырды Гайни, бригадирга күзләрен акайтып карап. — Безнең кебек вак-төяк белән чуаламыни алар? Ә син нигә монда, Казан ягы малае? Ну-ка, нигә син монда, нигә? —

Гайни Экрам каршына килеп туктады һәм көтмәгәндә аның колак төбенә йодрык белән сукты.

— Стой! — дип кычкырды абзый һәм кинәт Гайнинең кулларын арткы якка каерып куйды. — Нишлисең? Әллә син җүләрләндеңме, хайван?!

Гайни акырырга тотынды:

— Авырта! Җибәр, бригадир, авырта, дим, авырта! Җибәр!

Бригадир җибәрмәде. Гайнине ул, этә-төртә әүвәл коридорга, аннары икенче подъездга алып чыкты.

— Әйдә, үзеңнең урыныңа кереп ят, шайтан алгыры! — диде.

Гайни, юл буена сүгенеп, акырып барды:

— Җибәр, бригадир! Суям мин сине. Мин берәүдән дә курыкмыйм. Мин кеше үтермәдем. Подумаешь, бер бәндәгә пычак белән кадаган өчен дүрт ел... Әйт, бригадир, әйт! Нигә миңа зур срок бирделәр? Мин кулак малае түгел, интеллигент семьясыннан мин. Җибәр мине, җибәр, бригадир!!

Бригадир Гайнине тулай торак бүлмәсенә килеп кергәч кенә җибәрде.

— Ят, йокла! — диде, ләкин Гайни кинәт абзыйның битенә төкерде:

— Тфү, сәләмә солдат!

— Ах, шулаймыни? — дип кычкырды Экрам һәм Ярмөхәммәтовның эченә типте. — Мә, кирәгеңне ал, бандит!

Гайни егылды, әмма тиз торды, шул арада Оренбург егете аның кулларын сөлге белән бәйләде.

— Ят! — диде һәм Гайнине караваткa екты.

Гайни һаман да тынычланмады, акырды-үкерде:

— Чишегез! Кулны чишегез! Ни хакыгыз бар? Җалоба бирәм! Кыйнарга уйлыйсызмы? Попробуйте! Ник кыйнамыйсыз? Әһә, дусларымнан куркасыз! Мәрьям кайда? Фатыйма кайда? Нигә алар монда килмиләр? Мәрьям, Мәрьям! Су бирегез, сууу...

Гайнинең тавышы акрынайганнан акрыная барды. Ниһаять, Гайни тынды һәм йокыга китте.

— Аның башына капчык кидереп кыйныйсы калган, — диде Оренбург егете. — Андыйларның сабакларын укыта идек без кайчак.

Абзый көлеп җибәрде:

— Ничего, хәзергә җиткән, — диде һәм Ярмөхәммәтовның кулларын чиште. Гайни ничектер уянмады.

Баракта инде әңгер-мәңгер вакытлар иде. Бераздан ут кабынды.

— Әйдә, Экрам! — диде абзый, өстәл каршына килеп. — Әйдә, кичке чәй әзерлибез!

Алар чәй әзерләргә керештеләр...

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Бүген трест башлыгы абзыйлар бригадасын яңа участокка күчерде. Участок шәһәрдән дүрт чакрым кырыйда икән. Вакыт иртәнге җиде чамасы. Үткән көн һава бик дымлы иде. Хәзер исә салкынайтып җибәргән. Өстәвенә җил. Әллә нинди ачы җил, әле битне, әле колакны чеметеп ала.

— Менә, шайтан алгыры! — диде абзый, бүрек колакларын төшереп. — Хәер, гаҗәпләнергә бер дә урын юк, Урал бит, Урал! Һава торышы монда кайчак көненә биш тапкыр үзгәреп тора.

Абзый, Әкрам һәм башка эшчеләр «Студебеккер» исемле ачык машинага утырып яңа участокка баралар иде.

Абзыйның белмәгәне юк, гел сөйләшә, гел сөйли:

— Беләсезме, егетләр? — диде ул, машинаның озын-озын эскәмияләренә кулы белән күрсәтеп. — Немецлардан трофейга эләккән машина бу. Зур, иркен, көчле, шайтан алгыры. Аңлап барыгыз, кайчандыр ул немец солдатларын ташыган, мөртәт. Әкрам! Борыныңны ышкы. Мондый ачыкта машина җиле борынны өшетергә дә бик күп сорамый.

Әкрам җилгә аркасы белән утыра иде.

— Борчылма, Зиннәтша абый. — диде ул һәм тирә-юньгә карап барды.

Кызык, рәхәт. Кая гына карама саф кар һәм ял-ялангач кыр. Автомашина карлы һәм бозлы юлдан алга ыргыла. Әйтерсең елый, әйтерсең җан әчеттергеч тавыш чыгарып, никтер сыкрана. Юл буенда яңа казылган тирән канау. Аның кызыл балчыгы кызгылт еландай еракка сузылып киткән.

Бераздан урман башланды. Нарат урманы. Ямь-яшел урман. Җирдә куян эзләре. Нәкъ Зөябашындагыдай. Юан наратлар белән янәшә генә зур аланлыкта бөдрә чыршылар да бар икән монда. Карап туймассың, берсеннән-берсе матур!

— Зиннәтша абый! — диде Әкрам. — Карале, безнең якларга охшый икән бу җирләр!

Абзый наратларга күз салды:

— Әйбәт наратлар, — диде. — Синең кебек яшь әле алар. Но, ничего, үсәрләр. Син дә үсәрсең, тәмам ныгырсың!

Әкрам чыраен сытты:

— Нәрсә, мин әле һаман бала-чага рәтендәмени?

— Юк! — диде абзый кулы белән уңга күрсәтеп. — Күрәсеңме, әнә электростанция. Заманында без корган идек аны.

Әкрам юл буендагы биек корылмаларга карады. Анда, иң беренче булып, берсе биек, икенчесе тәбәнәгрәк ике морҗа күзгә ташлана иде. Аннары кара корымга чумган, зур-зур кирпеч биналар... Арырак күмер тавы, кайчандыр кара тузанга әверелгән кап-кара тау. Ул да түгел, тар гына чуен юлы һәм кечкенә генә тимер вагонеткалар... «Әх менә шушында эшләсәң иде!» — дип уйлады Әкрам һәм абзыйга сорау бирде:

— Зиннәтша абый! Эш урынына килеп җиттекме әле?

— Җитәбез, — диде абзый автомашинаның идәненә аягы белән «так-ток» итеп типкәләп. — Салкын, шайтан алгыры, туңма!

Ниһаять, алар эш урынына килеп җиттеләр. Унда нарат, чыршы һәм каен урманы, ә сулда бик зур күл. Әйтерсең диңгез! Бер караганда яр буеннан очы да, кырые да күренми кебек аның. Абзыйга мәгълүм икән: кайчандыр, кемдер һәм никтер Яктыкүл дип атаган бу күлне. Ләкин әлегә төсе күренми аның, чөнки кар һәм боз белән капланган ул.

— Вот так! — диде абзый, автомашинадан сикереп төшеп. — Килеп җиттек, Әкрам, әйдә.

Абзыйны һәм эшчеләрне прораб каршылады:

— Хәерле иртә, егетләр!

— Хәерле иртә, иптәш прораб!

— Әйдәгез өйгә, җылыныйк азрак! Сүзләр дә бар.

Кешеләр күл каршына корылган агач өйгә керделәр, түргә уздылар һәм андагы такта эскәмияләргә тезелеп утырдылар. Өй шактый зур һәм ул ташландык клубка охшый иде. Уртада тимер мич. Өйдә җылы. Каршы якта зур-зур ике тәрәзә.

— Иптәшләр! — диде прораб, стена буена куелган өстәл каршына килеп. — Шәһәребезнең Декабристлар урамындагы су канавы югары

сыйфат белән корылды һәм нык сыналды. Молодцы, егетләр! Трест башлыгы сезнең һәммәгезгә дә приказ белән зур рәхмәтен белдерә. Менә янә бер приказ. — Прораб кулындагы портфельне ачып кәгазь чыгарды. — Менә: «Декабристлар урамындагы су канавын төзүдә аеруча актив катнашкан өчен бригадир Зиннәтша Кәлимуллинны, рабочий Әкрам Кәлимуллинны һәм техник Мәрьям Казембәтованы алтмышар сум акча белән бүләкләргә», — диелгән.

— Дөрес! — дип кычкырды кайсыдыр аргы почмактан. — Дөрес!

Прораб дәвам итте:

— Иптәшләр! Хәзер без төзү эшләрен яңа участокта башлыйбыз. Эш бәясе — сдельщина, икенче төрле әйткәндә, эшеңә карап — ашың. Ә максат? Максат бер генә: шәһәрне, заводларны, фабрикаларны су белән тулысынча тәэмин итәргә кирәк. Озакламый торбалар ташыла башлар. Фәндә дә, практикада да исбат ителгән: су аркылы торбалар салу эшен кышкы айларда башкару ансатрак. Безгә ярдәмгә озакламыйча бульдозер килер. Без ышанабыз: килер! Ә хәзергә карны көрәк белән көрәргә туры килә. Ярый, башлыйк, егетләр! Сораулар юкмы?

— Бар! — диде бригадир. — Мин бу тирәдә сугышка чаклы эшләгәнем булса да сораганым юк. Нигә бу күлгә Яктыкүл дигән исем биргәннәр?

Прораб елмаеп куйды:

— Мин монда туган кеше. Монда үстем. Бу күлне суы саф, суы тонык булганга Яктыкүл дип атаганнар, бригадир. Башка сораулар юкмы?

— Бар! — диде Гайни һәм ул да бер сорау бирде. — Эшләнгән эш дөрес итеп хисапка алынырмы? Югыйсә казылган карны ничек үлчисең?

Прораб уйга калды.

— Эш хакыгыз югалмас, егетләр, — диде бераздан. — Һәр эшнең күләме була, расценкалар бар.

Гайни бу җавап белән канәгатьләнде, ахры:

— Ярый, — диде.

Прораб халыкны эш урынына алып чыкты.

## 2

Декабрьның икенче атнасы. Каршы якта Яктыкүл. Хәзер инде тирән кар белән капланган ул. Кайсыбер урыннарда ямь-яшел боз.

— Әнә! — диде прораб күлнең аргы ярына кулы белән күрсәтеп. — Әнә шул яргача булган урынны кардан тазарттырырга кирәк. Аннары торбалар урнашыр анда. Кардан әрчелгән канауларның киңлеге өч метрдан тар булмаска тиеш.

— Хәерле сәгатьтә! — диде бригадир һәм Әкрамга карап куйды. Әкрам инде, кулына көрәк алып, кар казый башлаган иде. Ничектер һич көтмәгәндә:

— Дөрес түгел! — дип кычкырды Гайни, прорабка карап. — Кем күпме эшләгәнен кайдан беләсең монда? Яшь малайга да, безгә дә бер нормамыни?

Әкрамның йөрәге «жу» итеп китте: «Кара син аны! Гайни һаман миңа кагыла, һаман миңа теш кайрый».

— Әйдәгез, Ярмөхәммәтов әйткәнчә булсын, иптәш прораб, казыларга тиеш урыннарны өлешләргә бүлик алайса.

— Ярый, — диде прораб. — Мин безнең арада ялкаулар булмас, дип уйлаган идем. Берәнә-берән ярдәм итәргә кирәк!

Табигый хәл, абзый да сүзгә кушылды:

— Чебешләрне күзен санныйлар, Гайни энем. Әллә синең колхозда эшләгәнең юкмы?

Гайни дәшмәде. Техник Мәрьям кар көрәлергә тиеш урыннарны өлешләргә бүләргә керешүе. Карап торырга күбәләктәй җиңел иде ул. Өстендә кыска гына ак тун, башында колаклы бүрек, аягында кара киез итек, ә бите салкын һавада комач кебек кызарган.

— Эш күләме турында башка исәпләшмик!—диде Мәрьям, Гайнигә карап.— Һәммәсен истә тотам: карның калынлыгын да, сукмакларның озынлыгын да.

Прораб бригадирны эш участоклары белән таныштыра башлады.

— Менә, иптәш бригадир, — диде. — Сугышка чаклы бу күл буенда санаторий корылырга тиеш иде. Мондый фикер, минемчә, тагын туачак. Гомумән, матур бу җирләр. Әнә, — прораб уң яктагы биек тау сыртына кулы белән күрсәтте.— Ә-әнә Малахит тавы. Беләсенме, малахит ташыннан иң матур әйберләр ясала. Ә-әнә аннан арырак Хрусталь тавы. Бөтен дөньяга дан казанган хрусталь савытларның нигезе менә шушы тауларда инде.— Прораб уңа борылды.— Тыңла, бригадир! Күлләр дә күп бу тирәләрдә. Саф елга да бар. Әнә Яктыкүл белән янәшә генә Әбиләр күле. Суы көмеш бөртеге кебек аның. Шифалы. Ярый, кар канауларын менә шушы урынгача казыгыз. Ә мин башка участокларга барам.

Прораб китте. Әкрам техник күрсәткән урыннан башлап кар казый. Кулда көрәк. Агач көрәк. Киләге чыкса тимер көрәк тә әзер. Әкрам эшли.

Әйе, кешеләрдән, бигрәк тә Гайни исерекбаштан артта калырга мөмкинмени? Юк, юк! Гарьлек ич, гарьлек! Берәүдән дә артта калмаска кирәк. Хәтта абыйдан да! Аңа да сүз тимәсен. Нигә артта калырга? Сугыш елларында мондый гына эшләргә күнегелмәгәнмени? Эшләргә, эшләргә? Э-эх... Урал тауларын актарып ташларлык көч табылса иде хәзер! Ләкин Әкрамны һаман нигә малайлар рәтендә хисаплыйлар?! Нигә, нигә? Кыен ич, ә бер уйласаң рәхәт тә... Алда — зур тормыш!

Әкрам тырышты. Җан-фәрманга тырышты. «Артта калган — тапталыр, алга чыккан — макталыр» ди иде аңа мәрхүмә әбисе. Әкрам һәр көрәк карны санап тондырырга керешүе. Күпмедер вакыттан соң аның тирә-юнендә кар коймалары пәйда булды. Ләкин көн салкын иде.

— Аһ! — диде Әкрам, кайчандыр катып үлгән чыпчыкны кар өстендә күреп.— Аһ, мескен! Ә күгәрченнәр... Алар да катып үләрләр микән? Ә норма?

Ниһаять, Әкрамның нормасы тулды һәм аның каршындагы кар коймалары якты боз юлына барып тоташты.

— Гайни!— дип кычкырды Әкрам, Ярмөхәммәтовка бирелгән өлешкә кереп.— Давай, мин сиңа ярдәм итим!

Гайни дәшмәде, ул да түгел, рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Әкрам, битең өшегән, малай, битең өшегән!

Әкрам кул учы белән битен каплады. Нишләргә? Аның бер бит алмасы чыннан да өшегән иде. Нәкъ шул секундта кар канавыннан абзыйсы күренде:

— Әкрам, битең өши башлаган. Яр буендагы урманчылар йортына йөгер! Ә нормаң тулган, хәзер инде барыбер әбәткә туктыйбыз.

Әкрам урман кырыендагы агач йортка йөгерде. Яңа гына күтәрелгән җил битне генә түгел, кулны да энә белән кадаган кебек чеметеп-чеметеп ала, салкын һава җелеккә үтә, карда төкерек ката, тешкә-теш бәрелә. Әкрам йөгерде дә йөгерде. Җилгә каршы битләрен уа-уа, кулларын болгый-болгый йөгерде ул, ләкин кинәт кенә абынып егылды. Сикереп торды да тагын йөгерде...

Экрам жылы өйгә килеп кергәндә техник Мәрьям өстәл каршында ниндидер исемлек төзеп утыра иде. Ул үзенең эше дәвам итте. Экрам исә, кулындагы бияләйләрен салып, тиз генә утлы тимер мич каршына килде һәм анда кулларын жылыта башлады.

«Эх! — диде Экрам эченнән генә. — Сул бияләйнең ике бармагы ертылган икән. Күрмәдем шул, сизмәдем. Менә хәзер бармаклар эри сымак. Рәхәт сымак...»

Экрам чыраен сытты. Ул да түгел, аның күз төпләренә яшь бөртекләре бәреп чыкты.

— Авырта!— диде Экрам акрын гына.— Кулым сызлый. Уф...

Мәрьям, өстәл артыннан тиз генә торып, Экрам каршына килде:

— Ни булды?

— Кулым!— диде Экрам, өшегән кулын мич авызына якынлаштырып. — Жылынмасмы дим? Өшеде, ахры. Авырта! Баштарак рәхәт иде, чымырдап торды.

— Ах!— диде Мәрьям, Экрамның өшегән кулын үз кулына алып.— Өшегән! Ник кар белән умадың?! Әйдә безнең медпунктка. Әйдә тизрәк.

Мәрьям, Экрамның өшегән кулын үзенең баш яулыгы белән бәйләде, киенде һәм алар медицина пунктына чыгып киттеләр.

### 3

Урман юлы шактый тирән кар белән капланган икән. Каршы яктан чана һәм автомашина эзе сызылып ята. Мәрьям, Экрамны ияртеп, менә шушы эзгә омтылды. «Эхх, Экрам, Экрам! — дип уйланды ул. — Инде нишләрсең, энем? Кулың озак сызлармы, яки тиз төзәлерме? Әгәр бу хәлне әниең ишетсә, ничек чыдар, ничек кенә чыдар икән, бичара?!»

Экрам да көенә һәм ул инде Мәрьямгә әйтмичә генә, үз-үзенә сызлана иде.

Әйе, салкын шул, салкын! Әйтерсең бөтен жир йөзе мәңгегә бозланып каткан. Әнә, урмандагы ялгыз йортның моржасыннан чыккан төтен дә салкын һава белән кысылып, күк йөзенә туры багана булып күтәрелә. Шулай да кайдадыр — якында гына балта тавышы ишетелә. Димәк, кемдер шундый салкында да урманда эшли. Ләкин барыбер кыен, бик кыен! Ә врач...

— Егет!— диде Мәрьям, Экрамның уйларын өзеп.— Әнә медпунктка килеп тә життек. Монда зур тәжрибәле фельдшер эшли. Йомыш белән килгәнем дә бар.

Медицина пункты урман юлы буендагы шактый зур һәм якты өйгә урнашкан икән. Фельдшер исә пеләш башлы, ак халатлы, кыска сакаллы, зур күзлекле кеше.

— Нәрсәгә зарланасыз?— дип сорады ул, Мәрьям белән Экрам кабинетка килеп кергәч тә.— Әллә туегызда сугыштыгызмы?

Сүзне Мәрьям башлады:

— Доктор! Менә безнең эшченең кулы өшеде.

Фельдшер житди төс алды:

— Каяле, егет, кулыгызны чишегез!

— Эх-ма!— диде фельдшер, Экрамның кул бармакларын капшап.— Өшегән шул, өшегән! Ә ничек, кайда?

Экрамның күзләренә тагын яшь бөртекләре килде:

— Эштә, авырта, доктор, сызлый!

— Түз! Туенача төзәлер,— диде фельдшер һәм шунда ук утырган медицина сестрасына Экрамның кул бармакларын дарулый башларга кушты.

— Та-ак,— диде фельдшер һәм сестра эшләгән арада Әкрам белән гәпләшергә тотынды:

— Син кайсы яктан буласың, егет!

— Казаннан.

— Үзеннәнме?

— Юк, Зөябашыннан.

— Ә мин Тәтештән. Нигә син кояшлы Идел буйларын ташлап салкын Уралга килдең? Мин монда биш елдан артык торам, ә Иделем буйларын һаман сагынам. Нигә килдең син монда, җүләр, нигә килдең, ник?!

Әкрам аптырап калды. Аннары, көттереп җавап бирде:

— Әниемә йорт кормакчы идем, доктор абый.

Фельдшерның чырае яктырмады:

— Әтиең?

— Әтием сугышта югалды,— диде Әкрам, балалардай үксенеп.— Үлде.

Фельдшер йомшарды:

— Да-а... Сугышта мин дә яраландым... Ә син иртәгә шәһәр поликлиникасына күрен, егет! Хәзергә эшкә йөрмә: бюллетень бирерләр сиңа. Авыруы ансат, терелү кыен...

Вакыт йөгерә, Әкрам белән Мәрьям медпункттан соң, күл каршындагы ялгыз өйгә кайтып кергәндә төзелеш эшчеләре инде шәһәргә китәргә әзерләнәләр иде.

— Утыр!— диде абзый, Әкрамга автомашинада урын күрсәтеп.— Хәлең турында юлда сөйләшербез.

Автомашина акрын гына кузгалып китте.

## АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

### 1

Әкрам иртәгәсен эшкә чыкмады. Вакыт иртәнге тугыз чамасы иде.

— Әкрам! — диде Фатыйма, бүлмәгә кереп. — Кулыңны өшеткәнсең икән лабаса, әзләп интегеп йөрмә тагын, әйдә, шәһәр поликлиникасына үзем илтеп барыйм, акыллым!

Әкрам инде юлга җыенган иде.

— Ярый,— диде һәм алар шәһәр поликлиникасына чыгып киттеләр.

Фатыйма Әкрам өчен борчыла иде. Ул, урамга чыккач та, һава торышы турында сөйли башлады:

— Кичә кырык биш градус булган. Мәктәпләрдә укулар тукталган. Ачык һавада эшләүчеләрне эштән азат иткәннәр, ә сезгә бу турыда белдерүче булмаган, ахры. Кем белә, бәлки башка өшүчеләр дә бардыр. Усал дисәләр диярләр, бу мәсьәләне җыелышта күтәрим әле. Хәер, бүген һава йомшарган. Ә син бияләеңне онытмадыңмы? Нишлисең бит, ертылган булган икән, кичә аны Мәрьям ямады. Сыйдымы?

— Сыйды, Фатыйма апа,— диде Әкрам.— Менә кидем, рәхмәт.

Көн җылынды дип уйлаган күрәсең: Фатыйма җиңел киенгән иде. Өнә өстендә кыска гына иске пальто, башында — күгелҗем шәлъяулык, ә аягында — солдат итеге.

— Салкын түгел,— диде ул, адымнарын ешайта төшеп.— Мин күнеккән инде, Уралда җиденче ел. Шулай да Ташкентны сагынам.

Алар, тулай торактан чыгып, Малыш урамы чатыннан үткәч, дүрт катлы зәңгәр йорт каршына килеп чыктылар.

— Экрам!— диде Фатыйма, шул йортка күрсәтеп.— Сугыш елларында монда вакытлыча үзбәкләр яшәделәр. Ватан чакырды, хәрби заводларда эшлиләр иде алар. Әйбәт халык, юмарт, ачык күңелле, кунакчыл халык. Һәммәсе дә олырак яшьтә. Берсе сугышка чаклы минем иремнең танышы иде. Ул, мине былтыр шушы урында очратып, адресымны алган иде, ә менә быел өч кило йөзем җибәргән, рәхмәт яугыры.— Фатыйма кулына кечкенә генә төенчек тоткан иде.— Хәзер сине поликлиникага кадәр озатам да, йөземне базарда сатам. Пальто кирәк. Мин, Экрам, киләсе елга яңадан Ташкентка күчәргә уйлыйм. Җылы як, матур як. Тамбовта минем барыбер беркемем дә юк хәзер. Әнә кызым да үзем.

Алар урам чатыннан уңга борылдылар һәм шәһәр буасы каршына килеп җиттеләр. Экрамның әле бу тирәләрдә бер дә булганы юк иде. Буа өсте кулларына кармак тоткан балыкчы малайлар белән тулган. Каршы якта — зур күпер. Бөтен тирә-юнь күренә моннан: уңда һәм сулда урамнар буйлап таш өйләр тезелеп киткән. Әллә ничәшәр катлы, төрле бизәкле һәм матур өйләр бар икән монда!

— Фатыйма апа! — диде Экрам, балконлы биек өйләргә карап. — Мондый зур йортлар кайчан корылган икән?

Фатыйма, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә тырышкан сымак, уйланып җавап бирде:

— Әллә кайчандыр, күптәндер, Экрам. Шәһәр әле ул чакларда Екатеринослав дип аталган икән. Син белмисең әлбәттә, заманында Колчакның, контрларның, шул чагында хәтта патшаның язмышы да шушы калада хәл ителгән диләр картлар. Абзый беләдер, сугышка чаклы татарлар күп булган монда. Дөрес, хәзер дә бик күп алар. Ә элегрәк үзләренең театрлары, мәктәпләре, техникумнары да булган аларның. Әнә күрәмсең. — Фатыйма сул яктагы калын таш коймага кулы белән күрсәтте.— Әнә үткән заманда «Акча сарае» булган дип сөйлиләр ул койма артында. Кем белә, бәлки алтын акча да шунда ясалгандыр. Әйе, кемгәдер алтын, кемгәдер салкын булган элек Урал...

Фатыйма шәһәр буасы белән янәшә генә өч катлы ак өй каршына килеп туктады.

— Менә поликлиника, — диде ул, ярты кварталга сузылган йортка күрсәтеп.— Мин базарга киттем. Ә син борчылма, яшь тәннең ямавы үзендә була диләр...

Чиратта бер генә кеше икән. Ихтимал, сугыш инвалидыдыр. Аның бер аягы юк. Экрам сызланды. Сызланды һәм уйланды: «Өшегән кул тынычлана төшкәндәй булган иде, ә хәзер яңадан сызлый. Йөрәккә үтеп, эчне пошырып сызлый! Ә доктор ни дияр икән? Кул төзәлерме, юкмы? Кайчан, ничек төзәлер? Абый эштәдер инде. Ә Мәрьям? Әйбәт кыз Мәрьям! Миһырбанлы кыз!»

Менә врач кабинетыннан баягы инвалид чыкты һәм аның урынына Экрам керде:

— Доктор абый! Мин кулны өшеттем. Эштә. Мине фельдшер җибәрде.— Экрам фельдшер язган кәгазьне врачка бирде.— Кыен! Рәтләп эшләгәнем дә юк иде әле, иптәш доктор.

— Кулын чишегез!— диде врач бер Экрамга, бер сестрага карап.— Карыйк, күрик!

Врач урта яшьләрдәге ир кеше. Чандыр. Күзләре зәңгәр. Нигәдер усал караучан кебек алар. Врач кайчандыр хәрби доктор булган күрәсең, аның чалбары әле дә хәрби, нечкә генә кызыл тасмалы. Нәкъ Зөябашына үткән ел ялга кайткан офицерныкы сыман...

— Ой, апа, ойй!— дип кычкырды Экрам, сестра аның кулын чишә башлагач.— Авырта, апа, бармакларым авырта!

Сестра олы яшьтәге хатын. Чәчләре ап-ак. Экрам аны үзенең элекке укытучысы Глафира Петровнага охшатты.

— Түз, егет!— диде сестра, Экрамның кулына бәйләнгән калын марляны чишеп.— Бармакларында кан әсәре бар. Димәк, кулың киселмәс!

Экрамның күз керфекләрендә кинәт кайнар яшь мөлдерәде: «Әллә бармакларны кисүләре мөмкинме?»

— Даа!— диде хирург, Экрамның кул бармакларын бөгеп-бөгеп карагач.— Яле, өшегән бармакларыңны үзең кыймылдат, үзең бөк, егет!

Экрам, чыраен сытып, үзенең бармакларын бөгә башлады, ләкин шунда ук:

— Авырта!— дип кычкырды.— Бөгелми, сөяге сына, доктор!

Врач, Экрамга карап, башын чайкады һәм аның янында тиз генә китеп, үзенең урынына барып утырды.

— Та-ак,— диде ул бераздан, нииндидер уйга чумып.— Та-ак... Шулай да дәвалап карыйк әле... Сенер, сенер...

Сестра зур саклык белән акрын гына Экрамның кулын юды һәм аңа нииндидер майлы дарулар сөртеп, ак марля белән бәйләп куйды.

— Егет!— диде сестра, Экрамның күзләренә туп-туры карап.— Син көн аралаш миңа килеп йөр. Килмичә калма, егет. Чиратта халык булса, чиратсыз кер. Эшкә чыкма! Бюллетень язарбыз. Аңлашыламы, улым?

Экрам үзенең әнисен күргәндәй булды.

— Аңладым, апа! Рәхмәт сезгә, бик-бик зур рәхмәт!!



## 2

Экрам поликлиникадан кайтып кергәндә Фатыйма тулай торакның идәнен юа иде.

— Кайттыңмы, Экрам?

— Кайттым, Фатыйма апа.

— Хәлләрең ничек?

— Врачлар «төзәлер», диләр.

Фатыйма елмаеп куйды. Маңгаеннан тир тама иде аның.

— Шөкер,— диде һәм халатының кесәсеннән алып папирос тарта башлады.

Экрам гаҗәпкә калды: «Шундый ягымлы, шундый акыллы һәм тырыш хатын нишләп тәмәке тарта?»

Фатыйма кинәт ничектер уңайсызланды:

— Гафу ит, энем!— диде һәм папиросын берничә тапкыр гына суырып, мич авызына ыргытты.— Сугыш еллары, кайгы-хәсрәт өйрәтте,— диде.— Ташлыйм, һичшиксез ташлыйм, Экрам.

Экрам дәшмәде, өс-башын чишенеп, тамак туйдырырга әзерләнә башлады, бактан кайнар су алды, өстәлгә арыш икмәге белән тоз китереп куйды:

— Фатыйма апа!— диде.— Минем ипи җитәрлек, әйдәгез, сез дә ашагыз!

Фатыйма үзенең бүлмәсенә ашыкты. Ул да булмады, апакай йөгереп килеп тә чыкты:

— Экрам! Менә сиңа Ташкенттан килгән күчтәнәч.— Фатыйма Экрам алдына ике уч йөзем китереп куйды.— Менә хәзер үк сыйлан! Иремнең иске дусы Фәйзулла җибәргән аны, рәхмәт яугыры. Эх... дуслар, иске дуслар... Үкенәм, Фәйзулланы монда кунак итә алмадым.

Экрамның йөзе кинәт яктырды.

— Рәхмәт, Фатыйма апа, рәхмәт!

Сүз дә юк, йөзем бик тәмле икән. Ә арыш икмәге белән бергә тагын да тансыграк. Экрамның уйлары дәррәү әллә кайларга таралып

китте: «Эх-х... Ташкентка барсаң иде. Эх... Ташкент ягында эшләсәң иде...»

— Завхозның рәте юк,— диде Фатыйма, идән юарга дип бирелгән чүпрәкләрне зур чиләккә тутырып.— Идәнне рәхәтләнеп юарлык чүпрәк тә алып бирми, гөнаһ шомлыгы! Бар бездә андый әрәм тамаклар, бар әле, бар, Әкрам.

Фатыйманың әле эше күп иде. Ул, чүпрәкле чиләкне кулына алып, башка бүлмәгә чыгып китте. Әкрам исә, тамагы туйгач, үзенең караватына барып ятты.

Халык эштә, бүлмәдә тын, бик-бик тын иде. Мондый чакта күңелдә нинди генә уйлар чуалмый?! Әнә Әкрамның күз алдында туган авылы Зөябашы һәм әнисе.

1943 ел. Кыш. Өй тәрәзәләре бозланып каткан. Яшүсмер малай Әкрам, әтисеннән калган иске толып белән бөркәнеп, мич башында утыра һәм мичнең кирпече араларыннан тырнагы белән казып, былтыргы арыш бөртеген җыя. Җыя да ашый. Ашый да тагын җыя. Тагын... Тагын.. Әкрам эченнән генә үз-үзе белән сөйләшә: «Нигә ашыйсың? Ачлыктан, комсызлыктанмы?!» Әкрам үзе үк җавап бирә: «Юк, комсызлыктан түгел, Әкрам, ачлыктан бу, ачлыктан! Кайчан гына өйлә вакыты җитәр? Кайчан гына көндәлек өлешем булган өч бәрәңге пешеп өлгерер?» Ниһаять, Әкрамның эче авырта башлый, косасы килә, саруы кайный. Озак та үтми: «Әни-и! Эчем авырта-а! — дип кычкыра Әкрам. — Үләм бит, әни, үләм!»

Әкрамның әнисе тиз генә мич башына менә: «Ни булды, балам, ни генә булды?» Әкрам сызлана: «Мичтәге кирпечләр арасыннан былтыргы арыш бөртекләрен җыеп ашаган идем». Әкрамның әнисе елый: «Кос, улым, кос!» Әкрам үз тамагына үзе бармагын тыгып коса. Көчләнеп, көчләнеп коса. Аннары рәхәтләнеп киткәндәй була...

...Әкрам бригадир тавышына уянып китте:

— Энем, кулың ничек? Сызлыймы һаман?

Көн кичке якка авышкан иде.

— Түзәрлек, абый!— диде Әкрам, караваттан торып.— Врач дәвалый башлады. Иң зур шатлык, кулны кисмиләр!

Абзый Әкрам белән озак итеп, рәхәтләнеп сөйләшергә уйлаган иде, ләкин аның моңа вакыты юк икән:

— Әкрам!— диде ул, яңадан ишеккә борылып.— Әйдәле ишегалдына, күр әле мин нинди малны кулга төшердем!

Әкрам Зиннәтша абзыйга ияреп барак ишегалдына чыкты. Чыкса, ни күзе белән күрсен, анда кайчандыр суелган зур һәм симез бер җылкы ята иде.

— Менә! — диде абзый, суелган атка кулы белән күрсәтеп. — Менә «Яктыкүл» колхозында ничектер аягын сындырган, шайтан алгыры. Һәммәсе дә законча; врач караган, суйганнар, аннары миңа саттылар. Хәтта үзләре йөк машинасында китереп тә куйдылар. Арзан. Менә Фатыйма килеп җитсен дә, тутырабыз. Ә итне сакларга урын әзер — утын склады, шайтан алгыры. Ну, ни дисең, Әкрам?

— Әйбәт! — диде Әкрам. — Ләкин миңа китәргә туры килмәсме икән, абый?

Абзый гаҗәпкә калды:

— Кайда?!

— Авылга, өйгә.

— Ник?

— Эшсез нишләп ятыйм мин? Әрәм тамак булыйммы?

— Булмассың, — диде абзый, һич көтмәгәндә ачуланып. — Нигә син борыныңны бик тиз төшердең? Әллә дөньяга яңа гына туган сары авызлы чебеш баласымы син? Тфү! Әтиеңә охшарга тырыш! Ул бик күп авырлыкларны татырга өйрәнгән кеше иде. Әмма дошманга тез-

ләнмәде! Бармаклары өшегән бер кеше тез чүгә башласа, нәрсә була ул? Кем син? Егетме, әллә яшь кенә маңка бер кызмы? Аңлашыламы, энем?

Әкрамның бит алмалары комач кебек кызарып чыкты:

— Аңлашыла, абый, — диде ул, түбәнгә карап. — Мин бәла булуым озакка сузылса дип кенә әйттем, абый.

Кулына балта һәм зур пычак тотып, Фатыйма килеп җитте:

— Әй молодец та үзең, Зиннәтша абый. Шундый вакытта, шундый шәп ит табып китергәнсең бит, ә?! Ничек кенә аны башка кешеләр эләктермәгәннәр?

Абзый, салкын тиюдән дә курыкмыйча, пинҗәк җиңнәрен сызганып куйды да, Фатыймага дәште:

— Әйдә, Фатыйма, мин балта белән, ә син пычак белән тура! Әкрам туралган итне складка ташыр. Ничего, сыңар кул белән дә ташырга мөмкин. Ат ите ат көче бирә. Ихтимал шуңадыр, хәзер аны руслар да яраталар.

Бераздан монда Мәрьям дә килеп кушылды. Шунысы гаҗәп — ул нәкъ базарда ит тураучылар кебек, зур алъяпкыч бәйләгән. Әкрам аны, гүя, беренче тапкыр күрә. «Их Мәрьям! Никтер күңелгә якын, йөрәккә ягымлы кыз. Әйтерсең бала вакыттан бирле таныш һәм дус... Әнә ул нинди чибәр. Әнә зәңгәрсу кара күзләр... Карап туймаслык нурлы чырай... Түгәрәк буй-сын...»

— Зиннәтша абый! — диде Мәрьям, кулына пычак алып. — Мин дә булышам, бәлки мине дә ат ите белән сыйларсыз?

Абзый Мәрьямнең ярдәмгә килүенә куана иде.

— Сыйламаган кая ул? Сыйлыйбыз, сыйлыйбыз, Мәрьям!

Шулай итеп, Мәрьям дә эшкә кереште. Әкрам исә, абзый әйткәнчә, туралган итне утын складына ташый башлады.

Күңелле иде. Төрле сүз, төрле гәп, төрле шаянлык. Нәкъ шул вакытта тулай торакка җир казучы Гайнулла кайтып килә иде. Аек. Ул, ит тураучыларны күргәч тә, кинәт туктады:

— Тәки алдыңмыни, бригадир?

— Алдык, — диде абзый. — Теләсәң, сине дә өлешкә кертергә мөмкин. Әйдә, колхоздагыча булсын!

Гайни һич көтмәгәндә айгырга охшарга тырышып кешнәп куйды һәм шунда ук шаркылдап көлеп җибәрде:

— Мин алаша түгел. Рәтле ат булса, сезгә эләгер идемени? Үләксә ич ул, бригадир! Ми-һаһ-һа-һа!

— Җүнсез егет син, — диде абзый, ачуын яшерергә тырышып. — Сугыш елларындагы авырлыкларны оныттыңмыни, шайтан алгыры? Яки ул авырлыклар сиңа эләкмәдемени? Хәер, син ул чакларда «кунакта» булгансың шул...

— Ярый, бригадир! — диде Ярмөхәммәтов, тешләрен кысып. — Бу сүзләреңне бер исенә төшерермен. Бәхетең бар икән, Мәрьям комачаулады. Саклан! Мин дуамал кеше. Аңла! Ат итенә караганда дуңгыз ите тәмлерәк миңа.

Гайни шулай диде дә, тиз һәм кискен борылып, баракка кереп китте.

Мәрьям дәшмәде. Ярмөхәммәтов өчен оят иде аңа. «Әллә мин дә бүлмәгә кереп качыйммы?» — дип уйлап куйды ул.

— Эх-ма! Менә безнең егет ничек кылана? — диде абзый сабырлык сакларга тырышып. — Но нишләмәк кирәк? Ул да адәм баласы. Җитмәсә якташ! Әнә төрмәдәге исеме дә Гайка диләр бит аның...

Фатыйма атның аякларын эшкәртә иде.

— Куркам мин Гайнидән, — диде ул шыпырт кына.

## ҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Яктыкүл — зур эш мәйданы... Көн бүген дә салкын. Шулай да бригадир шат:

— Кулга каз мае сөрттем, — ди ул. Кичә Фатыйма каяндыр табып бирде, рәхмәт яугыры. Молодец хатын, тырыш хатын, шайтан алгыры.

Эшчеләр янә төркемнәргә бүленеп, участокларны урап алдылар. Көн йомшарырга тели күрәсең, каршы яктагы нарат урманы артыннан кояш нуры ялтырый.

— Әйбәт! — диде абзый үз-үзенә. — Көн җылына, кояш күренә, эш тә шәп бара, молодцы, егетләр!

Әйе, эш кызу бара иде. Унга һәм сулга җәелеп киткән бозлы күл өсте әйтерсең сугыш кырына әверелгән. Кайда гына карама, тирән кар коймалары, боз сукмаклары, трактор китергән юан һәм озын торбалар, бульдозер, тимерне эретә торган электр машинасы. Кешеләр, эшчеләр...

Гадәттәгечә прораб алдынгы сафта.

— Бригадир! — диде ул, тәнәфес вакытында абзый каршына килеп. — Әх шәп лә соң кичә китергән торбалар. Менә күрерсез аларны су астына төшерү бик кызык булачак. Кешеләр юкны сөйлиләр, аста бернинди дә упкын юк! Фәкать өч-дүрт метр тирәнлектәге якты чыганак кына бар анда. Водолаз белән минем анда үземнең төшкәнем бар. Тик менә ярышта җиңеп чыгасы иде.

— Җиңәбез, иптәш прораб! — диде бригадир. — Нигә җиңмәскә! Тик менә минем энекәш кенә эшләми пока. Но, ничего, тиздән тереләр, иптәш прораб.

Тәнәфес бетте, эш яңадан башланды. Бригадир, бер төркем эшчеләр белән бергә, торбалар ташый һәм аларны эш урыннарына китерә башлады:

— Әйдә, алдык!

— Әйдә, алдык!

Гайни дә монда иде.

— Ярмөхәммәтов! — дип кычкырды аңа бригадир. — Тукта, сак бул, торба белән аягыңны бастырасың бит, шайтан алгыры.

Ярмөхәммәтов кулын гына селтәде:

— Курыкма, бригадир, ике килә торган үлем юк!

Гайни аек, ләкин аның авызыннан кичәге аракы исе аңкый иде.

— Гайнулла! — диде аңа бригадир. — Я сакланып эшлә, я тулай торакка кайтып кит. Яшермә, син әле айнып җитмәгән, брат.

Гайни дәшмәде. Шулай да ул торбалар тирәсендә сакланыбрак бөтерелә башлады. Әмма бераздан бригадирның колагына гына пышылдап әйтте: «Тырышасың! Газетада макталырга уйлый торгансыңдыр, бригадир?».

Вакыт тукталып тормый, ниһаять, күлнең аргы башыннан прораб килде.

— Әйдәгез төшке ашка, егетләр, столовойга!

Төшке аш Яктыкүлдән ике генә чакрым ары поселок ашханәсендә әзерләнгән. Ә икмәк карточкаларын ашамлыкка алыштыру мәсьәләләре үткән көндә үк хәл ителгән икән.

— Әйдә, бригадир! — диде прораб, абзый белән бер сукмактан атлап. — Мондагы ашханә безнең трест ихтыярында хәзер. Үсәбез. Тик планнар гына яхшы үтәлсен, дускай.

Эшчеләр, киек казлардай бер-бер артлы тезелеп, зур поселокка юнәлделәр. Прораб, әйтерсең экскурсовод, юлның юл буена мондагы урыннар турында сөйләп барды:

— Күрәсезме, бригадир? Ә-әнә анда Уктус таулары! — Абзый уң яктагы биек тауга карады. — Ә-әнә! — дип дәвам итте прораб. — Андагы яшел тауларны күреп ничек гаҗәпләнмәссең? Сугышка чаклы монда бөтен ил күләмендә үткәрелә торган чаңгы ярышларының трамплины урнашкан иде. Киләсе елга ул трамплин янә хәрәкәт итә башлар. Ә хәзергә шәһәр яшьләре генә сикерә аннан...

Берничә минуттан, урман сукмагыннан сул якта зур поселок күренде. Ул зур, әйтерсең район үзәге! Поселокның иң кырый урамында агач бараклар тезелеп киткән. Һәммәсе өр-яңа һәм яшелгә буялган.

— Монда әсирлеккә эләккән немецлар лагеры, — диде прораб, шул баракларга карап. Сүз дә юк, кулларыннан эш килә каһәрләрнең. Кыска гына вакыт эчендә әнә нинди казармалар төзеп куйдылар алар. Мин йортлар төзүче дә бит. Шушы лагерьны корганда совет белгече булып, немецлар белән бергә эшләргә туры килде. Шәп эшләделәр, җеннәр. Баедылар: кайберләре егермешәр мең төшерделәр. Китәләр инде. Безнең хөкүмәт аларга Германиягә кайтырга рөхсәт бирде. Әнә, китәргә әзерләнәләр! Әнә нинди сафларга тезелгәннәр...

Бригадир немецлар лагерына карады. Лагерь исә, чәнечкеле тимер чыбыклардан корылган коймалар аша, ачыктан-ачык күренә иде. Әнә, янәшәдәге мәйданда хәрби оркестр уйный. Ә Берлинга кайтырга җыенган хәрби әсирләр, җеп белән тигезләгәндәй, тигез сафларда басып торалар. Кызык, әсирләр һәммәсе дә үгездәй таза. Янә шунысы кызык, әсирләрнең һәммәсенең дә киемнәре яңа гына энә-җептән төшкән: өр-яңа колаклы бүрек, өр-яңа кыска ак тун, өр-яңа киез итек һәм җылы чалбар. Әсир немецларны күргәч абзый: «Эхма! — дип уйлады. — Кызганыч, Әкрам булмады. Боларны очратса, ни дияр иде? Мөгаен әтисен күз алдына китерер иде. Ихтимал, берәр әсирнең бугазын чәйнәргә омтылыр иде. Әмма нишләмәк кирәк? Эш әсир кулындамыни?»

Эшчеләр әсирләргә тукталып-тукталып карап тордылар. Аннары, прораб белән бригадирга ияреп, ашханәгә кереп киттеләр.

Ишектән килеп кергәч тә шактый зур зал. Анда — буфет. Гайни Ярмөхәммәтов буфетка ашыкты: «Кем белә, бәлки...»

## 2

«Эч поша! — диде Әкрам көнеленнән генә. — Зиннәтша абый эштә, бригадир эштә, ә мин, пешмәгән малай, кул өшетеп тик ятам. Укыр идем, берәр төрле китап та юк ичмаса. Хәтта газета кисәге дә юк!»

Әкрам тулай торакның тәрәзәсеннән урамга карап утыра иде.

Урамда йомшак кына кар ява. «Димәк көн җылына», — диде Әкрам эченнән генә һәм кинәт үзенең туган якларын күз алдына китерде.

Әкрам, яшүсмер чагыннан бирле кешеләргә әйтмичә генә, җырлар язып маташа иде. Авылдан китеп, Уралга килгән сәгатьләрдә дә, көнеленнән генә җырлар язгалап мавыкты Әкрам. Менә ул хәзер шул җырларның берсен үзе белгән авыл көенә, акрын гына, моңсуланып-моңсуланып җырлап җибәрде.

Алсу офыклардан
Кояш күтәрелә,
Нурландырып ерак тауларны,
Моңсуланып сайрый гүзәл бер кош, бер кош,
Тибрәндереп назлы талларны.

Гөлбакчада ике чия, ике чия,
Берсе — авырый, берсе — чәчәктә.
Күңел ярсый: «Ник булмаган, ник булмаган,
Икесе дә күркәм чәчәктә?»

Исә җилләр, еллар ага, ага еллар,
Кабындырып заман уйларын,
Гөлбакчада ике чия чәчәк ата,
Хәтерләтеп гомер юлларын.

Яңа язлар килә,
Сирень чәчәк ата,
Дөнья шаулый, дөнья дулкынлы,
Яңа язлар килә, яңа язлар, язлар...
Тик булмасын алар упкынлы![1]

Бүлмәгә көтмәгәндә Фатыйма килеп керде:

— Әй моңлы җырлыйсың ла, җанкисәгем! Әнә янәшә стена аша ишетелде дә, мәрхүмә әниемне күз алдыма китердең, Әкрам. Еладым. Ашыйсың киләдер, акыллым, менә ит, аша. Ат ите, абыең сиңа пешереп бирергә кушкан иде. — Фатыйма өстәлгә шактый зур кисәкләргә туралган ат ите китереп куйды. — Менә, суытма, аша, акыллым!

— Рәхмәт, Фатыйма апа! — диде Әкрам куанып. — Мин ач түгел, иртән чәй эчкән идем. Ипи бар, шикәр бар, нигә мин ач булыйм?

Фатыйма ашыга иде.

— Аша, Әкрам. Мин сине үземнең улымдай күреп әйтәм, аша!

— Фатыйма апа! Вакытлыча укып торырга сездә бераә китап табылмас микән? Минемчә, Мәрьямдә бардыр.

— Табарбыз! — диде Фатыйма һәм өстәлдән буш тәлинкәне алып, бүлмәдән чыгып китте.

— Менә! — диде яңадан әйләнеп кергән Фатыйма тышлары искереп беткән ике китапны Әкрамга биреп. — Менә Габдулла Тукай шигырьләре, менә Шәриф Камал романы: «Матур туганда». Укы! Мин аларны өстемдә бомба шартлаганда да югалтмаска тырыштым. Тукай китабын ирем дә ярата иде. Яшь чакларда бергә укыдык.

— Рәхмәт, апа, рәхмәт! — диде Әкрам, китапларны кулына алып.— Тукайны укыганым бар... Тагын, тагын укырмын. Шәриф Камалны да рәхәтләнеп укырмын! Әле минем клиникага барып кулны бәйлисем дә бар икән. Сестра көн аралаш килергә кушкан иде.

— Ярый, ярый, Әкрам! — диде Фатыйма һәм халат киеп, тулай торак идәнен юарга кереште. Әкрам исә, тиз-тиз җыенып, шәһәр поликлиникасына чыгып китте.

Клиникадан кайткач әнисенә хат язарга утырды:

«Кадерле әни! Мин исән-сау. Минем өчен борчылма! Мин, Зиннәтша абый белән бергә, тулай торакта яшим. Тирә-күрше әйбәт кешеләр. Без җылкы ите алдык. Тамак тук, икмәк күп. Кичә ашамлык карточкаларын трестка тапшырып, ашханәгә йөри башладым. Уңай, рәхәт. Әни! Әти турында яңа хәбәр юкмы? Мин аны һаман көтәм, төшемдә күрәм. Ә син кайгырма, әни, мин беренче мөмкинлек тугач, та, акча салырмын. Дусларга, авылдашларга миннән күп сәлам, әни. Глафира Петровнага аеруча зур сәлам, әни! Әгәр ул булмаса, рус телен ничек өйрәнер идем? Ә кирәге зур хәзер. Хуш, әни! Хатыңны көтәм. Улың Әкрам.»

Әкрам үзенең кулы өшүе турында әнисенә язмады: «Аны нигә борчырга?»

Әкрам хатны, шәһәргә баргач почта әрҗәсенә салырмын дип, тумбочка тартмасына куйды һәм Фатыйма биргән калын китапны күпме

---

[1] «Яңа язлар» исемле җыр. Сүзләре авторныкы, музыкасын Рөстәм Яхин язган.

тырышса да укый алмады, чөнки ул әле һаман хат тәэсиреннән, туган як тәэсиреннән арынып бетмәгән иде.

...1945 ел. Майның тугызы. Таң алды. Әкрамны көтмәгәндә әнисе уятты: «Тор, улым, тор! Без җиңдек, сугыш беткән, Гитлер тончыккан! Тор! Бәлки әтиең кайтыр?! Бәлки аның билгесез югалу хәбәре ялгыш булгандыр? Тор, улым, тор!»

Әнә, мәйданда халык!! Әкрам яшен тизлеге белән урыныннан торды һәм тиз-тиз генә мәктәп каршындагы киң мәйданга йөгерде...

Әкрам, менә шулай уйланып, ялгызы гына утыра бирде. Шул чак кинәт бүлмәгә эшчеләр кайтып керделәр. «Карале, халык эштән кайтты ич», — диде Әкрам эчтән генә һәм урыныннан торып, абзыйны каршылады.

Абзый шат иде.

— Менә тормыш рәтләнә, дип әйттемме сиңа, Әкрам? Әйттем. Менә якын арада икмәк карточкаларын бетерәләр ди. Бу — бер. Икенчесе — акчага да үзгәреш була икән. Аның бәясе кыйммәтләнә, ди. Яшибез, значет, яшибез, энем. Кайгырма! Бәлки әле әтиең дә исәндер...

Әкрам Зиннәтша абзыйга ышана иде.

— Мондый хәбәрләр өчен, әнием монда булса, авызыңа бал дияр иде, абый.

Абзый елмаеп куйды, плитә тирәсендә кайнашты да, Әкрамны табынга чакырды.

— Әйдә, энем, ат итен умырабыз! Хәер, бүген мин дә ашханәгә йөри башладым. Шулай да ат итен ташламыйк әле. Аннан чәй эчәрбез. Шикәр үз кулыбызда.

Алар кичке ашка утырдылар.

## СИГЕЗЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Якшәмбе көн. Халык ял итә. Сәгать иртәнге тугыз чамасы. Мәрьям белән Фатыйма апа иртәнге чәйдән соң аш өстәлен җыештырып йөриләр иде. Аларның бүлмәсенә көтмәгәндә Әкрам килеп керде.

— Хәерле иртә, Фатыйма апа. Хәерле иртә, Мәрьям!

Апа Әкрамны елмаеп каршылады:

— Әй, акыллым! Әллә яманлап йөрисеңме? Әле генә чәй эчтек. Тагын куйыйммы?

— Рәхмәт, Фатыйма апа! — диде Әкрам елмаеп. — Без инде абый белән столовойда булдык.

Әкрам, Габдулла Тукай һәм Шәриф Камал китапларын култык астыннан чыгарып, өстәлгә куйды.

— Мин боларны рәхәтләнеп укыдым, Фатыйма апа. Сездә тагын берәр китап табылмас микән? Нинди генә булса да ярый.

Мәрьям, аш өстәлен уңгарак күчереп, тәрәзә янында торган зур гына тумбочкадан бер китап чыгарды:

— Менә Николай Островский. «Корыч ничек чыныкты»

— Рәхмәт, Мәрьям, рәхмәт, укыганым бар. Ләкин тагын укыйсым килә. — диде Әкрам, китапны тиз генә кулына алып.

Мәрьям, елмаеп куйды да, көтмәгәндә егетне концертка чакырды:

— Әкрам! Бүген Луначарский театрында Вертинский концерты була. Вертинский чит илдә булып кайткан атаклы җырчы икән. Ул Максим Горькийның, хәтта Шаляпинның замандашы ди. Барыйкмы, Әкрам, әйдә барыйк, ә?

Әкрам уйга калды: «Мондый өс-баш белән театрга ничек барасың? Оят, килешми. Аякта олтан салынган иске итек, өстә этидән калган кыска костюм. Ә менә киногa барырга мөмкин, анда чишендермиләр».

— Юк, бармыйм, — диде Әкрам, кырт өзеп. — Юк. Ә кинога барам. Әйдә кинога барыйк, Мәрьям!

Кыз чыркылдап көлеп җибәрде:

— Әйдә «Спартак» клубына барабыз! Анда ике зал. Берсендә бүген «Себер җире турында әкият». Мактыйлар. Әйдә!

Алар, тиз-тиз генә җыенып, кинога чыгып киттеләр. Фатыйма ялгызы гына уйланып калды: «Әкрам әйбәт, тик инде кемгә генә насыйптыр шундый саф егет? Сизәм, Мәрьям ярата аны. Мактый: егет булса, Әкрамдай булсын, ләкин бик яшь ди.

Әйе, Әкрам Мәрьямнән ике яшькә яшьрәк шул, абзый әйтмешли, шайтан алгыры. Ә Гайни кешемени ул.

Яшьләр «Спартак» клубына җәяү генә киттеләр. Көн җылы, хәтта тротуарда кар эри иде. Әкрам кызны култыклап алмакчы иде, ләкин оялды: киемнең рәте юк. Ә Мәрьям әнә нинди матур кызгылт пальтодан. Шулай да борын күтәрми. Молодец!

— Әкрам! — диде Мәрьям, егетнең уйларын өзеп. — Минемчә, укырга кирәк сиңа. Һөнәр алырга кирәк! Беләсеңме, шушы арада безнең трестта юл төзүчеләр курсы ачыла. Кичке курс. Өч кенә айлык. Мин ышанам, син аннан бер дигән мастер булып чыгарсың. Әйтимме, списокка сине теркикме?

— Теркә, Мәрьям, теркә! — диде Әкрам, шатланып. — Болай да укыйсы килгән иде, ләкин... Ә син үзең кайсы институтка керергә әзерләнәсең, Мәрьям?

Кыз бер елмайды, бер җитди төс алды:

— Төзүчеләр институтына, Әкрам. Мәңге яшәрлек матур биналар яки юллар төзисем килә. Әнә, ә-әнә шундый биналар! — Мәрьям каршы яктагы зур-зур биналарны кулы белән күрсәтә барды. — Әнә, Луначарский исемендәге опера театры. Шәһәрдә ул иң матур бина. Әнә зур «Урал» кунакханәсе! Әйтерсең үзе генә дә аерым бер шәһәр... Ә промышленность йорты турында әйтәсе дә юк. — Мәрьям уң яктагы киң урамга карады. — Әнә биш катлы бер йорт ничә урамны бер үзенә сыйдырган. Ә инде арырак бер өй унике катлы. Якты һәм биек. Син әле белмисең, Әкрам, иске һәм яңа шәһәр бергә кушылган монда.

Мәрьям бер мәлгә сөйләшми барды.

— Менә шәһәрнең уртасы кайда икән?! — диде Әкрам, әле бер, әле икенче бинага борылып-борылып карап.

— Менә килеп тә җиттек, — диде Мәрьям тукталып. — Билет үзем алам. Икебезгә дә.

Алар, берничә минуттан соң, кинотеатр залына кереп киттеләр.

## 2

Прораб милләте буенча рус, ә хатыны татар икән. Кайчандыр, революция елларында ук, Эрбет шәһәрендә өйләнешкәннәр алар. Бер көнне эштән кайтышлый юлда сүз иярә сүз чыккач: «Так что мин яртылаш татар, бригадир» — диде прораб һәм абзыйны, дусларча, үзенең өенә чакырды, адресын бирде. «Барам, иптәш прораб, начальник чакыргач ничек бармаска?» — диде бригадир һәм бүген иртән сәгать унбердә прораб өенә килеп керде.

— Хәерле көн, иптәш прораб!

— Хәерле көн, бригадир. Ниһаять, килдең. Молодец, туган!

— Нигә килмәскә? Начальник чакырганда карт солдат килмичә каламыни?

— Әйдә, чишен, түргә уз! Тик менә карчык кәефне бозды әле. — Бригадир идәндә тузып яткан әйберләргә карады. Анда зур-зур балталар, әллә нинди пычкылар, камытлар һәм тагы әллә ниләр чәчелеп ята иде. — Акчаның бәясе үзгәрә икән, — диде прораб. — Ун сум бер сумга төшә икән. Әнә шуның өчен карчык җуләрләнә башлады. Күрәсеңме кибеттән нәрсәләр сатып алган? Тагын кибетләргә чыгып йөгерде. Әйдә, утыр!

Абзый, өске киемнәрен чөйгә элеп, беренче бүлмәгә үтте һәм ишек янында торган урындыкка килеп утырды.

— Түргә уз, түргә! — диде прораб.

Абзый итеген салды, түргә узды. Прораб кухня ягына чыгып китте. Абзый прорабның квартиры белән кызыксына башлады.

Әйе, шәп. Урамга дүрт тәрәзә карый. Әнә тагын бер бүлмә! Бу квартира хөкүмәтнеке микән? Әллә хуҗа монда карчыгы белән, ялгызы гына инде? Ә бала-чагасы?

Бүлмәгә прораб әйләнеп керде. Аның кулында зур гына поднос, ә подноста тозлаган кыяр, ак кәбестә, яшел помидор, ак ипи һәм бер шешә «Сырец».

— Гаеп итештән булмасын, туган! — диде прораб, ашамлыкларны өстәлгә тезеп куеп. — Ачык чырайдан башка, әллә ни сый юк миндә югын, әмма гаепкә санамассың дип уйлыйм, бригадир. Менә хәзер карчык та кайтып керер. Әйдә, утырыйк әле!

Ниһаять, утырдылар һәм тост әйтмичә генә берәрне җибәрделәр. Бригадирның күңеле ачылганнан-ачыла барды:

— Рәхмәт, иптәш прораб, сез бик тырыш инженер!

— Үзеңә рәхмәт, бригадир, эшне шәп оештырасың.

Рюмка артыннан рюмка, сүз артыннан сүз башлана торды. Прораб үз өендә яши икән. Өй аның әтисеннән үк калган. Әтисе дә инженер булган. Ул картаеп үлгән. Прорабның бер улы Ленинградта, бер улы Мәскәүдә яши икән. Янә бер нәрсә, прораб сугышта күперләр төзүче инженер-офицер булган. Урал яклары турында ул ниләр генә белми?! Дөньяда булган бөтен байлык бар монда.

Прораб Урал турында тагын ниләрдер сөйләмәкче иде, ләкин аның хатыны кайтып керде.

— Исәнмесез, кунак бар икән?

— Кунакның да ниндие әле! — диде прораб һәм абзыйны хатыны белән таныштырды.

Хатын татар телен бик сагынган икән. Ул кинәт чытлатып татарча сөйләшә башлады:

— Сез кайсы яктан? Казаннанмы? Аһ, кызганыч! Казанда булганым юк. Тик вокзалында, үтешли генә. Әйдәгез, табынны дәвам итик!

Хатын тиз генә кухняга ташланды һәм аннан куырылган йомырка белән сөт-катык чыгарып куйды.

— Хәзер кайнар аш әзерлим, — диде, ләкин абзый никтер ашыга башлады:

— Рәхмәт сезгә, борчылмагыз!

Шулай да мәҗлес дәвам итте. Әмма бераздан:

— Рәхмәт, иптәш прораб. Рәхмәт, ханым! — диде бригадир һәм урыныннан торды. — Кунакның туйдырмаганы яхшы диләр безнең якларда.

Прораб янә бер рюмканы тутырды:

— Юл аягы, бригадир!

Эчтеләр. Абзый, өй хуҗасы һәм аның хатыны белән бик җылы саубуллашып, баракка кайтып китте.

Абзый төзүчеләр шәһәрчегенә кайтып җиткәндә, каршы яктагы койма артыннан ниндидер исерек тавышы ишетелә иде.

Эчәбез дә типтерәбез,
Закускага колбаса.
Моннан китеп булмас инде,
Әби килеп алмаса.

Җыр тынды. Абзый, шәһәрчек урамына кереп, бараклар тыкрыгына борылгач, җыр янә башланды:

Кайт, зимагур, кайт өенә!
Өйдә икмәк игәрсең.
Бутылканны сука итеп,
Стаканың җигәрсең.

Җыр якынлашканнан-якынлаша барды. Ниһаять, абзый ни күзе белән күрсен, Ярмөхәммәтов икән. Исерек. Күренеп тора, әле уңга, әле сулга талпына. Әнә аңа, һич көтмәгәндә, ахры, Мәрьям белән Әкрам килеп очрады.

— Әһә! Эләктеңмени? — дип кычкырды Ярмөхәммәтов һәм кинәт Әкрамның күз төбенә йодрыгы белән сукты.

Нишләсен, сау кулы белән Әкрам да шул ук җавапны бирде. Исерек егылды, ләкин тиз торды һәм янә Әкрамга сукты. Нәкь шул секундта абзый йөгереп килде:

— Гайни, туктамасаң кыйныйм мин сине!

Шундук, әче тавыш чыгарып, Мәрьям елый башлады. Ул да түгел, җир астыннан калкып чыккандай, милиция күренде һәм Ярмөхәммәтовның кулыннан тотты:

— Ник сугышасың? Әйдә!

Гайни ялына башлады:

— Гафу итегез, иптәш начальник! Гаепле мин, гаепле, тилмереп сорыйм, зинһар гафу итегез!

— Күрдем! — диде милиционер, Ярмөхәммәтовны култыклап алып. — Күрдем, әйдә участокка. Әйдәгез сез дә!

Участок барак аша гына аерым бинага урнашкан иде. Гайни каршы тормады, барды. Ул, участокка килеп кергәч тә, янә ялынырга тотынды:

— Кичерегез, иптәш начальник! Башка булмас, һич булмас! Ант итеп әйтәм, иптәш начальник! — Гайни һаман талпына иде.

Участок башлыгы Гайнигә җирәнеп карады:

— Мондый эшне үзем генә хәл итәргә хакым юк, — диде ул, — менә монда җәберләнүчеләр бар, алар ни дияр бит? Күрмисеңмени әнә ул егетнең күз төбе ничек күгәреп чыккан?

Гайни кинәт Әкрамның аягына егылды:

— Кичер, Әкрам! Ходай өчен кичер дим! Гомер буе сиңа олтырак булырга риза! Туйдым, туйдым мин төрмәләрдән! Кичер, дустым, кичер! Бригадир, әүвәл син кичер!

— Тор! — диде абзый һәм Әкрамга карады. — Ничек? Әллә кичерикме, энекәш? Ул да адәм баласы. Кем белә, бәлки төзәлер, шайтан алгыры. Күрәсең ич, сүз бирә.

Әкрам аптырап калды. Шулай да бераздан:

— Кичерәм, — диде. — Әгәр дә тагын бәйләнеп йөдәтмәсә.

Гайни идәннән торды.

— Аңла! Соңгы тапкыр, — диде аңа милиционер.

Бу вакыйга барак халкына күңелсез хәбәр булып таралды, ә кайберләренә сабак булды.

Вакыт кичке тугыз чамасы иде. Тулай торак мичендә, кызыл телләр күрсәтеп, каен утыны яна. Гадәттәгечә халык инде йокыга әзерләнә.

«Менә йөр инде, күгәреп шешкән җимерек каш белән, — дип уйлады Әкрам, караватка ятып. — Әллә кулдагы облигацияләрне сатып, өйгә кайтып китәргә микән? Арзан бәягә алучылар табылыр!»

Әкрам күңеленнән генә Гайни турында кинәт бер җыр чыгарды.

Кайсы гына егетләрне кара җиргә
Зәм-зәм суы алып китмәде?
Эчтең, Гайни, нигә һаман эчәсең син,
Нигә сиңа акыл җитмәде?

Абзый да Гайни турында уйлана иде.

— Аһ, шайтан алгыры! — диде ул, йокыга китәр алдыннан караватта сузылып яткан килеш. — Менә бүгенге җәнҗаллар аркасында кичке чәйне дә рәхәтләнеп эчеп булмады, шайтан алгыры. — Абзый Ярмөхәммәтов караватына карады. — Бетсен мондый хәл! Оят кирәк. Фронтта безнең егетләр, бер-берен яклап, утка керделәр. Ә монда ни булып чыга? Аңлыйсыңмы, сүз синең хакта бара ич, Гайни? Мәрьямне сөям дигән буласың тагын, ә үзең рәтләп кырынмыйсың да. Әнә озын чәчләрең иңеңә төшкән, шайтан алгыры. Бер көнне күз алдымда Мәрьямгә бәйләнеп тордың: «Бер генә үбәм, бер генә», имеш. Урамда, кешеләр арасында кем шулай эшли? Сөй, ярат, кызганыч түгел, но тәртибен бел! Син миңа үпкәләмә, башка коткармыйм. Яши белмисең, шайтан алгыры. Ә яшәү рәхәт! Син түгел, сугышта үлемнән калган инвалидлар да кадерен белә аның. Әйткәнне тыңла, Гайни, мин синнән олы кеше.

Абзый тынды, шул үк бүлмәдә яшәүче Оренбург егете сүзгә кушылды:

— Бригадир дөрес әйтә, егетләр. Ярамый болай! Үткән көн газетада безне мактап яздылар. План үтәлә, «Уралспецгидротрест»ның эшчеләре алдынгы сафта, прогуллар юк, диделәр. Ә бездәге мондый хәл прогуллардан да яманрак түгелме? Вот нәрсә, үзара дуслык җитми безгә. Әнә халык әле һаман да тәгәрмәч өстендә яши, кайсы китә, кайсы кайта. Авыр югалтулар турында әйтәсе дә юк инде. Бер безнең авылдан гына йөз сиксән кеше сугыш кырында калды. Эх, Гайни, Гайни, син, дускай, алар турында ник онытасың? Менә минем бер абыем, бер энем Белоруссиядә һәлак булдылар. Гомергә буйдак булып йөрмәссең, Гайни. Өйлән. Хатыннар күп. Квартир тап, но Әкрамның ни гаебе бар монда?! Нигә син аңа суктың? Ә Мәрьямнең гаебе бармы? Йөрсеннәр, ник көнләшергә, иркенләп йөрсеннәр! Барыбер син берәүне дә көчләп яраттыра алмыйсың, малай. Кем эчми? Тавык та эчә. Ә акылын юньле кеше югалтмый.

Әкрам бу сүзләрне зур дикъкать белән тыңлый һәм борчыла иде. «Нигә кешеләр аракы эчәләр икән? Гайни кебек исерек башлар кайчан булса да бетәрләр микән? Әллә милициягә эшкә урнашыргамы? Юк, армиягә барасы бар бит әле. Кем белә, бәлки кызык җирләрдә, диңгезләрдә, чит ил тирәләрендә хезмәт итәргә туры килер? Әй матур ла яшел погон, яшел фуражка!»

Ярмөхәммәтов дәшмичә ятты. Әмма ул да уйлана һәм борчыла иде. Нигә аны гына сүгәләр? Ул Әкрамга хәнҗәр белән кадарга җыенмады ич! Ә кадаган булса, ни булыр иде? Ник аны бу кадәр рәнҗетәләр. Ник, ник? Әйе, Мәрьям белән ул былтыр танышты. Шушын-

да, тулай торакта. Аннан яратты, ә аракы эчү җинаятьмени? Әллә боларга отпор кирәкме? Тукта, кирәкмәс. Әйтсәң сүз чыга, төртсәң күз чыга дигәннәр картлар. Шулай да әйтер сүзе күп. Күп! Мәрьямгә дә, Әкрамга да, һәммәсенә дә... Үзенә дә әйтер сүзе юк түгел аның. Дөрес, аракыны ташларга кирәк. Ташларга, ташларга! Әмма ничек ташларга? Ничек? Тарта бит, ләгънәт, үзенә тарта. Җитмәсә Мәрьям дә эчне пошыра... Нигә ул ир-егетнең хисләрен аңларга да теләми? Нигә, нигә?

Гайни тагын бераздан күзләрен йомды һәм тиз генә йокыга китте.

## ТУГЫЗЫНЧЫ БҮЛЕК

### 1

Вакыт, агымсу кебек, Әкрамның кул бармаклары өшегәннән соң утыз көн үтте. Ул әле шушы атнада гына янә врачта булды: «Ярый, — диде аңа врач, куанып. — Иртәгә эшкә чыгарга мөмкин. Молодец, түзден! Югыйсә хәлең бер кулсыз калырга якын иде».

Ниһаять, Әкрам эшкә чыкты. Эш янә шул ук Яктыкүл чыганагына бәйләнгән икән. Вакыт иртәнге сигез.

— Энем! — диде абзый, эш башлануга Әкрам янына килеп. Мин прораб белән сөйләшкән идем, ул сине табельщик итеп күчермәкче. Җиңел эш, ди, яртысы конторда эшләнә, ди. Тик, менә акчасы гына азрак икән, шайтан алгыры. Ну, үзең ничек уйлыйсың? Ризамы, юкмы?

Әкрам уйланып та тормады:

— Юк! — диде. — Нигә миңа андый эш? Мин инвалид түгел ич. Ишеткәнем бар, эшкә чыкмаучыларны санап йөрисем килми. Авылда өй корасы бар...

Абзый дәшмәде. Әкрам эшкә ашыкты. «Менә рәхәт!» — дип уйланды ул яңадан эшли башлагач.

Менә сагындырган эш, сагындырган кешеләр, Әнә күл ярларында ничаклы халык! Ничаклы яңа техника, яңа торбалар! Эшнең хәзер иң кызык тармагы сварщиклар кулында икән. Әнә алар боз канаулар буенча нинди очкыннар очыралар! Әнә алар нинди юан, нинди калын торбаларны ничек итеп бер-беренә ялгыйлар! Кая гына карама, ут, очкын ыжгыра.

Абзый Әкрам белән янәшә эшли башлады.

— Егет! — дип кычкырды ул, бер сварщик каршына килеп. — Безнең биш торба әзер: эш синнән тора. Ашыгыр идең азрак, шайтан алгыры. Но, давай, давай!

— Тырышам, бригадир, — диде сварщик. — Ләкин генераторны өстерәшергә бер кеше кирәк, иптәшем авырый.

Бригадир Әкрамны чакырды:

— Әйдә, икәү өстерик! Бозда егылма, аяк тая.

Алар генераторны, сварщик кушканча, башка урынга җайладылар.

— Давай! — диде бригадир, сварщикны ашыктырмакчы булып.

Берничә секундка өзелеп торган чаткы авазлары тагын шаулый башлады.

Озакламыйча юл буенда автомашиналар күренде.

— Киләләр! — диде бригадир, күлнең аргы ягына карап. — Барлыгы бишәү икән. Һәммәсендә дә калын торбалар. Давай, Әкрам, син монда кал, бу егеткә ярдәм ит, ә мин машиналарны каршылыйм.

Бушатабыз.

Бригадир йөкчеләр төркеменә йөгерде:

— Әйдәгез, егетләр, тизрәк бушатыйк! Бушатыйк та сварщикларга бирик. Әйдәгез, үгезнең мөгезеннән, шайтан алгыры.

Алдагы автомашинаның кабинасыннан техник Мәрьям сикереп төште.

— Котлыйм, иптәш бригадир, котлыйм!

— Ни белән? — диде Зиннәтша абзый, җитди төс алып. — Әллә миңа бер матур кыз таптыңмы, шайтан алгыры?

Мәрьям чыркылдап көлеп җибәрде:

— Котлыйм, Зиннәтша абый? Сезнең бригада эш нормасын йөз кырык процентка үтәгән. Менә нинди куаныч, Зиннәтша абый!

Гадәттәгечә, Мәрьямнең бит алмалары кып-кызыл иде.

— Без шат! — диде бригадир. — Бик шат! Безнең трест шәһәрнең бер йөрәге. Моны кем белми? Кемнәр аңламый, Мәрьям?

Болар сөйләшеп торган арада прораб килеп туктады. Мәрьям аны да шатландырды:

— Шатлык, иптәш прораб, шатлык, сез алда! Миңа трестта әйттеләр, сезнең участок айлык норманы йөз кырык процентка үтәгән!

Прораб сабыр кеше һәм һәр вакыт аек акыллы. Шулай да:

— Юарга кирәк, егетләр! — диде ул, мыек астыннан гына көлеп.

Эш дәвам итте. Бүген кар яумый, һава саф иде. Каршы якта нарат урманы һәм каенлык. Каенлык белән янәшә генә биш катлы бина. Бинаның тәрәзәләре һәм балконнары Яктыкүлгә карыйлар. «Әх, матур ла, — дип уйланды абзый, шушы бинага карап. — Әйе, ишеткәнем бар: ял йорты монда. Ул сугышка чаклы корылган. Әнә хәзер яңадан эшли икән. Тормыш төзәлә, димәк. Кем белә, әгәр Зөябашына кайтып китмәсә, абзый да ял итәр әле монда?»

Абзый шулай уйланды. Уйланды да тагын эшкә тотынды. Эш... Эш... Ничә минуттан соңдыр кечкенә тәнәфес. Шул арада прораб абзый каршына килеп туктады.

Тәнәфес вакытында алар тагын прораб белән гәпләшеп алдылар.

— Менә күрәсеңме, беренче бишьеллык җимешләре алар. — Прораб кулы белән тау битендәге шәһәрчеккә күрсәтте. Әнә шул йортларның эчен күз алдыңа китер: урам кебек озын коридор. Коридор буйлап бүлмәләр төзелеп киткән. Бүлмәләрдә, аслы-өсле, яңа икешәр бүлмә. Америка фасуны, имеш. Тфү! Бер бүлмәдән икенче бүлмәгә керү өчен, тар баскыч аша, икенче катка күтәреләсең! Егыласың, табак-савытны гына түгел, аягыңны да сындырасың! Менә шул да уңай эш һәм яхшы сыйфат булдымы?! Моны мин ни өчен әйтәм? Сыйфатка игътибар бирик, дим мин, бригадир. Бәлки әле син дә шәһәрдә төпләнерсең?

— Аңлыйм! — диде абзый елмаеп. — Әйе, бәлки әле мин авылга кайтмам да. Анда минс кем көтә? Эш монда да табыла. Эшләрмен акрын гына. Акча җене сукмаган миңа.

2

Урамнарда караңгы төшеп килә, халык эштән бушады, кешеләр өйләренә кайталар. Әкрам исә, абзый белән берлектә ашханәдә тамак туйдырып, төзүчеләр клубына ашыкты. Клуб зур икән. Аның өске катында ташчылар өчен оештырылган курс урнашкан. Курс ихтыярында аерым бүлмә. Бүлмәдә озын-озын өстәлләр, эскәмияләр һәм йөзләп урын.

— Менә, Әкрам! — диде абзый, кечкенә авыл клубына охшаган зур бүлмәгә килеп кергәч тә. — Менә, картаеп беткәч, миңа да укыр-

га туры килә бит, шайтан алгыры, ә? Но, нәрсә эшлисең? Яшьлектә укып булмады. Әнә хәзер прораб бер үк сүзне чәйни дә чәйни, укы, бригадир, ташчылар курсында укы, ди. Әйбәт һөнәр, акчалы һөнәр, кешеләргә, юлчыларга, автомашиналарга файдалы һөнәр, ди. Ярый, мин әйтәм, менә килдем. Синең белән ярышмыйм только, Әкрам.

Курска шактый халык җыелган. Ярмөхәммәттов Гайни дә монда. Ләкин ул никтер арттагы сафта бер ялгызы гына утыра.

Беренче дәресне, дөресрәге, курсларга кереш сүзне трест башлыгы урынбасары башлап җибәрде. Сүз иярә сүз чыккач, прораб турында болай диде ул: «Александр Петрович Шадрин зур белемле, тәҗрибәле инженер. Кыскасы, әллә кайчаннан бирле юллар алласы. Аны яхшы тыңлагыз, тырышып укыгыз. Яз килүгә үзегез дә юл мастеры булырсыз, иптәшләр.»

Абзый канәгать иде. Әкрам да шулай. Башлык урынбасарыннан соң, прораб үзе сөйли башлады:

— Мин сезне беренче занятие белән тәбриклим, дуслар. Занятиеләр бик күп булачак. Безнең илдә юллар бик күп, — диде прораб. Совет илендәге юллар турында кызык-кызык мисаллар сөйләп, прораб стенага эленгән зур карта каршына килде. — Менә! — диде, булачак юллар сурәтенә күрсәтеп. — Менә мондый юллар безнең өлкә аша үтәрләр, ә менә монда яңа юллар корыла башлар, безнең трестның вазифалары киңәйгәннән-киңәя барыр, яңа трест оешыр, яңа мөмкинлекләр туар.

Прораб озак сөйләде. Аннары ташчыларны киләчәк занятиеләр планы белән таныштырды. Ниһаять, ул занятиене тәмамлады.

Халык таралды. Абзый шат иде.

— Вот, Әкрам, — диде ул, кайтырга чыккач. — Ташчылар булабыз, значет. Әйе, булабыз. Әйткән сүз — аткан ук дигәннәр. Булабыз, шайтан алгыры. Син әле ташчы гына түгел, ташчылар башлыгы да булырсың, энем.

— Көлмә, абый! — диде Әкрам, баракка ашыгып — Ташчылар курсына йөрибез, әлбәттә. Сиңа да кыен булмас, һөнәрле кеше булырсың. Атнага ике тапкыр монда килеп укулар үзе бер бәйрәм.

## 3

Гайни, ташчылар курсында дәресләр беткәч, клубның аскы катына төште, буфетка керде, өч шешә сыра алды һәм аерым бер өстәл янына утырып, күңелсез уйларга чумды.

Әйе, ул укымады. Аның барлык белеме дүрт кенә класс. Сәбәбе гади: Гайни укырга теләмәде. Усал да, ялкау да иде. Хәер, монда ул үзе генә гаепле түгел. Түгел! Әнә, һаман хәтердә: әнисе үлде, әтисә исә ниндидер усал кызга өйләнде. Гайни аны һич тыңламады. Аннары өйдә көне-төне җәнҗал кызды. Бер көнне Гайни үги әнисенең эченә типте. Шул чак әтисе аңа: «Вон өйдән!» — дип кычкырды һәм улын өйдән куып чыгарды. Әйе, Гайнигә әле унбиш кенә яшь иде. Шулай да Гайни китте... Китте... Сиксән яшьлек әбисендә яши башлады. Аннан соң, юллар... Ләкин әтисенә кайтмады. Юк, юк... Ә хәзер аның һич кирәге юк. Юк... Гайни әтисез үсте. Дуслар табылды... Эх, дуслар, дуслар. Әйе, Гайни урлап эләккәч, колониядән дуслар сүзенә ышанып качты. Аннары тагын... Тагын... Эх, җүләр. Нигә ул лагерьда укымады? Лагерьда уку өчен бөтен шартлар тудырылган иде ләбаса! Ә хәзер нишләргә? Нишләргә хәзер? Мәсәлән, аракыны ничек ташларга? Ничек, ничек?!

Гайни шулай борчылып сыра чөмерде һәм кинәт үзенең урта бармагына карады. Анда кайчандыр кара туш һәм энә ярдәме белән тә-

ре сурәте ясалган иде. Ә беләгендә аның тагын да ямьсезрәк рәсемнәр күренеп тора иде.

— Тфү! — диде Гайни эченнән генә, кинәт Мәрьямне күз алдына китерде.

Әйе, истә, ял көне иде. Мәрьям, әнисенә ярдәм итәм дип, тулай торакның идәнен юа иде. Гайни аңа үзе сүз кушты: «Мин дә ярдәм итиммe, чибәр?» Мәрьям сихерле итеп көлеп җибәрде: «Хәлеңнән килсә ярдәм ит!» Лагерьда чакта эшләмәгән эшмени? Гайни, кыз кулындагы чүпрәкне тиз генә алып, идән юарга керешә. Кыз гади һәм ачык күңелле икән, рәхәтләнеп көлде генә. Аннары трест клубы, кино. Мәрьям Гайнигә никтер бик-бик ошады. Әйтерсең Гайни бу кыз белән гомер буена таныш! Әнә Мәрьямнең түп-түгәрәк бит алмалары, аның кайчакта җанны эреткеч итеп чыркылдап көлүләре янә йөрәктә кайный.

Гайни, сыраның актыккы стаканын эчеп бетереп, урамга чыкты һәм баракка юл тотты. «Керәм!» — дип уйланды ул, урам буйлап баракка кайтканда.

— Хәзер Фатыйма бүлмәсенә керәм. Анда Мәрьямне күрәм. Күрәм. Күрәм. Ә Әкрам? Авызыннан әнисенең сөте китмәгән Әкрам?

Гайни адымнарын ешайтты, бараклар чатына килеп җитте, ләкин ул, ни күзе белән күрсен, кинәт аны сукмакта Мәрьям куып җитте.

— Гайни! Син кайдан болай?

— Клубтан.

— Киноданмы?

— Юк, ташчылар курсыннан.

— Менә молодец! Ә мин библиотекада булдым.

Гайни кызга сәер итеп карады:

— Берәр егет белән очрашуда түгелме?

Кыз үпкәләде:

— Булса соң!? Миндә кемнең нинди эше бар?

Егетнең ачуы килде:

— Минем эшем бар!

Кыз гаҗәпләнде:

— Нинди?

Егетнең ачуы басылмады:

— Эшем түгел, хакым бар!!!

— Нинди хакың бар?

— Яратырга хакым бар. Мин сине яратам, Мәрьям! Үлеп яратам, тик менә аңлата гына белмим.

— Яраткан кеше яратам дими.

— Миңа ышан, Мәрьям, әйдә, иртәгә үк загска барыйк?

Мәрьям елмаеп куйды.

— Юу-ук! — диде бераздан, күз карашын бер читкә алып. — Квартир бармы? Юк! Минем институтка керәсем бармы? Бар!

Егет туктады. Тагын атлады:

— Квартир... уку... ә сөю кайда? Сөю булса шалашта да оҗмах дигәннәр түгелме соң? Әйт әле, Мәрьям, дөресен әйт, только! Синең сөйгән егетең бармы?

— Бар, — диде Мәрьям, Гайнигә туп-туры карап. — Бар, Гайни, бар!

Гайни әллә нишләп киткәндәй булды:

— Кем ул, кем, кайда?

— Армиядә, — диде кыз. — Без аның белән мәктәптә бергә укыдык. Ә Әкрамнан син юкка көнләшәсең, Әкрам миңа малай гына ич!

Гайнинең күңелендә ниндидер җиңеллек туды. Шулай да ул тынычланмады.

— Мин бәхетсез, Мәрьям. Гарьлек миңа, бик гарьлек! Кулымнан килсә, бөтен дөньяны әллә нишләтер идем.
Ярмөхәммәтов тагын нидер әйтмәкче иде, ләкин әйтмәде.
Мәрьям өйгә ашыкты:
— Хәерле төн, Гайни абый, иртәгәгә кадәр, яме? — диде һәм башка бер сүз дә әйтмичә, баракка таба китте. Гайни исә ачуыннан дер-дер калтырап:
— Аңлыйм, мин сиңа тиң түгел! — дип кычкырып калды.

## УНЫНЧЫ БҮЛЕК

### 1

Көн артыннан көн туа барды. Эш әле һаман Яктыкүл участогында иде. Вакыт көндезге унбер чамасы. Кечкенә тәнәфестә абзый эштән туктады да зур гына бер торбага утырды.
«Менә бит адәм баласы! — дип уйлады абзый, тирә-юньгә карап. — Менә бик кыска гына вакыт эчендә ничаклы эш эшләнде. Ә-әнә, күлнең аргы башында, нинди биек, нинди зур водокачка корылды! Ә-әнә күл өстенә ташылган, аннары бер-беренә ялганган торбалар. Алардан да арырак тышлары җылы киезләр белән уралган торбалар ничаклы! Ә алардан ундарак биек-биек баганалар. Тимер күперләр. Димәк, эшне тиздән җиңәбез!
Абзый кинәт сискәнеп куйды, аның артына һич көтмәгәндә тавышсыз-тынсыз гына прораб килеп баскан иде:
— Ник уйга чумдың, бригадир?
— Юк, болай гына, иптәш прораб. — Бригадир күл өстенә кулы белән күрсәтте. — Әнә ничаклы эш көтә. Әйеме, прораб?
Прораб та торба өстенә килеп утырды һәм киләчәктә башланырга тиеш эшләр турында сөйли башлады.
— Дөрес, бригадир. Менә безнең өлкә озакламыйча, Кыңгыр үзәне аша, Чүсәй елгасы белән кушылачак. Чүсәй — зур елга, бик үткер елга. Эх, бер егерме елга соңгарак калып туган булсаң, үзең әйтмешли, шайтан алгыры!
Болар шулай сөйләшеп утырган чакта, күл каршындагы йорттан Мәрьям йөгереп килде.
— Иптәшләр, тыңлагыз! — Мәрьям «Урал эшчесе» газетасыннан яңа бер хәбәр укый башлады. — Менә Хөкүмәт хәбәр итә, иптәшләр... «Икмәк һәм башка ашамлыкларга карточка системасын бетерергә! Әйберләрнең бәясен ундүрт процентган башлап утыз өч процентка киметергә! Моннан соң промышленность һәм авыл хуҗалыгы бирә торган барлык әйберләрне дә елдан-елга арзанайта барырга...»
Абзый урыныннан торды:
— Менә әйткән идем бит! — диде куанып. — Менә дөнья рәтләнә ич, җәмәгать, рәтләнә!
Прораб абзыйның кулын кысты:
— Котлыйм! Сугышта җиңү нәтиҗәсе бу.
Мәрьям укыган газета хәбәре эш мәйданына яшен тизлеге белән таралып китте, кешеләр җыелды, кай арададыр Гайни дә килеп җитте.
— Бригадир! — диде ул. — Карале, бригадир, аракы бәясе дә төшкәнме?
Тирә-яктагылар шаулатып көлеп җибәрделәр.
— Нигә авыз җырасыз? — диде Ярмөхәммәтов. — Әллә үзегез салмыйсызмы?
Мәрьям дәшмәде. Тәнәфес бетте, участок халкы янә эшкә ябышты.

## 2

Клуб. Эшчеләр җыелышы. Вакыт алтыга якынлашты. Ләкин җыелыш башланырга әле унбиш минут вакыт бар. Мәрьям гадәттәгечә буш рак рәткә кереп урнашты.

Шул вакыт Мәрьям янына абзый белән Әкрам килеп утырдылар. Сүзне абзый башлады:

— Ни хәлләр, Мәрьям?

— Яхшы, Зиннәтша абый! Иртәгә әнинең туган көне, Әкрам белән бергә безгә рәхим итегез!

— Менә шәп! — диде абзый. — Обязательно, шайтан алгыры.

Җыелышны трестның профком председателе ачты. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә иkән: «Халык судына утырышчылар сайлау».

Беренче сүзне, аңлатма рәвештә, халык судьясына бирделәр. Аннары эшчеләр халык утырышчысына кандидатлар күрсәтә башладылар. Көтмәгәндә кинәт абзый сүз алды:

— Иптәшләр! — диде ул. Абзыйның түшендә медальләр ялтырый иде. — Иптәшләр! Минем бригадада рабочий Кәлимуллин Әкрам бар. Грамотный егет! Стахановчы. Аракы эчми, тәмәке тартмый, хәтта кызлар белән дә йөрми пока. — Залда халык шаркылдап көлеп җибәрде, Әкрам кызарды. Абзый дәвам итте. Бер дә көлке түгел, иптәшләр. Менә инде минем тәкъдимемне тыңлагыз: халык утырышчысы итеп Кәлимуллин Әкрамны сайларга кирәк!

Зал тынды. Бераздан кемдер: «Дөрес», — диде. Ләкин җыелышны алып баручы иптәш абзыйның тәкъдимен куәтләмәде:

— Дөрес, Кәлимуллин тырыш егет, — диде ул йөткереп — Әмма ул әле кеше язмышын хәл кылу өчен яшьрәк шул, иптәшләр. Икенче төрле итеп әйткәндә: тормыш тәҗрибәсе юк әле аның. Менә сорасагыз судья да шулай дияр.

Абзый тынды. Әкрам да дәшмәде. Шулай да Әкрамга кыен, бик кыен булып китте: «Ник аны шундый уңайсыз хәлдә калдыралар? Ул инде эшче! Ана инде унсигез тулды! Нигә ул һаман малайлар рәтендә йөрергә тиеш?»

Сайлау тиз үтте. Әкрам, сайланучылар исемлеген куәтләп, үзе дә кул күтәрде. «Әйдә, шулай кирәктер», — дип уйлады ул. Абзый, Мәрьям һәм Әкрам җыелыштан бергә чыктылар.

— Син үпкәләмә, Әкрам, — диде абзый, юлда барганда... — Син әле чыннан да яшь. Нишләмәк кирәк? Тормыш тәҗрибәләре тиз генә килми. Мин үземне генә алам: менә былтыр кырык икене ваттым, ә тормышта тәҗрибә һаман да җитми әле, шайтан алгыры. Кырык ике кыска гомерме? Кыска! Ә шулай даниләрне генә сынарга туры килмәде. Син белмисең, конечно, әтинең аты булмады, читтә бурлак булып йөрде, значет. Әнием — батрачка, кешеләрдә йон эрли, тула баса, киндер тукый, оек бәйли. Мин ул чакта авыл баеның җирен сукалыйм. Батрак, значет. Әле дә истә, унҗиде тулгач мине фәкыйрьләр комитетына сайладылар. Кулаклардан икмәк җыеп, дәүләткә тапшырабыз. Но бирмиләр, собакылар, әллә кайларга яшерәләр! Шулай да берсеннән ачуны алдым. Ничек дисеңме? Просты гына, көз көне тоттым да салкын суга күпердән бәреп төшердем, собакыны. Аңа пычагым да булмады, конечно, но яңа туны белән салкын суда йөзде. Начар кеше иде ул, ләгънәт, ачлык елда кәҗә урлап эләккән бер фәкыйрь кешене тереләтә җиргә күмүдә катнашкан бәндә. Ул елларда шунысы начар: надан идек без, шайтан алгыры. Хәер, фәкыйрьгә нинди белем? Аякта җәен-кышын чабата. Ничего, Әкрам, синең әле бәхетең алда. Мәрьям! Синең бәхет тә алда. Мин дә бәхетле. һаман исемдә, үлемнән Украина егете коткарды мине...

— Зиннәтша абый! — диде Мәрьям, бригадирны култыклап алып.— Бу турыда сөйләшмик, яме? Сез кулаклар турында сөйләрсез бәлки?

Абзый берничә секунд тын гына барды. Аннары дәвам итте:

— Фашист — фашист инде ул. Заманында кулак та фашисттан бер дә ким түгел иде. Әле дә истә 1930 ел. Колхозлар төзелә башлаган чак, значет. Бер көнне күрәм, мәчет каршында урам тулы хатын-кыз чыр-чу килә. «Безгә, ят ирләр белән бергә, гомуми юрган асты кирәкми» — янәсе. Ул гынамы? Карыйм, хатыннар комсомол секретарена һөҗүм итәргә исәплиләр. «Үтерәбез!» — янәсе. Ачу йөрәккә сыймый. Мин комсомол секретарен яклыйм. Кулда колга. Безгә кем якынлаша, шуңа кизәнәм. Галәмәт икән ул хатын-кыз дигәнең котырса! Һәммәсенең диярлек күзләре тонган. Тик иртәгесен генә билгеле булды: кулаклар мәчеткә җыелып, намаз укыганда хатын-кызларны колхозга каршы котырткannar: «Активларны турагыз, сезгә суд булмый, сез хатын-кызлар», янәсе. Әйе, бар иде еллар...

### 3

Көн кичке якка авышты. Абзый белән Әкрам, әүвәл эш хакы алып, аннары кибеткә барып, тулай торакка кайтып керделәр. Икесе дә шат:

— Молодец, Әкрам, бу айдагы эш хакың 1240 сум!

Әкрам кибеттән үзенә өр-яңа пальто алган иде. Менә ул хәзер шул пальтоны өстенә киде һәм аны абзыйга күрсәтергә тотынды.

— Килешә! — диде абзый. — Бик әйбәт. Ял көннәрендә рәхәтләнеп киярсең.

Әкрам, яңа пальтоны тумбочкага куйды да, әнисенә хат язарга утырды .

«Хөрмәтле әни! Миннән сиңа күп һәм кайнар сәлам. Мин исән-сау, һаман Зиннәтша абый белән бер участокта эшлим. Эшләрем яхшы, кызыклы. Мин якын арада гына ташчылар курсына укырга кердем. Абый да укый. Ният — юллар төзергә!

Әни! Бүген безгә акча бирделәр. Үткән айдан калган акчам да бар иде әле. Менә өр-яңа пальто алдым. Язда, көздә генә киярлек. Тышы — постау. Сиңа бүген 1200 сум акча җибәрдем. Йорт салу ягын карарга кирәк, әни. Акча тагын салырмын. Әти турында берәр яңа хәбәр ишетелмиме? Аның шулай фронтта хәбәрсез югалуы дөрес микәнни? Югыйсә монда: «Әсирлектән кайтучылар бар икән», — дигән сүзләр ишетелгәли.

Хуш, сау бул, әни. Хатыңны көтәм. Авылдашларга, тирә-күршегә миннән сагынычлы сәлам. Бишенче апрель, 1948 ел».

Әкрам хатны почта әрҗәсенә чыгарып салды. Әрҗә исә тулай торакның ишеге алдында гына иде.

Коридорда аны Мәрьям очратып кунакка чакырды: «Абзый белән безгә керегез, әнием көтә. Белегез аны, кучтәнәч-мазар кирәкми».

Әкрам бүлмәгә йөгереп керде:

— Зиннәтша абый! Фатыйма апа көтә, әйдә!

— Әйдә, әйдә! — диде бригадир, кулына ниндидер төргәк алып. — Әйдә, үзебез сөйләшкәнчә, тапшыручы мин, чөнки мин синең абзаң!

— Ярый, абзый, ярый!

Әкрам шат иде. Алар, тиз-тиз генә җыенып, Фатыйма бүлмәсенә ашыктылар.

Бүген Фатыйманың туган көне. Шуңадыр ахры, аның бүлмәсе ал да гөл.

— Фатыйма! — диде абзый, бүлмәгә килеп кергәч тә. — Бүлмән бүген җәннәткә охшый, шайтан алгыры. Но эш анда түгел. Без сине, Әкрам белән бергә, туган көнең белән котлыйбыз! Озын гомер, бәхетле гомер телибез! Менә бездән кечкенә генә күчтәнәч сиңа.— Абзый кулындагы төргәкне Фатыймага бирде. — Менә, Фатыйма, өстеңдә тузарга насыйп булсын!

Фатыйма төргәкне ачты:

— Крепдешин, крепдешин! Ой, рәхмәт, ой, рәхмәт сезгә! —Фатыйма әүвәл Әкрамны, аннан абзыйны чуп итеп үбеп алды.

— Ә мине тагын бер тапкыр! — диде абзый, елмаеп. — Мин олырак ич.

Абзый бераз тын торды да, сорап куйды:

— Фатыйма, нигә Гайнине чакырмадың?

— Әй, Зиннәтша абый, — диде Фатыйма, бүләк ителгән крепдешинны бик пөхтәләп кенә караваттагы ак мендәр өстенә куеп. — Гайни каядыр киткән. Кичә исерек иде. Күңелем нидер сизә, куркам мин аннан, кереп тавыш чыгаруы бар.

Өстәл бай иде. Әкрам моңа бүлмәгә килеп кергәч үк игътибар бирде. Әнә әллә кайчаннан бирле бик сагындырган майлы каз ите, аның белән янәшә кылчыксыз балык һәм кабартмалар. Ә өстәлнең аргы башында зур шешә белән шәраб.

— Утырыгыз, кунаклар! — диде Фатыйма, өстәл каршына килеп. Әйдәгез, утырышыйк. Әйдә, Мәрьям!

Алар, бер семья кебек, өстәл тирәли тезелеп утырдылар. Ниһаять, мәҗлес башланды. Әүвәл Мәрьям үзенең әнисенә карата бик җылы сүзләр әйтте. Аннары Әкрам, аннары абзый.

Фатыйма гел кыстый иде.

— Ашагыз, әчегез, дуслар! Кичәгенә миңа премия бирделәр, рәхмәт игълан иттеләр. Әйбәт безнең кешеләр, әйдәгез аларның да исәнлегенә булсын!

Эчтеләр. Әкрам эчмәде. Фатыйма аны кыстамады.

— Әкрам! — диде Фатыйма, бераз башына киткәч. — Җырла әле, җаным, җырлачы, җырла! Әй матур да җырлыйсың бит син!

Әкрам оялудан кызарынып китте. Шулай да ялындырмады:

...Изге теләгеңне гүзәл маяк итеп,
Урал якларында эшлим, әнием!
Кайда гына булып, кайда барсам да мин,
Гел исемә төштең, әнием!

Фатыйма кинәт елап җибәрде:

— Рәхмәт, Әкрам, рәхмәт, җаным! Бала чагымны, мәрхүмә әниемне искә төшердең!

— Туктале, әни! — диде Мәрьям, урыныннан торып, — пластинканы үзгәртик әле. Мондый көнне нигә еларга? Дошман еласын!

Мәрьям урыныннан торды, комод алдына барды һәм тиз генә патефон көйләп җибәрде:

Нинди матур тирә-якта,
Бөдрә чыршы, ак каен.
Киң аланнар гөрләп тора
Без монда килгән саен...

Мәҗлес дәвам итте. Минут артыннан минутлар үтте. Бүлмәдә һава эсселәнде.

— Әкрам! — диде Мәрьям, маңгай тирләрен сөртеп. — Әйдә һавага чыгыйк! Бәлки шунда циркка да керербез? Бүген анда бик кызык программа.

Әкрам икс дә уйлап тормады:

— Әйдә! — диде.

Егет белән кыз, тиз-тиз генә киенеп, урамга чыгып киттеләр. «Яшьләр бит, яшьләр»,— дип уйлап калды Фатыйма. Аннан соң Зиннәтшага үзенең үткән төндә күргән төшен сөйли башлады:

— Кояшлы көн, җылы көн икән. Мин ниндидер койма башында эленеп торам. Коймадан төшәргә телим, ләкин койма бик биек. Кычкырам икән: «Рәхим, Рәхим!» Ничектер кинәт Рәхимем пәйда булды, янына килде. Килде дә мине, койма башыннан түгел, ниндидер котчыккыч тирән бер упкыннан күтәреп алды. Рәхим ул минем фронтта һәлак булган ирем. Әллә кайтырмы икән? Гел кайтыр кебек! Бу нинди төш икән, Зиннәтша абый, аны ничек юрарга?

— Белмим,— диде бригадир һәм стаканга коелган шәрабны голтголт итеп эчеп җибәрде.

Абзый инде шактый җылынган иде.

— Кайгырма, Фатыйма! — диде. — Син әле яшь хатын. Тырыш, чибәр. Сиңа әле бер дигән ир табылыр.

Фатыйма елмаеп куйды, ләкин ул шунда ук җитди төс алды:

— Юк инде, юк, Зиннәтша абый. Зур кыз үстергән, ә бүген кырык бер ягына киткән тол бер хатынның кемгә кирәге булыр?

— Миңа, — диде абзый һәм кинәт Фатыйманы кочаклап, үбәргә үк тотынды. Ләкин Фатыйма көтмәгәндә учы белән абзыйның битенә сукты.

— Сез мине кемгә саныйсыз, иптәш бригадир? — диде ул ачынып.

Абзыйның күз алдында ут чәчрәп киткәндәй булды:

— Кичер, Фатыйма! Шаярдым гына. Шәп хатын икәнсең, шайтан алгыры. Нишлим, яратам сине! Да, син минем шүрлеккә каты тондырдың бит, ә? Мин ялгыз кеше, Фатыйма, әйдә өйләнешик! Әйдә, хет бүген үк загска барыйк!

Фатыйма хавап бирмәде. Үткер карашын бер читкә борып, тик кенә утыра бирде. Абзый ялынырга тотынды:

— Без рәхәттә яшәрбез, Фатыйма. Ялгызлык бик туйдырды. Мин карт түгел әле. Авылга кайтмам. Квартира алырбыз. Радио сатып алырбыз. Башкорт көйләрен яратам мин. Бергәләшеп концертлар тыңларбыз. Теләсәң, Казанга барып килербез. Яки авылга кайтып урнашырбыз.

## УНБЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Менә инде икенче атна кышны куып яз килә, җир елый, урамнарда кар эри, елгалар ага. Әнә Яктыкүлдә дә нәкъ шундый ук күренеш: кар китә, бозлар кузгалырга чамалый. Ә мондый чакта яшь күңелдә нинди генә хисләр кабынмый!?

— Эх, җылы яз! — дип уйланды Әкрам, Яктыкүл өстенә кереп. Яктыкүл исә, кышкы карлардан гына түгел, инде калын боздан да котыла башлаган иде. Ләкин әле күл өстендә, кая гына карама, юанюан торбалар ята. Торбалар, торбалар... Бер-беренә бик нык ялганган килеш, күлнең уртасын бизәгән иде алар. Кайсы ямь-яшел, кайсы чем-кара. Аларны Әкрам да буяшты. Ул менә хәзер дә шул эш белән мәшгуль иде, ләкин аны көтмәгәндә абзый чакырды:

— Әкрам, әйдә собраниегә!

Вакыт көндезге өч чамасы. Абзый участок идарәсенә ашыга икән. Әкрам да аңа иярде. Бераздан алар прорабны куып җиттеләр.

— Мин сезне аңлыйм, иптәш прораб,—диде бригадир, аңа карап.— Бик яхшы аңлыйм. Әйе, кешеләр өчен яхшы юллар төзү изге эш. Мин Германия юлларын күргән, сынаган кеше, Александр Петрович. Сүз дә юк, юллары шома, каһәрләрнең. Әйтерсең көзге! Но, немецларның юллары кыска. Ә безнең Россияне аркылыдан буйга үтеп карагыз әле! Очы да, кырые да юк аның. Менә моннан Казангача гына да сигез йөз километр!

Алар күл буендагы юллар участогының зур гына бинасына килеп керделәр. Бина авыл клубы сымак. Эшчеләр инде анда җыелып киләләр. Прораб сәхнәгә үтте.

— Александр Петрович зур начальник булачак, — диде бригадир, Әкрам белән бергә алгы сафка кереп утыргач. — Әнә сәхнәгә кара!

Сәхнәдә өстәл, өстәл каршында трест башлыклары утыра иде. Александр Петрович та шунда килеп урнашты. Җыелышны моңа чаклы трестта күренмәгән яңа бер кеше ачты.

— Иптәшләр! — диде ул, ягымлы тавыш белән. — Мин монда Мәскәүдән җибәрелгән вәкил. Иптәшләр! Мин сезгә кайсыбер идарәләрне яңадан оештыру мәсьәләләре буенча килдем. Ишеткәнсездер, хөкүмәтнең бик мөһим карары бар, менә шушы айда без «Уралкоммунстрой»ның махсус трестын икегә бүлеп, яңа идарә — юллар төзү идарәсе оештырырга тиеш. Әйбәт карар бу: артта калган эшләрне алга җибәрүдә ярдәм итәчәк. Эшчеләр дөрес аңласыннар, монда эшсез калучы булмас! Янә бер сүз: сезнең прораб иптәш Шадрин Александр Петровичны без юллар төзү идарәсенең башлыгы итеп билгеләдек. Кем аңа эшкә күчәргә тели, рәхим итегез! Ләкин эштән куркучылар аңа кирәкми.

Вәкил сүзен бетергәч, абзый урыныннан торды:

— Сез әйбәт хәбәр алып килгәнсез, иптәш начальник, эш бездән тормас, әмма трестлар бүлешкәндә квартирлар мәсьәләсе ничегрәк хәл ителер соң?

Мәскәү вәкиленең җавабы әзер икән:

— Без уйлаштык, иптәш. Быел шәһәр советы сезгә сиксән квартира бирәчәк. Квартиралар икегә бүленәчәк: яртысы иске трестка, яртысы яңа трестка. Аңладыгызмы, иптәшләр?

— Аңладык,— диде абзый һәм урынына утырды.

Залдан сәхнәгә менеп сөйләүчеләр дә булды... Шулай да җыелыш озакка сузылмады.

## 2

Кичә кояш кыздырган иде, ә бүген көз көннәрендәгедәй, салкын яңгыр ява башлады. Бу көннәрдә Әкрам белән абзый зур йөк машинасында Әбиләр тавы ягыннан шәһәр урамнарына вак таш ташыйлар иде. Алар һәм шофер, автомашина зур булганлыктан, өчесе дә бер кабинага утырганнар. Автомашина озакламыйча шәһәргә килеп керде, уңга борылды һәм олы урамнар буйлап, турыдан-туры алга ыргылды.

Ярмөхәммәтов Гайни, нәкъ шундый ук эштә, нәкъ шундый ук автомашинага утырып, өч-дүрт километр чамасы арткарак калып килә иде. Ни сәбәптәндер, Гайни утырган автомашинаның каршына милиционер чыгып басты, кулын күтәрде. Машина туктады, ишек ачылды.

— Яңгыр! Ашыгам,— диде милиционер һәм кабинага менеп утырды. Машина кузгалып китте. Гайни инде милиционер белән янәшә иде.

— Нигә син безне туктаттың, милтун?! — диде Гайни, тешләрен

кысып. — Кем син? Хөкүмәт башлыгымы? Нигә син безне эштән аерасың? Кем бирде сиңа мондый хокукны, кем бирде, кем?

Гайни исерек иде. Милиционер моны шундук аңлады һәм шелтә белән шоферга карады:

— Таш төягән арада эчкәндер, каһәр! — диде шофер. — Андагы киоскаларда кайчакта аракы була.

— Ах, милтун! Менә нәрсә эшли бит, милтун!? Нигә син безнең эш планын бозасың? Кем җилкәсендә утырасың син? Әйт, кем җилкәсендә? Һәр көнне күпме взятка аласың син?

Милиционер түземлеген югалтты, күрәсең:

— Җитәр! — дип кычкырды. — Тизрәк кайт та йокла! Югыйсә мин сине кулга алырга мәҗбүр булам, исерек баш!

Гайни бөтенләй чыгырыннан чыкты:

— Кем сыйлады мине? Синме?! — дип кычкырды һәм кесәсеннән буш шешә алып, милиционер башына сукмакчы булды, ләкин шофер аның кулыннан тотып калды һәм тиз генә машинаны туктатты.

Милиционер шундук шоферга боерык бирде:

— Әйдә, иптәш, бүлеккә алып бар безне!

Автомашина янә кузгалып китте.

Шулай итеп Гайнине кулга алдылар. Иртәгесен айныгач, милициядә сорау алганда ул: «Исерек идем, — дип җавап бирде. — Мин берни дә хәтерләмим».

Ике көннән соң аны больницага урнаштырдылар. «Юк, мин тиз генә югалмыйм әле», — дип уйлады Гайни, эченнән генә хәтәр хәйләләр корды. Ул акылдан язганга сабышты:

— Мин Суворов!

— Мин Кутузов!

— Мин Петр Великий!

— Нигә сез мине монда тотасыз?

Ләкин белгечләрне алдарга мөмкинмени? Ниһаять, бер көнне врачлар менә нинди нәтиҗәгә килделәр: «Ярмөхәммәтов Гайни һичшиксез сау-сәламәт кеше. Ул үзе кылган һәр эш өчен җавап бирергә тиеш!»

Шулай итеп, больницада эш бетте, аны яңадан милиция ихтыярына кайтардылар.

Җирне инде яз кояшы кыздыра иде. Әйбәт кеше кешедән качмас, бер көнне иртүк Зиннәтша абзый, ничектер сорашып белеп, прокурор кабинетына килеп керде:

— Иптәш прокурор! — диде ул. — Мин юлчылар идарәсеннән мастер Кәлимуллин Зиннәтша булам. Фронтовик. Карт солдат дип атыйлар мине. Безнең эшче Ярмөхәммәтов Гайни менә инде айга якын милициядә утыра, ә безгә никтер очрашу мөмкинлеге бирмәделәр. Мин дөрес әйтәм, иптәш прокурор, Ярмөхәммәтов гаепле егет: эчә, милиция работнигына шешә белән сукмакчы булган. Гаепле, конечно. Но бездә дә гаеп зур, иптәш прокурор. Менә мин дә гаепле монда, шайтан алгыры. Нигә мин аның әйтик, без юлга таш китергән чакта аракы эчеп йөргәнен күрмичә калдым? «Бер эшче — һәммә эшчеләр өчен, һәммә эшче — бер эшче өчен җавапта булырга тиеш,» — дип дөрес сөйлиләр. Менә безнең эшчеләр шуны онытмаска тырышып, эшче Гайнине порукага сорыйлар. — Абзый прокурор өстәленә ниндидер зур гына кәгазь чыгарып куйды. — Менә безнең трестта үткәрелгән собрание карары. Әгәр фронтта булса, мондый эшләр белән баш ватмас идек, конечно.

Прокурор Зиннәтша абзый биргән кәгазьне зур игътибар белән укыды. Аннары:

— Мин бу эш белән таныш, — диде, — Ярмөхәммәтов әлек тә

төрмәдә булган. Менә тагын яңа җинаять! Нишләргә? Аптыраш! Дөрес, ул амнистия белән чыккан...

Абзый каушый-каушый сөйли башлады:

— Аңлыйбыз, иптәш прокурор. Безгә дә җиңел түгел. Но халык Гайнидән көчлерәк! Бездә төзәлмәс кеше юк диләр. Төзәтәбез без аны. Обязательно! Кызганыч бит, әнисез үскән малай. Әтисенең дә рәте булмаган. Үги ана. Амнистия.

Прокурор уйга калды:

— Да-а,—диде. Аннары ул милиция начальнигына шалтыратты:

— Ярмөхәммәтов эше турында фикерегез ничек?

Телефонның аргы башыннан озак итеп әйтелгән ниндидер җавап яңгырады.

— Ярый!—диде прокурор, телефон трубкасын өстәлгә куеп.—Ярый, Ярмөхәммәтовны азат итәбез, ләкин актыккы тапкыр.



## УНИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Җир кипте. Тирә-юньдә йомшак җил исә. Елның апрель урталары. Кая гына карама, ямь-яшел чирәм. Ташчылар һәм асфальт җәючеләр бүген завод юлларын төзәтәләр. Завод исә, үзенең зур-зур цехлары белән, километрларга сузылып киткән. Абзый инде монда юлчыларның олы мастеры. Әкрам да үсә: ул хәзер асфальт һәм таш эшләре мастеры. Ләкин абзый аны әлегә һәр көн шелтәли: «Мастермы син, әллә рядовой рабочиймы? Нигә карама, кулыңда көрәк, маңгаеңда тир! Нигә син ташчылар өчен үзең эшлисең? Алар тәмәке тарта, ә син гел эштә. Бер караганда бик молодец, конечно. Но син бит мастер, син кешеләрне өйрәт! Аларны эшкә оештыр! Синең кулыңда утыз кеше бит!» Әкрам мондый чакларда абзый каршында акланырга тырыша: «Мин, абзый, тик торырга өйрәнмәгән шул».

Ташчылар кыска ялга туктаганнар иде. Әкрам заводның кайсыбер цехлары белән кызыксына башлады. Иң дәһшәтле цех—корыч коючылар цехы, күрәсең. Тимер баскычлардан чуен күпергә менгәч мартен мичләре. Меңләгән тонна кара тимерне эретә икән бу мичләр. Битләрен уттан каплаган кешеләр эшлиләр икән монда... Күршедәге урам кебек зур бинада механик цехы. Монысы үзе генә дә аерым бер зур завод сымак. Әнә анда ничаклы станоклар авазы чыңлый. Әнә каршы якта янә бер цех. Анда тимер баганадай зур чүкеч, җирне тетрәтеп, әле генә уттан чыгарылган кып-кызыл тимергә суга. Суга да тимерне изә. Әкрам тукталып-тукталып карап торды: «Ай... яй! Менә ул кайларда эшли икән эшчеләр сыйныфы! Менә нинди заводлар була икән дөньяда! Ә нинди батыр, нинди зур һөнәрле кешеләр эшлиләр икән монда? Ай-яй!»

Әкрам, цехлардан чыгып, эш участогына килде, абзыйны очратты:

— Зиннәтша абый! Мин заводка күчәм. Корыч эретүчеләр цехына!

Абзый аптырап калды:

— Нигә күчәсең?

— Корыч ясаучы буласым килә.

— Алмаслар сине.

— Ник?

— Корыч эретүче түгел син. Моңа тәҗрибә кирәк! ФЗУ га керергә иде сиңа, но армия хезмәтең бар...

Әкрам башка дәшмәде. Мәрьям дә монда иде. Ул кайчакта шаярырга, ә кайчакта моңланырга ярата. Менә хәзер дә, никтер Әкрамга карап, акрын гына җырлап җибәрде:

Ой, рябина, рябинушка,
Белые цветы,
Ой, рябина, рябинушка,
Что взгрустнулась ты?

Абзый нindидер уйга калды, ә Гайни Мәрьямгә ялынырга тотынды:
— Җырла, Мәрьям, җырла әле, зинһар туктама!
— Хәзергә җитәр!—диде абзый.—Җыр төпсез диңгез түгел, шайтан алгыры. Әйдәгез, эшкә тотыныйк!
Эш дәвам итте. Эшчеләрнең кайсы таш вата, кайсы ком ташый, ә кайберләре, төркемнәргә бүленеп, асфальт җәяләр.
Көндезге аштан соң юллар төзү башлыгы Александр Петрович килде. Абзыйны ул таш җәючеләр арасында очратты һәм аны бер читкәрәк чакырып алды.
— Я, эшләр барамы, Зиннәт Кәлимуллович?
— Бара, Александр Петрович, ә кумасаң юк. Менә комны соңгарак калып китерделәр, шайтан алгыры.
—Ә тагын?
— Тагынмы? Вот нәрсә, Александр Петрович: мин гомергә монда калырга уйлыйм, тик менә квартир мәсьәләсе... Ә миңа бит өйләнергә дә вакыт, Александр Петрович!
Башлык рәхәтләнеп көлеп җибәрде:
— Молодец, Кәлимуллович! Ә квартирны тиздән хәл итәрбез, ахры. Безнең трестка кырык квартир бирәчәкләр. Берәр, икешәр бүлмәлеләре дә бар. Син канәгатьме?
— Рәхмәт, Александр Петрович!—диде абзый шатланып.—Рәхмәт, Петрович, рәхмәт!
Эштән соң абзый, Әкрам һәм Мәрьям, трамвайга утырып, баракка кайтырга чыктылар. Аларга Гайни дә иярде. Ул Мәрьям белән янәшә генә. Шәһәрдә эш сәгате беткән вакыт булганга трамвай шыгрым тулы халык! Вагонда кинәт бер урын бушады һәм Мәрьям шул урынга утырыйм дигәндә анда яшь кенә бер ир утырып өлгерде.
— Тор!—дип кычкырды аңа Гайни.—Тор, хатын-кызга урын бир, оятсыз!
Ир ашыкмады, утыра бирде.
— Тор!—диде Гайни.—Тормасаң авызыңа тондырам бит!
Ир торды.
— Синең авыз да минем белән янәшә генә,—диде ул.
Абзый сагайды, Гайнигә үгет-нәсихәт бирә башлады:
— Нигә син болай тупасланасың, Гайнулла энем? Нигә кешеләр белән талашырга гына торасың? Нигә син минем киңәшне онытасың?
Гайни дәшмәде, тын гына барды...

## 2

Барак. Бүген ял көне, ә иртәгә—бәйрәм. Әйе, күңелле бәйрәм, Беренче Май бәйрәме! Вакыт иртәнге ун чамасы. Барак халкы кайсы кая таралышып беткән. Абзый да юк. Әкрам исә әле генә хат алды һәм аны, тиз генә ачып, ашыгып-ашыгып укый башлады:
«Әкрам улым! Бик-бик сагынып, бик күп сәламнар сиңа. Булган рәхмәтләрем йөрәккәемә сыймый, син җибәргән чәчәкле ситсыдан бик матур күлмәк тектердем. Рәхмәт, рәхмәт, зур бәхет телим сиңа! Үткән хатымда әйткән идем инде, өйне өлгерттем. Инде мич кенә чыгарасы

калды. Колхозга да зур рәхмәт! Урманнан агач ташуда, бура бураудa колхоз ярдәм итте. Әй хәзер яңа өйне әтиең күрсә, ничек кенә шатланмас иде, улым! Әмма нишләмәк кирәк. Язмыштан узмыш юк. Улым! Син инде тизрәк авылга кайт. Яңа өйнең рәхәтен күрергә насыйп булсын. Әкрам! Сиңа авылдашлардан, тирә-күршедән сәлам, аларның һәммәсе дә сиңа рәхмәт әйтәләр. Бу арада үлем-китем юк.

Хуш, сау бул, улым, тизрәк кайтуларыңны көтәм. Әниең».

Әкрам шундук, өстәлдән дәфтәр алып, әнисенә җавап яза башлады:

«Әнием! Хатыңны алдым, рәхмәт! Өйнең өлгерүенә мин бик шат. Мичне инде көзгә өлгертсәк тә бик әйбәт булыр. Минем тормышта үзгәрешләр юк. Заводка күчмәкче идем, ә Зиннәтша абый ашыкма диде. Мин һаман юллар мастеры. Көзгә укырга керәсе иде, ләкин... Армиягә барасы бар бит әле. Әни! Әти турында тәки яңа хәбәр килмәде бит, ә? Мин аны бәлки әсирлектә булгандыр дип уйлаган идем. Әни, монда озакламыйча сабан туе булачак. Мин дә сабан туена барам.

Ярый, әни, исән-сау бул, хатыңны ешрак җибәр!

Сагыну сәламе белән: улың Әкрам».

Тулай торакның тәрәзәсе каршында ак сирень чәчәккә бөреләнгән иде. Әкрам шуңа карады, тумбочка тартмасын ачты, аннан кичәгенәк үзе чыгарган бер шигырьне алып, акрын гына җырлый башлады:

Исеңдәдер, әни, язлар килеп,
Гөрләвекләр тулып актылар.
Хуш исләрен сибеп киң алангa,
Ак сиреньнәр чәчәк аттылар.

Карап калам гүзәл аккошларның
Безнең якка үтеп киткәнен.
Белсәң иде минем йөрәгемнең
Сезне сагынып ничек типкәнен?!

Кайтам инде, кайтам туган якка,
Шомыртыбыз чәчәк аткандыр?
Тын Зөяннең ярларын тутырып
Язгы сулар инде аккандыр.

Әкрам җырлап туйгач күрше бүлмәгә чыгып китте. Аңа Мәрьямне яки Фатыйманы күрергә кирәк иде. Кем белә, бәлки алар киногa барырлар...

## 3

Бүген бәйрәм! Әйтерсең табигать аны ай буена сагалап торган: күк йөзендә ник бер генә болыт күренсен! Каршы якта Җиңү мәйданы. Абзый белән Әкрам стахановчылар ич, алар өчен мәйданга ике билет бирелгән. Көтелмәгән мондый шатлыктан абзыйның да, Әкрамның да йөрәкләре леп-леп итәләр: «Хәрби парад ич, аннары демонстрация!»

Ниһаять, хәрби парад башланды. Әнә Җиңү мәйданын хәрби сафлар биләгән. Взводлар, роталар, батальоннар. Әнә карап туймаслык матур атка атланган маршал күренде.

Маршал, бөтен мәйданның игътибарын үзенә алып, парад кабул итә башлады:

— Исәнмесез, иптәшләр!

— Исәнлек телибез, иптәш маршал!

— Сезне Беренче Май бәйрәме белән тәбриклим!

— Урра... Урра... Урраа-аа...

Зур мәйдан хәрбиләр тавышы белән тула.

Маршал, парадны кабул иткәч, ат өстендә уңга борылды һәм тиз генә мәйдан кырыена омтылды, әмма ярсу ат, канатланып очып китәрдәй булып, кинәт аягүрә басты. Ләкин маршал, яшен тизлеге белән, аттан җиргә сикерде һәм күз ачып йомган арада трибунага менеп, кайнар речь сөйли башлады.

— Вот молодец!—диде абзый, Әкрамның кабыргасына төртеп.— Вот командарм!

Әкрам кинәт абзыйның беләген кысты:

— Абый! Мин дә тизрәк армия сафына китәм. Китәм, танкист булам.

Гадәттәгечә, хәрби парад бетүгә, демонстрация башланды. «Бәйрәм нинди дер дулкынга охшый»,—дип уйланды Әкрам һәм бөтен дикъкатен халык дулкынына текәде. Халык җырлый, халык «ура» кычкыра иде.

— Яшәсен Бөек Октябрь!

— Яшәсен Беренче Май бәйрәме!

— Яшәсен данлы Уралның данлы хезмәтияләре!

— Яшәсен илебезнең хәрби көчләре!

— Яшәсен, яшәсен...

Бәйрәм демонстрациясе көндезге өчкәчә барды. Әкрам шат иде. Мондый чакта хисләр кайларга гына очмый?! Әкрам, парадтан соң баракка кайтып килгәндә, бүген парадны кабул иткән маршал турында уйланып барды. «Менә нинди икән ул командарм? Ләкин мин танкист булам».

— Әкрам!—диде абзый, егетнең уйларын өзеп—Никтер бик тын киләсең? Әйдә тизрәк баракка! Мәрьям белән Фатыйма апаң пилмән әзерлибез,—дигәннәр иде.

Әкрам кинәт абзыйдан алда йөгереп китәрдәй булды, ләкин хатынкызларга бәйрәм бүләге аласы бар иде әле.

## 4

Иртәгесен Әкрамны Гайни уятты:

— Әйдә, Әкрам, вакыт!

Әкрам тиз торды, тиз юынды, тиз киенде һәм Гайни белән бергә ашханәгә чыгып йөгерде. Гайнинең бер көн күрешми торып та сүзләре күбәйгән икән:

— Әкрам! Парадта булгансың икән?

— Булдым.

— Ну, ничек үтте?

— Бик әйбәт, бик!

— Мәрьям дә анда идеме?

— Белмим.

— Ничек инде белмисең. Әллә бергә булмадыгызмы?

— Юк.

— Мин дә булмадым. Бик күп салынган, абзый әйтмешли, шайтан алгыры. Но ничего! Безнең урамга да кояш чыгар әле бер көнне. Йөрәк авырта только: чәнчи! Әллә врачка барырга инде?

— Барырга кирәк, Гайни, һәм эчүеңнән туктарга кирәк сиңа. Иптәшләреңнән оял, алар бит сине порукага алып калдылар.

— Акыл өйрәтәсең, э. Өйрәт, син начальник кеше бит. Мастер, стахановчы, ә мин рядовой ташчы гына.

— Гайни!—диде Әкрам, чыраен сытып.—Саруыңны юкка кайнатма!

Гайни тынды. Алар ашханәгә кереп киттеләр.

Төн җилле һәм яңгырлы булды. Ә бүген һава сулап туймаслык. Өстә-

венә иртүк кояш елмая. Юлларны төзү һәм аларны төзәтү эшләре дә гел үзгәрә барды. Завод юлларындагы эшләрне тәмамлагач, абзыйга Покров, Әкрамга Спартак урамын рәтләүне тапшырдылар. «Ярый, яшь малай кулында эшләп карыйк», — диде Ярмөхәммәтов, юл төзүдә катнашучы кешеләр турында уйланып.

Әйе, бер караганда хәйран калырлык: кемнәр генә юк иде монда!? Әнә төзүчеләрнең кем булулары аларның төс-битләреннән һәм киемсалымнарыннан ук күренеп тора. Әнә рус, башкорт, чуваш, удмурт кызлары. Әнә татар, казакъ һәм украина ирләре.

Гайни теләр-теләмәс кенә эшкә кереште. Нишләсен? Курсларда алган кәсебе: юлга таш тезә, ком җәя иде ул бүген.

Өйлә алдыннан күкне кара болыт каплады. Гайни эштән туктады һәм Әкрам янына килде.

— Мастер, ә, мастер!

— Кем тия?

— Мин берәүгә дә тидермәм, мастер. Тик менә яңгыр башланыр, ахры?

— Эремәбез.

— Һе, стахановчы эримени? Эресәң дә әллә ни булмас, дошман шатланыр, дуслар көенер. Дөресме, Әкрам?

— Дөрестер.

— Әкрам! Дөресен генә әйт әле, Мәрьямне чынлап яратасыңмы?

— Белмим. Уйланганым юк.

— Нигә син аның белән киноларга йөрисең, яратмагач?

— Дусларча.

— Ә мин көнләшәм. Каты көнләшәм! Онытма, минем янә бер исемем бар: Гайка.

Әкрам бәхәсләшмәде:

— Эшлә!—диде һәм асфальтчылар янына китте. Гайни тәмәке кабызды һәм үзе белән янәшә эшләүче Оренбург егете белән сөйләшергә тотынды.

— Ишеттеңме, татарларның сабан туе була ди?

— Ишеттем.

— Рәхәтләнеп саласы бар, значит.

— Мин салмыйм. Әйдә эшлә! Сдельщинага эшлибез ич.

— Никтер йөрәк авырта, малай. Врачта булдым, аракыны ташла, ди. Ә миңа нәрсә? Миңа барыбер. Морадыма ирешсәм шул җитә миңа.

— Нинди морадка?

— Әйтмим хәзергә.

Гайни эшкә тотынды һәм дәвам итте:

— Син белмисеңдер, малай, безгә башлык Шадринның сөйләгәне бар, бик кызык вакыйгалар булып үткән икән мондагы урамнарда. Революциягә чаклы, конечно. Шунысы кызык, усаллар җыйнган. Көчлеләр дә, конечно. Сөйлим, тыңла! «Сугыш — стена» дип аталган үзара сугыш турында сөйлим.

Берәр бәйрәм җиттеме, бер урамның яшьләре икенче урам яшьләренә каршы «стена» булып тезелә торган булганнар. Тезелгәннәр дә ике арада аяусыз сугыш, аяусыз кыйнаш башлаганнар. Һич ялганламыйм, үлүчеләр дә, гарипләнүчеләр дә күп булган бу сугышларда. Вот нинди рәхәт заман булган, ә? Никакой суд!

Оренбург егетенең юньләп тыңламавын күргәч, Ярмөхәммәтов тынды, эшкә кереште. Тирә-юньдә таш һәм чүкеч тавышлары яңгырый башлады.

## УНӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Шулай итеп, янә бер атна үтте. Шул арада шәһәр урамнарындагы афишаларда менә нинди хәбәр таралды:

«Шәһәребезнең хөрмәтле хезмәт халкы! Киләсе ял көнне татар халкының язгы бәйрәме, хезмәт бәйрәме—сабан туй үткәреләчәк. Сабан туе ял һәм культура паркында башланачак. Тамашачылар игътибарына:

— Милли көрәш.
— Күз бәйләп, чүлмәк вату.
— Йөгерү һәм капчык киеп чабу.
— Багана башына менү.
— Көч сынау.
— Сикерү һәм башка бик күп ярышлар.

Җиңүчеләргә бүләк: патефон, аккордеон, велосипед, кул сәгате, мотоцикл һәм башка кыйммәтле әйберләр.

Ял итегез, күңел ачыгыз, сабан туена килегез, дуслар!»

Шундый ук белдерү моннан бер атна элек газетада да басылып чыкты. Аннары ул берничә тапкыр радиодан да тапшырылды. Мондый эшләргә шәһәр советы депутаты, юллар төзү трестының башлыгы Александр Петровичның да катнашы булган. Бер көнне ул абзыйны чакырып алып:

— Иптәш Кәлимуллин! Без сине сабан туе комиссиясенә билгеләдек. Ярыймы, туган?—диде.

— Ярый,—диде абзый.—Мин дә бер начальник булып карыйм әле, шайтан алгыры.

...Шәһәр паркы. Монда сабан туе башлана. Тирә-юньдә ямь-яшел урман. Ямь-яшел аллеялар, яшел сукмаклар. Каршы якта—киң болын. Сагындырган бәйрәм ич! Абзый белән Әкрам монда беренчеләрдән булып килделәр һәм шундук мәйдан каршындагы утыргычларга урнаштылар.

— Тәртип булырга тиеш! — диде абзый, беләгендә кызыл тасма булганга горурланып.—Әнә ничаклы халык килә!—Абзый аллея буйларына карады.—Әнә ничаклы буфетлар әзерләнгән! Әйбәт, бик әйбәт. Монда бүген Казан, Уфа, Оренбург, Төмән, Чиләбе көрәшчеләре катнашачак. Урал шәһәрләреннән җыелган кунакларның исәбе-хисабы юк. Азмыни бу якларда туган-тумача?

Абзыйга Әкрам нидер әйтмәкче иде, ләкин паркта әүвәл ниндидер танго, аннары кинәт Салих Сәйдәшевнең Кызыл Армия маршы яңгырый башлады.

— Эх!—дип кычкырды абзый һәм бу көйне тын алмыйча тыңлады.

— Вот, Әкрам!—диде аннары.—Бу көйне ишетү белән йөрәкләр әллә нишли, яңадан армиягә барасы килә, шайтан алгыры.

Бакчада халык артканнан-арта барды. Ниһаять, сабан туенда йөгерешләр башлану турында игълан ителде.

— Мин дә, мин дә катнашам!—диде Әкрам, урыныннан сикереп торып.—Киемне караштыргала, абый!

Әкрамның өс-башы әйбәт иде. Өстендә—койган кебек чем-кара чалбар, изүе ачык күгелҗем күлмәк, аягында өр-яңа туфлиләр. Әкрам боларны, күз ачып йомган арада салып, абзый алдына куйды һәм тиз генә йөгерүгә катнашучылар сафына барып басты.

— Мин юл мастеры Кәлимуллин Әкрам, языгыз, мин дә катнашам!—диде.

Кешеләр, Әкрамны күргәч, пырхылдап көлеп җибәрделәр: Әкрам ап-ак штан балагын сызганып килгән иде. Озакламыйча старт башланды. Әкрам, сигнал булгач та, киң болын һәм урман юллары буйлап йөгерә башлады.

«Ара — дүрт километр. Йөгерүчеләр унике кеше. Күбесе яшьләр. Хәтәр, — дип уйланды Әкрам, — ярышчылар арасында спортсменнар да бардыр, ахры».

Әкрам, яшүсмер чагындагы кебек, кулларын йодрыклап, җан-фәрманга йөгерде.

Тик бераздан аңлап алды—ярышучылар арасында иң тиз йөгерүчесе кыска буйлы, зәңгәр майкалы егет икән. Карап торырга Әкрамнан аз гына олырактыр, ахры, ләкин әйтерсең лачын, әйтерсең аның аяк табаны җиргә дә тими, әйтерсең оча!

Әкрам янә бөтен көчен җыеп йөгерергә тотынды. Ул үзенең авыл малайлары белән ярышуларын һәм алардан һәр вакытта да узып килгән чакларын хәтерләде, ә бер вакытны хәтта сабан туенда бүләк алуын искә төшерде.

Мондый чакта юл буйлары буш булмый. Әкрам шатланды. Аңа тамашачылар да дәрт бирәләр иде:

— Ак ыштан, бирешмә!

— Уз, куып уз, егет!

— Җиңәсең, егет!

Ниһаять, Әкрам җиңеп чыкты. Аңа кул сәгате бүләк иттеләр.

— Молодец, энем!—диде абзый, Әкрамны кочып.—Сабан туендагы йөгерешләрдә этиең дә беренчелекне ала иде. Кара син, кан канга тарта икән, ә?

Тагын берничә минуттан соң көрәш башланды.

— Карыйк!—диде абзый, күз карашын көрәшчеләргә текәп.—Кызык, кем кемне егар? Кем батырга калыр? Зур бүләк кемгә? Монда Казаннан килгән атаклы көрәшчеләр бар икән. Уфа башкорты да шәп көрәшә, диләр. Тик менә безнең кызлар кайда йөриләр икән, шайтан алгыры.

Әкрам елмаеп куйды:

— Без соңарак барабыз дигән иде Фатыйма апа. Ихтимал бакчада йөриләрдер.

## 2

Бу вакытта Фатыйма белән Мәрьям, чыннан да, бакчада иде. Сокланмыйча үтәрлек түгел, икесе дә парлап киенгән. Әнә икесенең дә өсләрендә ак ефәк күлмәк. Башларында—зәңгәр косынка. Аларны бакчага чыгып китәр алдыннан гына Гайни очратты. Алар сабан туена бергә килделәр. Килделәр дә аллеяларга кереп киттеләр. Мәрьямгә кызык иде: кая гына карама — халык! Кемнәр генә, нинди генә кешеләр юк монда?!

Фатыймага да күңелле иде.

— Менә сабан туй!—диде ул,—менә ял көне! Әнә яшьләр генә түгел, картлар да җыелган бүген.

Гайни дәшми барды. Әмма бакчадагы киосклар каршына җиткәч, ул да сүзгә кушылды:

— Һава саф монда, ә юлларда нинди күңелле! Ә халык нинди матур киенгән!

Фатыйма Гайнинең өс-башына күз салды: «Ярый, бик начар түгел, кып-кызыл күлмәк, ялтыравыклы туфли».

Алар озак йөрделәр, болын буйларыннан үттеләр, күз бәйләп, чүлмәк ватучыларга карап тордылар, аннары тагын аллея ышыгына кереп киттеләр.

Ниһаять, Гайнинең түзәр хәле калмады, ул Мәрьямне һәм Фатыймаңы буфетка кыстый башлады:

— Бер генә кружка сыра яки ситро эчәбез! Әйдәгез, бик тәмле конфет алам.

— Ярый, әйдә, алайса,—диде Фатыйма һәм алар киоскка якынлаштылар.

Нәкъ шул вакыт чирәмле юл буенда Фатыйманың ниндидер танышлары очрады.

— Әйдә, Фатыйма, безнең белән бергә кунак булыгыз! Әйдәгез, табынга рәхим итегез!

Алар яшел чирәм өстендә табын әзерләп, самавар куеп, ширбәт белән сыйланып, җырлашып утыралар икән. Җыр дәвам итте:

Кайдан килдегез сез безгә?
Батмаенча дингезгә.
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итик сезгә?

Болар табынга урнаштылар. Табигый хәл, Фатыйманың да сумкасы буш түгел иде.

— Сыйланыгыз!—диде ул, табынга бутербродлар чыгарып.

Олы гына бер хатын гармун уйный башлады.

Мәҗлес дәвам итте. Гармун бию көенә күчте. Ләкин бу мәҗлес Мәрьямгә бик үк күңелле түгел иде. Ул урыныннан торды да каршы яктагы урманлы тау буйларына карап тора башлады.

— Мәрьям!—диде Гайни елмаеп.—Бер урында гына утыру туйдырдымы әллә? Әйдә болын буйларын яки Якты елга ярларын күреп килик. Чынлап әйтәм, Якты елганы күрсәң, исләрең китәр!

— Әйдә! — диде Мәрьям, кинәт шатланып. — Якты елгада минем дә булганым бар. Әйдә, ерак түгел ул.

Алар, тиз генә урман юлына чыгып, Якты елга ярларына киттеләр.

— Һай, нинди әйбәт,—диде Мәрьям, Якты елга ярына җиткәч. Ләкин Ташкент яклары тагын да әйбәтрәк. Бала чагымнан бирле хәтердә саклыйм: җимеш, җимеш, җимеш.

— Монда бик матур,—диде Гайни, елгага кулы белән күрсәтеп.— Әнә күрәсеңме суы нинди саф! Аның төбендә ак ташларга кадәр күренеп ята. Монда тирән, коенырга да мөмкин, но әлегә салкын. Ә-әнә, Урал тавыннан килә бу елга. Әйдә, утырыйк, ял итик!

Гайни яр кырыена, чирәмгә утырды. Мәрьям тирә-юньгә карады. Каршы якта ямь-яшел нарат урманы, ә аңда каенлык. Каенлык белән янәшә генә яшел хәтфәдәй яшел сукмаклар.

— Нинди шәп урын,—диде Гайни.—Утыр, Мәрьям, утыр!

Мәрьям утырды, ярдан түбәнгә карады:

— Ой, нинди текә, ой, нинди дулкыннар кайный монда!?

— Әйе,—диде Гайни һәм үзенең чалбары кесәсеннән бер шешә чыгарды.—Әйдә, эчәбез. Спирт бу. Дуслар бирде. Менә конфет.—Гайни ике данә конфет чыгарды, шешәнең авызын ачты һәм андагы спиртны голт-голт итеп йота башлады.

— Эчмә, Гайни, исерәсең!—диде Мәрьям, чыраен сытып.—Эчмә, эчмә, дим!

Гайни шактый гына эчте дә Мәрьямне кыстый башлады:

— Эч, Мәрьям! Врачлар әйтә, кызыл ширбәттән спирт мең мәртәбә яхшырак, диләр.

Мәрьям эчмәде:

— Юк, эчмим! Эчмим!

Гайни спиртны тагын берничә тапкыр йотты һәм рәхәтләнеп киткәндәй булды:

— Мәрьям!—диде ул.—Мин сине яратам. Берәүгә дә бирмим мин сине. Синсез миңа тормыш кирәкми! Аңлыйсыңмы син шуны, юкмы.

— Юк.
— Ник?
— Әйткәнем бар ич, минем егетем армиядә, тиздән кайтачак.
— Алдама, синең егетең—Әкрам!
— Әкрам минем өчен малай гына ич!?
— Ә нигә аның белән йөрисең, сөйләшәсең, көлешәсең, кинога бергә барасың?
— Дусларча, Гайни.
— Ә нигә мине кырый кагасың? Сизәм ич, гел сизеп йөрим.
— Ә мин берни дә сизмим.
— Сизәсең. Сизмәсәң, әйтим, син минем хатын булырга тиеш! Мин алдамыйм сине, яратып әйтәм, син мина хатын буласың!

Гайни тынды. Аннары кинәт Мәрьямне кочты һәм көтмәгәндә, шашып-шашып, кызны үбә башлады. Мәрьям яшен тизлеге белән урыныннан торды һәм Гайнидән ычкынырга омтылды. Ләкин Гайни аны куып тотты, җиргә екмакчы булды.

— Нишлисең?—дип кычкырды Мәрьям һәм Гайнине бөтен көченә этеп җибәрде.

Гайни башы белән Якты елга ярында яткан очлы ташка барып бәрелде һәм яткан көе селкенмичә тынып калды.

— Гайни, Гайни!—дип кычкырды Мәрьям, әмма Гайни җавап бирмәде. Мәрьям кычкырып-кычкырып елый башлады:
— Нишләдем мин? Нәрсә эшләдем?! Аңын югалтты! Үтердем ич! Ярдәм итегез! Ярдә-әм!!!

Аның кычкыруын якын тирәдәге кешеләр ишетеп җыела башлады.
— Ни бар?
— Ни булды?
— Кем үлгән?
— Ник үтергәннәр?
Тавышка килүчеләр арасында Фатыйма да бар иде.
— Аһ!—дип кычкырды ул, Мәрьямне кочып.—Ни булды, ни генә булды, балам?!
Озакламыйча Якты елга буенда ашыгыч ярдәм машинасы күренде.

### 3

Иртәгесен врачлар Гайни турында менә нинди нәтиҗә ясадылар:
«Ярмөхәммәтов Гайнулла Баязитович кичә исерек булган. Аның Якты елга янында ташка егылу нәтиҗәсендә баш сөяге ярылган, мие селкенгән. Хәле бик начар. Яшәрме-юкмы, әлегә әйтү кыен».
Мондый чакта тикшерү органнары кырыйда каламени?

— Туры телем таш ярсын!—диде Мәрьям, бер елап, бер тынычлана төшеп.—Мин хәзер гаепсезгә гаепле кыз. Ышаныгыз, мин болай буласын белмәгән идем. Мин үземне җәберләтмәскә генә тырыштым. Аңына килгән секундта Гайни дә аңлатма бирде.
— Мин үзем гаепле. Мәрьямгә тимәгез! Үләм...

Якшәмбе көн иде. Әкрам ничектер ялгызы гына, ашханәдән кайтып килгәндә почтальоннан хәрби хат алды: «Гражданин Кәлимуллин Әкрам Фәттаховичка.

Сез, шушы айның егермесенә иртәнге[1] сәгать сигездән кичекмичә, шәһәрнең хәрби комиссариатына килеп җитегез!
Үзегез белән бергә паспорт һәм хәрби таныкламагыз булырга тиеш».
Абзый каядыр чыгып китәргә җыена иде.

— Абый!—диде аңа Әкрам, бүлмәгә йөгереп кереп.

Абзый туктады.

— Тыңлыйм, энекәш.

— Абый, мин армиягә китәм.

Абзый берничә секунд дәшмичә торды.

— Кайчан?—дип сорады.

Әкрам елмайды.

— Менә!

Ул абзыйга военкоматтан килгән хатны күрсәтте.

Абзый хатны укыды, елмаеп куйды.

— Менә яшьлек!—диде.—Менә ул, менә! Армиягә барырга кирәк, конечно, но ярый ла алсалар?

Әкрам гаҗәпләнде:

— Ник алмасыннар? Мин кешедән киммени, абый?

— Ким түгел, конечно,—диде абзый һәм үзенең кайчандыр, егет чагында, армиягә киткән көннәрен күз алдына китерде. Аннары ул да Әкрамга яңа хәбәр әйтте:

— Менә тормышлар яңара бара, миңа да квартир бирмәкчеләр. Кухнясы күршеләр белән бергә только, шайтан алгыры. Әллә...

Абзый нидер әйтмәкче иде, шул чакта бүлмәгә көтмәгәндә Фатыйма йөгереп керде:

— Зиннәтша абзый! Шатлыгым зур, үбәм, билләһи үбәм!—Фатыйма, абзыйны кочып, чалт итеп үбеп алды. — Миңа яңа йорттан яңа бүлмә бирәләр, Зиннәтша абзый. Квартир ике семьяга булса да кухнясы бик зур. Шатлыгым эчемә сыймый: туйган идем бу бараклардан, Зиннәтша абый.

— Котлыйм, Фатыйма апа, котлыйм, ә мине армиягә алалар,—диде Әкрам һәм шундук Мәрьям бүлмәсенә йөгереп кереп китте.

Фатыйма тынып калды: Әкрам әйбәт егет иде дә, ул да китә икән ләбаса! Ә Мәрьям?

Абзый да уйланып тора иде.

— Фатыйма!—диде ул.—Утыр әле янымa, бер генә минутка булса да утыр!

Фатыйма утырды. Абзый аңа кинәт үзенең йөрәк серен чишә башлады:

— Фатыйма! Беләсең ич, мин тол ир. Килгән көнемнән үк сиңа күз салып йөрим. Мин тәмле итеп сөйләшә белмим, турысын әйтәм, ошыйсың, яратам. Күпме түзәргә мөмкин? Миңа да бүлмә бирәләр. Әйдә бергә урнашыйк! Әйдә загска барыйк, җаным!

Бүлмәдә тынлык урнашты. Уйлар. Уйлар. Аннары Фатыйма, басынкы тавыш белән:

— Әй, Зиннәтша абый!—диде.—Оят ич, оят! Мәрьямнән оят! Кырыкны тутырган тол хатынга нинди ир кирәк? Картаям инде. Үпкәләмә, гафу ит, Зиннәтша абый!

Абзый урыныннан торды:

— Фатыйма! — диде ул. — Мәрьям белән мин үзем сөйләшәм, аның рөхсәтен алам, квартирларны бергә кушабыз, Мәрьямгә дә урын җитәрлек булыр. Риза бул, Фатыйма! Әкрам китә, миңа да кыен, мин дә ялгыз калам.

Гаҗәп, Фатыйманың күзләренә кинәт яшь бөртекләре килде. Ул урыныннан торды:

— Кыздан оялам, Зиннәтша абый! — диде һәм бүлмәдән чыгып китте.

— Эх-х,—диде абзый һәм Мәрьямне күрергә Фатыйма бүлмәсенә ашыкты.

## УНДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1



Сәгать әле иртәнге ун тулмаган иде.

«Сүзне нидән башларга? Шайтан алгыры?»—дип уйланды абзый һәм ничектер бик кыюланып Фатыйма бүлмәсенә килеп керде. Анда моңа чаклы абзыйга һич кенә дә таныш булмаган бер хәрби кеше утыра иде.

— Зиннәтша абый!—диде Мәрьям, урыныннан торып.—Таныш булыгыз! Менә минем егетем. Ул әле кичә генә Германиядән кайтты. Әтисе йортына. Генерал булырга ниятли, гөнаһ шомлыгы, ә үзе әле лейтенант кына.

— Нигә гөнаһ шомлыгы булсын? Настоящий лейтенант!—диде абзый һәм хәрби егет янына килеп утырды.

— Танышыйк! Кәлимуллин Зиннәтша абзагыз булам, электә старшина, ә хәзер юллар төзүче. Мирный кеше, значет.

Егет елмайды:

— Лейтенант Кашапов Гариф.

Фатыйма инде лейтенант белән очрашкан икән. Ул урыныннан торды, бик нык пошаманга калган Әкрамга карады:

— Әкрам! Кибеткә барып киликче, бәрәңге аласы бар.

— Ярый!—диде Әкрам.—Какраз кул кычыта иде.

Алар ниндидер сумкалар алып, кибеткә чыгып киттеләр.

Абзый сөйләшергә, танышырга ярата торган кеше.

— Так-так, иптәш лейтенант, — диде. Мин Мәрьямнең әтисе кебек кеше, бер үк трестта эшләгәнлектән, хәсрәтебез дә, шатлыгыбыз да бергә. Әллә үзем дә өч елдан артык армиядә булганга, хәрби егетләрне яратам. Әнә минем энем Әкрам да армиягә алына. Пограничник булам, ди. Ә сез үзегез бу як егетемени?

— Әйе, мин монда туып үстем,—диде лейтенант.—Без Мәрьям белән бер мәктәптә укыган идек. Уны бетергәч, армиягә алындым, хәрби училищены тәмамладым. Ният гомер буе армиядә хезмәт итәргә. Әти-әнием монда яшиләр. Үзләренең йортлары бар. Миңа, абый, якын арада китәргә туры килер. Хезмәт! Тәмәке тартмыйсызмы?

— Ташладым, җитәр, күп тарттым.

Лейтенант урыныннан торды:

— Кичерегез, Зиннәтша абый! Мин тәмәке тартып керәм,—дип, авызына папирос каба-каба бүлмәдән чыгып китте.

Мәрьям, ирләр сүзенә игътибар биреп, дәшмичә утыра иде.

— Зиннәтша абый!—диде ул, лейтенант чыгып киткәч,—егет ошыймы?

Абзый елмайды:

— Ошый. Ә үзеңә ошыймы, яратасыңмы?

— Без инде бер-беребезне биш елдан бирле беләбез, Зиннәтша абый. Әйбәт егет ул. Яшермим, яратам. Сүз куешкан идек, көттем. Ай саен хатлары килеп торды. Ул мине Германиягә алып китәм, ди. Барам, Зиннәтша абый. Укуны кайткач дәвам итәрмен.

Абзыйның йөрәге жу итеп китте:

— Мәрьям!—диде ул шыпырт кына.—Мәрьям! Оят булса да әйтәм, без әниең белән загска барырга җыенабыз. Фатыйма каршы булмас, минемчә. Ул да ялгыз ич. Миңа квартир бирәләр. Ике бүлмәне бергә кушып алабыз. Трест башлыгы Александр Петрович риза. Ә син риза булырсыңмы, Мәрьям? Ризамы син, Мәрьям!

Кыз тынын өзде, абзыйдан бер читкә караган килеш, аптырап торды. Бүлмәгә лейтенант керде.

— Уйларга кирәк, абый,—диде кыз һәм сүзне башкага борды,—Гариф, Германиядә ничә ел хезмәт итәләр?
— Өч ел, Мәрьям.
— Ә аннары?
— Аннары туган илгә кайтырга мөмкин.

## 2

Тормыш. Әйе, бер уйлаганда бик гади нәрсә икән ул тормыш... Мәрьям тулай торакның абзыйлар бүлмәсенә килеп керде. Абзый ялгызы гына бәрәңге әрчеп утыра иде.
— Зиннәтша абый!—диде Мәрьям, тартынып кына.—Мин сезнең турыда әни белән сөйләштем. Мин риза, Зиннәтша абый. Калганын үзегез хәл итегез!
Абзый урыныннан торды:
— Рәхмәт, Мәрьям!—диде.—Алай булгач без яңа квартирга бергә күчәбез!
Кызның болай да алсу бите тагын да алсуланды, ә күзләрендә нур пәйда булды.
— Зиннәтша абый!—диде ул, оялып кына.—Мин Гариф белән язылыштым. Озакламыйча бергә китәбез. Миңа да, эти кебек, шәһәрләрдән-шәһәрләргә йөрергә туры килер, ахры.
Нәкъ шул вакыт бүлмәгә Әкрам кайтып керде:
— Абый! Алдылар. Иртәгә тресттан расчет алам. Әнигә телеграмма бирдем, бәлки мине озатырга килеп өлгерер?
Абзыйның уйлары таралып китте.
— Өлгерер, — диде ул бераздан. — Өлгерер, энем. Килер, килмичә түзмәс. Тик менә поезд гына...
— Ә самолет!—диде Мәрьям, Әкрамның кулын кысып.—Армиягә китүең белән котлыйм!
— Рәхмәт,—диде Әкрам һәм сагышлы гына елмаеп куйды.
...Абзый эштән дүрт күнлек ялга чыкты. Бүген алар Фатыйма белән язылышырга баралар. Вакыт иртәнге сигез. Абзый өр-яңа бастон костюмын киде, дүрт медаленең дүртесен дә күкрәгенә такты. Шул арада бүлмәгә Фатыйма килеп керде. Чуктай киенгән. Үзе елмая, бер уйлана.
— Тәки барабызмы, Зиннәтша абый?
— Әйдә, киттек, Фатыйма.
Ничектер загста эшләр озакка сузылмады: «Уйладыгызмы?»—«Бик нык уйладык.» — «Рәхәт тормыш телибез!» — «Рәхмәт сезгә!»
— Әйдә, Фатыйма!—диде абзый, загстан чыккач.—Квартирга ордер алабыз, кунаклар чакырабыз, безнең туйны да, Мәрьям туен да бергә-юлы үткәрәбез!
Санаулы көннәр озакка сузыламыни! Абзый алган кыска вакытлы ялның ахыргы көне. Вакыт кичке җиде чамасы. Кунаклар әллә ни көттермәделәр. Олы кеше буларак, мәҗлесне Александр Петрович ачты:
— Иптәшләр! Без монда, өч шатлыкны бергәләшеп билгеләргә дип, бер табынга җыелдык.—Петрович төрле ашамлык-эчемлекләр белән тулган озын өстәлгә һәм аның каршына тезелешеп урнашкан кунакларга күз ташлап алды.—Кадерле дуслар! Миңа күп язмышлар күрергә туры килде. Менә монда яңа язмышлар! Бүген без хезмәт сөюче, бик әйбәт кешеләребез Зиннәтша энем Кәлимуллинны һәм Фатыйма сеңелем Казембәт кызын яңа квартир, яңа никах белән котлыйбыз! Без аларга чын күңелдән зур саулык һәм зур дуслык телибез!—Бүлмәдә көчле алкыш яңгырады. Петрович дәвам итте.—Дуслар, энекәшләр, сеңелкәшләр! Безнең өчен янә бер шатлык бар. Әйдәгез безнең иң сылу кызыбыз Мәрьямне һәм аның дусты лейтенант Кашаповны бәхетле никахлары белән кот-

лыйк! Алар, вакытлыча, чит илгә китеп баралар. Жирнең чиге юк. Киту-кайтулар булыр, тик соңгысы булмасын! Күпне күрдем, күпне сынадым, олы кеше буларак әйтәм, хәзерге яшьләр өчен мәңге-мәңгегә тынычлык таңнары телик! Лейтенант белән безнең Мәрьямнең юллары уңышлы булсын!—Табында янә алкышлар яңгырап торды. Петровичның маңгаена тир бәреп чыкты.—Дуслар!—диде ул, тостны дәвам итеп.—Дуслар! Без ике көннән үзебезнең иң яраткан, иң тырыш, иң яшь эшчебез Зиннәтшаның энесе Әкрам Кәлимуллинны Совет Армиясе сафына озатабыз. Аңа хәрби юлларда зур уңышлар телибез! Әкрам, улым! Менә сина безнең комсомолкалар кечкенә генә бүләк тапшырырга куштылар, безнең урта Урал ягының жылы истәлеге булсын,—диделәр.

Александр Петрович урыныннан торды, Әкрам янына килде һәм аңа бик матур итеп чигелгән кулъяулыгы тапшырды. Әкрам комач кебек кызарды.

— Әй рәхмәт, әй рәхмәт, башлык!—диде абзый, Петровичның кулларын кысып.—Гомергә бергә булырга насыйп булсын, Петрович.

Мәҗлес озак барды. Тик Александр Петрович Шадрин гына иртәрәк китте: «Гафу итегез! Иртәгә иртүк командировкага!»—диде ул. Байтак кына күңел ачкач Әкрам: «Бәлки энидән телеграмма бардыр?» — дип уйлады һәм ул да үзенең тулай торагына жыенды.

— Юк, юк, кунып китәсең,—диде абзый, ләкин телеграмма турында әйткәч, тынычланды. Шулай да ул Әкрамны озата чыкты.

— Ничего, энем, син бер дә кайгырма, яме? Әнинең килер, ана кеше килмичә түзмәс.

Абзый шактый кызмача иде. Ул һава иснәде, күккә карады. Күктә тулган ай йөзә, йолдызлар балкый, зәңгәр таң ата иде.

— Күрәмсең, Әкрам? — диде абзый, күк йөзенә карап.—Ә-нә Чулпан йолдызы! Яшь чакларда без: «Ай янында якты йолдыз, минем йолдызым гына»,— дип жырлый идек. Карале мин карт бүрене, жырлыйсы килә, шайтан алгыры.

## 3

Сишәмбе көн иде. Вакыт иртәнге сигез чамасы. Әкрам тулай торакта үзенең кием-салымын һәм башка әйберләрен жыештыра. Әкрам юлга жыена һәм уйлана иде. «Әни инде килмәс, ахрысы... Әллә телеграмма барып житмәде микән? Кем белә, бәлки әни авырыйдыр? Бәлки акчасы юктыр? Бәлки башка сәбәпләр бардыр?» Әх, жүләр, жүләр! Нигә Әкрам, ял алып, авылга кайтып килмәде? Хәер, жыенырга вакыт бик аз бирелгән иде. Военкоматта: «Сез резервтан, тиз генә расчет алыгыз, юлга әзерләнегез!» — диделәр. Ярый әле, абый бар. Әйберләрне авылга ул жибәрер.

Шул вакыт тулай торакка Фатыйма йөгереп керде:

— Әкрам! Әнием килде!

Әкрам ишеккә ташланды:

— Әни! Килдеңме, әни?!

— Килдем, улым! Әнисенең керфекләре кинәт яшь белән тулды. Ул әле шактый яшь хатын иде.—Килдем, улым, килдем!

Бүлмәдә тынлык урнашты.

— Елама, әни, әйдә түргә уз!—диде Әкрам, өстәл каршына урын күрсәтеп.—Утыр, әни, утыр!

Ана утырды һәм тынычланды.

— Ярабббый!—диде.—Гомеремдә утырганым юк иде, самолет белән килдем. Аэропорт дигәннәреннән ниндидер бер шофер китереп куйды, рәхмәт яугыры.

Әкрамның әнисе тулай торакка күз төшереп алды: «Әй бала, бала! Шушында яшәгәнсең икән».

— Әни!—диде Әкрам.—Мин хәзер чәй куям. Соңрак столовойга яки абыйларга барырбыз. Юлда аргансың, ял ит!

Әкрам әнисенең кулында ниндидер төргәк бар иде.

— Менә улым, сиңа күчтәнәч!—диде ул, шул төргәкне ачып.—Менә син кайтырсың дип бер казны былтырдан бирле сакладым. Шөкер, үзенә насыйп булган икән.

Фатыйма куана һәм Әкрамның әнисенә карап сокланып утыра иде. Бу хатын әле алай карт түгел. Әнә ул да ирен югалткан. Күренеп тора хәсрәтне күп татыган, күз төпләре җыерчыкланган, чәчләренә ак төшкән. Шулай да әле чибәр ул. Өстендә зәп-зәңгәр матур күлмәк, соры фуфайка, кызгылт косынка.

Фатыйма бер читтәрәк утыра иде. Бераздан сүзгә кушылды:

— Кичерегез, ханым! Мин сезне, Әкрам сөйләве буенча, хәтсездән беләм. Монда мин җыештыручы хатын. Әйдәгез безгә! Зиннәтша абыйны да күрерсез шунда. Әйдәгез хәзер үк безгә барыйк! Әйдә, Әкрам, әйдә! Әйберләрең төрелгән инде.

— Әни!—диде Әкрам, гадәттәгечә ничектер уңайсызланып.—Бу— Фатыйма апа. Зиннәтша абыйның хатыны хәзер. Җиңги!

Әкрамның әнисе гаҗәпкә калды:

— И-и... Шулаймыни? Яңа семья оештымыни? Әйбәт, бик әйбәт! Инде без үзара туганнар икәнбез, алайса?!

Фатыйма кинәт Әкрамның әнисен кочып алды:

— Әйдә, килендәш, әйдәгез безгә! Калганын анда сөйләшербез.

— Ярый, алайса,—диде Әкрамның әнисе.—Тик менә Әкрам...

— Фатыйма апа!—диде Әкрам.—Без әни белән килербез. Хәзер килербез. Син кайта тор.

Фатыйма, тулай торактагы кайбер эшләрен тиз-тиз генә эшләштереп, яңа квартирга чыгып йөгерде. Әкрамның әнисе баягы төргәкне ачты һәм аннан ниндидер бер хат чыгарып, Әкрамга бирде:

— Менә, улым, нинди яңалыклар бар бездә!

Әкрам хатны укый башлады: «Кадерле Хәдичә һәм улым Әкрам!— Әкрам коелып төшкәндәй булды.—Мин кичергән газаплар, минем йөрәккә тулган кайгы-хәсрәтләр турында яза башласам, меңнән артык хатка да сыймас! Сез мине дөрес аңларсыз бәлки! Кызганычка каршы—мин әле һаман исән. Шулай да мин илемне сатучы түгел! Юк, кара елан түгел мин. Минем кайтасым килә. Сагындым мин, бик-бик сагындым! Бу дөньяда сез минем иң якын кешеләрем. Мин пленда идем. Миңа кайтырга мөмкин булыр, ахры. Кабатлап әйтәм, минем, батырларча үлә белмәүдән башка, бер гаебем юк. Ышаныгыз, юк! Сәгать саен, минут саен сездән хат көтәм, кайтыйммы? Сез мине кабул итәрсезме? Хат көтәм, җавап көтәм. Хат язучы: Кәлимулла улы Фәттах.

1948 ел, 18 май».

— Әни!—дип кычкырды Әкрам.—Әни! Бу нинди хәл?

— Менә шундый хәлләр, улым,—диде Хәдичә.—Бу хат әле үткән атнада гына килде. Мәскәү аша. Атаң кайтырга мөмкин икән.

Әкрам чиксез шатланды.

— Кайтсын, әни, тизрәк кайтсын!—диде ул.

Бераздан алар абзый һәм Фатыйма өенә чыгып киттеләр.

— Әни!—диде Әкрам.—Иртәгә юлга! Бик еракка. Ерак офык буена.

Көн аяз иде. Хәдичә үзе килгән якларга, офык буйларына карады. Һавада бүген бер генә кисәк тә болыт күренми иде.

*1975 — 1978 еллар.*

## Кави Латыйп

# ЯКТЫЛЫК ТИЗЛЕГЕ

*Кави Латыйп халык җырлары стилендә кыска шигырьләр дә язып карады, повестьлар да иҗат итте, үз тавышын таба алмый интекте.*

*Аның менә бу шигырьләр бәйләмендә яңалык, үзенчәлек сизелә. Әгәр бу аның язу алымына әйләнеп, һәм ул шигырьләр һәр вакыт камиллеккә ирешкән булсалар, шагыйрь, чыннан да, үзен тапты дип әйтергә булыр.*

*ГАРИФ АХУНОВ.*

### Яктылык тизлеге

Яктылык тизлеге белән исәпләгәндә,
миңа бер генә яшь икән.
Алай булгач, кайчан килеп җитәр сиксән?
Галәмдә узган бер ел гомер
җирдәге илле яшькә тиң икән,
яктылык сәгате белән үлчәгәндә...
Шулай булгач, мин тәпи генә баса башлаган,
ипи генә ашый башлаган,
имезлекне генә ташлаган, —
яктылык гомере белән үлчәгәндә.
Уйларымны уртаклашучы якын дустым әйтә миңа:
яктылык тизлеге белән исәпләгәндә,
Тукай, димәк, исән!
Исән, дим мин, яши, яшьни безнең Тукай
карагруһларның баш өстендә,
яшен булып яшьни бүген дә:
намуссызлык, хокуксызлыкны фаш итә,
азатлык, бәйсезлек өчен кылыч уйната
Европа, Америка, Африка, Азиядә...
Тукай нинди генә вакыт белән үлчәгәндә дә яши,
Тукай нинди генә тизлек белән исәпләгәндә дә исә
Тукай — түгел шәм,
ул метеорит!
Тукайның һәр сүзе, һәр фикере, һәр шигыре
яктылык гомеренә тиңләшә!

## Оркестр уйный

Оркестр уйный, оркестр уйный...
Тауларны, диңгезләрне, илләрне буйлый...
Оркестр уйный, оркестр уйный:
җирдә — туплар,
океанда — крейсерлар,
галәмдә — кораблар...
Сенаторлар, конгрессменнар, банкирлар бии...
Заводлар, шәһәрләр, штатлар бии НАТО көенә, —
циркач атлар шикелле.
Карап торучы тамашачылар сөенә,
Чехов пьесасындагы дамалар сыман.

Ачык авыз тамашачылардан битәр,
көрәшчеләр кирәк җир йөзенә
бүгенгесе көндә —
егерменче гасыр азагында,
нейтрон — атом заманында!..
Җир шарын хезмәт мәйданына,
Тынычлык зонасына әверелдерер өчен...

Уйна, оркестр, уйна,
тауларны, диңгезләрне, илләрне буйла, —
көрәшчеләр чакыр...
Сенаторлар, конгрессменнар, банкирлар
биеп калсын НАТО көенә
соңгы тапкыр, соңгы тапкыр!..

## Минем кайнарлыгым — уттан

Минем кайнарлыгым уттан —
бабам күптән тапкан уттан.
әтием кылычы чаткысыннан капкан уттан,
фашистларга абыем аткан снаряд ялкыныннан —
кызган, кайнар туптан...

Минем тугрылыгым — уктан,
дөресен ярып әйтәм мин, —
хыянәтченең чикәсенә суккан сыман чалт итеп!
Туры сөйләмәсәм, минем өчен дөньяның бер чите китек.

Минем вөҗданым, намусым — тау чишмәсеннән дә саф.
Коммунист күңеленнән эзләмә син керне, —
мин уттай кайнар, судай пакь.
Коммунистлар сафлыгы, пакьлеге белән
дөнья якты, дөнья ак!..

## Карбышев йолдызы

Совет астрономнары яңа йолдыз тапканнар — ул Советлар Союзы Герое Дмитрий Карбышев йолдызы, номеры 1959.

*Газеталардан*

Яңа йолдыз яна күк гөмбәзендә —
генерал Карбышев йолдызы.
Аны күрәләр бөтен җирдә:
Берлинда, Нью-Йоркта, Лондонда,
Казанда, Рязаньда, туган җире Себердә.

Аны Карбышев әйтерсең лә
йөрәк ялкыны белән кабызган, —
Данко сыман!
Әйе, Карбышев кеше булып үлгән,
ә йолдыз булып туган...

Фашистлар аңа җирдә яшәү вәгъдә иткән,
ә ул үзе теләп йолдызлар дөньясына киткән, —
җир йөзен яктыртыр өчен
караңгы төннәрдә.
Карбышев йолдызын ирек сөючеләр күрәләр
төрмәләрдән...

Карбышев йолдызы кешелек тәрәзәсенә карый.
Карбышев йолдызы — ул Советлар Союзы,
аны барлык планета таный, —
номерсыз да!..
Баш ия аңа картлар, яшьләр, —
бөтен дөнья...

## Тын океанга

Суга таш атып коймак ясый алмавына
гарьләнә әнә бер бала.
Ә кемнәрдер океанга әҗәл көймәләре сала.

Океан, син нәрсә карап ятасың?
Шаула, дула, күтәр өермә.
Әҗәл көймәләре — АКШ маркасы сугылган
акулалар җибәрүче мундирлы ир-атлардан,
егерменче гасырдагы пиратлардан
үзеңне көймәләр, кораблар зиратына әверелдертмә.
«Ирек!» — дип лыгырдаучыларга ирек бирмә,
Океан, бул иркле,
шаула, дула, күтәр өермә, —
гаделлек, тынычлык урнашсын өчен җирдә!

Әхәт Гаффар

# БЕР ЙОТЫМ СУ

ХИКӘЯ



Янгын командасы башлыгы Тәхау Яркәев авыл китапханәсеннән уналты мең дүрт йөз утыз җиденче дип тамгаланган китапны алып кайтты.

— Менә, карчык, соңгысы,— диде Тәхау һәм, кер юып яткан хатынын үчекләгәндәй, кызыл тышлы китабын әйләндергәләп алды.

— Ай-һай...

— Нәрсә — «ай-һай?»

— Соңгысы микән дим. Ничәнчесе инде?

Тәхау китапның өченче битен ачты да ниндидер горурлык сизелеп торган тавыш белән, тик ничектер моңсу һәм әкрен генә:

— Уналты мең дүрт йөз утыз җиденчесе,— диде.— Шукшин...

— И алла! Бу көннәрне күрергә дә насыйп булыр икән! — диде Хәкимә, сабын күбегенә буялып беткән кулын сөрткәләп. — Инде ничек торырсың икән соң? Китапсыз дим.

— Киләсе кварталда китапханәче тагын алып кайта.

— Әйтәм ич!.. Ничек туйдырмыйдыр шулар?.. Бусын укып бетергәч, бәлки үзеңә генә яза башларгадыр?

Тәхауның күкрәгендә ниндидер бер авырту уянып киткән сыман булды: Хәкимә кер юу машинасының капкачын ачып җибәрде. Аннан, ачык читлектән азат ителгән кошлар кебек, эреле-ваклы дистәләгән сабын куыгы очып чыкты. Алар йөзләрендә дөньяны чагылдырып ялтыраштылар да, бераз күтәрелүгә, тавышсыз гына юкка чыгып беттеләр.

Тәхау ямьсез яшәмәде. Укыган бер китабы саен, караңгы төннәрдә яктырган күбәләкләрдәй, аның хыялында ак кәгазь белән алтын каләм хәрәкәткә килә иде. Менә шушы сабын куыкларыдай ялтырашып, аның күз алдыннан ничәмә-ничә еллар йөзеп үтте. Ул елларның һәркайсында Тәхауның хыял дөньясы чагыла иде дә өн-тавышсыз гына сүнеп юкка чыга иде. Ул хыяллар — язылмаган катаплары аның...

— ...Бәлки, үзеңә генә яза башларгадыр?

— Янгын сүндерүче белән йоклап туйдың мәллә?

— Тагын кем белән йокларга кушар идең?! — диде гаҗәпсенгән Хәкимә.

— Язучы белән, мәсәлән.

— Язучы белән?

— Язучы белән, карчык. Мал врачы белән генә йоклау мине туйдыра башлады.

— Тагын кем белән йоклар идең, оятсыз? — дип, Хәкимә еларга ук кереште.

— Язучы хатыны белән.

— Укый-укый соңгы акылларың чыгып бетә бит инде, бәгырькәй!

— Язучы хатыны буласың киләме соң?

— Каян килгән ди безгә язучылар?

— Ә мин? Кара бу мыекны! Галимҗан Ибраһимовныкыннан кимме әллә?

— Аның чәче булган. Ә син — пеләш.

— Пеләш язучылар күбрәк ул. Суйган да каплаган язучы мин!

— Кодрәтеңнән килгәч, академикка ук әйлән инде.

— Язучыга җитсәм, академикларыңны сызгыртып узып китәм мин! Алар шундый халык. Академикларың бер читтә торсын... Була алмыйсың син язучы хатыны, Хәкимәкәй җанаш! Үлсәң дә.

— Кара, кара! — дип көлде Хәкимә. — Җүләр җүләрлеген акыллыга сылтаган ди.

Ишегалдында әрле-бирле йөренүеннән капылт туктап, Тәхау хатынына текәлде. Аның йөзе ниндидер уй белән яктырып, янгын сүндерүчеләр өйрәнүендә көйдереп кайткан керфекләре эчендәге зур зәңгәр күзе ниндидер үкенеч белән тулы иде.

— Сылтамыйм, сылтамыйм, җан кисәгем! Сиңа сылтамыйм мин үземнең язучы булмаганлыкны. Тик моңа мин дә гаепле түгел.

— Ә кем? Мин дип шикләнәсең мәллә? Соңаргансың. Башта ук әйтәләр аны.

— Кайчан?

— Өйләнешер алдыннан. Уйлаган булыр идем. Кем белә, бик тырышкан шәттә берәр язучы кисәге очраткан булыр идем әле. Әллә кем түгелләрдер. Ит белән сөяктән торалардыр.

— Билгеле, бер җирләре дә алтыннан коелмагандыр, хы-хы...

— Әнә ич, килгәлиләр клубка. Бер дә кешедән узмаганнар шикелле. Карап торышка битләрендә тамчы гөлләр дә үсми. Кигәннәренең дә артык җире юк. Сөйләшүләре дисәң генә инде.

— Шул-шул, Хәкимә. Синең белән миннән ким түгелләр.

— Артык булмасалар, ким түгелләрдер анысы. — Хәкимә ирен баштан-аяк карап чыкты: ябык, кояшта янган йөз, яргаланган ирен, тыгыз итле төксез тән... Су төбендә озак ятып шомарган, тагын да катылана төшкән кайрысыз имән агачымыни.— Алайса ник язучы гына булмадың, янгын сүндерүче булып калдың?

— Хәзер иskә төште: бер йотым су җитмәгәнгә.

— Бер йотым су?

— Су, гап-гади су.

— Язучы булганнарга җиткәнме?

— Аларга һәрчак нидер җитмәгән.

— Шуңа күрә яза башлаганнармыни?

— Шуңа күрә.

— Ә син ник башламаган алайса?

— Телисеңме, бүген башлыйм?

— Бәлки мәшәкатьләнмәссең? Нәрсәгә ул сиңа?

— Сине язучы хатыны итәр өчен.

— Юк белән баш катырганчы, әнә, мунча ләүкәсен төзәт. Кичкә мунча ягам.

— Чынлап әйтәм.

— Мин янгын сүндерүче хатыны булуга да бик риза.

Тәхау каһәгать кыяфәт белән тамагын кырып куйды:

— Ул яктан, карчык, зарланырлык түгелсең, кхм-кхм... Утны ялкын белән сүндерергә синнән узганнар юктыр.

Хәкимә, су коенып чыккан казлар канатларын иплэгәндәй, көянтәне сыгып китергән кер тулы чиләкләрне җиңел генә итеп иңенә элде.

— Ләүкәне төзәт, — диде ул һәм капканы чыгышлый тагын борылып карады. Сипкелле йөзе саран гына елмаеп алды. Тәхау тәненә сагындырып килгән яңгырның беренче эре тамчыларын тойгандай булды. Көянтәсен сыгылдыра-сыгылдыра Хәкимә ачык капкадан урамга атлады, урамнан тыкрыкка, тыкрыктан инешкә таба төшеп китте...

Хатыны Хәкимә иренең «китап җенен» куып чыгарыр өчен заманында телен кылыч итеп кенә айкамады. Бу мәсьәләдә җиңү Тәхау ягында калды. Унөч ел элек, Джек Лондон китапларын сабан туе мәйданына да чыкмый укып яткан бер көнне, Хәкимә ничә елларга сузылган изге көрәшне соңгы кат рәхәтләнеп, җәелеп елавы белән тәгәлләде дә солых төзәргә тәкъдим итте. Ул куйган таләпләр кыска иде:

— Тәхау Яркаев мәҗлес-мазарларда, өмә-бәйрәмнәрдә, юлда-фәләндә йөз граммнан артык аракы эчми (Хәкимә авызга да алмый дигән дәгъва куярга курыкты — бер дә эчмәсә, ир кешедә саранлык чире кузгалуы ихтимал икәнлеген ул яхшы белә) һәм тәмәке тартуны ташлый;

— йорттагы хакимлек дилбегәсе бөтен тулылыгы белән Хәкимә кулына күчә.

— Я китап укуыңны ташлыйсың, я мин әйткән белән килешәсең.

— Темпора мутантур ет нос мутанус ин иллис, — диде Тәхау моңа каршы.

Читтән торып авыл хуҗалыгы техникумында укыган чакта латин белән байтак интектерүләренә карамастан, Хәкимәнең колагы чит сүзләрдән бизәргә өлгергән иде инде.

— Сүгенмә әле,— дип кисәтте ул ирен.— Мине иблис белән күп бутасаң, бүгенгедән идәндә йоклый башламагаең.

— Мал врачы булырга укыган чагыңда синең китапларыңны кочаклап ятканнарымны оныткансың, карчык.

— Аңа инде күпме гомер.

— Яшисең, яшисең... Ә темпора мутантур икә-ән, ет нос мутанус ин иллис икә-ән...

— Бутаптыр шул, бутаптыр.

— Нәрсәне «бутаптыр?»

— Минем белән китапларыңны бутап яшисеңдер дим.

— Юк. «Вакытлар үзгәрә, аның белән бергә без дә үзгәрәбез» дим мин, латинча. Үзең өйрәттең ич теге вакытны. Хәзер «ясалма каплату» дигәннең латинчасын да оныткансыңдыр инде.

— Синең җиде класс белемле башыңда шул гыңа торса тора инде...

Менә бусы кирәкмәс иде. Хәкимәнең сүзләре Тәхауның күңеле аша бал кортлары күче кебек мыжгып, болганып узды. Шавы басылды басылуын, мәгәр ул күч шунда, йөрәк астында калды.

Бу сөйләшүдән соң Тәхау авыл һәм мәктәп китапханәләрендә ничә китап булса — шуларның һәммәсен укып бетерде. Хатынының «җиде класс» дигәненә үч итеп. Бүген инде менә соңгысын алып кайтты.

Тәхау, өйгә кереп, бер чүмеч салкын су эчеп чыкты да, алма бакчасының теге ягындагы куе чиялектә күмелеп утырган мунчага таба китте. Тик кулында балта, ышкы-пычкы түгел, ә уникe битле шакмаклы дәфтәр белән шәмәхә карандаш иде. Мунчада аның итек баса

торган өстәле бар. Ул кергәндә өстәлдә гөберле бака утыра иде, Тәхауга исе дә китмәгән кыяфәт белән яңакларын бүлтәйтә-бүлтәйтә сулый бирде. Әйтерсең лә сагыз чәйни.

— Нәрсә, дәфтәр күргәнең юк мәллә?— диде ул бакага. Бака авызын шара күзенә җиткәнче ерып җибәрде дә бөтен мунчаны тутырып кычкырып куйды.

— Өстәлне бушат. Язам, ф-фәл-лән-төгән!— Тәхау, салкын сыртыннан тотып, аны ләүкә астына төшереп җибәрде. Ә анда тамырдан борнап чыккан зәгыйфь ике чия үсентесе агарып утыра иде. Тәхауның аларны йолкып атасы килде. Тик кулы үзеннән-үзе ярты юлда туктап калды. Шул үсентеләр сыман, аның күңелендә дә нидер борнап чыгарга тормыймы соң? Кемгәдер аның язганы да шулай зәгыйфь тоелыр. Тик ул аны тиз генә йолкып атуларын теләмәс иде бүген.

Нәрсә язарга? Ул бер генә нәрсәне белә: аның язганы бүтәннәр башына килеп тә карамаган нәрсә хакында булырга тиеш. Берәр яңалык шундый, кызык. Көлке булса, бигрәк тә шәп. Бусы иң авыры бугай. Көлүе генә җиңел ул. Аңларга тырышмасаң, бигрәк тә. Көлкене аңлагач, көлке буламыни? Көлкене аңлагач, еларга кирәк. «Шул ук бер йотым суны ал,— дип уйлады ул.— Бер караганда көлке ич инде».

Шул бер йотым су аңа гомер буена тынгылык бирми килә. Бу хакта бер кемгә дә сөйләгәне юк. Әллә ничек шунда, оят. Иң элек энеләреннән. Алар оныткандыр да инде. Хатынына да сөйләмәде. Хәкимә белән аның арасында яшертен серләр күптән юк инде югын. Ир белән хатын тормышы ачкыч белән йозак кебек бит ул. Бер-береңә туры килмәсәң, изалану гына. Ә туры килер өчен ачкычның йозакка билгесез чемәге, йозакның ачкычтан яшертен биге булмавы кирәк. Тәхау шулай яшәде дә. Сөйләмәгән бердәнбер нәрсәсе шул — бер йотым су. Ә сөйлисе килә үзе! Бүген аеруча. Күңелдән ташыр дәрәҗәдә. Язучылык та шундый шөгыльдер ул бәлки — яшертен, үзеңә кадерле, сине борчып торган, йокы бирмәгән сереңне кешеләргә сөйлисе килү. Тик оялып.

Карандаш очын теле белән юешләп, Тәхау дәфтәр битенең нәкъ уртасына бер сүз язып куйды:

# СУ

Һәм башлады. Берни күрмәс, дөньяның бернинди өнен ишетмәс булды. Әйтерсең лә буранлы төндә җигүле чанага утырып бара. Андый чакта бар ышанычыңны ат сизгерлегенә тапшырасың. Дилбегәне бушатасың. Инде юлга ат үзе хуҗа. Тәхауны да, шул ат шикелле, күңеленнән ыргылып торган ниндидер бер аваз әйдәп китте. Тик ул аваз белән аның арасында ниндидер дилбегә бар бугай. Тәхау бар көченә шуңа ябышкан, ул менә-менә шартлап өзелер күк. Тәхауның үз күңелен, бөтен дөньяга күренерлек итеп, кешеләр алдына җәеп саласы килде.

Сыер какысының чәчәк аткан чагын күргәнегез бармы? Яр буйлары, тугайлар, күл тирәләре сап-сары була. Кояшта ялтырап торган җиз ләгән мени! Чын менә! Ышанмасагыз, безнең авылга килеп карагыз... Тик хәзер соң шул инде. Бераз алданрак кирәк иде. Моңарчы кайда йөрдегез соң? Шайтаным да үсми хәзер су буйларында! Бушлыкларда да. Маллар белән тракторларга таптатып бетердек. Янгын машинасыннан су сиптереп үстерәсеңмени хәзер аларны? Үзебез гаепле, нәрсә аны... Ә исе дә иде соң, исе! Бөтен авылга тарала иде. Ирта-кичен яңа сауган сөт исе дә сыер какысы исе иде. Сыер какысы исе — сыер какысы исе инде ул, җәмәгать!

Аны язуыннан бүлеп, ләүкә астындагы бака аваз салды. «Дөрес, сыер какысының ни катнашы бар минем бер йотым суда?» Язган битен ертып, мич авызына ыргытты. «Ул көнне үләнгә бардык без. Июль башы иде инде. Сыер какысы чәчәген койган чак»,— дип уйлады ул. Тирләгән маңгаен күлмәк җиңе белән сөртеп алды да, карандаш сөрмәсен төкереге белән юешләп, тагын язып куйды:

## Су!

«Беренче һәм соңгы тапкыр мин үземне унөч яшемдә үтердем...»

Болай башлау Тәхауга ошады. Нәрсә сузып торырга. Яр да сал. Тегермәнче Галәветдин сымак комнан бау ишмә. Әнә нәрсә дип сөйләп ята бер көнне! Имеш, эчкәннәр болар. Эчсәләр соң! Әллә Тәхауныкын эчкәннәрме? Мактана! Сезнең эчү — эчүмени ул, янәсе. Менә алар ичмаса!.. Эчкәннәр, эчкәннәр... Берзаман теше сызлый башлаган моның үтерә язып. Берсе киткән Мәфтуха эбиләргә. Сөлеккә. Алып килгәннәр бер банка сөлек, Галәветдиннең бөтен битенә каптырып куйганнар. Күзе генә агарып кала тегенең. Сизә бу — суыралар моның каның. Суыралар да, туеп, тегермән ташына коелышалар икән. Коелыша торалар, кочаклашып: «Эти тапкан мал түгел, кешенеке җәл түгел»,— дип җырлый-җырлый буа суына төшеп чума торалар ди, имеш. Аракылы кан эчеп исерешкәннәр канэчкечләр... Көлке, билгеле. Тик көлкенең мәгънәсе булырга тиеш бит.

Тукта, ни өчен үтерде соң әле Тәхау үзен унөч яшендә беренче һәм соңгы тапкыр?

Шул бер йотым су аркасында инде. Кешелегемне үтереп, хайванга әйләнгән идем. Бик каты сусаган идем мин. Суга гына түгел. Дөнья назына, туйганчы бер йокларга, симез суалчаннарга балык каптырып утырырга, чыклы чәчәкләр чабып, печән итеп киптерер өчен, кул арбасы белән алып кайтырга түгел, ә күрше кызы Зөлфиягә такыя үрер өчен алып кайтырга сусаган идем... Ә мин үз-үземне үтердем. Эчемдә посып яткан бөтен дөньяга үпкәле бүрене мин хыянәтчел төстә ике энекәшем өстенә өстердем дә кояш көйдергән кара җирдә аунага-аунага гөнаһсызга талаттым. Менә шунда үлеп калдым мин. Йөрәгемә таш булып утырган ул гаделсезлегем бүтән бер кайчан да баш күтәрмәсен өчен мин үземне беренче һәм соңгы тапкыр унөч яшемдә үтердем. Нәрсә шыңшып утырасың, башың пеләшләнеп беткәнче яшәгәнсең ич дип бәйләнүегез дә ихтимал. Юк, балавыз сыкмыйм мин. Ә ул көнне еладым мин, яшермим. Ул күз яшьләре, һавалар, елгалар аша океан дулкыннарына кадәр җитешеп, әле дә булса әчелеген җуймаганнардыр әле. Янсә шул чактагы җинаятем өчен кемнәндер җавап таләп итеп, континентлар ярын тырныйтырный үксидер. Усаллык һәм явызлык, кайда гына кылынса да, шушы — без басып торган җиргә төшә.

Ул көнне, җәйнең һәр көнендәгечә, без үләнгә бардык. Мин, сипкелле аркама чалгы салып, алдан киттем. Ул сипкелләрне кытыршы куллары белән сыйпап, әни миңа бәхетле булырсың дия торган иде. Хәзер бәхет шәрифләренә карата зарым юк анысы. Өс бөтен, тамак тук. Хатыннан да уңдым. Тик ул көнне бүгенге бәхетләргә ерак иде әле. Үз насыйбың барыбер үзеңә киләсен белгән булсам, мин ул көнне ничек тә түзгән булыр идем. Инде хәзер башны ташка орасыңмыни? Үкенүдән ни мәгънә. Андый үкенеч сәбәбе минем кебекләргә бөтен бер гомергә җитә ул.

Ул җәйнең коры килгәне истә калган. Эти вафат булганның икенче җәе иде. Җирне терелэй тунагандай итеп, кылган, ак әрем, кыр кыягы, сары мәтрүшкә, кыр канәфере катыш үлән чабам. Чалгы үткен.

һәвәслегем дә булгандыр, мактанып әйтүем түгел. Эти чалгысы үткән җирдә дә ике елсыз үлән чыкмый ди торганнар иде.

Ярар. Иртәнге сигездән уннарга кадәр шулай бер арбалык үлән хәзерләп куйдым. Җир яна. Әйтерсең лә дегет һәм күмер яндыру өчен каен әрдәнәсен күмгән җир өеме өстенә менеп басканмын! Элек дигетне, тимерчелек күмерен туфрак белән күмгән каен я туйра ягып алалар иде. Хәтерләүчеләр дә бардыр әле... Ул җәйне кылганнар гына түгел, ә минем куе чәч, каш-керфекләргә кадәр бабайларныкыдай агарып килде. Йөздән тозлы тир ага. Күз ачарга ирек бирмичә. Буранга каршы баргандагы шикеллерәк. Тузанлы биттә тир эзләре сузылып кала. Картлык буразналары мыни! Без тормышка хезмәт аша килеп кердек шул. Хәзерге бала-чага шикелле трай тибеп түгел.

Бер заман каршыдагы үр сыртына арба тарткан энекәшләрем килеп чыкты. Олысы Ризван, кечесе Рәмзи. Хәзер берсе Казанда врач, икенчәсе атом бозваткычында штурман. Ул вакытта берсенә унбер, икенчесенә сигез генә яшь. Рәшә аларны ниндидер бөҗәк сөйрәп барган сары кырмыскалар күк итеп күрсәтә. Рәшә теләсә нишләтсен, миңа алар су тутырган ике шешә булып күренде. Берәүләргә хәзер тик торганда да аракы шешәсе күренә. Азынды халык. Ә миңа су гына кирәк иде ул көнне. Иреннәрне тел белән ялап кына чылатам.

Мин печәнне бодай басуы белән шактый текә үр арасында — авыл көтүе якын килмәгән җирдә чапкан, басу уртасында буш калган төшләрдәге кузлут, сусән уты үләннәрен кул белән җыйган идем. Арба тартып менүе энекәшләрнең үзләренә генә авырга киләсен белсәм дә, каршы төшмәдем. Алар әле яңа гына килә, ә мин күпме кырам инде кайнар җирнең сирәк чәче булып җилфердәгән кылганлы үләнне. Түзәрләр, янәсе. Кабахәт, ә?! Түзәрләр, имеш! Менә сез арба тартып менеп карагыз әле шул текә үргә, нишләрсез икән! Карап торыр идем мин бераз... Беренче хатам шул булды. Үчләндем. Шуннан китте. Текә тау маңгаеннан тәгәрәтеп җибәргән таш шикелле китте. Кем дә туктата алмаслык булып. Без җыйган печәнне ашаячак сыер-сарыкларга, янәшәдәге Чүнник күленең төбен ярылып беткәнче киптергән кояшка, безне салкынча сулы инешләрдән аерып, печән җыярга мәҗбүр иткән тормышка, шул тормышны бөтен Европаны айкап кайтып та яхшылый алмый үлеп киткән әтигә үпкәләмәдем мин һәм әле һаман да үр сыртына менеп җитә алмаган энекәшләргә үчләндем. Зиһенне шул чуалтты — су, су.

Ниһаять, күтәрелделәр. Әлсерәшкәннәр, тирләп ямьсезләнгәннәр. Килеп туктаулары белән кычкырдым мин боларга:

— Ник, мәйтәм, Ямаш карт үгезе шикелле сөйрәләсез?

— Эссе, — диләр. — Арба авыр.

— Буш арбамы? Әле сез миңа үләнне бер үземә җыйдыру гына түгел, бер үземә тарттырып та кайтармакчымыни?

— Без булышырбыз.

— Тәртәдән сезгә тоттырам, белегез аны.

Арбаны тәртәдән тартуга караганда, арттан этүе җиңелрәк шикелле. Тәртәдән тартканда арбаны алга да, артка да чөйкәлдермичә тигезләп кайтасы да бар. Ә арттан, көчәнеп этәсе булса да, башны үләнгә терәргә мөмкин, таудан төшкәндә инде син бөтенләй азат, бар хәсрәтең хәлсез аякларыңны өстерәү.

— Ярар, — диделәр.

— Су!!!

Рәмзи минем кулга сулы шешә китереп тоттырды. Иренем белән шешә авызына ябыштым. Бер йоттым, ике... Бөтен авызны тутырып.

Өч йоттым, дүрт... Су түгел, бер уч ком гына йотып җибәрәмдер сыман. Йотым саен тамак төбе авыртып кына кала... Күкрәк тотырып сулыйм да тагын йотам, тик инде чынлап та су түгел, ә үз төкерегемне генә. Шешә авызын иреннән алмый гына энекәшләрнең күзләренә карыйм. Гүя миңа кирәк бишенче йотым суны шул күзләрдән агызып булыр күк. Ә ул бишенче йотым су миңа бик кирәк. Сусауны, хәлсезлекне, эчтәге бар үпкәне басар өчен.

— Эх, сез әле алаймы? Килеп җитмәс борын эчеп бетердегезме, бирәннәр?

— Без үз өлешебезне генә ич. Бишәр йотым гына.

— Миңа ник дүртәү генә калган?

— Без тигез бүлдек.

— Алдашмагыз! Дүрт йотым гына калган!!

— Син зур йотымнар белән эчтең. Шуңа дүрт.

— Санап тордыгызмыни әле?!

Дәшмәделәр. Үзләре дә сусаган бит. Тик тагын бер генә йотым булса да су эчәсе килү мине сукырайткан иде инде. Һәм мин үчле күңелем кайнарлыгын бастым, күзләреннән яшь итеп агызып. Кыйнадым мин боларны. Хәлсезлектән кошлар да ара-тирә генә аваз салган ялан кыр буйлап куа-куа кыйнадым. Кыйнадым дип... ул хәтле түгел инде. Әмма ул чакны дөнья уртасында аларның елаган тавышлары гына торган шикелле иде. Карышмадылар да ичмасам. Мескеннәрем минем, мескенкәйләрем!! И-эх!..

Тәхауның күзеннән яшь бәреп чыкты. Үрдән кетмәгәндә ишелеп төшкән кар суларыдай мул күз яше. Сөртмәде. Акты да акты. «Егерме елдан соң бит, ә?» — дип гаҗәпсенде ул үз-үзенә. Бер йотым су өчен егерме елдан соң балавыз сыксын инде ир кеше.

— Юк, үзем өчен еламыйм мин хәзер,— диде ул һәм йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты. — Аларның күз яше өчен елыйм мин.

Суга чумар алдыннан киң итеп тын алгандай сулап куйды да дәвам итте.

Авылга хәтле ерак — дүрт чакрымнан артык. Тагын бер йотым су эчмичә торып кайтып җитәлмәм шикелле. Җыелган үләнне төйи торырга кушып, суга киттем. Ике чакрым арырак Түллинкә урманы бар. Ә анда — сыерчык оясыдай кечкенә генә буралы кое. Кире як дип тормадым, бодай, тары басуларын турыга кистереп, шунда киттем. Бару-кайту дүрт чакрым. Авылга җитәрәк без аркылы чыгасы юл күпере астындагы Лашман чишмәсенә дә шул кадәр генә. Мин бер йотым су якынрак якка киттем...

Шуннан соң ни булганын Тәхау төшереп калдырды. Тизрәк ахырын язасы килде. Аныңча, иң кызыгы ахырда иде. Теләсә нәрсәнең иң кызыгы ахыры дип белә иде ул. Тормыш та шулай аныңча. Югыйсә, иң кызыгы ахырда булмаса, уналты мең дүрт йөз утыз алты китапны иң соңгы битенә чаклы ник укып я актарып чыкты соң ул? Иң кызыгы ахырда дип көтелмәсә, дөньяда ник соңгы сулышка кадәр яшәде соң? Алай гына да түгел. Иң кызыгы ахырда булсын өчен гомеренең башын да, уртасын да кеше мәгънәле итеп яшәргә тырыша.

Коеда эчкән белән дә туймадым. Миңа гел җитмәгән бишенче йотым су энекәшләргә дип тутырган шешәдәдер төсле тоела иде. Ул суның биш йотымы барыбер минем өлеш ич. Түзмәдем. Яннарына барып җиткәнче үк, шешәнең өчтән берен эчеп бетердем.

— Мәгез, эчегез.

— Анда барып йөргәнче, кайтып җитә язганыек инде,— диде Рәмзи.

— Эч, эч!

— Әле тагын бер мәртәбә әйләнәсе ич, ә сәгать инде уникеләрдер. Өйлә җиткән иде инде, анысы хак — кыр читендәге мәче борчагының чәчәге йомылган чак. Ә печәнгә тагын бер барасы бар. Яңгыр яумаганда көнгә ике юл ясыйсың. Өч ай җәйгә алты ай кыш туры килә. Без алып кайта торган бер арба кычыткан, кузлут, сусән уты, эт әчәгесе, кыргый тары үләннәреннән, киптергәч, сыер белән сарыкларга өч салырлык печән чыга. Бер көнлек, димәк. Шуннан инде исәпләп карагыз. Көнгә ике юл — моны безгә әни түгел, тормыш куша. Ә без тормыш кушканны үтәргә өйрәнгән. Әзергә бәзер булу безнең нәселдә юк ул.

— Әнә бит, үз өлешеңне син дә эчеп бетергән. Килеп җиткәнче үк... Ризванның кыймый гына әйткән бу сүзләре мине арттан килеп суга төртеп төшердемени! Күз карашларыннан утка салган кәгазь шикелле бөрешеп, аркан бастым. Яшеннән качкандагыча, карашларыннан качасым килде. Кыр киң. Мин кеп-кечкенә. Энекәшләремнең күз карашыннан качарлык җир ул көнне дөньяда юк иде. Минем эчне бишенче йотым су тырный. Аларга каршы борылдым да, күлмәк якасын ачып, елый-елый җиргә чүктем.

— Кыйнагыз мине дә!

— Син үз өлешеңне генә эчкән. Безнекен түгел.

— Кыйнагыз дим!

Минем кычкырудан өркеп, аяк астыннан гына тургай очып китте.

— Сук, Ризван... Рәмзи, сук инде!

— Кайтыйк. Тагын киләсе бар.

— Берәрне генә сугыгыз, миңа күп кирәкми.

— Безнекен эчмәгән син.

— Эчкән булсам, сугар идегезме?

— Юк.

— Ник?

— Син абый ич. Су була ул. Әни самавар куйгандыр инде.

Тимәделәр. Мине үчекләгәндәй үр сыртында ялгыз бытбылдык кына кычкырып калды. Мин кыйнаганны әнигә дә әйтмәделәр. Инде үзләре оныткannардыр. Ә мин — юк. Ничек онытасың үзеңнең беренче мәртәбә үләсе килүеңне? Үзеңнең бала чагың егылып үлгән көнне ничек итеп истән чыгармак кирәк? Ауный-ауный елап, кояш көйдергән ялан кыр уртасында үлеп калды минем балачак. Җәлке, егетләр! Их, ничек кенә җәлке әле. Ә хәзер нинди тормыш китте? Бер генә сүз — матур. Елыйсы килә!..

...Төнлә яшенле яңгыр яуды. Мунча кереп кайткан Тәхау белән Хәкимә кече өйдә йокламый яталар. Уллары олы якта. Хәкимә, күк чатнаган саен сискәнеп, йөзен иренең култык астына яшерә. Тәхауның киң күкрәгендә аның күз яшьләре кибә. Әле генә ул аңа үзенең беренче һәм соңгы хикәясен укып күрсәтте. Яңгыр, агачлар шавы, күк күкрәве, яшен чаткыларына кушып укыды Тәхау үз язганын.

— Сук әле миңа, карчык,— дип пышылдады ул.

Хәкимә, калтырап, аның күкрәгенә капланды:

— Син нәрсә? Тәхау, син нәрсә?

— Берне генә сук инде, карчык. Җәлләсәң, авырттырмый гына. Миңа шул да җитә.

— Тик торгандамы? Гомер булмаганнымы?

— Булсын әле бер.

— Икебезгә уртак булган бәхетнең үз өлешеңә тигәнен дә миңа биргәнең өченме?

— Үз өлешемне үземә алам мин. Сиңа соңгы тамчысы гына эләгә.

— Соңгы тамчы су иң җитмәгәне, иң кирәге... иң татлысы,— дип пышылдады Хәкимә, сулышы белән аның колагын кытыклап.

Ә яңгыр яуды да яуды, яшен яшьнәде дә яшьнәде.

— Шәп ява,— диде Хәкимә.

— Җир туярлык була.

— Ул туйса, без тук инде.

Беравык сүзсез генә тыңлап яттылар.

— Хикәяңне нишләтәсең?

Тәхау торып газ кабызды да, дәфтәрен урталай ачып, почмагына ут элде.

— Нишлисең?

— Янсын, карчык. Йөрәкне көйдереп тормасын.

— Кызганыч.

— Кызганычрак шул. Ә мин кызыкларын яратам аларның. Кызганычларын түгел.

Өйне тутырган сары ут шәүләсен яшеннең зәңгәрсу яктысы басып киткәли.

— Дөрес әйтәсең син, карчык. Янгын сүндерүче — янгын сүндерүче инде ул. Язучы түгел.

Ә олы яктагы телевизоф өстендә Тәхауны Шукшинның авыл китапханәсендә уналты мең дүрт йөз утыз җиденче сан белән йөргән кызыл тышлы китабы көтеп тора иде. Тәхау ул китапны язган кешенең язучы Шукшин булганчы тракторчы Вася булып йөргәнен иртәгә генә беләчәк.

*1978, май.*

## В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ ТУЛУГА, ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН ОЧЕРКЛАРДАН

«ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕ» КОНКУРСЫНА




Изаил Зарипов

# УРЕНГОЙНЫҢ АК БОЛАНЫ

## Мусин кодалый...



Бүлмәгә Мусин килеп керде.

— Арагызда балыкчылар бармы?— диде ул.

Уренгой экспедициясенең тәэминат базасындагы ир-атлар аны ничек аңларга да белмәде. Шаяртып әйтәме начальник, әллә чынлап та егетләрне балык тотарга алып чыгарга җыенамы? Йөзе җитди, уйнап сөйләшкәнгә охшамаган. Пур елгасы да әллә ни ерак түгел, балыгы күп диләр. Кармак-калкавыч ише нәрсәләрне һәрчак кесәләрендә йөртүче, «балык» дигән сүзне ишетүгә бөтен дөньяларын онытучы берничә ир Мусинга өмет белән карады.

— Боз астыннан балык тотарга кайсыгыз хирыс?— дип кабатлады Мусин.

Дүрт-биш кеше торып басты.

— Кая барабыз, Марат Гатуфович?

— Нәрсәгә каба икән хәзер?..

Болар — заманында Әлмәт якларында девон тирәнлекләрен штурмлаган бораулау осталары да, ял көннәрен кышын-җәен Кама буен-

да кармак салып утырырга өйрәнгән балыкчылар да иде. Уренгойга күченеп килгәндә, боз тишә торган бораударына хәтле алганнар, балык тотарга кирәкле бөтен нәрсәләре брезенттан тегелгән махсус капчыкта чишелмәгән килеш ята. Балык каптырып утырырга җай чыкмый, ә Мусин аны тапкан, күрәсең.

Озын буйлы, киң җилкәле бораулаучы Зелюнин бигрәк кызып китте.

— Боз тишә торган боравым да монда, Марат Гатуфович, — диде ул.

— Ал боравыңны, киттек.

Башка «балыкчылар» шаулаша башлады:

— Ә без, Марат Гатуфович?..

— Пурда безнең өчен урын тар мәллә?

— Сезнең белән бүтән чакта, егетләр, — диде Мусин. — Хәзергә икәү генә тәвәккәллик. Разведка шул булыр...

Трактор кабинасына чыгып утырдылар һәм кузгалып та киттеләр. Зелюнин артка борылып карады. Тракторга бер кран иярүен күреп алды.

— Ул да барамы? — диде Зелюнин, йөртүчене күздә тотып.

— Беләсеңме, нинди балыклар каба?.. Крансыз алырмын димә!..

— Арттырасыз, Марат Гатуфович.

— Күрерсең. Мин дә ышанмый идем.

— Ничә бәке кирәк булыр икән соң?

— Утыздан ким ярамый.

— Егетләрне дә алырга иде бит, Марат Гатуфович.

— Син үпкәләмә, туганкай, җитди эшне уен-көлкедән башладым, — диде Мусин бераз баргач. — Балык тотарга бармыйбыз без...

— Ә кая соң?

База начальнигы аңа көздән Пур елгасында боз әсирләрендә калган баржа торуын, шул баржада авырлыгы берничә тонна булган пневма чүкече ятуын, трактор белән автокранның шуны алырга баруын әйтте.

— Безнең өчен иң кыйммәтле балык — шул пневма чүкече! — диде ул. — Күреп торасың, шунсыз — экспедиция ике кулсыз.

— Ә бу нәрсәгә? — Зелюнин аяк очындагы боз тишкечкә тибеп куйды.

— Анысы да кирәк...

Әлмәттән Уренгойга күченеп килгән бораулаучылар арасында Марат Мусин — иң зур «стажлы» кеше. Институт тәмамлагач, Әлмәттәге бораулау җиһазлары төзәтү трестында механик булып эшләде. Себер туфрагына беренчеләрдән булып 1972 елда аяк басты. Килеп җитүенә, муеннан мәшәкатькә чумды — аны Медвежье төбәгендә газ ятмаларын үзләштерергә җибәрделәр. Ул инде Ныда дигән урында җыйнак кына йорт-җир дә корып җибәргән иде, оясыннан тагын кузгаттылар. Төньяккарак — Пангодага күчерделәр. Хатыны Мәрхәбә Ныдадан Әлмәткә кайтып китте. «Малай алып килергә!» Бу якларда бала табу йорты юк, нишлисең, озатырга туры килде. «Туп-туры Пангодага кайтырсың», — дип калды. Мәрхәбә өч айлык баласын күтәреп Пангодага килеп төшсә — Мараты анда да юк иде инде.

— Уренгойда, — диделәр.

Тынгысыз картын Мәрхәбә шунда килеп кочты, яңа урында яңа «куыш» корырга тотынды. Бәбиләре төньяк һавасына күнекте, чирлорны белми, туп кебек тәгәрәп үсә. Күз генә тимәсен!

Уренгой экспедициясенең начальнигы итеп билгеләнгән Александр Подберезный Әлмәттә эшләгән чакта ук Мусинны яхшы белә иде.

Оештыру сәләте бар, эшкә тиз төшенә, бораулауның бөтен нечкәлекләрен өйрәнгән. Теория ягы да төпле. Шуларның барысын да исәпкә алгандыр инде, Маратны һич икеләнүсез иң җаваплы урынга — экспедициядә производствоны тәэмин итү базасының башлыгы итеп билгеләде. Тавык та чүпләп бетермәслек мәшәкатьләрдән гыйбарәт булган бу хезмәт Мусинны өермәдәй бөтереп кенә алды.

Ул, эшкә тотыну белән, кайда ни барын, кайсы участокка ни җитмәвен барлады. Барыннан югы күбрәк иде, әлбәттә. Иң авыр һәм катлаулы участок — торба бораулагычларны төзәтү цехы. Автомат ачкычлар, кишτәләр, стендлар җитми, забойга төшерелә торган двигательләр аз. Цех бинасы кечкенә, анда хезмәтне механикалаштыру, җиһазлар урнаштыру мөмкинлекләре аз.

Уренгой газ ятмаларында җир катламнары кайракка ярардай каты комлы. Беренче скважинаны бораулларга керешкәч үк, базага төзәтергә дигән турбобурлар агыла башлады. Аларның иң явыз дошманы — шул ком. Борауны ашый, аерым төен-тоташмаларга, детальләргә тула. Вакытында карап, чистартып, ремонтлап өлгермәсәң, турбобур бик тиз сафтан чыга. Цехта аларны идәнгә урнаштырып, кулдан төзәтәләр иде. Бораулау эшләре киңәя барган саен, коллектив аларны төзәтеп-көйләп өлгерә алмый башлады.

Мусин шундый шартларда киләчәккә күз салып фикер йөртте. Һәм Әлмәтне күз алдына китерде. Андагы турбобур цехы — чын индустрия предприятиесе. Мусин аның башлыгы иде. Станоклар камил, кулдан башкарыла торган бер генә эш тә юк. Татарстан нефтьчеләре вышкаларны сүтмичә күчерергә тотынгач, Кершенбаум күтәргече дигән нәрсә дә кирәксезгә чыкты. Әлмәттә чакта шуны металл ватыгына тапшырырга кулы күтәрелмәде Мусинның. «Музейга куярлар бәлки», дип уйлаган иде. Нефтьчеләргә күп еллар хезмәт иткән механизмнарның соңгы бер данәсе иде диярлек. Себердә Маратның фикере үзгәрде: «Эх, булсын иде хәзер шул Кершенбаум күтәргече!» Кадерен белерләр иде! Бу хакта экспедиция начальнигы белән сөйләшкәч, Подберезный аның фикерен хуплады.

— Әлмәткә бар. Эшкә ярарлык тимер-томырлар тапмассыңмы шунда.

Әлмәт бораулау идарәсенең баш инженеры Рәшит Хәсәнович Фәткуллин якташын ачык каршылады. Маратның җавапларыннан, тел төбеннән Фәткуллин аның Әлмәттәге коллегаларыннан кайбер нәрсәләр «эләктереп» килүен абайламады түгел. «Безнең Уренгойда болар әлегә юк, фәләне юк, төгәне җитенкерәми», ди Мусин. Фәткуллин да аның хәленә керә: бүген Уренгойда эшләсәләр дә, әлмәтнекеләр ләбаса алар, ничек булышмыйсың? Аннары тагын дәүләт мәнфәгатен олылау да шуны таләп итә. Ярдәм итсәң икән — гомуми эш ота, илдә газ һәм нефть чыгару арта. Монысы инде «үземнеке — үзәктә» дигән караштан өстен. Шуларны уйлый Фәткуллин һәм Мусинны килгән саен буш кул белән кайтармый. «Бу кадәр тимер-томырны шундый ерак җиргә ничек җиткерерсез икән соң?» дип, коллегасын кызганып та куя.

— Булсын гына, безгә шөреп тә кыйммәт.

Фәткуллин сараңланмады. Тик кунак Кершенбаум күтәргече турында сүз кузгаткач, гаҗәпләнүен сиздерде:

— Хан заманыннан калган техника бит инде ул!

— Булсаңи, иске яңаны саклый, — диде Мусин. — Без аны яңача файдаланырга җыенабыз.

— Тагын ни кирәк?

— Ике кеше. Оста турбинчы, бик шәп бораулаучы. Безнең экспедициягә күчертеп алыр идек.

— Остасы да, шәбе дә кирәк шул сезгә.— Фәткуллин уйга калды.

Мусин сораган һөнәр ияләре Әлмәт бораулау идарәсенең үзендә дә артып ятмый. Иң уңган эшчеләрне, иң белемле инженерларны, иң оста бораулаучыларны сорый Уренгой. Җибәрмәсәң — Себердә эшләүчеләргә кыен, җибәрсәң — үзең авыр хәлдә каласың. Алай да үтенеченә колак салалар. Әзерлекле белгечләрне Әлмәт бирмәсә, Уренгой хәзинәләрен үзләштерүдә кыенлыклар тагын да артачак.

— Әрсез кода син, Марат,— диде Фәткуллин.— Кайткан саен — ике-өч кеше.

— Чакырабыз икән — димәк ышанабыз. Зур эшкә чын осталар кирәк, беләсең.

Төмән якларында Татарстан бораулаучыларын күтәреп алгандай итәләр. Безнең якташлар умыртып эшли. «Тюменгазпром» Бөтенсоюз промышленность берләшмәсе начальнигының бораулау эшләре буенча урынбасары Леонид Анатольевич Строгальщиков болай ди:

— Әлмәт, гомумән, Татарстан белгечләренә зур ихтирам белән карыйбыз. Яхшы әзерлекле кешеләр, эш яраталар. Себер шартларына тиз күнегәләр. Һәр яктан җитешкән кадрлар. Татарстанда башлаган новаторлык традицияләрен дәвам иттерәләр. Монысы бик әһәмиятле. Хәзер Обь елгасы буенда эшләүче бораулау осталары «Татнефть»тә сыналган алымнар кулланалар...

Мусин белгечләрнең нәкъ шундыйларын «кодалый» да инде. Уренгойга идарә күчергән кадрлар белән генә дә чикләнмәс әле ул — күптәнге таныш-белешләре арасыннан тагын берничә белгечне «үз теләкләре белән» Уренгойга күчәргә күндерер. Тегеләре, Мусин китеп атна-ун көн үткәч, идарә начальнигына гариза кертерләр. Кесәләрендә Подберезный кул куйган чакыру кәгазьләре булачак. Мусинның Әлмәткә һәр сәяхәте шулай тәгәлләнә. Үзара гына сөйләшкән чакта, шаяртып, аңа «Себер кодасы» дип тә эндәшкәлиләр. Әлмәт бораулау идарәсенә килеп кергәнче үк, ул инде үзенә кирәкле кешеләр белән очрашып сөйләшкән була. Әлбәттә, аларны хәзер үк Уренгойга җибәрегез дип үтенсә дә, аңа каршы төшмәсләр иде. Ләкин Мусин да кунак йоласын саклаган була — тыйнак кына сөйләшә.

Марат Мусин Әлмәттә үткәргән көннәрендә бик күп дуслары-танышлары белән очрашты. Кем белән сөйләшсә дә, кая гына барса да — Уренгой экспедициясе өчен кирәкле нәрсәләрнең эзен җуймады, аларны онытмады. «Ни хәлләр бар?» — дип күрешкән-сөйләшкән арада, бер иптәшеннән ул фәлән-фәлән җирдә редуктор барлыгын белеп ала. Өч-дүрт көннән редукторны Уренгойга озаталар.

«Татнефть» берләшмәсендә Мусин баш механик Эскин белән шактый озак гәпләште. Сүз уңаеннан гына әйтеп куйды:

— Бездә буровой өчен бик әйбәт автомат ачкычлар бар, ул яктан җаным тыныч ичмасам...

Кыек атып, төз тидерәсен белә ул: нәкъ шушы чакларда Татарстан нефтьчеләре шундый ачкычларга мохтаҗ иде. Баш механик утырган урыныннан сикереп торды:

— Безгә дә өлеш чыгара алмыйсызмы соң шулардан, Марат Гатуфович?

— Була ул! Барын уртаклашу кыен түгел, югын табу авыр. Миңа менә провенторлар кирәк.

— Алары бездә бар.

Провентор дигәне Уренгой экспедициясенә бик кирәк иде, чөнки шунсыз газ ятмаларын бораулау мөмкин түгел. Скважинада ул юк икән — газ дулый башлый, җир астыннан ыргылып чыга да, бөтен җиһазларыңны пыран-заран китерә. Шундый кирәкле «тимер кисәге» алып китте Мусин.

## «Җилкенеп аласыңмы, якташ?»

Уренгой экспедициясе базасына фондтан тыш кергән эш кораллары, детальләр, җиһазлар барыннан да бигрәк базаның баш механигы Юрий Анатольевич Лукинны сөендерә иде.

Лукин — җир асты хәзинәләренә юл яру эшенә бөтен гомерен багышлаган кеше. Үзе турында тешен агартырга яратмас, ләкин эшеннән бик канәгать булган чакларында әйтер:

— Яратам. Бораулаучы һөнәре миңа әтидән калган мирас, — дияр.

Заманында аның атасы Татарстандагы нефть ятмаларын үзләштерүгә бар көчен, белемен, осталыгын биргән. Тынгысызлыгын, осталыгын улына да күчерә алган. Әлмәттә бораулау идарәсенең производствоны тәэмин итү базасында механик булып йөргәндә үк инде Юрий Лукин тыелгысыз дәрт, гаҗәеп тырышлык һәм ялкын белән эшли белүен күрсәтте. Үз дигәненә ирешә, башлаган шөгылен ахырына җиткерми тынычланмый. Бер вакытта да кызып китмәс, сабырлыкның сары алтын булуын онытмас. Нинди генә четерекле хәл килеп чыкмасын — Лукин аннан котылу юлын таба. Өстенә җаваплылык алудан курыкмый.

Марат Мусин Медвежье газ ятмалары мәйданын үзләштерергә киткән чакта аның шул сыйфатларын искә төшергән иде. «Себергә Юрий Анатольевич кебек кешеләр кирәк», — дип уйлады ул. Уйлаганы — кылганы дигәндәй, аны үз янына эшкә кодалады.

Пангодада алар бер җан булып эшләделәр. Уренгойда да яңа базаны бергә оештырдылар, авырлыкларын бергә күтәрделәр. Нәкъ шул вакытта Лукин турбобурлар төзәтүдә редуктордан файдаланырга тәкъдим итте. Уен тормышка ашырырга керешге. Вакыт белән исәпләшмәде. Башлаган эшен тәмамлап куйгач кына, үз-үзеннән һәм иптәшләреннән канәгать булып, ләкин моны бирәүгә дә сиздермәскә тырышып, Юрий Анатольевич бер-ике көн ял итә иде. Карыйсың, ул инде яңа эш тапкан һәм, мөкиббән китеп, шуны башкара.

Татарстан нефтьчеләре бүләк иткән редуктор Уренгойда турбобурлар төзәтүдә хезмәтне бик күпкә җиңеләйтүче җайланмага әверелде. Моны да Лукин булдырды. Уйлаганы тормышка ашкач, үзенең дә башы түшәмгә тиде. Цехта эшләп торган редукторга елмаеп карады, канәгатьләнүен белдереп, гадәтенчә, тамак кыргалады. Һәм цехта эшләүчеләрнең барысы да моны үз хезмәтләренә мактау дип кабул иттеләр.

Татарстаннан килгән Кершенбаум күтәргече дә зур эшкә ярады. Турбиннар төзәтү цехының стеналарын шуның белән күтәрделәр, нигезне биегрәк итеп салдылар. Стеналар да киңәеп киткәндәй тоелды. Монда хәзер кул хезмәтен механикалаштыру җайланмаларын сыйдырырга, производство җиһазларын уңайлырак итеп урнаштырырга җай туды.

Лукин — урта буйлы, юанрак гәүдәле, өлкән яшьтәге кеше — сабан туенда бил алышырга чыккан көрәшче егеттәй җилкенеп, цех уртасына басты да инде шактый пеләшләнгән башын капшады һәм ике кулын да өскә, түшәмгә таба сузды.

— Күрдеңме? Иркен, биек! Ягез, егетләр, машиналарның бөтенесенә дә җан кертик әле.

Ремонтчылар дәррәү эшкә тотынды — технологик җиһазларны көйләде. Берничә көннән, редуктор инде бөтен куәтенә эшли башлагач, Лукин цехта иң осталардан саналган токарь Софьян янына килде.

— Үткәннәрне искә төшереп, бер җилкенеп аласыңмы әллә, якташ? — диде ул аңа. — Берәр нәрсә уйлап тап шунда, сызгалап кара,

Павел Григорьевич, ә?.. Турбиннарны Әлмәттәге кебек, әйләндереп кенә чыгарырлык булсын, мәйтәм. Уйлап карарсың бит? Әлмәткә командировка кирәк дисәң — анысы да булыр.

Лукин токарьга кайсы яктан суктырырга белә. Павел Софьин Әлмәт якларында туып-үскән кеше түгел, шулай да аның өчен бик истәлекле булган хезмәт еллары шунда, нефть башкаласында үткән. Әлмәттә ул бик актив рационализатор булып танылган иде. Мактама бораулау конторасында эшләгәндә ул турбобурларны тоташтыру һәм аерып алу өчен бик уңайлы җайланма уйлап тапкан иде. Аның рационализаторлык тәкъдиме забой двигательләрен төзәтү вакытын күпкә кыскартты. Лукин шуны искә төшерә.

Токарь, аның киңәшенә колак салып, чынлап та, җилкенеп алды. Мактамада уйлап тапкан җайланмасын тагын да камилләштерә төшеп, яңасын эшләп бирде, ремонтчыларны кинәндерде. Турбобурларны төзәтү бермә-бер тизләште.

Турбиннар цехында эшләр азмы-күпме җайлангач, барысының да игътибары тимерчелеккә юнәлде. Бу цехны вакытлы гына булыр дип тотынганнар иде — шөгыленә керешкәч, күп еллар буе эшләрлек бина булып чыкты. Бер ягы начар — кувалда белән эш итәләр, пневма чүкече юк. Лукинның уенда да шул икән. Бер көнне ул Мусинга:

— Сукканда тундраны дер китererлек чүкеч табасы иде, Марат Гатуфович,— диде.

— Үземнең дә төшкә керә,— дип җавап бирде Марат.— Тик кайдан табасы да, ничек Уренгойга китертәсе.

— Чын күңелдән еласаң, сукыр күздән яшь чыга, диме әле сезнең халык?

Лукин белән сөйләшү Мусинны уйга салды. «Табарга кирәк!» — дип карар итте ул һәм Мәскәүгә пневма чүкече юлларга китте.

Башкалада аңа иске танышы — элек Әлмәттә бергә эшләгән коллегасы булышты. Буровойдан министрлык аппаратына күтәрелгән бу кеше бораулаучыларның ихтыяҗын яхшы белә, Себердә газ ятмаларын үзләштерүчеләргә кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә әзер тора. Уренгой экспедициясенә ярардай унбиш тонналык чүкечне Воронеждан таптылар. Министрлыктан тиешле оешмаларга аны бик тиз озатырга һәм Пур елгасы буенда урнашкан Уренгой базасына җиткерергә күрсәтмә бирелде.

Марат Гатуфович Мәскәүдән эзләгәнен табып кайтты, ләкин пневма чүкече узасы юл озын иде әле. Аны Воронеждан Төмәнгә җибәрделәр, ә соңрак баржага салып, Обь елгасы буйлап сәяхәткә чыгардылар. Су юллары ябылса, бу эш тоткарланачак иде.

Шулай булып та чыкты. Елга туңды. Чүкечне алып килүче баржа Самбург тирәләрендә тукталып калды. Моннан экспедиция базасына күп дигәндә йөз чакрым, әмма шуны үтү өчен тугыз ай чамасы көтәргә туры киләчәк икән!

— Көтмибез,— диде Лукин.— Карап кайтыйм әле шул баржаны.

Икенче көнне үк вертолет Лукинны Самбургка алып китте. Боланчылык совхозы янындагы мәйданчыкка утырдылар. Вертолеттан төшеп, шыгырдап торган карга аяк басарга өлгермәде Лукин — янына берничә ненец һәм милиция капитаны килеп басты.

— Документларыгыз!..

Юрий Анатольевичның паспортын карый башлагач, яшь капитанның кырыс чырае ачылып китте.

— Якташ та икәнсез,— дип сүз башлады ул.— Мин дә Татарстаннан. Алабуга милиция мәктәбеннән җибәрделәр.

— Алабугада милиция мәктәбен тәмамлаган якташ, сез башта миңа шуны аңлатып бирегез: ни өчен мине болай каршылыйсыз?

— Гафу итегез. Мине болан караучылар чакырган иде. Менә бу иптәшләр.— Ул ненецларга ымлады.— Бер ак боланны браконьерлар аткан. Җирле халык уренгойлылардан шикләнә.

Лукин хәлне аңлап алды. Берничә көн элек Уренгойдан һәвәскәр аучылар, вездеходка утырып, ак төлке эзләп чыккан иде. Ләкин бу житез җәнлекне гомер буе аучылык иткән ненецлар, хантлар һәм мансилар да тиз генә эләктерә алмый. Билгеле инде, Әлмәт якларында куяннан башка киек күрмәгән бу «аучылар» борыннарын салындырып коры кул белән кайтырга борыла. Шулчак якындагы үр артында мылтык гөрселди. Вездеход шул якка ыргыла. Үр өстенә күтәрелгәндә этләр җигелгән бер чана, кар бураны туздырып, икенче калкулык артына кереп күздән югалганын гына күреп калалар. Ә вездеход болан эзләре буйлап китә.

Ике үр арасындагы уйсулыкта ак болан ята. Тирә-ягындагы кар алланган. «Аучылар» вездеходтан төшеп, аның янына үк килделәр. Болан, башын күтәреп, әле генә дөньяга килгән баласына карарга гына өлгерде, шундук танавы белән карга төртелеп, тынып калды. Ә хәлсез бозау аның салкын җилененә үрелә, сөт эзли... Яңа туган боланның тиресе кыйммәт йөри — шуны чамалагандыр, кабахәт җан! Ана боланның бозавын ялап бетергәнен көткән, шуннан соң гына аткан. Пычак тотып яңа туган җан иясенә ташланырга торганда гына вездеход тавышы аның ниятен өзгән.

Күз алларында ап-ак мәһабәт боланның башы кар өстенә салынып төшүен, әле генә дөньяга килгән көчсез, хәлсез болан сабыеның дерелдәп торуын күргән кешеләр боегып калды. Аучыларның берсе, иңеннән ике көпшәле мылтыкны салды да вездеходның корыч чылбырына орды. Мылтык түтәсе чәлпәрәмә килде, ә көпшәсен аучы читкә ыргытып бәрде.

Ак болан бозавын, җылы тунга төреп, машинага салдылар һәм поселокка алып кайттылар.

Лукин моны ишеткән иде, ләкин болан баласын карарга бара алмады — вакыт тимәде. Ә поселок халкы, бигрәк тә хатын-кызлар, үксез бозауга куертылган сөт ташый, сыек ботка пешерә. Тик болан баласы берни ашамый, эчми. Аңа сөт кирәк, ана сөте!..

Болан караучылар шул кечкенә болан баласын эзли икән. Ненецларның берсе — Солиндер исемле иде ул — Лукин каршына басты да:

— Кайтар безгә болан баласын!— диде.— Кайтар! Сезнең кулда яшәми ул, үлә. Аңа болан сөте кирәк...

Милиция капитаны да Лукинга карап тора: ни әйтер, янәсе.

— Болан баласының кайда икәнен беләм, Солиндер,— диде ул.— Уренгойга алып кайтканнар аны. Ант эчәм: сезгә кайтарырлар ятимне. Юк, үзем алып килермен!..

Йөзләр яктырып китте. Милиция капитаны болан караучыларга борылды. Сүз әйтмәде әйтүен, әмма бөтен кыяфәте: «Күрдегезме инде, Уренгойда нинди яхшы кешеләр яши!» дигән төсле иде.

Ненецлар Лукинны кунак итте, аннары болан көтүе йөргән урынга алып бардылар. Лукин Пур елгасы буена төшеп китте. Бозлар арасында кысылып, кечерәеп калган баржаны карады, аны урап чыкты. Кайсы яктан, нинди транспорт белән килергә кирәген чамалады, бозның калынлыгын үлчәде. Тырышкан Себер суыгы! Баржа тирәсендә боз катлавы метр ярымнан артыграк иде.

Икенче көнне генә вертолет аны алырга килде. Шул ук мәйданчыктан күтәрелеп киткәндә Лукин тагын ак болан баласын күз алдына китерде. Кайда икән ул хәзер?.. Исән генә була күрсен! Совхозга кайтарып куячак ул аны, һичшиксез, кайтарачак! Ләкин экспедициягә кайткач, Юрий Анатольевич бу хакта теш агартмады,

баржа турында гына хәбәр итте. Аннан пневма чүкечен алып чыгу мөмкинлеген әйтте.

Мусин белән Зелюнин шул эшне үтәргә баралар да инде.

Вездеход артында, кар каплаган киңлектә, корыч чылбыр эзләре сузылып кала. Марат бу якларда беренче вышкалар күчергән чакларны искә төшерә.

Вышкаларны Надымнан күчерделәр алар. Түбәләре болытка тиеп торган ул тимер алыпларны беркайчан да, дөньяның бер илендә дә мондый ерак арага күчергән осталар юк. Ә болар — Әлмәттән килгән бораулаучылар — шундый зур эшкә һич икеләнмичә җөрьәт итте. Күктә төньяк балкышы уйнаган, җир өстен ап-ак кар каплаган мәңге туң тундра буйлап дистәләгән трактор моторларының куәтле гөрелтесе яңгырады. Юл ерак, юл билгесез, юл авыр! Һәр якта — ап-ак кар диңгезе генә. Кайда коры җир дә, кайда сазлык — аерырлык түгел. Сазлыклар аша үткәндә боз түзәрме, тракторлар батмасмы? Вышка ауса, ни кылырсың? Кыскасы, шикләр күп төрле, җавап юк. Алар — беренче булып юл яручылар.

Поляр көн ярты тотам гына. Кояш күренеп ала да, теләр-теләмәс кенә түбәнәя һәм кисәк бата. Ул яктыртып торган арада, күп булса, өч-дүрт чакрым үтәсең. Юлда туктап, җиһазларны барларга, тросларның ныклыгын тикшерергә туры килә. Һәр көнне кич белән Лукин, вышка күчерүчеләрдән алгарак чыгып, төнге ял өчен урын эзли. Учак ягасы җир күл өстенә яки сазлыкка туры килмәсен — шуны карый. Тундрада бөтенесенә әзер булырга кирәк.

Өч көн буена экспедиция юлында ник бер җан иясе очрасын! Вакыт-вакыт күңелгә шом төшә. Булырмы бу бушлыкның чиге? — дип уйлый башлыйсың. Көннәрнең берендә вышка монтажлаучыларның берсе шатланып кычкырды:

— Карагыз, күк төлкеләр!..

Бораулаучылар да җәнлекләрне күреп алды. Алар вышка янәшәсендә теркелдиләр иде. Үкереп алга үрләгән тракторларга, очы күккә терәлгән вышкага гаҗәпләнгәндәй, текәлеп карап торалар. Ул да түгел, каршыга төшеп, тагын туктыйлар. Тундра сылулары озак бармадылар, күрендек — шул җиткән дигән сыман, поляр шәфәкъ нурларында эреп киткәндәй, юкка да чыктылар.

Күк төлкеләренең болай сәяхәт итүен бу якларда язның иртә килүенә юрыйлар. Әгәр шулай икән, аларның очравы экспедициягә бернинди сөенеч вәгъдә итми. Аяк асты йомшарса, газ ятмалары табылган Уренгой төбәгенә барып җитә алмавың ихтимал. Үтәсе юл ерак әле, башкарасы эшнең очы-кырые күренми. Базаны да шунда корырга ният иттеләр. Вышка монтажлау бригадасы оештырылачак, бораулаучылар коллективы тупланачак. Беренче скважиналарны кору урыннарын билгеләргә кирәк. Тундрада монысы да четерекле: кышкы суыкларда эшләрсең эшләвен, ә җәен бөтен корылмаларың сазлыкка чумса?.. Барысын да алдан күрергә — бурыч шундый. Экспедиция үзенең бер эшен дә җилгә җибәрә алмый, аның һәр адымы төгәл булырга тиеш. Мусинны озатканда Подберезный моны тагын бер кат кисәтеп әйтте.

— Сезнең эздән иң кирәкле җиһазлар барачак, бораулау кораллары ташылыр. Кешеләр торырлык вагоннар илтербез. Туң эреп өлгергәнче бораулауны да башлап җибәрергә иде...

Шундый зур эшләр, олы ниятләр белән бара экспедиция.

## «Кирәкми, Уренгой, йөрмә!..»

Экспедиция начальнигы Уренгой газ ятмаларын үзләштерүдә җирле халык та катнашыр дип өметләнә иде. Татарстанда шулай булды бит. Әләзәр егетләре гаҗәп тиз арада бораулаучы, вышка коручы-

га әверелде. «Кара алтын» чыгару серләренә төшенеп, рекордлар куйдылар. Шулар осталыгына таянып әшләде Подберезный, бөтен Татарстанга мәшһүр, илгә танылган бораулаучы булып җитеште.

Көнбатыш Себердә — Нижневартовский, Нефтеюганский, Сургут һәм башка районнарда да хантлар һәм мансилар буровойларга эшкә килде. Уренгойда өмет акланмады. Җирле халык Уренгойны каргалган, каһәрле, убырлы җир дип саный икән. Вышка күчергәндә булган бер очрашу шуны раслады.

... Лукин, гадәттәгечә, кунар урын сайларга китеп барды. Көн шундый — тәүлекнең кайсы вакыты икәнен дә өзеп әйтерлек түгел. Күктә ни ай, ни кояш. Вездеход фараларыннан төшкән яктылык җәяүле буранның аксыл дулкыннарында тирбәлә. Шул дулкыннар арасында Лукин түмгәктәй калкып торган кар өемнәре күреп алды. Шуларның берсе янында машинаны туктатты. Лукин аһ итте. Кар астында кеше ята ич. Шоферга кул изәп, кар өеменә иелгән иде — каршысына ненец торып басты.

— Ни атаң башына йөрисең монда йокы бүлдереп!— диде ул, тозлы-бурычлы сүзләр кушып.

— Туңып үләсең ич, — аптыраудан бүтән сүз таба алмады Лукин. — Туңып үләсең!..

Ненец, хант һәм мансиларның карга күмелеп, табигать үзе биргән ак юрганны ябынып, шулай әче суыкларда йоклый алуы, туңудан саклануы турында ишеткәне бар иде аның. Әмма моңа бигүк ышанып җитми иде.

— Үзең туңарсың, мин туңмыйм!— диде ненец.— Мин арган, этләр алҗыган. Йокыбыз килә. Сиңа тундрада урын җитмиме әллә? Юлыңда бул, этләрне уятма! Өшерләр...

Түмгәккә охшаган элеге өемнәрнең башкалары этләрне каплаган кар икән.

— Исемең кем синең? — дип сорады Лукин.

— Солиндер.

— Уренгойга моннан еракмы, Солиндер?

— Ике көнлек юл...— Кинәт ненецны алыштырып куйдылар диярсең. Ул кулларын бутый-бутый, нәрсәдәндер шомланган шикелле, пышылдарга кереште: — йөрмә Уренгойга!.. Яман җир — Уренгой. Хәтәр җир!.. Безнең аучыларның башын ашый, көтүчеләрне бетерә... Боланнарны адаштыра. Барма син, барма Уренгойга!..

Солиндер, сиңа әйтергә теләгәнем шул иде, калганы үз ихтыярың, дигәндәй, кул селтәде дә, карга чумды. Шундук йоклап та китте.

Төнге ялга туктагач, бораулаучылар бу очрашу турында шактый озак гәпләштеләр.

— Тундрада кар өеме күрсәң дә сәлам биреп уз, Юрий Анатольевич, — диде бер шаяны. — Ник дисәң, ул көртнең кешегә әверелүе ихтимал.

Лукинның мыегы да селкенмәде. Ул мәсьәләнең җитдирәк ягын уйлый иде.

— Болай булгач, җирле халыктан кадрлар таба алмабыз.

— Уренгойда убыр юклыгын расларга кирәк, — диде Марат Гатуфович. — Килерләр.

Тундра төненең караңгы кочагында учак яна. Аның тирәсендә бер төркем кеше. Тирә-юньдә шомлы тынлык. Кайсы тарафка юнәлсәң дә калын кар катламы астында җансыз яткан мәңгелек туң җирләр. Уренгой дигәннәре хәтәр җилләр оясы да икән әле. Кешеләрнең шомланулары нигезсез дә түгел: иң кыю аучыларны адаштырып, иң чыдам этләрне дә бер мизгелдә бозга әвереллерә торган зәмһәрирләре, күз ачыргысыз өермәләре куркыныч икән Уренгойның. Сирәк-

мирәк кенә утырган кәрлә агачлар тавыш-тынсыз гына: түзәрме бу адәм затлары, әллә монда хакимлек итүче Суык белән Җил алардан көчлерәк булырмы? — дигәндәй сынап карыйлар шикелле.

Таң атты — экспедициянең Уренгой җирендәге беренче таңы.

Кәрлә агачлар җилдә тирбәлә, башларын селкетә: күрсәнә, китми бит кешеләр! Тагын күпме түзәрләр икән?..

Кырык баһадирдай кырык бораулаучы тундрадагы иң хәтәр җиргә казыклар какты. Монда поселок булачак, монда Уренгой экспедициясе урнаша! Моңарчы беркайчан ишетелмәгән тавышлар яңгырады, металл чыңлады, моторлар гүләде. Кешеләр палаткалар корды. Суык һәм Җилгә бирешмичә, үз эшләрен башкардылар.

Булды, барысы да булды — суыклары да, җилләре дә. Әмма кешеләр бирешмәде. Надымнан җылытылган вагоннар алынды, рәт-рәт тезелеп, җилгә каршы басты. Бораулаучыларның тагын бер төркеме Уренгойга килеп җитте. Аларны инде рәсми кәгазьләрдә «Уренгой бораулау экспедициясе» дип атый башладылар. Беренче тапкыр бу атаманы 1975 елның 4 апрелендә телгә алдылар. Шул көнне экспедициягә план да җиткерелде: ел ахырына кадәр биш мең метр җир катламы бораурларга!

Уренгойда зур эшләр шулай башланды. Хәзер инде бораулау көе айдан-айга кызулый бара. База цехларына да җиһазлар табыла тора. Менә пневма чүкечен дә алып кайтсалар...

*
* *

Пурда Зелюнинның боз тишә торган боравына эш җитәрлек булды. Баржа тирәсендә утыз ике бәке уйдылар. Шунсыз автокран баржадагы йөккә сузыла алмый иде. Пневма чүкечен сүтеп, ике өлешкә бүлгәч, автокран аларны боз өстенә төшерде.

— Менә бу балык! — диде Марат. Зелюнин бу юлы аңа үпкәләмәде.

— Егетләр дә сөенер инде, — дип, шаяртуга уен сүз белән җавап бирде.

Ниһаять, чүкеч — йөк машиналарында. «Балыкчылар» кайту юлына кузгалды.

Ике көннән Уренгойга кайтып җиттеләр. Мусин туп-туры Лукинга килде.

— Өмет синдә, Юрий Анатольевич. Күрсәт кодрәтеңне, тизрәк урнаштыр шул пневманы.

— Карарбыз, Марат Гатуфович... Җиңеп кайтуыгыз белән котлыйм! Шул чүкечне цехта урнаштырып, гөрселдәтеп бер суктырабыз әле, Марат Гатуфович. Чыңы бөтен тундраны уятырлык булыр!

Боланчылык совхозында булып кайтканнан соң, аның күңелендә тагын бер хыял кабынды. Ничәмә-ничә мең чакрым ераклыктан кайтарылган, кырыкмаса-кырык мәшәкать белән Уренгойга җиткерелгән шул чүкечне урнаштырыр да Лукин, эшләтеп карар, аның тавышын тыңлар. Шуннан соң үксез болан баласын алып, совхозга китәр. Самбургка. Анда Солиндер көтә аны, болан караучылар көтә. Юрий Анатольевич илтеп тапшырган болан бозавы бер заман бик матур, мәһабәт булып үсеп җитәр. Ненецлар аны зур бәйрәмгә — боланнар чабышына алып чыгар. Тантанага Лукинны да чакырырлар, әлбәттә. Шунда әлеге ак болан беренчелекне алыр. Экспедиция кешеләре дә күрер аның көчен, матурлыгын, елгырлыгын.

Киләчәкне, нигәдер, ак болан белән бәйләнештә күрә башлады Лукин. Пневма чүкечен тимерчелек цехына урнаштырып, көйләп йөргән хезмәттәшләренә дә сөйләде бу хыялын.

Себердә Татарстаннан килгән бораулаучылардан, монтажчылардан берәү дә характеристика-мазар сорап тормый. «Мин — Әлмәттән», «Мин — Баулыдан» дигән сүзләр җитә. Ләкин моны дөрес аңларга кирәк. Безнең кешеләр мондый ихтирамны эш рәтен белүләре, хезмәттәге фидакарьлекләре белән яуладылар.

Әлмәт якларыннан бер төркем бораулаучы килеп төшкәч, экспедиция җитәкчеләре мәҗлес оештырды.

— Зур эшкә тотыныр алдыннан, сезнең белән очрашу шатлыгын уртаклашу өчен, безгә Татарстаннан танылган осталар килү хөрмәтенә... — дип, табын башлыгы тост әйтергә генә керешкән иде, хәвефле хәбәр китерделәр.

— 213 нче буровойда авария!..

Мөлдерәп тулган касәләрне кире куйдык. Аварияның ниндирәк булуын сораштык. Моңарчы тел дә тибрәтми утырган Фәхразый Юнысов:

— Киттек, егетләр, буровойга! — диде.

Ник берсе калсын. Буровойны беренче күрүебез, аның холкын белмибез. Эш режимын сораштык инде анысы. Әмма чын бораулаучы скважинаның кайсы төшендә ни барын күңел күзе белән күрә. Җилкенеп эшләдек. Татарстан буровойларында мәйдан тоткан осталар бөтенләй таныш булмаган урында да могҗиза күрсәттеләр. Гаҗәпләнерлек тә түгел. Бораулау эшенең аслары җыелды бит. Мөҗәһит Кашапов, Павел Софьин, Фәхразый Юнысов, Александр Краснов, Мәхмүт Мотыйгуллин, Николай Столяров, Инсаф Хафизов, Михаил Петров — менә кемнәр! Берсе дә рәсми боерык белән эш урынына беркетелмәгән әле, ашыгыч ремонт үткәрергә дигән үтенеч тә, боерык та алмаган. Әйтерсең шул 213 нче буровой өчен барыбыз да җаваплы. Сәгатьләр үткәнен дә онытканбыз — өченче тәүлек башлангач кына Пангодага кайтып кердек.

Әлеге вакыйгадан соң да төрле четерекле хәлләрне аз кичермәдек. Әлмәттән килгән осталар кайчакларда шундый хәтәр аварияләрне бетерә — уйлап куясың: бу батырлык, бу фидакарьлек өчен бүләк бирсәләр дә урынлы. Шундый эшләрнең берсен гомердә онытасым юк. Башкортстаннан килгән Виктор Душин бригадасы бораулаган скважинада газ бер яктагы каплагычны ашаган. Шундый көч белән өскә атылып чыга — гүләве унбиш-егерме чакрымнан ишетелеп тора. Сәгать саен көчәя бара тагын. Теләсә кайсы мизгелдә шартлавы бар, ул чагында скважинадан тимер-томыр кисәкләре генә калачак.

Сургуттан махсус авария бригадасы килгәнче, газ шартлавын булдырмый калу өчен чаралар күрергә дип, Фәхразый Юнысов бригадасы китте. Үзләре теләп алындылар. Бу бригада Әлмәттән бөтен килеш килгән иде. Ике-өч сәгать буе шашкын көч белән тартышкач, иң хәвефле минут җитте. Кемдер газ гүләп торган скважинага керергә, көчле басымнан тимерләре дерелдәп торган арматура арасында капшанып йөрергә, ташкынны томаларга тиеш иде. Мондый чакта кешенең икеләнеп калуы да гаҗәп түгел. Берәүгә дә гомер ике килми. Бораулаучы Кашапов белән аның ярдәмчесе Галимов бер дә икеләнеп тормадылар — үкереп торган дәһшәтле арыслан авызына кереп киттеләр. Түбәннән, җир куеныннан ажгырып торган газ өстә суыктан куера, томан булып җәелә. Ул «томан» зәһәр, аның эчендә суларга һава җит-

ми. Кайда арматура, кайда каплагычы — барысын да капшанып эзләргә кирәк. Ике оста скважинаны каплап торган аксыл болытка кереп чумгач, тәннәребез эсселе-суыклы булып китте. Барыбыз да тынсыз калдык. Колакта — газ ташкынының дәһшәтле гүләве, күз алдында — шул зәһәр болыт. Ә күңелдә — ике иптәшебез... Мондый чакларда минутлар да бик әкрен уза икән. Һәр секунды җаныңны өшетеп, йөрәгеңне тырный. Өлгерерләрме егетләр ул котырган дию пәриенең авызын томаларга, әллә ул үзе... Юк, юк! Бу хакта уйлавы да авыр.

Ничә минут узгандыр — бер мәлне җир белән күкне тоташтырып торган газ болыты скважинадан аерылмасынмы! Гүләү авазы да тынып калды. Берничә реактив самолетның моторы берьюлы эшләүдән туктадымыни. Ләкин тынлыкның да алдаучан булуы мөмкин. Ниһаять, сыеклана башлаган болыт арасыннан ике кеше килеп чыкты. Барыбыз да котларга керештек.

Шул вакыйгадан соң себерлеләр, теге чакта өзелгән мәҗлесне дә искә төшереп, зур банкет оештырдылар. Коткару отряды командиры Васильев хәтәр чакта салкын канлы булса да, кулына гармун алгач, кайнарланып китте. Газ промыселлары идарәсе начальнигы Стрижов гитара чиртә. Ни җитте көй уйнамый — «Вена урманы әкияте»н сыздыра. Ул көйне мин скрипкада гына уйныйлар дип йөри идем — ялгышымны шунда гына аңладым. Үземнән дә җыру әйттерделәр — «Зөлфия»не җырладым. Тавышым ничек яңгырагандыр — анысын әйтә алмыйм, әмма мәҗлес халкы кулны җәлләмәде.

Якташларны кайда очратсаң да, күңелләр күтәрелеп китә. «Җан тартмаса да кан тарта» диләр бит. Ә алар шундый батыр да, уңган да, оста да, фидакарь дә булса — икеләтә күңелле. Монысы инде горурлык хисе уята торган очрашу.

Уренгойның кендеге хәзергә Татарстанның «кара алтын» башкаласы Әлмәткә бәйләнгән. Тирән бораулау экспедициясендә күбесенчә шуннан килгән осталар тупланды. Кайберәүләр, чын хәлне чамалап җитмәстән, моны үзләренчә юрап, экспедиция начальнигына төрттереп тә куйгалый. «Сез, иптәш Подберезный, кадрларны якташларыгыз арасыннан гына сайлыйсыз», янәсе. Андыйларга Подберезныйның җавабы мондый:

— Карачай-черкас өлкәсендә тудым мин, иптәшкәем. Грозный шәһәрендә укыдым. Краснодарда бораулаучы идем. Татарстан кешеләре белән якташ буламмы мин, юкмы?.. Хикмәт анда түгел, абзыкаем. Татарстанда эшләгән бораулаучыларның осталыгына мөкиббән кеше мин. Шул җәһәттән мин аларның якташы.

...Экспедиция базасының тимерчелек цехында пневма чүкечен монтажлау тәгәлләнеп килә иде инде. Лукин цехның төп куәтен үзенә туплаган шушы күп тонналы тимер йодрыкны ерактанрак карарга теләгәндәй, ишеккә таба атлады. Борылып, чүкечкә карады һәм ишек янагына тотынды. Нидер әйтергә теләгәндәй, кулын күтәрде һәм идәнгә чүкте. Иптәшләре йөгереп аның янына килгәндә ул инде соңгы сулышын ала иде.

Бораулаучылар аны соңгы юлга озаттылар. Аның табутын вертолетка күтәргәндә, тимерчелек цехындагы чүкеч беренче тапкыр гөрселдәде. Бу аваз, останың якты истәлеге булып, еракларга яңгырады. Лукинның бер хыялы тормышка ашмый калды — ул ак болан бозавын совхозга озатырга өлгерә алмады.

— Юрий Анатольевичның бу теләген үзем үтәрмен,— диде Мусин.

# Вертолет командиры

## Виктор Кузнецов хикәяте

Безнең экипаж Надымга очарга әзерләнгән иде. Кинәт һавалар бозылып китте. Көчле җил чыкты, тизлеге — секундка утыз метр. Суыгы да кырык градустан ашкан.

— Иртәгә очарбыз,— диделәр безгә. Ләкин икенче көнне дә җил йомшармады, буран тынмады. Атна-ун көн дуларга чамалый иде, күрәсең.

— Бер вертолет та очышка чыкмаячак,— дип белдерделәр безгә. Тик шул минутта ук рация шытырдый башлады, радист ашыга-ашыга нидер язарга тотынды. Беравыктан ул:

— Кичә Пангодадан кайтучы унлап машина юлда калган. Трассаны көрт баскан булса кирәк. Шоферлар һәм йөкчеләр бригадасы тундрада төн үткәргән,— диде.

Шәфкатьсез тундра әсирлегендә калган юлчыларга ярдәмгә ашыктык. Күтәрелеп китәргә, трасса буйлап узарга, хәлне ачыкларга рөхсәт сорадык. Дистәләгән кешене буран арасында калдырып булмый бит. Белмәссең, иртәгә һава тагын да яманрак булыр.

Пангода ягына очабыз. Өермә аша күзгә ак-кара күренми. Приборлар кышкы трассаның шушында гына булуын күрсәтә, ләкин юлны табу бик читен. Очу биеклеген һаман киметәбез, вертолет инде җиргә тияр-тимәс кенә бара. Берзаман ак кар диңгезендә төрле урында каралыбрак торган нокталар күренде. КРАЗлар бер-берсеннән икешәрөчәр чакрымда туктап калган. Бөрсе янында кар казыйлар. Алар вертолетка кул изи башладылар. Без дә сигнал бирдек: күрәбез, төшәрбез!

Юлдагы бөтен машиналарны барлап чыктык та кешеләрне бортка ала башладык. Бәхеткә каршы, берсе дә өшемәгән.

— Эреткеч лампалар коткарды,— диләр.— Шуларны дөрләтеп, КРАЗ кабиналарын җылыттык.

Шоферлар да, Себер йөкчеләре дә, гомумән, югалып кала торганнардан түгел. Ә безнең Уренгой егетләре исә — кылны кырыкка ярыр, буранны бау итеп ишәр азаматлар. Берсе безнең вертолет үзен алырга төшкәч, кабинадан зур кружка белән кайнар чәй алып чыкты.

— Яңа яуган карның суы бик йомшак, бик саф — ди,— татып карамыйсызмы, егетләр?

— Вертолетка утыр тизрәк! — диләр аңа. Ләкин ул җылыга керә посарга ашыкмады. Машинасына кайтып, лампасын алып килде. Вертолетка кергәч тә әйтә бу миңа:

— Әнә, алдагы машина янына төшәрсең әле.

— Ник?

— Аларга лампа калдырырга кирәк. Тундра хәлен белмәссең.

— Хәзер кайтып, аларны да алабыз бит,— дим. Ишетергә дә теләми.

— Алсагыз алырсыз, лампаны калдырыйк. Килә алмасагыз нишли алар? Әлмәт егетләре ич анда.

Шоферның кәефен җибәрәсебез килмәде: махсус тукталыш ясадык. Бер сәгатьтән, икенче рейста, аларын да Уренгойга кайтарып куйдык. Ул көнне, җил-буранга карамастан, дүрт очыш ясадык. Бармак очын өшеткән кеше дә булмады.

Буровиклар безне мактыйлар. КРАЗ кабинасында чәй кайнаткан шофер:

— Бүген килеп җитмәсәгез, авырга килер иде безгә, рәхмәт, Себер бөркетләре! — ди. Уйласаң, көн саен батырлык эшләүчеләр алар үзләре бит.

Мин тагын бер егетне хәтерлим. Ул да Әлмәттән. Заманында комсомолның шәһәр комитеты секретаре да булган. Монда хәзер хуҗалык эшендә, җитәкче.

Уренгойдагыларның һәркайсы — җитмеш һөнәр иясе. Кирәк икән — шофер да ул, дизельчы да. Мин белгән Юрий Ланцев та шундый кеше.

Безгә Пур буеннан бораулаучылар эшли торган скважиналарның берсенә вертолет белән нindидер эш кораллары, җиһазлар илтергә куштылар. Аларны Юрий тиешенчә нығытып, ыргакка әләргә әзерләп куйган иде. Йөк күләмле генә. Безгә төшеп утырырлык мәйдан юк, йөк элмәгән ыргакка вертолет һавада «асылынып» торган килеш кидерергә уйлыйбыз. Ланцев шуңа әзерләнде. Ләкин аның кулындагы элмәк вертолет ыргагына якынлашу белән, Юрийны электростатик көч җиргә лып итеп утыртты. Мондый электр кыры вертолет винтларының әйләнеп торуыннан барлыкка килә. Җиргә төшми торып, ток бетми.

Мин Ланцевка ишарәләр белән аңлатырга тырышам: «Тизрәк элэктерергә тырыш!.. Тизрәк!..» Әмма электр дигәнең кешедән өлгеррәк шул — аны тагын бәреп екты. Ярдәмгә бортмеханик төште. Электр көче аны да читкә алып ташлады. Машинаны көч-хәл белән булса да төшереп утыртырга мәҗбүр булдык. Механик көлә:

— Үз этең үзеңә дошман дигәннәре шулдыр инде, — ди. — Вертолетны әйтәм, ятларны да суга, үзебезнекеләрне дә ега!

Шулай Себер суыкларына түзеп, электр кырларында чыныгып эшли торгач, Юрий Ланцев үзенең төньякта яшь алачагына, артык кашык булмаячагына инана. Гаиләсен чакырта. Әлмәттән хатыны Лида күченеп килергә ризалык бирә. Аларны алырга китәсе көнне Юрий буровойларның берсенә торбалар озатты. Монысы җәй көне булды. Июль урталары. Көн аяз, тундра киңлекләре кояшлы. Себер черкиләре генә үзәккә үтә — бөтен тирә-юньне каплап алалар да, якты көнең кара төнгә әйләнә. Махсус сыекча сеңдерелгән киемнәр дә, битлекләр дә өркетә алмый ул хәшәрәтләрне. Якадан, җиң очларыннан эчкә үтеп, җелекләреңне сызлатырлык итеп тешлиләр.

Канэчкеч бөҗәкләр болыты арасында Юрий Ланцев машинага торбалар төйи. Ашыга. Буровойда торба көтәләр. Икенчедән, кесәдә — самолет билеты. Ул гаиләсен алып килергә кайтасы.

«Урал» машинасы шактый күләмле бит инде — ул да черкиләр болыты арасыннан күренмәслек булып калды. Юрий үзе дә күренми. Бары тик торбалар чыңлавы гына ишетелә. Димәк, Ланцев эшли.

Торбаларны төяү-нығыту берничә сәгатькә сузылды. «Урал» кузгалып киткәч, Юрий аңа кул болгап калды. Кичкенә йортына — вагонга кайтып көзгегә караса, битләре шешеп чыккан, кул сыртлары чабырып беткән. Әмма Ланцевның моңа исе китмәде. Торбалар буровойга озатылды — шунысы кыйммәт. Үзе Әлмәткә кайтып китә бүген. Тиздән гаиләсе белән очрашыр — монысы инде күптән көтелгән бәхет.

## Илдус Юнысов турында хикәят

Подберезный кабинетына Илдус Юнысов кергәндә, анда «Тюменгазпром» берләшмәсе начальнигы Алтунин да утыра иде.

— Ныгыйбыз, менә тагын бер инженер килеп җитте, — дип, Подберезный аны берләшмә начальнигы белән таныштырды. — Әлмәттә бергә эшләгән идек.

Ул чакларны искә төшереп утырдылар.

Бораулау остасы Александр Подберезный белән нефть чыгару мастеры Юрий Корчагин скважиналарны агым методы белән корырга — нефтьчеләргә аны «кара алтын» фонтаны бөркеп торган килеш тапшырырга мөмкин булуын раслаган еллар иде ул. Әлмәттә үткәрелгән зур слетта да шул хакта сүз барды. Анда, яшь нефтьчеләрнең чакыруына колак салып, көләч йөзле галим-профессор Гыйлем Камай да килгән иде. Ул речь тотты:

— Мин шушы залга җыелган яшь осталарны, хезмәт новаторларын, заманыбызның корчагиннарын тәбрикли алуыма бик шатмын, — диде галим. — Сез башлаган эш, нефть һәм газ чыгаруда сез ачкан яңа алымнар озын гомерле булыр дип ышанам. Бу методларны һәркайда файдаланырга мөмкин — аларның киләчәге зур...

Гыйлем ага Камайның алдан күрүе рас килде. Шул чакларда Подберезный бригадасында бораулау мастеры булып эшләгән Дамир Нуретдинов соңгы елларда скважиналар коруда агым методыннан файдаланып, зур уңышларга иреште. Нефть промышленностенда эшләүче барлык бораулаучылар яңа ысулны күтәреп алды. Дамир Нуретдиновның хезмәте СССР Дәүләт премиясенә лаек дип табылды. Уренгой экспедициясендә дә беренче көннән үк газ ятмаларын шул ысул белән бораuларга керештеләр.

Подберезный һәм Алтунин белән сөйләшеп утырганда Юнысов шуларны күз алдыннан үткәрде.

— Смена мастеры бик кирәк безгә, Илдус,—диде Подберезный.— Тәвәккәлләп тотын...

Юнысов беравык уйланып торды да башын чайкады:

— Юк, хәзергә инженер эшенә бармыйм, — диде.

— Ни өчен?

Илдус үз карашын аңлатырга кереште:

— Дүрт ел партия эшендә булдым, анысын сез беләсез. Аннары, өч ел участок начальнигы. Бораулаучы һөнәрен оныта да башладым шикелле инде. Шуңа күрә буровойдан башларга кирәк миңа. Шулай хәерлерәк булыр.

— Да-а,— дип сузды Подберезный.— Ярый, минемчә, дөрес эшлисең. Тик бер шарт белән: буровойда пешеп җиткәч тә, бригаданы барыбер аласың! Шулай килешәбез.

Яшәү һәм хезмәт урынын алыштырырга җыенган һәм төньяктагы буровойларга, промыселларга юл тоткан осталарның күбесе әүвәл үз-үзен сыный. Өйләренә язган хатларында: «Сәламәтлек хәзергә әйбәт, күнегеп киләм, киләчәктә ни булыр — карарбыз»,— дигән сүзләр була. Кырт кисәргә берәү дә ашыкмый. Илдус Юнысов та шулай башлады. «Буровой эшчесе булып йөрим башта, түзә алсам — өйдәгеләрне кузгатырмын,— дип уйлады.— Дәрт-дәрман җитмәсә, Себердә селкенеп йөрисем юк».

Буровойда ротор янына баскач та, Илдусның күңеле күтәрелеп китте. Хезмәт юлының тәүге адымнарын нәкъ менә шушындый машина янында, шундый гөрелте астында мәш килүче бораулаучылар янында атлаган иде бит ул.

Беренче шәмне алдылар, икенчесен... Юк, яшьтән өйрәнелгән һөнәр онытылмаган. Кайчан нинди хәрәкәт ясарга кирәген чамалый Илдус. Шулай да күзләрен бораулаучы ярдәмчесеннән алмый. Бигрәк пөхтә, төгәл эшли шул тегесе. Икесенең дә хәрәкәтләре төңгәл булса — Юнысов сабыйдай куана, элеватор уемына элмәк кидергәндә бер мизгелгә генә соңласа да — борчыла. Эшли торгач, Илдус күңелендә ышаныч ныгыды.

Борауны алмаштырырга керештеләр. Забойдан күтәрелгәне кырылып беткән. Себер җиренең таш-комлы катламнары борауны тиз

ашый икән. Яңасының забойда гүләве дә башкачарак шикелле. Хәер, монда роторны электр моторлары түгел, дизельләр әйләндерә. Татарстанда мондый двигательләр калмады инде. Электр моторының тигез гүләве астында забойдагы борау авазы үзенә бер көй булып яңгырый. Тәҗрибәле оста, шул авазны тыңлап, бораунын нинди катламны тишүен, аны нинди тизлектә эшләтергә кирәген чамалый, кайчан алмаштырырга икәнен билгели. Бу бик әһәмиятле. Ашалган борау белән эшләү хәтәр, ә таш-комны әле кимерә алырлыгын забойдан чыгару бораулау тизлеген киметә. Мастерга бораунын эшли башлаган чагын билгеләү иң авыры. Буровойда яңгырап, чыңлап, гөрселдәп торган төрле тавышлар арасында тирәннән килгән шул борау көен аера белергә өйрәнде Илдус. Ширбәт эзләп очкан бал корты, чәчәккә кунар алдыннан, бер мизгелгә элпә канатларын җилпеми тора, чәчәкнең иң баллы төген карый. Нәкъ шуның кебек, забойда тишелмәгән катламга орыныр алдыннан бораунын да гүләве үзгәрә. Ул кинәт кенә ераклаша кебек, тоныкланып кала. Борау ком-ташны кимерә башлагач, көе янә үзгәрә. Шуны тыңлый, ишетә белгән осталар уйнап кына эшли шикелле. Юнысов шуңа ирешергә теләде һәм ирешТе. Гаиләсен чакырту хакында да уйлана башлады. Нинасына озын итеп хат язды. Озакламый җавабы да килде: «Без риза, барабыз». Ә өлкән кызы Лилия өстәп тә куйган: «Без сине сагындык, әтием!»

Бу хатны алгач, Илдус үз шатлыгын Подберезный белән дә урталашты. Экспедиция начальнигы аның кулын кысты да:

— Болай булгач, килешүебезнең икенче параграфын үтәргә кала инде, Илдус,— диде.— Квартира җайларга да бригада алырга кирәк үзеңә. Шул иде бит безнең сөйләшү.

Юнысовка икеләнеп торырга, ык-мык итәргә урын калдырмады Подберезный.

— Килүеңә үк бригада бирмәдем, хәлеңә кердем, туганкай, җитте! Татарстанның бораулау остасы җитәкли торган беренче бригада була бу. Беренче!..

Начальникның бөтен кыяфәте: «Белеп тор, туганкай, бернинди ташлама булмаячак сиңа, Татарстан маркасын сакла!» дип әйтеп тора иде.

...Юнысовның бригадирлыгы бер скважина арматурасын корудан башланып китте. Аңа кирәкле җиһазларны көздән китереп калдырганнар. Илдус туплаган коллективны башта шунда эшләүче бригадага ярдәмгә генә җибәрмәкчеләр иде, Юнысов үзе дә, егетләре дә баш тартты.

— Кешегә булышканда гына үз көчеңне сыный алмыйсың,— диде монтажчыларлың берсе.— Скважинаны башы-аягы белән үзебезгә генә тапшырсыннар...

Бу тәкъдимне экспедиция җитәкчеләре бик теләп кабул күрде. Әлеге скважинада эшләүче бригаданы яңа урынга күчерделәр. Юнысов егетләре эшне, үзләре теләгәнчә, «башы-аягы» белән алды. Вахтага чыгып, арматураны күргәч тә, барысы да аһ итте. Бөтен җиһазлар балчык белән аралашып каткан. Арматураны лом белән кубарып алырлык та түгел. Әйтерсең бер бөтен гранит катламы!

Дизельче Касыйм Шәрәфетдинов скважина тирәсен хуҗаларча карап йөрде дә арматура өеме янына килеп басты. Бригадирга эндәште:

— Ломнар белән маташмыйк, Илдус. Ай буе чокчынсак та, рәтле эш чыкмас. Себер суыгы металлга катырган балчыкны беләм мин, валчык-валчык кына куба.

— Нишләргә кушасың соң?— дип сорады Илдус.— Арматура корудан баш тартыргамы?

— Алай диярге, башыма тай типмәгән, мастер. Менә бу өемне,— Касыйм арматурага ымлады,— дизель мае сибеп, яндырырга кирәк. Илдус шунда гына дизельченең фикерен аңлап алды.

— Монысы идея, якташ!— диде Юнысов.— Кабыз, әйдә, дизеленне!

Суык катырып ябыштырган балчык һәм тимер өемен трос белән уратып тракторга тактылар, скважинадан читкәрәк тарттырдылар. Шунда галәмәт тә зур учак дөрләде.

Учак җылысында арматурага ябышып каткан балчык йомшара, аны зур кувалдалар, ломнар белән бәргәләп тимердән аералар. Ике-өч сменага торырлык озын төн шул шөгыль белән узды. Ә көндез арматураны монтажларга керештеләр. Озакламый скважина газ кудыру торбаларына тоташтырылды. Шул арада Юнысов егетләре бармаган бригада яңа скважинада биш йөз метр бораурларга өлгергән. Моны ишеткәч, егетләрнең башы түшәмгә тиде. Ярдәмче булып кына барсалар, шул ук эшне барысы бергә дә башкара алмаган булырлар иде, ә хикмәтен белеп тотынгач, ике урында да уңышка ирештеләр.

Янәшәдәге ике скважинада бер үк вакытта эшләү Уренгой газ ятмалары мәйданында беренче тәҗрибә иде. Юнысов бригадасы үзенең шундый яңалыгы белән барлыкка килде. Соңга таба бу ысулдан киңрәк файдалана башладылар. Бер төркем бораулаган скважинада итәк-җиңне җыеп, җеп очларын төенләргә кала, ә икенчеләре яңа урында яңа скважина ачарга керешә.

Бригада башлыгы кул астындагы һәр кешенең мөмкинлекләрен, үзе әйтмешли, «дәрт-дәрманын» чамаларга тырышты. Бераүләр тәҗрибәле, башкаларында шунысы җитенкерәми. Бер вахтада осталар күбрәк, икенчесендә яшьләр. Илдус үз бригадасы осталарының бөтен тәҗрибәсен «уртак казанга» салу өчен күп нәрсәләр эшләде. Менә бер генә мисал. Ишханов вахтасында бораулаучы ярдәмчесе комнан аркан ишәрлек егет, уңган, оста, өлгер иде. Кирәге чыкса, буровойда эшчедән башлап инженерга кадәр теләсә кемне алмаштыра ала торган кеше. Юнысов аны яшьләр күбрәк булган вахтага күчерде. Ә Ишхановка әле тәҗрибә тупларга өлгермәгән яшьләрне җибәрде.

— Синең остазлыгың бар, егетләрнең өйрәнергә теләкләре зур, икесен бергә куш та вахтаны берләшмәдә бер булырлык итеп үстер,— диде.

Эдуард Ишханов та Әлмәттән килгән бораулаучы. Аны да заманында шул ук Мусин «кодалаган»— ул чакыру кәгазен кем исеменә язарга кирәген яхшы белә. Ялгышмаган. Ишханов беренче көннән үк бригададагы яшьләрнең остазы да, хезмәтне оештыруда Юнысовның уң кулы да булып китте. Коллектив тупланып җиткәч тә, бригадада коммунистлар сигез кеше булды. Партгруппа оештырылды. Аның җитәкчесе итеп Ишханов сайланды. Ул үзенең төп эшеннән тыш, вахта эшчеләренең техник укуын, үзара тәҗрибә уртаклашуын башлап җибәрде. Бригадада өйрәнерлек кешеләр дә, бораулау эшенең иң нечкә серләрен өйрәтерлек осталар да бар. Юнысов та, Ишханов та беренче көннәрдән үк верховой Василий Михалевның җитезлегенә, осталыгына игътибар иттеләр. Эшне ыгы-зыгысыз башкарыр, һәр хәрәкәте төгәл булыр аның.

— Синең белән эшләүләре рәхәт, Василий,— диде аңа Ишханов.— Син вахтада булсаң, күңел тыныч.

Астан караганда кечкенә әрҗә сыман күренгән «бишегендә» утырган чакта Михалев үзен бик иркен хис итә. Хезмәтен ул бер дә көч куймыйча, уйнап кына башкара кебек. Бу инде — осталык га-

ләмәте. «Бригадада һәркайсыбыз шундый булсачы!» — дип уйлый еш кына Юнысов.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре Пастухов Уренгойга килгән чагында Юнысов бригадасында да булып китте. Коллективның хезмәте, тормышы-көнкүреше белән танышты. Скважинаны да карады. Көне зәһәр суык иде. Илле градуслар чамасы. Югарыда — әлеге әрҗә сыман «бишектә» тирбәлгән верховойга карап, Пастухов гаҗәпләнде:

— Анда ничек утыра ул, ничек туңмый? — дип сорады.

— Утырмый ул анда, эшли, шуңа туңмый,— диде Илдус.

Пастухов верховойга янә карап алды да:

— Отыш сезнеке, исәп ике — ноль,— диде.

— Һәр кешене шундый осталыкка өйрәтә алсак, отыш тагын да зуррак булачак,— дип елмайды Илдус.— Ниятләребез зурда...

Юнысов ул чакта күңелендә яткан иң зур теләген әйтеп бирде. Буровой эшчеләренең, бораулаучыларның барысын да эш остасы итеп үстерү турында кайгыртмаган көне юк аның. Бораулау ярдәмчесе булып килгән Вячеслав Мусиенко белән үткәргән тәҗрибә уртаклашу дәресләрен остаз үзе дә, шәкерте дә онытырлык булмады.

Янәшәдә эшләүчеләрдән калышмаска тырышып, Вячеслав гел кабалана иде. Ашыккан саен берничә секундка булса да кичегә, бораулаучы эшен тоткарлый. Моңа үзе бик борчыла, һәр вахтада күңелсезләнә. Табигый хәл: кечкенә генә операцияләрдә секундларны югалтудан минутлар-сәгатьләр җыела бит. Илдус аңа буровойда кирәкле эшләрнең барысын да берәм-берәм күрсәтеп бирде. Сызымнар сызып та аңлатты, бораулаган чакта аның янына вахтага да басты.

Мусиенко нефть институтын тәмамлаган, берничә ел фәнни-тикшеренү лабораториясендә үткәргән, ә практик эштә булырга туры килмәгән аңа. Юнысов үз тәҗрибәсеннән дә белә: кайбер институтларда белгечләр әзерләүнең практик эш ягына игътибар җитенкерәми. Вуз тәмамлап килгән яшь инженерларның күбесен, гадәттә, бораулау бригадасына мастер итеп җибәрәләр. Ләкин алар, практик эш алымнары белән таныш булмаганга күрә, бу урыннарда озак тормый, идарә бүлекләренә төрле хезмәткә күчеп бетәләр.

Ярый әле, Вячеслав үзе үҗәт булып чыкты, Илдус та аның хәлен дөрес аңлады. Вакытында ярдәм кулы сузылгач, Мусиенко тиз арада буровойдагы эшләрне җитез башкара торган булып китте.

Эше җайлырак бара башлагач, Мусиенконың да күңеле үсте. Себер җиренең авыр шартларына эче пошмый, исе китми хәзер. Җан тынычлыгын тапкандыр егет. Кем белсен, Илдус ише түземле остазга юлыкмаса, Вячеслав, ихтимал, Уренгойда да калмаган булыр иде. Китәргә кыбырсынган чаклары аз булмады.

Илдус Юнысов бригадасының сүзенә экспедиция җитәкчеләре дә, берләшмәдә дә, министрлыкта да колак салдылар. 1978 елда Эдуард Ишханов «Правда» газетасына «Бораулаучы, синең урының кайда?» дигән мәкалә язды. Танылган бораулаучы, бригада партгруппоргы бу язмасында «Тюменгазпром» берләшмәсен һәм газ промышленносте министрлыгын тәнкыйть итә. Поляр өлкәләрдәге экспедицияләр һәм бораулау бригадалары арасында социалистик ярышның тиешенчә оештырылмавын, хезмәт алдынгыларының уңышлы адымнарын пропагандалау җитәрлек түгеллеген дәлилли. Ишхановның «Правда» сәхифәсендә әйтелгән сүзе тәэсирле, йогынтылы, нәтиҗәле булды.

Экспедицияләр, бригадалар, вахталар арасында ярыш уты һәркайда кабынды.

Күптән түгел генә Илдус Юнысовны экспедиция конторасына чакыртып алдылар. Подберезный аны бригада ирешкән уңышлар белән котлады да:

— Сезгә дизельләр белән хушлашырга туры килер, Илдус,— диде.— Берничә скважинаны электр челтәренә тоташтыру мөмкинлеге бар.

Рәхмәтен әйтте әйтүен Илдус, әмма үзенең башына уй төште. Себер бит бу, давыллы-өермәле көннәр еш була. Дизельләрдән аерылу әйбәт булырмы, әллә начарракмы? Ярый ла, электр белән тәэмин итүдә өзеклекләр булмаса... Аның уйларын белгәндәй, экспедиция начальнигы кисәтеп тә куйды:

— Электрга да күчергәч, сездән күбрәкне сораячакбыз.

— Белеп торам,— диде Илдус.— Анысына инде без күнеккән. Егетләр сынатмас. Шул вәгъдә җитеп торырмы, әллә язмача да кирәкме?

— Синең бригада телдән генә әйтсә дә җитә,— диде Подберезный.— Уңышлар телим!— Ул танылган бригада башлыгын озата чыкты.— Кара әле, Илдус, бервакыт син ак болан турында әйткән идең. Нишләттегез, озата алдыгызмы аны?

Юнысов вездеход ишеген ачкан килеш туктап калды.

— Юрий Анатольевичның теләгән үтәдек: ак болан бозавын совхозга илтеп тапшырдым.

— Үсәме?

— Үсә, Анатолий, бик матур булып үсеп килә.

Юнысов утырган машина, Уренгойдан чыгып, тундра киңлекләренә юл алды.

*Уренгой — Әлмәт*

**Рәшит Зәкиев**

# КОЯШ ИҢГӘН АЯЗ АЛАН

●

Тормыш миңа авыр сорау куйса,
Киңәш белән барыр кемем бар?
Күзгә карап хәлне тыңлар кешем —
Әткәм кебек якын Ленин бар.

Юлга чыксам, көләч чишмә суын
Миңа сузар юмарт җирем бар,
Кулдан алып кыяларга бергә
Күтәрелер юлдаш — Ленин бар.

Илнең кайсы сукмагына бассам,
Анда минем якты көнем бар,
Көннәребез торган саен балкый:
Янәшәдә чөнки Ленин бар.

## Үз балама карап

*Вәгыйз дуска*

Бигрәк таман туны әткәйләрнең,—
Өч кенә көн кигән тун бит ул.
Иңнәреңә салган саен синең
Йөрәгеңә төшкән моң бит ул.

Кемгә тагын аны күтәрергә, —
Сагышларның, моңның олысын...
Киемнәре саклый әткәйләрнең
Безгә тими калган җылысын.

Шул җылыны, шул моңнарны йөртә
Безнең иңнәр, безнең күңелләр.
Һәйкәлләргә кемнәр гөлләр илтә? —
Балалардан ядкарь бу гөлләр.

Уттан йолып безне, утка кергән
Солдатларның кайнар җаннарын
Үз балама карап, бар хәятем,
Яратуым белән аңладым.

●

Янды хисләрем, көлләрен
Җилләр таратыр инде,
Үкенеп үтсә көннәрем,
Кемнәр юатыр мине?

Сизмәстән килгән моңнарым
Күңелдә мөлдерәмә...
Уяу аттырган таңнарны
Ирләр соң белдерәме?

Сабыр канатым сынса да,
Сыгылмам мин, бөгелмәм.
Сауса, йөрәккә кан савар
Түзим диеп түзүдән...

●

Сине төнлә йолдыз итеп күрдем,
Көннәремә кояш китердең,
Мең хафага, мең уйларга төшеп
Кордым һаман өмет күперен.

Күперемнең аргы ягы ерак,
Авырлыктан сыгыла иңнәрем,
Әмма шушы татлы авырлыктан
Котылуны һич тә теләмим.

Кояш иңгән аяз алан төсле
Гүзәллеген тойдым җанының,
Ачышларның бөек ләззәтен мин
Синең күңел аша таныдым.

●

Таңнар дәшә, җаннар бергә түгел,
Икебезнең ике юлы бар.
Каян килеп күрдем өннәремдә,
Төшләремә керде толымнар.

Яшьлек һаман үтмәгәндер сыман,
Чәчкә суза гүя болыннар,
Чәчкәләрнең барсын алыштыра
Язгы төндәй назлы толымнар.

Туган җирнең рәхәт җиле булып
Кагылалар миңа бу моңнар.
Соңгы күкрәү, зәңгәр хыял миңа —
Башкаларга насыйп толымнар.

## Әхмәт Рәшитов

# ТАЛПЫНУ

### Биографиянең башлануы

Хәтерләмим, илгә дошман килгәч,
Әтием ничек солдат булганны да,
Билләренә каеш буганны да,
Күзләренә яшьләр тулганны да,
Ул киткәчтен койма ауганны да,
Аның соңгы хатын алганны да.

Дүрт ел үтте. Бер көн әни әйтте:
Зарыктырып көткән җиңү килде;
Ир затыннан йортта хәзер инде
Син бер үзең генә калдың, диде.

Мин малай чак белән саубуллаштым,
Койма төзәтергә чыгып бастым.

### Кәгазьгә мәдхия

И кәгазь, ап-ак кәгазь, төсле кәгазь,
Синдә көч, синдә әмер, синдә вәгазь,
Син—язмыш, синдә хөкем һәм ярлыкау,
Синдә ут, кайнар чишмә һәм карлы тау.
Герблы, су тамгалы, мөһер баскан,
Гомер юлына төрле фаллар ачкан
Син—чал картлык һәм сабый елмаюы,
Кояшның чыккан чагы һәм баюы.
Йөрисең төрле кыяфәткә кереп,
Акча булып, акыл булып, кильки төреп,
Булмасаң белмәс идем кем кемлекне,
Үземнең хәтта үзем икәнлекне.
Елъязмачы булса элек һәр эштә
Ике иңгә кунган ике фәрештә,
Хәзер исә гөнаһ—савап бик аздан—
Характеристика атлы кәгазьдән.

Һәм яласын, һәм ялганын, һәм үчен
Син—мескен күтәрәсең бөтенесен,
Низаг, талаш, сугышлар хисапчысы,
Кешелекнең кешелеге сакчысы.
И кәгазь, син сердәш бул гел җаныма,
Сакчы бул иманыма, вөҗданыма;
Шагыйрь кулында һич яман түгел син,
Ак битеңә ак уйларым түгелсен.

## Минем мәхәббәтем

Мәхәббәтем минем шундый көчле —
Үлгән алиһәләр терелер төсле,
Таш сын булып каткан Терпсихора
Иңнәремә килеп үрелер төсле.

Ага һаман хәят чишмәләре,
Исә җилләр—кичә заманалар;
Заманалар башы—мәхәббәттән,
Җанга утлар аннан кабыналар.

Бу хисне мин мең гасырлар буе
Җәбер-золымнардан саклый-саклый
Үткәннең иң зур мирасы итеп
Алып барам киләчәккә чаклы.

Ә син, Магдалина, тәүбә итмә,
Булган-булсын, ашса-ашсын хәттин...
Юк, кимсетмә, тезгенләмә хисең—
Чөнки син дә минем мәхәббәтем.

Юк, Җан-Таһир түгел Зөһрә белән,
Бу—мин...
Бу—мин. Бу җыр—минем ярам,
Бу—мин, Таһир булып, дәрьяларга
Яшел сандыкларда агып барам.

Мәхәббәттә канун тик бер генә—
Олыласаң, хаклыйм дисәң хакын,
Тик антка —ант, тик теләккә — теләк,
Тик күзгә—күз, тик ялкынга—ялкын.

Бу мин — кеше — мең гасырлар буе
Гайбәт-каргышлардан саклый-саклый,
Үткәннәрнең иң зур васыятен
Алып барам киләчәккә чаклы.

●

Һәр язымны әрнеп озатып калам—
Китә язлар, китә кайтмаска;
Йөрәкләрдә ялкын сүнә бара—
Гамьнәр башка инде, шарт башка.

Их, кайда син, яшьлегемнең төсе—
Чит-читләре бизәк кульяулык,
Үзеңә генә мәгълүм серецнән дә
Йөргән чаклар янып, оялып.

Еллар күкрәгенә ятып елыйм—
Кайтарыгыз үткән язларны,
Тормыш бусагасын атлау белән
Онытыла язган назларны.

Үтим әле бер урамнар урап
Унҗидесе җиткән кыз белән,
Бик заманча гына чөкердәшеп,
Бәхетле һәм горур йөз белән.

Карыйм, карыйм, карап туя алмыйм—
Һәр яз саен арта гүзәллек,
Бөтенесе Мәҗнүн Ләйләсе күк,
Бөтенесе үзәк өзәрлек.

Һәркайсына чәчәк бирер идем,
Сөйләр идем сөю хакында;
Бар гомеремне алыштырыр идем
Яшьлек дигән сүнмәс ялкынга.

Елмаймагыз, сәер теләкләр, дип —
Җирдә әле бит аз яшәлгән.
Туеп буламыни мәхәббәттән,
Туеп буламыни яшәүдән?!

## Әмир Мәхмүдов

### Хезмәт яме

Атом чоры—җирдә патша,
Тормышыбыз тизләтелгән.
Җир туктар күк әйләнүдән,
Ямь тапмасам хезмәтемнән!

Кеше өчен дөнья үзе
Нигезеннән үзгәртелгән.
Гүзәл чәчәкләр шиңәр күк,
Ямь тапмасам хезмәтемнән.

Юллар илтеп җиткермәс күк
Мул уңышлы көзләремә.
Тереклек суы корыр күк,
Ямь тапмасам хезмәтемнән!

### Февральләрдә яз исе

Бөек Ватан сугышына кадәр
Муса Җәлил Васильевода ял иткән.

Кышлары да монда җылы,
Февральләрдә—яз исе.
Хуш исләрдән айный алмый
Яшисе дә яшисе!

Туа монда теләкләрнең
Күркәмнәре, изгесе.
Җәлил йөргән урманнарда
Үлемсез моң, яз исе!

Бәлки шунда эзләгәндер
Җәлил «Алтынчәч» эзен?!
Язгы сукмаклардан үтеп,
Чит җирдә күргән көзен.

Фашист балтасы кискәндә
Газиз башын шагыйрьнең,
Васильево наратының
Тартышкандыр тамыры.

...Васильево күге аяз,
Февральләрдә—яз исе!
Җәлил эшен дәвам итеп
Яшисе дә яшисе!

●

Яңа гомер бүләк итә оста куллар—
Җанланалар үлгән уен кораллары.
Борынгы саз аһәң бирә күңелләргә,
Тын калдыра колонналы зур залларны.

Тереләләр үлгән уен кораллары!
Борынгы көй моңын тыңлап тетри җаның.
Сәхнәләргә гөслә белән курай менә,
Яңгыратып җырларга бай халкым даның.

Мең яшәгән кыллы арфа ачып бирә
Музыкада фәлсәфәсен заманнарның.
Гармуннарда, габойларда, кубызларда
Үлмәс җыры, рухы кайта бабамнарның!

## Гүзәллек көче

*Галимә Шөгеровага*

Зәңгәр экран нәфис татар кызын
Күрсәтәдер бәлки үзгәртеп.
Әмма беләм, аңа гашыйк булган
Җир кешесе карый үз итеп.

Кырыс гүзәллеге таң калдыра,
Тылсым мәллә нәфислек көче?!—
Батырларча—матурлыкны раслый,
Гүзәллек-көч күңелгә күчә.

Ышандырмас мине комментатор:
— Шөгерова җиңелде, — дисә.
Матурлыкны җиңеп буламыни,
Гүзәллек ул үлемсез ләса!

●

Ак болытлар йөзеп үтте:
— Аны оныт! Аны оныт!
Ак каеннар өзеп әйтте:
— Аны оныт! Аны оныт!
Ак торналар очып үтте:
— Аны оныт! Аны оныт!

Ул синең мәңгелек ярың!—
Диде сыман бары өмет.

...Ап-ак өмет, якты өмет,
Сүнмәс өмет, алтын өмет.

## Нәҗибә Әминева

### Иң кирәклесе

Борчу-мәшәкатьләр белән
Үтеп китте бу көн дә,
Тик эшнең иң кирәклесе
Калды кебек бүген дә.

Эш белән үтте кебек көн,
Һаман ни тынгысызлый?
Җирдә мин бәйләр яра бу,
Күңелемә күчеп сызлый.

●

Шатлык та юк,
Сагыш та юк бүген,
Күңелем тып-тын,
Юк бер дулкын.

Моңайтмаган,
Елмайтмаган нинди көн бу?
Дөньясыннан читтә торган
Мин соң кем бу?

Бу дөньяның
Нишләп миндә
Бетте эше?!
Нишләдем,
Мин — нинди кеше?

Мең соравы белән вөждан
Дер селкетте —
Күңелемдә — тынлык бетте.

### Шәм яктысы

*Электр сүнгәч*

Шәм яктысы
Сары икән, тып-тын икән,
Шәм яктысы — саркып торган
Бер моң икән.

Җанга бакты
Шәм яктысы сагыш сыман.
Моңсу көлеп
Онытылган тавыш сыман.

●

Уятты жанны дулкынның
Ярлардан ашкан чагы,
Кушыласым килде давылга,
Шар ачып шашкан жанны.

Кузгатты жанны камышның
Күлдәге күләгәсе,
И килде күңелнең тынып
Шул күлгә төбәләсе.

Давылга, я бер тын моңга
Жанның кушылыр чагын
Уралып, уртача тормыш,
Туктатмасаңчы тагын...

●

Балаларым,
Бу дөньяның
Салкыннарын сизмәгез дип,
Куеныма алыр идем
Уйнап үскән бүлмәгезне.

Бер үстерсәм,
Үзләре дә
Өреп назлы сулышларын
Жылытырлар — әнкәләре
Яши торган бу Жир шарын!

●

Еласаң, туктый белмисең,
Көлсәң, яңгырый өйләр.
Синең өчен чамасы юк —
Бу, балам, дөнья диләр.

Чамасыз елап кал әйдә,
Чамасыз көлеп кал бер.
Тормыш чама калыбына
Салачак бит барыбер.

●

Ясамасын балам Жирдә
Ялгышын дип борчылам,
Ясый алсачы дөньяда
Язмышын дип борчылам.

Ялгышында язмышы да
Язылыр дип борчылам.
Бу —
Балам баскан Жир үзе
Чиксез галәмдә берүзе,
Ялгызы дип борчылам...

## Батулла

# ЯШЕНЛЕ ЯҢГЫР КӨТКӘНДӘ

хикәя

Гафур ашыкмый гына атлый. Кая ашыгырга? Кешеләр кичке ашка кабалана. Гафур йоклар алдыннан ашамый. Ял йортының атаклы пешекчесе аның бу гадәтен белми, шуңа күрә Гафур өлешен өстәлгә куеп, тастымал белән каплап китә.

— Нигә син кичен ашамыйсың? — дип сорады бер тапкыр Гафур белән бер өстәлдә утыручы Александра Тимофеевна.

Аңа каршы Гафур болай диде:

— Иртәнге ашны үзең аша, әбәтеңне дустың белән уртаклаш, кичкесен дошманыңа бир!

Бу сүзне ишеткәч, Тимофеевна куанычын яшерә алмый әйтте салды:

— Алайса, милок, мин синең дошманың! Миңа бир син ужиныңны!

Шул көннән Гафур үз өлешен Тимофеевнага калдырып китә торган булды.

Бу минутта ял итүчеләр барысы да ашханә залында утыра. Гафур ялгызы гына сукмак буйлап бара да бара.

Яфраклар яңгыр чакыра. Каядыр еракта ара-тирә яшен яшьнәп куя. Ләкин күк күкрәгәне ишетелми.

«Аҗаган шикелле!» — дип куйды Гафур үзалдына гына.

Сукмак Гафурны тау башына алып чыкты.

Тау итәгенә сарылып авыл йоклый. Авылның аргы ягында басу. Караңгы басуда трактор эшли.

«Юк, трактор түгел бугай. Кайдадыр кино күрсәтәләрме?»

Гафур тау башындагы утыргычка килеп утырды. Ике тезен кочаклап ул шулай озак утырды, йокымсырый башлады. Ял йортындагылар инде җиденче төшләрен күреп ята торганнардыр. Авыл этчләре дә бер-бер артлы кычкыра башладылар. Ниһаять, Гафур кайтырга дип урыныннан торды.

Төн уртасы булса да өч кеше йокламый. Бер егет белән бер кыз куе куаклар арасындагы утыргычта утыра. Гашыйклар өчен ул утыргычны юри аулак җиргә ясап куйганнардыр инде. Ләкин егет белән кыз кочаклашу түгел, янәшә утырырга да кыймыйлар.

Соң ятучыларның өченчесе — Гафур үзе. Тирән уйлардан арыну өчен, ул юри үзалдына сөйләнеп йөри. Куаклар шаулашканны тыңлый-тыңлый, берни уйламыйча, тынычланып йөрергә ярата ул.

Офыкта тагын яшен ялтырады. Ялтырау сүнгәч офык кап-караңгы, салкын, әллә ничек шомлы булып кала. Әнә шул шом Гафурны борчый. Шомнан качкандай, ул тиз генә икенче якка борылды. Бу якта офык матур. Кояш әллә кайчан җир астына төшеп киткән инде, ә нурлары күкне һаман балкытып тора. Бу якта офык зәп-зәңгәр. Шул зәңгәр пәрдәгә агачларның кара кучкыл кәүсәләре ябышкан.

— Курчак театрындагы сыман! — диде ул. — Күк — пәрдә, агачлар — декорация. Кешеләр — курчаклар йоклый!

«Тфу, шайтан!— диде ул үз-үзенә.— Әгәр дә мин театрда утырсам, карале, нәкъ чын күк йөзе инде, дияр идем... Ни өчендер адәмнәр табигатьне сәнгать белән, сәнгатьне табигать белән чагыштыралар? Ни пычагыма инде ул чагыштыру?!»

Андый чагыштыру сәнгатьне дә, табигатьне дә кимсетә, кечерәйтә кебек тоелды аңа. Ул, кемгәдер үпкәләгән шикелле, тынып калды. Кемгә үпкәләде соң әле ул? Ни өчен? Сәнгатьне үзенчә яклавы идеме бу, әллә табигатьне кызгануы идеме?

— Табигать өстенә әйтергә ярамый! Матурлыкка төртеп күрсәтү гөнаһ!— ди торган иде әбисе.— Яшенгә бармак белән күрсәтмә! Зиратка да төртеп күрсәтмә!

Ни өчен ярамый, анысын әбисе аңлатмый иде. Ярамый — вәссәлам! Андый чакта әбисе бармакны бик каты тешләп, як-ягына төкерергә куша иде. Төкеренгәндә:

— Тфу-тфу, бәла-казалардан үзең сакла! — дип әйттерә торган иде.

Тагын яшен яшьнәде.

— Тфу-тфу, бәлаләрдән үзең сакла! — дип пышылдады Гафур.

Ышанып кабатлавы идеме бу сүзләрне, әллә шаярып кылануы идеме, әллә бер гадәт буенча гынамы, анысын ул үзе дә белми. Бәлә-кайдән үк канга сеңгән инде.

Ял йорты янәшәдә генә булса да, бүлмәгә керәсе килми. Барыбер йокы алмый!

Якында гына ат пошкырганы ишетелде. Бу аксак атны һәр вакыт төнгелеккә урманга җибәрәләр. Килгән көнне үк дуслашып киттеләр алар. Аксак алаша да Гафур.

«Мескен, үзе карт булмаса да эшкә ярамый, нигә аны ял йортында асрыйлар икән?»

Гафур якынлашканны сизенеп, ат һәр кичне шулай салмак кына кешни, пошкыра башлый.

— Боһ-боһ-боһ! — дип чакыра атны Гафур.

Ат тагын пошкырды да Гафурга таба килә башлады. Караңгыда да аның аксаганы сизелеп тора. Алгы сул аягында нindидер төзәлмәс яра бар бугай.

— Шунда гына тор инде, бичара хайван! Үзем киләм бит янына! — диде Гафур.

Һәр кичне дип әйтерлек Гафур алашаны шикәр кисәге, ипи катылары белән сыйлый. Һәр кичне дип әйтерлек ат аны сукмак буенда көтеп тора.

Гафур ат белән озак кына сөйләшеп торды, муенын, күкрәген сыйпады да, сукмак буйлап китеп барды. Ишетелер-ишетелмәс кенә пошкырып, ат Гафурны озатып калды.

Гафур тагын егет белән кыз утырган утыргычка килеп җитте. Ул аларны әйләнеп тә үтә ала иде югыйсә, ләкин аларга комачаулама-

сын ул алдан ук белә иде. Кыз һәр көн утыргычның бер башында, егет икенче очында утыра.

— Гафур абый! — диде кыз йомшак кына. — Бераз утырып китегез.

— Хәерле кич! — дип исәнләште егет.

— Утырмыйча да булмас, ахры... — дип, Гафур егет белән кыз уртасындагы буш урынга утырды.

Ләкин берәү дә сүз башламады. Егетнең дә юкбар сораштырган булып, я булмаса, картаеп, йоны коелган анекдот-мәзәк сөйләп, сүз куертырга исәбе юк иде, ахрысы. Гафурның да сөйләшәсе килеп тормый иде. Шулай тын гына утыру өчесенә дә рәхәт иде. Беркемнең дә үпкәсе юк. Мондый чакта кайберәүләр кешеләрнең күңелен күтәрәм дип, мәзәк сөйләгән була — кызыгы юк. Мескен мәзәкчене кызганып куясың. Безнең өчен тырышты бит дисең дә, күңеле булсын дип, ирексездән көләсең. Миһербанлы булам дип, үзеңне ирексезлисең, ялганларга мәҗбүр буласың.

«Миһербанлылык ялганга этәрә микәнни соң? Өчебез дә кай ягыбыз беләндер бер-беребезгә охшаганбыз...— дип уйлый Гафур.— Озак йоклый алмый йөрүебез белән генә түгелдер, мөгаен... Бәлки сүзгә саранлык беләндер? Юк, аз сүзлеләр белән дөнья тулы. Әмма болай әйләнә-тирәдәгеләргә артык йөк булмыйча гына яши белү бар кешеләрдән дә килми шул».

Хәтта Гафур аларның кем икәнлекләрен дә белми. Кыз аның туган якларыннан бугай. Егетне ул бөтенләй белми. Ял итәргә килгән көнне үк егет белән кызга игътибар иткән иде ул. Тиктормас ял итүче халык арасында алар әллә каян аерылып тора. Гафур шау-шулы күңел ачуларны яратмый. Берәрсе кызык сүз әйтәм дип, оятсыз мәзәк сөйли дә — барысы да аһаһайлап көләргә тотына. Тапкыр сүздән түгел, путевка бәясен чыгару өчен генә көләләр. Егерме көнгә түләнгәнме? Түләнгән! Кызык булмаса да — көл! Кәефең булмаса да — шатлан! Алай ясалма итеп хөрти театрдагы хиссез актерлар гына көлә.

«Фу, әкәмәт!.. Мин үзем шундый мыжык, әчпошыргыч, сөмеки! Шаяра белми торган бер бәндә. Кешеләр белән аралаша алмаганга алардан гаеп табам. Бәлки чыннан да аларга кызыктыр? Әнә Александра Тимофеевна! Ит бүкәне. Һәр вакыт ни дә булса уйлап чыгара. Я ирләр киеме киенеп, кеше көлдерә. Беркөнне шулай чыраена корым сөрткән дә, бөтен бүлмәләргә кереп, кешеләрнең күңелен күреп йөрде. Я булмаса, тиктомалдан кычкырып торып җырлап җибәрә... И ямьсез дә җырлый инде үзе. Бррр!» — Гафур бу уйлардан арынырга теләгәндәй, башын чайкап куйды. Андый җырчыларны ул үз гомерендә күп ишетте. Өйдә дә күрше фатирда торучы хатын исереп кайтса гел шул җырны җырлый:

От зари до зари о любви говори...

— Бөркү дә соң...— диде кыз.

Кыз тавышы Гафурны ямьсез хатирәләрдән аерды.

— Җил тынды. Явар, ахрысы,— диде Гафур.

— Кичәгенәк тә шулай булган иде. Читләтеп узды. — диде егет.

— Иртәгә дә шулай алдалап кына йөрер-йөрер дә әйләнеп узар әле,— диде кыз.

Аңа каршы җавап кайтаручы булмады.

— Гафур абый!— диде кыз кинәт кенә.— Сезнең гаиләгез бармы?

— Сүз югында сүз булсын, ата казыгыз күкәй саламы?— диде Гафур.

— Шулай шул, — диде кыз, уңайсызланып башын иде.— Кеше күңеленә керсәң, адашып калуың бар.

— Кеше кешедән таш стена артына качарга тиешмени соң?— диде егет.

Гафур аның тавышында үпкә ишетте. Бу — ниндидер җитди сөйләшүнең дәвамы кебек тоелды аңа.

«Нигә гаиләгез бармы, дип сорады соң әле бу кыз?»

Гафурның әлеге сорауга җавап кайтарасы килә башлады.

— Матур гына тормыш итәргә хыяллана идем мин,— диде ул озак тынлыктан соң.— Барып чыкмады...

Ул тагын байтак вакыт дәшми торды. Аннан соң дәвам итте:

— Шуны ишеткәч, күп вакытта: хатының гаепләме, әллә үзең башканы яраттыңмы, дип сораучан булалар. Безнең әллә ничек булды инде ул тормыш дигән нәмәрсә. Ул үзен хаклы дип саный иде. Мин — үземне. Менә шул ике хакыйкать тора-бара фаҗигагә әверелде. Унбиш еллап бар инде аерылышканга.

Ул туктады. Тынлык урнашты.

— Кузгалырга кирәк!— диде кыз.— Йокы килә башлады...

Кыз торып китте. Егет тәмәке кабызды.

Яңгыр болытлары ял йортын тагын читләтеп узды. Офык кырыеннан шуыша-шуыша барып алар күк пәрдәсен бөтенләй капладылар.

Гафур, егет белән хушлашып, бүлмәсенә кереп китте.

Икенче көнне иртән иртүк аны Александра Тимофеевна уятты. Гафур бөтенләй чишенеп йокларга ярата. Тимофеевна шакымый-нитми генә бүлмәгә керде. Аны күргәч, Гафурның йөрәге жу итеп китте: мондый хатын уйлап тормый, өстеңдәге чүпрәгеңне тартыр да алыр!

Гафур, ике куллап җәймәгә ябышты да, караватпочмагына сеңде. Ялангач калудан куркуы түгел иде Гафурның, ул ит бүкәне Тимофеевнаның юеш, симез куллары кагылудан курка иде. Тимофеевна кып-кызыл чырайлы, шуның өстенә кабартма чаклы иреннәренә бер мыскал иннек сылаган, күзләрендә әдәпсез шатлык ялтырый.

— Тор, милок! Бүген ат чабышлары! Сабан туй. Мин синең белән ярышырга телим. Тор!

Тимофеевна акрын гына караваткa таба килә башлады һәм... эчке бер куану белән кинәт чырылдап куйды:

— Ә-ә-ә... Син менә ничек?..

Ул Гафурның серенә төшенде булса кирәк, чөнки тиз генә коридорга йөгереп чыкты да башкаларны чакыра башлады.

— Әй, килегез әле, бер кызык күрсәтәм!

Гафур ул арада сикереп торды һәм җәймәсен итәксыман итеп биленә урап өлгерде. Ял итүчеләр төркеме өерелеп бүлмәгә килеп керде. Алар Гафурның бу кыяфәтен күреп, егыла-егыла көләргә тотындылар.

Уеннар-кичәләр оештыручы егетнең:

— Атлар әзер! Барыгыз да аланга чыгыгыз! Бәйрәм башлана!— дип кычкырганын ишеткәч кенә хатын-кызлар Гафур бүлмәсенән чыгып чаптылар.

Гафур киенде, бер чокыр кымыз чөмерде дә ишегалдына чыкты. Анда өч-дүрт карт бия, бер-ике алаша тирәсендә кешеләр кайнаша иде.

«Кымыз заводының эшче атларыдыр инде»,— дип уйлады Гафур.

— Менә дигән чабышкылар!— дип кычкырды уен оештыручы егет.

Һәммәсе дә егетнең сүзләрен ишетеп көлә башлады. Егет үзе елгыррак атка атланды. Аның киемен күреп, Гафур көлеп җибәрә язды. Аягында гусар итекләре, өстендә татар камзулы, башында баш-

корт башлыгы. Бусы ата-бабаларыбызның хәрби киеме санала торгандыр инде. Атларның һәммәсен дә алып бетергәннәр иде инде. Бары тик бер атның гына ияре буш тора. Гафур төнге дусты аксак атны танып алды. Янәшәдә яшь алаша янында өч ир белән Тимофеевна азаплана. Тимофеевнаны алашага атландыру зур бер тамашага әйләнде. Ял йорты тарихында мондый тамашаның булганы юктыр! Ирләрнең берсе атның башыннан тоткан. Икенчеләре тыпышып-тырмашып Тимофеевнаны ияргә утыртырга маташа. Ирләр, каян әлекте шуннан тотып, хатынны өскә этәләр. Тимофеевна рәхәтләнеп чиный. Ниһаять, көч-хәл белән Тимофеевна ияргә менеп атты. Ике кулы белән атның ялына чытырдатып ябышты да, башы белән алаша муенына сеңде. Моны күреп, ял итүчеләрнең күбесе чирәмдә тәгәри-тәгәри көлештеләр.

— Карагыз әле! Алашабыз дөягә охшап калды лабаса!— дип кычкырды ирләрнең берсе.

Бу сүз кешеләрне бөтенләй эштән чыгарды. Хәтта Гафур янында басып торучы егет тә елмаеп куйды.

— Гафур абый!— диде егет.— Әйдәгез әле, без дә ат сорыйк.

— Юк, мин катнашмыйм! — диде Гафур.

— И какой же русский не любит быстрой езды?!— диде егет.

— Мин — татар!— диде Гафур.

— Ат күрсә, татар җан атар!— диде егет.

— Мондый атларны күрсәм, җаным тәнемнән чыгып китә яза!

— Әйдәгез инде, бераз күңел ачыйк!— диде егет.

Җайдаклар ишегалдыннан чыгып китте. Халык дәррәү кубып алар артыннан иярде. Гафур белән егет тә капкадан чыкты. Нидер эзләгәндәй, Гафур як-ягына карана. Егет тә күзләре белән кызны эзли. Ләкин атлылар арасында да, җәяүлелер янында да, ашханәдә дә кыз күренмәде. Кайда икән ул? Бәлки кайтып киткәндер? Әллә кәефе юкмы? Бу егет алдында йөгерә-йөгерә кыз эзләп йөрүе уңайсыз.

Алар аланга таба киттеләр. Дәшмичә генә баралар. Менә аланны да узып киттеләр. Урманга да керделәр. Икесе дә һаман кыз турында уйлый.

— Әйтегез әле, егет, сезгә кыз ошыймы?— дип сорады Гафур.

Егет тиз генә җавап бирмәде. Ул юкә яфрагы өзеп алды да бармагына урады.

— Минем бу турыда уйлаганым юк, Гафур ага. Әллә нинди сәер кыз ул.

Кире борылдылар. Алар каршына кыз килә иде. Ике ирнең дә күңеленә җылы йөгерде.

— Белмим!— диде егет сүзен дәвам итеп.— Бәлки ул миңа ошыйдыр да...

Кыз әтисе белән абыйсы каршына килгән кебек кочагын җәеп йөгерә башлады.

Ләкин килеп җитәр-җитмәс кинәт туктап калды.

— Исәнмесез, егетләр!— диде.

— Кая югалдыгыз сез?— диде Гафур.

— Йокы симерттем. Радиодан бүген яшенле яңгыр була диделәр. Яратам яшен яшьнәгәнне. Яшен ялт итә, бераздан чатырдатып күк күкри. Төнлә яшен карармын дип, йокы туйдырдым. Сез дә яшен карарга чыгыгыз.

Аланда атлы уеннарның иң кызган чагы гына иде әле. Ару-талуны белмәс уен оештыручы егет алдан уйлап куйган уеннарны әйрәтеп, ял итүчеләрнең күңелен таба. Алашалар, бияләр оештыручы егетнең боерыгын ялкау гына үтиләр.

— Ял итүче иптәшләр! Ат чабышлары башлана! — дип сөрән салды оештыручы егет.

Барча атлылар да бер җиргә тупланды.

— Гаҗәп, безнең якта, исерекләр сугыша башласа, «әнә, сабан туй башланды», диләр.

Бу сүзләрне Гафур артында торучы бераү әйтте.

— Чын сабан туйны күрмәгән кеше генә шулай әйтә аны,— диде икенчесе.

Уен оештыручы әче итеп бер сызгырды. Ат чабышлары башланды.

— Шулай булырга тиештер дә инде ул! — дип дәвам итте әлеге ир.— Вакытлар узу белән бәйрәмнәр дә бозыла, үзгәрә. Кайсылары бөтенләй юкка чыга. Ат халкы да бер заман бетәчәк. Атлы гаскәр беттеме? Бетте! Гамәлдән чыккан нәрсәләрне тормыш үзе сызып ташлый бара. Колхозда ат мөһим көч булып саналмый хәзер. Димәк, бер ун елдан боларын да күрмәссез!

Кемдер ат өстеннән егылып төште. Кемнәрдер сызгыра, кычкыра башлады. Кәлсәң — көл, еласаң — ела! Картайган атлар берсен-берсе куып җитәргә, узарга, уздырмаска талпыналар. Җайдаклар бар көчләренә атларны куа, үкчәләре белән кыйный, камчы белән сыдыралар. Ләкин атлар барыбер шуннан артыгын чаба алмый.

— Бу атлар беткәч, кешеләр бәйрәмнәрен ничек үткәрерләр икән? — дип һаман фәлсәфә корып азаплана теге бәндә.— Бәлки атлар урынына роботлар уйлап табарлар, ә? Ә кымызны нәрсәдән ясарлар икән, ә? Ясалма сөттән, порошоктанмы?

Гафур аны тыңламый иде. Ул аксак алашаны күзәтә. Үзе дә сизмәстән, Гафур уенга бирелеп китте. Бәлки уенга бирелү дә түгелдер, гарип хайван өчен җан ату, аны кызгану гынадыр.

Аксаккай чынлап торып ярышырга тырыша. Башкалардан калмаска азаплана.

Атлар алан түгәрәген бер кат әйләнеп үттеләр. Аксак ерак-еракта калды. Тимофеевна җитди рәвештә аксакны кыйный.

Менә аксак Гафур белән тигезләнде. Алашаның борын тишекләре киерелгән. Ул, өмет белән, интегеп алга карый. Башка атлар аксакны узып китеп, яңадан әйләнеп килделәр. Аксак ат берничә мизгелгә барыннан да алда булып чыкты.

Ләкин бу хәл бары тик бер мәл генә булып алды. Икенче мәлне инде аксак ат тагын иң артта калды. Көндәшләр, куып җитә алмаслык ара калдырып, узып киттеләр.

Ниһаять, аксак үз хәлен аңлады булса кирәк, атлап кына бара башлады. Ял итүчеләр тагын да ныграк көләргә тотындылар.

— Җитәр! Туктатыгыз! — дип кычкырды Гафур.

Ул сабан туй рәисе вазифасын үтәүче каравылчы бабай янына килде.

— Агай, аксакны интектермәгез инде! Туктатыгыз, зинһар!

Каравылчы карт Гафурны төшенмәде шикелле, комачаулап йөрмә әле эш вакытында дигән сыман, беләге белән этәреп, кычкыруында булды:

— Дуй, Тимофеевна, дуй!

Ул арада атлар финишка килеп беттеләр. Беренче килгән атларга каравылчы бабай сөлге, тастымаллар бәйләп чыкты. Ял йортында эшләүче берничә кеше атларны тезгеннәреннән алып, алан әйләнә китеп бардылар.

Аксак сыртында дырык-дырык азапланып, Тимофеевна ялыккандыр, ахрысы, икенче әйләнгәндә ул аттан төшеп калды. Төште дә кычкырып, сызгырып утыручылар янына таба китте. Салмыш берничә ир аны һавага чөяргә азапланалар.

— Молодец, Тимофеевна, молодец!

Аксак ат финишка берүзе генә килде.

Гафур ат аяклары арасында сөйрәлеп килүче тезгенне алды. Аксак Гафур янында туктады. Ул танавы белән Гафурның уч төбенә килеп төртелде. Гафур кесәсеннән ипи сыныгы чыгарды. Ләкин ат ипине иснәп тә карамады.

— Кайгырма, дускай, кайгырма!— диде Гафур.

Шунда аксакның күзеннән зур гына яшь тамчысы мөлдерәп чыкты да Гафурның кул сыртына тамды. Тамчы Гафурның кулын көйдереп алгандай итте.

— Бичаракай!— диде кыз.

— Барыгыз!— дип дәште Гафур кызга.— Барыгыз, зинһар, яулык алып чыгыгыз!

— Нигә ул? Минем яулыгым юк!— диде кыз.

— Сөлге, шарф, берәр ситсамы — ни булса да алып килегез! Тиз булыгыз!

Кешеләр тарала башлады. Гафур аксак ат яныннан китмичә торды. Атның ялын, аякларын сыйпады, иркә сүзләр әйтте...

Ул арада шарф тотып кыз килеп җитте. Гафур шарфны ат муенына бәйләп куйды, авызлык яныннан ук тотып, алан буйлап йөртергә алып китте.

Егет белән кыз аңа иярде.

— Нигә алай итәсез, Гафур абый?— дип сорады егет.

— Ул барыннан да ныграк тырышты. Димәк, аңа да бүләк тиеш.

Егет ни өчендер мәгънәле генә итеп көлеп куйды.

Кыз атның икенче ягыннан атлый, бертуктаусыз атның маңгай ялын сыйпый.

— Әй! — дип кычкырды каравылчы бабай. — Аксакны монда алып кил әле, агайне!

Гафур тезгенне бабайга тоттырды.

— Интекте дә инде, мескен! — диде кыз.

— Интегергә озак калмады инде аңа! — диде карт. — Тиздән — аллаһе әкбәр...

Бабай сүзен әйтеп бетермичә алашаны әйдәкләп алып китте. Алан бушап калды.

Кич җитте. Гафур тагын кичке ашны ашамыйча яр буена китте. Һәрнәрсә кичәге кебек кабатлана бара. Тагын офыкта яшен уйнаклый. Офык кичәгедәй зәңгәр. Агачлар нәкъ кичәге шикелле каракучкыл. Мең тапкыр кабатланган күренеш. Азагы да нәкъ кичәгедәй бетәр төсле.

«Алар хәзер утыргычка таба килә торганнардыр инде!» дип уйлый Гафур.

Ул яр башына басып, зәңгәр офыкка, авылга карап тора.

Гафур күңеле белән кемнеңдер якынлашканын сизде. Куркырга сәбәп булмаса да, аның күңелендә шомлы бер сагаю сызылып үтте. Кеше канында борынгы бабалардан калган үзеңне-үзең саклау тойгысы бар диләр. Шулдыр, шәт. Гафур кинәт артына борылды.

Килүче әлеге кыз иде.

«Нишләп утыргычта түгел соң әле ул?» дип үзалдына сорады Гафур.

— Гафур абый, мин дә ашамадым бүген, —диде кыз килеп җиткәч.— Кичкә ат ите пешергәннәр. Аксакны суйганнар бугай...

Гафур, үзе дә сизмәстән, кызның ике беләгеннән тотты.

— Юкны сөйләмәгез, аксак биредә генә. Боһ-боһ-боһ...

Якында гына дәртле итеп ат пошкырганы ишетелде. Алар икесе дә аксак янына китте. Гафур атны шикәр белән сыйлады. Кыз иркә сүзләр әйтә-әйтә атның ялын, яңакларын сыйпады. Аннан соң алар аксак белән саубуллашып, максатсыз-нисез генә йөреп киттеләр.

Кыз Гафурны култыклап алды.

— Гафур абый, сөйләп бетерегез әле...

«Болай итеп яшь кызлар әткәләрен генә култыклый!» дип уйлады Гафур.

— Кичә башлаган сүзегезне сөйләп бетерегез әле...

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның?— диде Гафур.— Мин командировкада чакта ул бәбәйләде. Мин югында баланы үз фамилиясенә яздырган...

Бу сүзләрне ул кызны шелтәләгән шикелле әйтте. Әйтерсең лә кыз аның баласын үз исеменә яздырган!

— Вак мәсьәлә инде ул үзе,— дип башлаган иде дә Гафур, аны кыз бүлдерде:

— Юк, Гафур абый, димәк, вак булмаган ул...

Нәрсә әйтергә теләде кыз моның белән? Гафурны гаепләве идеме? Аның элеккеге хатынын шелтәләве идеме? Белгән юк!

— Шуннан соң мин командировкаларга китәргә ашкынып кына тора башладым. Командировкада миңа җиңел. Кешеләр белән рәхәт. Бервакыт Себердә чакта телеграмма алдым: тиз кайтып җит, улыбыз каты авырый! Бүлешә алмаган улыбыз мин кайтканчы дөнья куйган иде инде...

Күк күкрәде. Агачлар яңгыр киләсен сизенеп, сагаеп калды.

— Явар микән, Гафур абый?

— Кем белә инде аны.

Күк йөзен тагын яшен ялмап алды. Яшен гигант агачның тамырлары шикелле күз алдында байтак яктырып торды.

— Әһә, бу бик якын гына,— диде Гафур.

— Әйттем бит, яшенле яңгыр була, дидем.

— Радиодан әйттеләрме?

— Юк шул, мин шаярып кына әйткән идем.

Күк шартлап ярылды. Мең базга кабык белән бәрәңге койган тавыш озак яңгырап торды. Кыз Гафурга сеңде.

— Бу теге яшен тавышы!— диде кыз.

Яңгыр алдыннан исә торган куәтле җил агачларны уятты. Тагын яшен яшьнәп, күк күкрәде.

Алар кайтырга борылды. Яшен суккан саен, кыз чак сизелерлек итеп, Гафурга елыша. Гафур нәрсә уйларга да, нәрсә эшләргә дә белми. Эре-эре тамчылар яфракларга шапылдап төшә башлады. Җиргә, маңгайга тамалар.

Алар утыргыч янына җиткәндә бөтен җир йөзе яктырып китте. Гафур егет күләгәсенең агачлар арасына кереп күмелгәнен абайлап алды. Кыз да егетнең тиз генә, аларга күренмәскә тырышып, куак арасына кереп киткәнен күрде. Ләкин һични әйтмәде.

— Әйдәгез, гөмбәз астына!— диде кыз.

Гафур аның тавышында ниндидер каушау-курку сизде.

— Сез яшен карарга җыенган идегез бит.

— Юк-юк, мин яңгыр килсен дип юраган гына идем.

Гафур елмайды:

— Сез ырымнарга ышанасызмыни?

— Мин гореф-гадәтләрне хөрмәт итәм. Кызу һава туйдырды бит. Җир дә, күңел дә яңгыр тели.

Күк ертыгыннан чиләклэп яңгыр коя башлады. Гөмбәз ышык

урын булып чыкмады. Яннан бәргән яңгыр икесен дә чылатып бетерде. Икесе дә бүлмәләргә ашыкты.

Бөтен бүлмәләрнең дә тәрәзәләре ябык. Гафур бүлмәсенең генә тәрәзә капкачлары шарт та шорт бәрелә.

Гафур баштанаяк чишенеп ятты да тирән итеп көрсенде, әйтерсең лә ул тагын бер көнне сызып ташлады.

Яңгыр чиләкләп коя. Җил тәрәзә капкачларын кубарып алырдай итеп дулый.

— Һәй, тугызынчы бүлмә, тәрәзәңне яп!— дип кычкырды каравылчы.

Гафур җәймәгә уранып торды да тәрәзә төбенә ятып, җилпенүче тәрәзә канатларын тотып, беркетеп куйды.

— Гафур абый!— дигән тавыш ишетелде ярым ачык калган ишектән.— Гафур абый, керим әле...

Гафур җавап бирергә дә өлгермәде, кыз инде ишекнең бу ягында басып тора иде.

— Мин яшен вакытында берүзем генә калырга куркам. Сездә утырып торыйм әле,— диде кыз, башына ураган сөлгесен рәтли-рәтли.

«Нәрсә инде бу? Шаяртамы соң кыз? Әллә чынлап та яшеннән куркамы?»

Гафур берни дә аңламады. Төн уртасында ябь-яшь кыз белән нәрсә турында сөйләшсен инде ул? Урманда йөргәндә рәхәт иде. Сөйләшсәң дә, тып-тын йөрсәң дә читен түгел иде.

Нишләргә белми аптырагач, Гафур ике касәгә тигез итеп кымыз салды.

— Ярамый.— диде кыз.— Яшен вакытында ашарга-эчәргә ярамый!

Кыз кымызны кире шешәгә салып өстәл астына яшереп куйды.

— Нигә? — дип сорады Гафур.

— Әни әйтә, азык яшен чакыра, ди!

— Әкият!— диде Гафур.

Гафур касә төбендә калган кымызны эчеп куйды. Кыз Гафур сөлгесен алып, шкаф көзгесен каплады.

— Яшен вакытында әни һәрвакыт шулай итә иде. Сез дә чәчегезне икенче сөлге белән бәйләп куегыз! Чәч магнитлы ул!

Кыз урындык аркасындагы тастымалны алып, Гафурның чал башына каплады. Каплады да чалма кебек итеп урарга тотынды. Гафур ни әйтергә белмичә, кыз бармаклары тиеп киткәнгә ләззәтләнеп утыра бирде.

Гафурның күкрәген чеметтереп әллә нинди дулкын йөгереп узды. Кызның бармаклары аның тәненә тиеп киткән саен, йомшак сулышы маңгаена бәрелгән саен ул дулкын һаман күкрәкне чеметтерде.

— Менә сез хәзер чын-чынлап көм гарәбенә охшагансыз!

Кыз каршы урындыкка утырды.

— Әни кушканны эшләмичә калганым юк минем. Үзем шуларга ышанмыйм да, үзем шулай эшләргә яратам. Ул әдәпкә өйрәтә.

Гафур икенче торшерны кабызды.

— Кирәкми! — диде кыз һәм ике лампаны да сүндерде.

Алар дөм караңгыга чумдылар. Ара-тирә бүлмә яктырып куя. Гафурга аның бераз агарган, матур булып сулган яңаклары күренеп ала. Яшен уты сүнгәч, Гафур күз алдында кызның йөзе кала.

Яшенле яңгыр таң атканга кадәр туктамады.

Мәрди Рафиков

# СУДА БАЛЫК ЙӨЗӘДЕР

## 1

Төнлә күк йөзе чалт аяз була. Йолдызлары, кышкы кичне хәтерләтеп, хәйран җемелдиләр. Ләкин, таң сызылу белән, барысы да югала. Каяндыр килеп чыккан көпшәк болытлар кичкә кадәр туктау белми агыла да агыла. Аргы яктагы таулар өстендә генә тоткарланган сыман тоела. Шунда бер мәлгә тыгызланып китәләр дә җиргә салкын, вак яңгырларын сибәли башлыйлар. Шыксыз һава ничә көннән бирле инде теңкәгә тия.

Балыкчылар, күңелләре белән шөкәтсез болытларны куалап, озак утырдылар. Шулпа да өлгерде. Вагонда, калын такталардан укмаштырылган өстәл тирәли утырып, сөйләшмичә генә әбәтләп алдылар. Кайберләре, икенче якка чыгып, тәмәке төтәтеп керде.

Владимир Евдокимов ишеккә юнәлде һәм аны бөтен киңлегенә ачып куйды. Бүлмәгә дымлы җил һәм яңгыр тавышы бәреп керде. Барысы да бусагада басып торган бригадирга карадылар. Аның йөзендә чакыру да, каттыйлык та бар иде. Балыкчылар Владимир Викторовичны сүзсез аңладылар һәм, брезент пинжәкләрен киеп, бригадирга ияреп тышка юнәлделәр. Күк гөмбәзенең болытлардан арынганын көтәргә башка чамалары калмаган иде инде аларның.

Күл суы шаулап ага. Япкычны алдан ук күтәргәннәр. Су дамба астындагы торбадан ургылып чыга да, тимер челтәр аша үтеп, елгага китә. Ә яшь маймычлар челтәр алдында тоткарланып кала. Бу урында су кайнап тора. Әсирлеккә эләккән балыклар, ни кылырга белмичә, туктаусыз сикерешәләр. Ләкин язмышлар билгеле: бәләкәй җәтмәләр белән сөзеп алалар да, су тутырылган брезент савытларга салып һәм автомашиналар белән, тирәнрәк булган кышлату күлләренә илтеп җибәрәләр. Болай да мәшәкатьле эш яңгыр астында һәм кием эченә үтеп кергән боектыргыч җилдә чын газапка әйләнә.

Акчарлаклар гаугалана. Көтүләре белән җиңел табыш эзләп килгәннәр. Өзлексез кычкырышалар, бер-береннең балыгын алырга итенәләр. Күл төбендәге ясалма ерганаклар буйлап су белән торбага таба агучы маймычларның сырты күренә калса, берничә акчарлак берьюлы шунда ташлана.

Лидия Александровна Чиркова да шул акчарлакларга каерылып карый-карый килә иде. Җиңел курткадан. Башлыгын маңгаена ук төшергән. Башлык астыннан бүселеп чыккан коңгырт чәче юешләнергә өлгергән. Яңгыр тамчылары аның какча битеннән дә сызылып төшкән.

Балыкчылар, баш белгечнең сәламенә игътибар итмичә, зарланырга ук тотындылар. Шилә яуган яңгыр манма су итә, кулда җәтмә тормый. Төнге аяз һавада су өсте бозланган булган. Үткен кырлы боз кисәкләре монда да агып килә, маймычларны сосканда җәтмәләрне ертып азаплыйлар. Лидия Александровна бу турыда үзе дә яхшы белә. Көзнең мондый дуамаллыгына, көтмәгән комачаулар китереп чыгаруына борчылып бетә алмый. Балыкчы егетләрнең үз итеп кенә зарлануларын да аңлый, аларның кыен шартларда да эшләүләренә шатлана.

Лидия Александровна җиргә чүмәште, тимер челтәр яныннан җәтмә белән сөзеп алган маймычларны җентекләп карый башлады. Балыклар тигез түгел: кайберләре урта бармак буе, эрерәк үскәннәре дә бар. Сәбәбе билгеле: язгы-җәйге якта суның җылылык режимы тигез булмады, балыклар уылдыкны тоткарлыклар белән чәчтеләр, шуңа кайбер маймычлар исәймичә калды. Кышлатуны вакытында һәм дөрес оештырмасаң, моның киләсе җәйдә товарлыклы балык җитештерүгә тискәре йогынтысы булыр. Баш белгеч шуңа борчыла. Бу мизгелдә аны агроном кебек күз алдына китерәсең. Ә агрономның чәчүлек басуы була. Ул андагы эре бөртекләрне җыеп амбарга салып куя, шул кадерле орлыкларны «язның алтын фонды» дип атый, «киләсе елгы уңышның нигезе» дип зурлый. Лидия Александровна да утыз биш гектарлы күлдә Владимир Евдокимов бригадасы зур мәшәкатьләр белән уылдыктан үстергән шул фондны җыйдырта һәм кышлату өчен ышанычлы саклагычка күчертә. Таш яуса да алырга тиеш ул бу байлыкны. Чөнки аның язмышы да, үзе белән ерактан алып килгән якты хыяллары да шушы байлыкка бәйләнгән.

Бер әңгәмә вакытында кайсы яклардан булуын сорадым. «Каспийдан!» — диде Лидия Александровна. Аның бу сүзендә иң кыен чакта көч бирердәй горурлык сизелә иде.

Табигатькә ленинчыл мөнәсәбәт, табигать байлыкларын саклау һәм күбәйтүгә ленинчыл караш, халкыбызның матур гадәте буларак, дәвам итә һәм ныгый. Халык ихтыяры һәм партия, хөкүмәт карары белән Идел бассейнында кыйммәтле балык үрчеткеч хуҗалыклар үсеп чыга. Аның берсе Зөя елгасы уйсулыгында төзелә. Бу хуҗалык башта Иделгә һәм бүтән сулыкларга җибәрү өчен сазан маймычлары үстерә. Аннары, хуҗалык киңәйтелгәннән соң, товарлыклы балык җитештерергә боерык ала.

Каспий балыкчылары арасында үскән, гүзәл табигать кочагында тәрбияләнгән, шул якның махсус уку йортларында белем алган кыз матур хыяллар, тирән омтылышлар белән шушы хуҗалыкка килеп чыга һәм ихлас күңелдән эшкә чума. Каспий кызы бу якны шулай үз итә.

Кармак салу гына түгел шул балык үрчетү, мәшәкате ел буена җитә. Балыкларны уылдык чәчүгә әзерләү һәм чәчтерү Лидия Александровна өчен, мөгаен, иң җаваплысыдыр. Хәзер нәсел балыклары челтәр аша үтәли агып торган тирән сулыкта тотыла. Майларын сыза-сыза кышларын да шунда үткәрәләр. Бер рәткә тезелеп киткән кечкенә күлләрдә су җылынгач, нәсел балыкларын уылдык чәчү өчен шунда күчерәләр. Һәр күлгә бер ана, ике ата балык җибәрелә. Җылы күл суында берникадәр вакыттан төртке-төртке маймычлар күренә башлый. Аларны никадәр куркыныч көтә, алар әле монда да,

исәя төшеп зуррак күлгә күчерелгәч тә кешенең игътибарына мохтаҗ.

Кеше күзәтүе һәм ярдәме белән инде менә нинди булып үскәннәр. Лидия Александровна аларны игътибар белән карый, сәламәтлекләрен тикшерә, тазару дәрәҗәләрен билгели. Маймычлар язын тагын күлгә кайтыр: тагын да иркенрәгенә! Буй җиткерергә, ялтырап торган көмеш тәңкәләре белән кеше күзен кызыктырырлык булып үсәргә.

Күл өстеннән үрдәкләр очып әйләнде. Алар бер мәлдә Зөя ягына ук уздылар. Аннары, текә борылып, тагын күл өстенә килделәр. Үрдәкләр туган күлләре, шаулап утырган камышлары белән саубуллаша иде. Моңсу булып китте.

Күлнең суы шактый тартылган иде инде. Балыкчылар да, яңгырга үч итеп, хәйран эшләделәр. Аннары, бүгенгә җитәр дип, япкычны төшерделәр, суны туктаттылар. Челтәр алдында тоткарланган барлык маймычлар сөзеп алынды. Бу вакытта инде шәфәкъ алланган, Зөя буена тагын йолдызлы кич килә иде.

## 2

Балыкчылар машинасында кайтабыз. Егетләрне алыштырганнар диярсең. Сөйләшеп туя алмыйлар. Бүгенге эшләреннән канәгать калганнары сизелә. Бер-берен иртәгә вагонда яңгыр сагалап утырмаска, көне буе эшләргә өндиләр, шулай итеп, маймычларны бер-ике көндә күчереп бетерергә өметләнәләр, мәшәкатьле эшнең уңышлы тәгаллә нәчәгенә ышаналар. Шуңа бәхетле алар бүген!

Кеше ихтыяры һәм куәте бу якларны әкияттәге кебек үзгәрткән. Басу урынында — күлләр көзгесе. Иң зурлары йөзәр гектарлы.

Иртә. Зөя аръягындагы таулар өстеннән кояш күтәрелә. Үлән кыякларындагы чык бөртекләре таңдагы матурлыкларын кадерләп җемелдәп утыра. Күл өсте көзгене хәтерләтә. Таң кызы, аның ярына басып, бөтен чибәрлеген күрә алыр иде.

Бер уйлаганда шушы гүзәллек тә бик җиткән. Ләкин бу урында табигать бөтен юмартлыгын күрсәткән диярсең. Елга ярының әрәмәлеге, Зөя өстенә үк авып торган тауның карсак урманы ниндидер хозурлык бирә. Шунда республикабыз хөкүмәте карары белән табигать һәйкәлләре рәтенә кертелгән тау наратлыгының үзен күрәсең. Ул кучкылланып тора. Галимнәр шул җирдә борынгы наратларның нәселен тапканнар һәм фән өчен файдаланалар. Табигать һәйкәле... Бик кызык. Кеше ниләр генә уйлап чыгармый. Табигать могҗизасын һәйкәл дип ничек зурлаган! Ә үз хезмәтен тыйнак бәяләгән: «Балык хуҗалыгы». Тургайлар оя типкән җирдә дамбалар белән уратып дистәләгән күл күтәргән, арыклар сузган, елгада бетон буа, насос станциясе төзегән — зур хезмәт куйган. Ә кеше башкарган файдалы хезмәт, башкалар тарафыннан танылган олы хезмәт үзе һәйкәл дип аталырга хаклыдыр.

Мотор кабыздылар. Ул дөп-дөп итеп алды да тоташ гөрелтегә әверелде һәм саңгырау авазы белән тирә-юньне уятып җибәрде. Камыш арасыннан үрдәкләр күтәрелде. Күлләр өстеннән бер уратып килделәр дә, шомланыр нәрсә булмагач, яңадан үз урыннарына төштеләр.

Без, дамбаны каплаган куе үлән арасыннан салынган сукмак буйлап, гөрелте килгән якка киттек. Анда, иң аргы йөз гектарлы күлдә, балыкларга азык бирергә әзерләнәләр иде.

Катер янында Ренат Сабирҗанов белән Юрий Любимцев кайнаша. Мөшкәле бункерга комбиазык тутырылган. Азыкны бөтен хасиятен китереп әзерләгәннәр. Балык дигәч тә, бик талымлы нәрсә ул. Хәер,

терлекләргә дә азыкларны фән нигезләрен кулланып белгечләр төзегән рацион буенча кухняларда хәстәрләп бирәләр, ничек ашауларын күзәтеп торалар. Ә махсус хуҗалыкның балыкларына шундый игътибар артыкмы? Юк, артык түгел! Аларга да азыкларны ихтиологлар киңәше белән әзерлиләр һәм бирәләр. Монда балык хуҗалыгы директорының гадәти бер боерыгы да күп нәрсәне ачыклый. Ул бригадирларга, белгечләр белән бергә, балыкларны ашатуның технология картасын төзергә куша. Бу картада известь, минераль һәм органик ашламалардан файдалану, балыкларның азыкны ничек ашауларын күзәтүдә тоту өчен һәр күлдә кимендә 4 өстәл булдыру, суның температура һәм газ режимын күзәтү, табигый азык базасын тикшереп тору һәм башка чаралар карала. Аммиак селитрасы һәм суперфосфат та кирәк икән. Күл ләменә известь та кертәләр, су чиленә органикасын да салып чыгалар. Ә анда инде балык яраткан су борчалары һәм башка җимнәр күп була.

Тәмле, майлы балыкны табында хезмәт куймыйча гына күрә алмыйсың. Балыкчы эше — кул хезмәте; күп игътибар сорый. Азыкны таратып чыккач, озак та үтми, белгечләр күлнең контроль өстәлләрен тикшерәләр. Анда азык калдыклары күбрәк табылса, пошамангa төшәләр, күп төрле сораулар туа. Бәлки балыкларга сый ошамагандыр? Бәлки температура һәм газ режимы бозылгандыр? Балык дигәнең тынычлыкны да, артык җылы, я артык салкын суны да өнәми. Җитезлеге сүнә, сүлпәнлек баса. Андый балык сыза башлый. Бу очракта белгечкә азык составын яңабаштан карап чыгарга туры килә. Насос станциясен эшләтеп, күлнең суын сафландыру чарасы күрелә.

Ренат белән Юрий, балыкларның иртәнге ризыкларын алып, күлгә кереп киттеләр. Тамаша башланды. Хәер, ул фермада да шулай. Азык күтәреп килүче кешене терлек авазланып каршылый, пырдымсызлыгын күрсәтә. Охшаш холык балык затында да бар икән ләбаса! Алар азык төягән катерга өерләре белән иярделәр. Бөтереләләр, сикерешәләр. Катер басма янына кайтып туктагач та күл өсте «кайнап» тора башлый. Ә балыкчыга балык чупылдаганны тыңлаудан да рәхәт нәрсә юктыр!

3

Көзге көннең көенә һич төшенә алмассың. Кичә күл эшчеләрен туктаусыз яуган яңгыр интектерде. Ә бүген иртән болытлар сөрүдән чыккан мамыклар кебек тузгыганнар, күпмедер яңгыр тотарлык әүкатләре калмаган. Хәтта җиргә кояшның сүрән генә нурларын да үткәргәннәр. Хәер, көзге көннән тагын ни көтәсең? Болыт аша саркып чыккан шул нурлар да күшеккән күңелне язып җибәрә бит.

Хуҗалык директоры Николай Александрович Любимцев, шомланып, күккә карангалап ала. Андый чакта ул тырпаеп торган коңгырт кашлары астында ялтыраган күзен җиңелчә кыса, аннары, ни өчендер, кулын уа. Ә сүзгә әллә ни юмартланырга теләми. Хәер, болай ул үзен басынкы тота торган кеше. Тирәнтен уйланыр, ләкин нәтиҗә ясарга ашыкмас. Николай Александрович тормышта күп нәрсә күргән, мәгънәле кеше. Журналист сукмагын узган. Бу сукмак никадәр шатлык белән очраштырган да, борчылырлык, уйланырлык никадәр вакыйгалар күрсәткән. Партия райкомында, аннары колхоз коммунистларына җитәкчелек эшендә кешеләр тәрбияләү өчен бик кирәкле һәм кадерле чыныгу алган Николай Александрович, карашын да, омтылышын да үстергән. Ә кеше, үзендә канат барын сизсә, талпынырга көч таба. Канат — бәхет.

Без инде дамба буйлап ике күл уздык, өченчесенә барып җиттек. Николай Александрович шунда туктады да кулындагы тал чыбыгы белән су читенә ымлады:

— Күрәсеңме, нәрсә үсә?

— Камыш.

— Ә безнең өчен бәла.

Ул бу сүзләрен нindидер зәһәр белән әйтте. Үзәгенә үткән кеше генә, мөгаен, шулай каһәрли беләдер.

Мин төрлечә уйладым. Бу камышлар кисәк кенә директорның телен ачты. Әмма шунда ук мине уңайсыз хәлдә калдырды. Чөнки алар яныннан узганда камыш шаулавы турында лириклар әйткән сүзләрне кабатларга риза идем. Яр буенда әнә ничек матур тезелешкәннәр.

Ләкин балык хуҗалыгының директоры күл камышына бөтенләй башка караштa икән. Ул сүзен тагын кабатлады:

— Әйе, бәла үсә, үзәккә үтә,— диде.— Күл эшчесе җәй буе камыш кыркырга мәҗбүр.

Ясалма күл өчен утрауларның да кирәге юк икән. Алары күлнең вакытыннан элек саегуына китерә. Камыш шундый урыннарны көтеп кенә тора икән. Сай һәм җылы суда күтәрелеп чыга да киң фронт белән һөҗүмгә күчә, балыкның ризыклану урынын кысрыклый башлый.

Балык күлләрен культуралы тоту — тиз хәл ителергә тиешле зур проблема ул. Шул хакта сүз чыккач, Николай Александрович нindидер канәгатьләнү белән җиңел сулап куя. Чөнки сызлавына дәва таба. Нинди дисезме? Балыкчылыкны үстерү турында ил уйлый, Ватан кайгырта. Мәсьәлә партия Үзәк Комитетының 1978 елгы июль Пленумында бөтен җитдилеге белән күтәрелде. Анда азык ресурсларын тулыландыру өчен җирле сулыкларны яхшырак файдалану исәбенә балык җитештерү эше белән конкрет шөгыльләнү кирәклеге, практик яктан мөмкинлекләребез чиксез булу да күрсәтелде. Ә партия һәм хөкүмәтебезнең шуннан соң кабул ителгән махсус карарында бу мөмкинлекләр тагын да тулырак ачыла, практик эшләр билгеләнә. Анда буа-күл хуҗалыкларын техник коралландыру, зур балыкчылык-мелиорация эшләре үткәрү турында әйтелә.

Директор кичә азаплы яңгыр астында «чәчүлек басуыннан» «орлыклык фондны» җыйдыртучы Каспий кызы Лида Чиркованың тирән борчылуын искә төшерде. Кичә, аның янындагы балыкчыларның эшенә төшенмичә, гади күзәтүче булганбыз. Ә директор анда тирән проблема ятуын раслый. Үсеш юлын да күрәсең. Хуҗалык уналты ел буе гади питомник эшен үтәде: бар булган маймычны елгаларга, бигрәк тә Иделебезгә җибәрәләр иде. «Ул маймычларның хәле мөшкел түгел»,— дип кем әйтер? Ана куенында яшәп, чиксез далада калдырылган иркә бала кебек ич алар — яши дә, саклана да белмиләр. Аннары ул Идел-диңгездә йөзеп кайчан өлгерә дә, кайчан промыселчы балыкчыны куандыра?

Бүген инде менә биш ел буена бу — интенсив типтагы хуҗалык: тәмле, майлы балыкларны тиз өлгертеп, турыдан-туры табынга бирә. Хәзер инде балык маймычлары белән хуҗалыкның үз-үзен тәэмин итү бурычы тора. Шул ноктага җиткәч, ихтиолог та, директор да, күл эшчесе дә сукранып куя. Күл ысулы белән маймыч алу кеше ихтыярында гына түгел икән шул. Нәкъ җырдагы кебек: «Суда балык йөзәдер, су салкынын сизәдер...» Су салкынында, яр буена утырып еласаң да, балык сиңа уылдыгын чәчеп күрсәтми. Күл төбенә безнең фатирларыбыздагы кебек җылы торбаларны да суза алмыйсың. Маймыч алу тоткарлана, балыкларны интенсив үстерү акланмый. Маймычларны завод ысулы белән алу проблемасы туа.

1978 елда хуҗалык күптән хыялланып көткән яңа җиһазларны алган һәм бик кирәкле инкубатор цехы төзегән. Җиһазларны сынап карарга да өлгергәннәр. Иң беренче булып, балык заводы промыселчылары соравы белән һәм алар ярдәмендә, Иделгә кадерле санитарлар — йөзләрчә мең чуртан маймычлары җибәрелгән. Алар инкубаторда уылдыктан чыгарылган.

Инкубатор цехы балык хуҗалыгының тормышына яңа сулыш булып керә һәм аның куәтен күз алдында үстерә. Күл суының балык уылдык чәчәрлек дәрәҗәдә җылынуын көтәсе булмый. Интенсив типтагы хуҗалык өчен күп вакыт янга кала. Маймычларның тигез үсүенә мөмкинлек арта. Инкубатор цехында уылдыктан маймычны да күбрәк аласың. Мондагы сазаннар бер-берсе сигез йөз мең чамасы уылдык чәчәргә сәләтле. Болай караганда зур байлык кебек тоела: күлне балык белән кырыеннан тутыр! Ләкин мондый беркатлылык белән эш йөртеп булмый икән. Суның температурасы төшсә, уылдык әчи. Монысы — котылгысыз беренче бәла. Уылдык белән су кошлары да сыйланырга ярата — тагын бәла. Шулай югалта торгач, сигез йөз мең бөртек уылдыктан алтмыш мең маймыч алсаң да бик канәгатьләнәсең. Бу әйбәт эш рәтенә керә — норма. Ә инкубатор цехында бөтен уылдыкның илле процентыннан таза балык маймычы алырга була. Директор шушы мөмкинлекне күрсәткәндә «таза» сүзенә басым ясый. Балыкчы өчен монысы бик әһәмиятле икән! Чөнки инкубатор шартларында маймычның йогышлы авыру алу куркынычы бетә. Ә сәламәт балык тиз үсә, майны тиз җыя.

Инкубатор цехы шулай яңа перспектива ача. Хәзер мондагы күлләрнең мәйданы бер җәйдә дүрт миллион сазан маймычы үстерергә мөмкинлек бирә. Дүрт миллион! Ә хуҗалыкның үзенә товарлыклы балык җитештерү һәм күл мәйданын тулы файдалану өчен бер миллион чамасы маймыч җитә. Калганын — колхоз буаларына, башка сулыкларга... Автомашиналарда, «тере балык» вагоннарында ил гизсеннәр маймычлар, күлләрен, елгаларын тапсыннар! Шөкер, алары һәр җирдә көтәләр.

...Болытлар тәмам таралган иде. Әсирлектән котылган кояшның нурлары күл суында чагыла-чагыла коена башлаганнар. Алар дулкын уйнаганда бихисап төсләргә кереп җемелди, әйтерсең офык артыннан болытлар кузгалганчы шулай рәхәтләнеп калырга телиләр иде. Бу минутта директор күңеленең күтәренкелеген сиздем. Ул тагын нииндидер уйлары, яңа проблемалары белән эчке ләззәтләнү кичерә, татып туя алмаслык тәм таба кебек иде. Без, янәшә атлап, иң ерактагы күл буена киттек.

4

Йөз гектарлы беренче күлнең суын җибәргәннәр. Су дамба астындагы торбадан тулып чыга да арык буенча Зөягә ага. Ә эре тәңкәле симез сазаннар челтәр киртә алдында токтарланып калалар, кая барырга белмичә бөтерелә башлыйлар. Ләкин озакка түгел. Балыкчылар сазаннарны кечкенә җәтмә белән сөзәләр, автомашинаның брезенттан махсус җиһазланган әрҗәсендәге суга салалар.

Анатолий Казаков автомашинасын улы Константин машинасы белән бергә куйган. Юлга икәү чыгалар: берсе — Казан шәһәренә, икенчесе — Зеленодольскига. Шәһәр кешеләренең кичке табынына илтеп җиткерергә иде!

Монда Бәхетгәрәй Мөхәммәтҗанов бригадасы эшли. Һәр чак ачык чырайлы, исәп-хисап яратучы бу кеше бригададагы сигез еге-

тен берьеллык балыкларны алты йөз граммга кадәр үстерергә, шушы күлдән ике йөз тонна сазан алырга өндәгән. Бригада шундый матур омтылыш белән эшләгән. Ә хәзер шатланып уңышын җыя. Күршедәге икенче күл хуҗалары Азат Минһаҗев бригадасы егетләре ярдәмгә килгән. Арыкта чупырдаган сазаннарны сосып алган саен шау-гөр куба:

— Күрегезче, җиде йөз грамм булыр!

Машиналар килеп тора. Теләсә кемне кызыктырырлык сазаннарны «тере балык» вагоннарына да илтәләр. Алары бүген үк КамАЗ, Түбән Кама якларына китеп барыр. Балык җитәрлек. Әле Минһаҗев бригадасында башламаган күл бар. Егетләр аннан 120 тонна сазан сөзәргә вәгъдә итәләр. Дөньяда тиңдәшсез планнар белән янып эшләүче шәһәр кешеләренә авылның бүләге булсын. Бу бүләкне Сафа Кәлимуллин, Тәлгать Яруллин, Юрий Яшин, Гарәф Корбанов, аталы-уллы Казаковлар, Любимцевлар, Анисимовлар, Каспий кызы Лида һәм башка уңганнардан киң күңел белән кабул итсеннәр.

Бригадир сөрәкәләрне әзерләргә боерык бирде. Аны искәрмәсез дә аңлыйлар, кичекмәстән үтәргә кирәклеген дә беләләр. Чөнки су эчендәге утрауларның балчыгы ашалып төпкә ләм булып яткан, күлнең югары өлешендә байтак балыкны бүлеп калдырган. Шул сазаннарны сөрәкәләр белән бик тиз җыеп алырга кирәк. Юкса, «адашканны аю ашар...» дигән кебек, балыкны козгын, ала каргага тикле ауларга керешә. Аның товар буларак сыйфаты да югала. Аннары тап син бозылган малга ия.

Сөрәкә көйләүче егетләрнең йөзләренә карыйм: тирән борчылу бар. Хәзер алар ләм эченә барып керерләр, кунычтан чума-чума авыр сөрәкәләр белән калдык суда елгыр балыкларны аулап йөрерләр. Алар күз алдында хезмәтнең тәме, ихтимал, өреп очыргандай юк була. Кешенең ихласын кайтарырга күл ләменә бер мәртәбә кереп чыгу да җитә ич. Кайчандыр күлне проектлаган, кәгазь битләренә хисләнеп утраулар төшергән иптәш бу хәлне, мөгаен, белмидер, су җибәргәндә авышлыктан түбәнге якка балык агып килергә тиешле махсус ерганакларның бик тиз томалануын һәм кешеләргә никадәр өстәмә мәшәкать тудыруын күз алдына да китермидер. Яңадан мелиорация эшләре үткәрмәсәң, бу хәлнең бәла булуы ихтимал. Күлсез калуың мөмкин, күлсез!

Эш өстендә вакыт тиз уза. Төш җитте. Балыкчыларны ашка чакырдылар. Пинжәкләрен салып, юынып алгач, барысы да өстәлгә утырды. Күңелле гәпләшеп, үзара мәзәкләп балык шулпасы ашый башладылар. Кыр вагоны борынны кытыкларлык тәмле ис белән тулды. Кара икмәк һәм балыкчылар гына пешерә ала торган шулпа исе тышка таралып, су һәм ләм исе белән аралашты. Күлдә үскән балык күл буенда бигрәк тә йөрәккә ятышлы була икән. Хәер, Кайбыч балык хуҗалыгы сазаннарыннан әзерләнгән ашны Казанда да, КамАЗда да, башка җирләрдә дә гел мактап ашыйлардыр. Чөнки балыгын үстерүгә киеренке хезмәт куелган, ә хезмәт җимеше һәр чак татлы була.

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 80 ЯШЬ

## РЕДАКЦИЯДӘН



*Әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезнең күренекле аксакалы, армый-талмый хезмәт итүче киң карашлы, тирән мәгълүматлы галимебез Нәкый ага Исәнбәткә 80 яшь тулды.*

*Аның Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк бөреләнгән иҗади эшчәнлеге үзенең тамырлары белән гади халыкның өмет-теләкләренә барып тоташа, якты идеалларны раслау өчен көрәш юлына алып чыга:*

*Хәзер мин юлдамын — һичтөрле арганлык ирендермәс,*
*Хәзер мин юлдамын — һичтөрле көч юлдан чигендермәс!—*

*дип яза яшь шагыйрь 1916 елда.*

*Нәкый Исәнбәт әсәрләрендәге эчтәлек һәм форма бердәмлегенең, камиллегенең нигезе — халыкчанлык. «Уракчы кыз», «Бормалы су» кебек җырларының чын мәгънәсендә халыкныкы булып китүе, ә күп санлы баллада, поэмаларының һәм драматик әсәрләренең халык иҗаты җәүһәрләреннән иҗади файдаланып язылуы — әнә шуңа бер дәлил.*

*Нәкый Исәнбәтнең Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә ике мең тапкырдан да күбрәк куелган һәм тамашачыларның мәхәббәтен яулаган «Хуҗа Насретдин» комедиясе, шулай ук «Рәйхан», «Зифа» һ. б. сәхнә әсәрләре драматургиябез хәзинәсенә зур өлеш булып керде. Совет сәнгате өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре өчен Нәкый ага Исәнбәткә РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде, ул хөкүмәтебезнең югары бүләгенә — Ленин орденына лаек булды.*

*Аның балаларга атап язылган әсәрләре, шулай ук рус һәм чит ил классик әдәбиятыннан татар теленә тәрҗемәләре дә укучыларда даими кызыксыну уятты.*

*Бала чактан ук әкиятләрдә, җыр-такмазаларда, мәкаль-табышмакларда халык рухының тылсымлы көчен күрергә өйрәнгән Нәкый Исәнбәт озак еллар дәвамында фольклор материалларны җыю һәм аларны гыйльми тикшерү эшенә зур көч куйды. Татар халык мәкальләрен туплаган һәм шәрехләгән өч томлык хезмәте өчен ул республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде. Гомумән, тел һәм әдәбият тарихы, аеруча фольклор буенча бу киң колачлы фәнни эшчәнлек халкыбызга, фәнебез үсешенә чын күңелдән хезмәт итүнең күркәм үрнәге булып тора.*

*Соңгы елларда галим татар теленең фразеологик әйтемнәр сүзлеген төзү белән мәшгуль. Билгеле булганча, әйтемнәрнең тарихи шәҗәрәсе, телдә тоткан урыны һәм мәгънәви мөмкинлекләре — әлегә аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе.*

*Түбәндә Нәкый Исәнбәтнең шушы мәсьәләгә багышланган хезмәте тәкъдим ителә. Юбилярны журнал укучыларыбыз исеменнән кайнар котлыйбыз. Һәр вакыт яшьләрчә көр күңелле булыгыз, иҗат чишмәләрегез мөлдерәп торсын, Нәкый ага!*

Нәкый Исәнбәт

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕМНӘРЕНДӘ ТАРИХИЛЫК ҺӘМ ҮТКӘН БЕЛӘН ХӘЗЕРГЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Телебездә төрле юралышлы мәгънәләрдә әйтелеп йөргән бик күп төрле тәгъбирле сүз төзелмәләре (сәер гыйбарәләр, телбизәкләр, кинаяләр, сүз җилемнәре һ. б.), хәзергечә әйткәндә, фразеологик әйтемнәр бар. Шулай ук әйтемнәрдән саналган һәртөрле штамп-тәгъбирләр, кереш сүзләр, теләк-каргышлар, кушсүзләр һәм башкалар да күп. Алар сөйләм телендә бик нык катнашып өзлексез актив роль уйныйлар. Шулай ук халык иҗатында да (әйтик, мәкаль, табышмакларда, җырларда һ. б. ) зур урын тоткан кебек, язма әдәбиятыбызда да кулланышта. Әдип-шагыйрьләребез, журналистларыбыз аларны төрле дәрәҗәдә файдаланалар һәм үзләре дә заманча төсмерләрдә иҗади яңарталар. Төрле систем фразеологик сүзлекләр һаман чыгарыла тора. Төрки халыкларда да бу шулай эшләнә, шулай алып барыла. Димәк ки, һәр халыкта да булган кебек, фразеологик әйтемнәр бездә дә татар теленең иң юрамлы, иң тере, тәгъбирчән җегәрле һәм характерлы элементлары булып торалар. Ул милли тел байлыгыбызның хәрәкәттәге хәзинәсе һәм ул шуның саен үзенә бик нык игътибарны җәлеп итә. Мәсьәлә шулай актуаль торганга күрә, бездә дә, билгеле, бу хакта кул кушырып торылмый. Кайбер теоретик гыйльми тикшеренүләр, эзләнүләр күренде һәм күренә. Кечерәк булса да кайбер җыентыклар да чыккалады, сүзлекләрдә дә әйтемнәрдән мисаллар, аңлатмалар бирелгәли килә. Ләкин без әле боларга карап кына татар теленең фразеологик әйтемнәре инде тупланды, өйрәнелде, нинди дә булса бер калыпка, бер системага салынды, зуррак күләмле бер махсус сүзлеге чыгарылды яки дә төпле бер гыйльми теориясе торгызылды дип әлегә әйтә алмыйбыз, әлбәттә; аныСы әле күтәрелмәгән чирәм дияргә була.

Шунлыктан телебезнең бу мөһим тармагында укучыларны борчыган мәсьәләләр һәм кызыксындырган төрле сораулар туу, аларга җавап көтүләр булуы һич тә гаҗәп түгел, киресенчә, бу бик табигый.

Мәсәлән, бу кереш мәкаләне укыгач та күңелдә туачак шундый сорауларның берсе:

### ТЕЛ ҺӘМ АНДАГЫ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕМНӘРНЕҢ ТАРИХИ САКЛАНУЧАНЛЫГЫ ХАКЫНДА ҺӘМ АҢА МИСАЛЛАР

Тел — күңелдә туган уй, хиснең мәгънә һәм форма тапкан юралышы һәм ул, аңлашу чарасы буларак, халыкның үз тарихы, үзенең культурасының җимеше. Шуның белән һәрбер тел үзенә хас структуралы, мөстәкыйль, тотнаклы һәм бөтенлекле бер организм. Тел заманнар үтә-үтә һаман өстәмә үзгәрешкә дучар булса да, нигездә сүз һәм әйтемнәр үз төзелешен, ягъни тел үзенең хәзинәсен гасырлар аша саклый алучан. Бигрәк тә төрки телләре үзләренең борынгы сүз тамырларын һәм сүз төзелешләрен, грамматик структураларын нык саклап килгән булулары хакында соңгы заманнарда күп язылды һәм языла килә. Бу исә борынгы баба төрки телнең асылда үз ясалышы бик төпле, нигезле булуына, табигате төзек, үскерем һәм нык үзенчәлекләргә ия булуына, үз эчке культурасына бәйле.

Инде шулар эчендә фразеологик әйтемнәргә килсәк, алар һәр телнең бары тик үзенә генә хас формалы милли байлыгы итеп карала. Шунлыктан соңгы вакытларда төрле халыкларда бу хакта төрле тикшеренүләр, гыйльми хезмәтләр, эзләнүләр мәйданга чыгып тора. Аларда үз телләрендәге кайбер әйтем-гыйбарәләрнең, телбизәк-

ләрнең тарихта берәр булып үткән вакыйгага уңае белән әйтелгән булуын күрсәткән мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, руслар үзләренең **«Вот тебе, бабушка,. Юрьев день!»** дигән әйтемнәренең гасырларча сакланып килгән булуын аңлатып бирделәр һ. б.

Менә шуннан безнең укучы алдына бик табигый бер сорау килеп басачак: тарих та тарих, саклана да саклана дисез, бездә, ичмасам, бер генә дәнә булса да, шулай тарихи сакланып килгән, килә алган фразеологик әйтемебез бармы? Булса, була алган булса, ник ул хакта бездә бер кайда да язылмады, язылмый? Гомумән, татар фразеологиясендә тарихи бер эзлеклелек бармы соң? Әллә алар Г. Тукайның Болгар хәрабәләре хакында язганынча: «Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады» дигән кебек, булдылар да беттеләр дибезме?

Бу — күп төрле сораулардан бер генәсе, әлбәттә. Шулай булса да ул бик урынлы, бик мөһим һәм җитди сорау, минемчә. Моңа без уңай җавап таба алмасак һәм мисаллар да китерә алмасак, телебезнең мөһим элементы булган татар фразеологиясенең тарихи-иҗтимагый урыны һәм роле булып-булмавына шик төшәчәк һәм, гомумән, безнең әйтемнәребезнең кыйммәте, әһәмияте булу-булмавы да бәхәсле калачак. Әгәр безнең әйтемнәребез шулай тарихи эзлекле булмыйча, бүген туып иртәгә онытыла торган очраклы гыйбарәләр генә булсалар, аларның татар теле тарихы һәм үсеше-барышы ягыннан әллә ни әһәмияте дә булмас, татар фразеологиясе, гомумән, вакытлыча гына йомыш үтәүче сыман нәрсә итеп каралыр иде. Һәм, нәтиҗәдә, татар халкы гүя ки үзе дә моңарчы тарихта үз дәүләтле, үз мәдәниятле һәм үз тел-әдәбиятлы, тотнаклы бер халык булмаган һәм гүя ки без үз ата-бабаларыбыздан да тумаганбыз, бәлки кисәктән генә топ-томалдан яп-яңа бер халык булып, ясалып төшкәнбез, тиз генә модный галстук кисәге такканбыз һәм шуның белән нәтиҗәдә үзебез дә юньле-башлы, тотнаклы бер халык булу урынына, Тукай әйтмешли, «әллә нинди американизовать ителгән» бер жаргонда сөйләшүче ниндидер нәсел-нәсәпсез адәм тәганәләре булып киткән булыр идек. Тагын да хәтәррәге — үз культура мирасыбызны белмәүне үзебезнең бик нык алга китүебез билгесе дип санап, рус фразеологиясе белән әйткәндә, «не белмеса не знает» (белмәсне дә белмәс) томаналар булып калган булыр идек.

Шик тә юк, телебез белән бергә безнең борынгы әйтемнәребез дә сакланып килә, алар кулларына ордер алып иске йорттан сулы-газлы яңа квартирага күчкән бүгенге квартирантлар кебек, иске авыздан чыгып, үз авызларыбызга күчеп, үз телләребездән әйтелеп, әле бездән соң да калып яшәргә ниятләнеп йөриләр. Ләкин без телебезнең һәм фразеологик әйтемнәребезнең дә тарихын яхшы белмәгәнгә, тиешенчә өйрәнмәгәнгә күрә генә аларның да күпләренең тарихимы, әллә кичә яки бүген генә туганмы икәнен белмичә яшибез.

Шунлыктан, хөрмәтле укучым, безгә дә сезнең белән телебезнең бу тармагына, тарихка кечкенә бер экскурсия ясап әйләнү артык булмас дип беләм.

Юнәлдек...

## ЕРАК ТАРИХТАН БЕР СӘХИФӘ

Моннан мең ярым еллар элек бабаларыбыз булган болгарларның Урта һәм Түбән Иделдә, Донда һәм Азов-Таманда яшәгән булулары билгеле хәл. VI йөздә төрки халыкларның үзәкләшкән зур бер бөек патшалыгы булган каганлык (каганат) төзелә. Ул Төньяк Корея чикләреннән Азов буйларынача җәелгән була. Димәк ки, ул заманнарда Идел-Донда яшәгән безнең болгар, хәзәрләр дә бу каганлыклар системасында булганнар. 6—7 нче гасырда гарәпләр ислам байрагы астында берләшәләр һәм Иран, Византияләргә басып керәләр. Идеологиядә фанатикча дини, китаби бер тәгълимат белән гайрәтләнгән һәм Ром-Иран белән сугышларда аларча хәрби филләр менеп катапульталардан утлы нефтьләр аттырып сугыша белгән бу ислам мөҗаһитләре инде Бохара чүлләренә басып керәләр, кабиләләр союзы булган төркиләр каганлыгын дини тәгълимат белән дә, аның өчен «шәһит китеп» сугышулары белән дә эчтән-тыштан таркатa башлыйлар. Икенче яктан, 50 елга сузылган кытай әсирлегендә халык бик каты бөлгенлеккә төшә һәм озак сузылган азатлык сугышларыннан соң, Урхан (Орхон) буйларында яңадан көнчыгыш төрки каганлык торгызыла.

Бу сугышлар хакында язылган борынгы ташъязмаларның берничәсе Себердә Орхон буйларында сакланып калган. Алар 730—735 нче елларда утыртылганнар. Шунысы кызык, бу ташъязма васыятьнамәләр гарәпчә дә, фарсыча да, кытайча да түгел, бәлки безнең борынгы үз тамга хәрефләребез белән язылган булып, аларда ул замандагы төрки халыкларның гомуми һәм уртак әдәби тел үрнәкләре сакланган.

Шундый бер сорау туа: моннан мең-мең ярым ел элекке ташъязмаларда сакланган кайбер фразеологик әйтемнәр белән безнең бүгенге татар әйтемнәре арасында сүз һәм мәгънә тәгъбире булу ягыннан берәр төрле охшашлык, уртаклык яки мирасыйлык бармы, булса ни дәрәҗәдә? Шул сорауга җавап йөзеннән түбәндә кайбер мисаллар китерәм.

VI һәм VIII гасырлар каганлык чоры ташъязмаларыннан мисаллар:

АЛЛА ЯРЛЫКАСЫН. Теләк сүз. Бу әйтем гарәпчә «алла» сүзе белән әйтелгәнгә, без аны болгарлар мөселман булгач кына телебездә ясалган дип, ягъни X гасырның 22 нче елларыннан соң гына чыккан дип уйлыйбыз. Ләкин бу дөрес түгел. Чөнки VIII гасырда 730 елларда куелган Тоньюкук тамга ташъязмасында «ТӘҢРЕ ЯРЛЫКАЗЫН» дип язылган әйтем бар. Димәк, башта бу әйтем безнең телебездә «тәңре» сүзе белән әйтелгән дә соңыннан, ислам кабул иткәч, «алла» сүзе белән алыштырылган була. Димәк ки, бу әйтем кайчандыр исламга кадәр мәҗүси-шамани заманнарда да телебездә йөргән.

Искәрмә. Тәңре сүзенең тагын күк түгәрәге (тәңер), шаман тәңгере (түгәрәк барабан, аны кагып шаман күк түгәрәгенә эндәшә, тәңрене ярдәмгә чакыра...) һәм тагын башка мәгънәләре дә бар.

АҢАР КҮРӘ. Кереш сүз. Анлыктан, аңа карап, аның буенча, аның белән чагыштырып карап; шуңа күрә, димәктән — бүгенге телебездә дә бер актив гыйбарә. VIII гасырда тамга хәрефләр белән язылган Күлтәгиннең кече ташъязмасында мондый сүзләр: «Аңар керү билиң амты, төрек будун бәгләр». (Анлыктан белегез инде, төрек халык бәкләре.)

БОЛЫН-ЯРЫН КИЛҮ, БОЛЫН-ЯРЫН ЯШӘҮ. Сөйләм телендә. Төрле якка бүгәләнеп, анда-монда таралышып, як-як булып һәм карулашып яшәү димәк.

Болын сүзе бездә хәзер чабынлык, тугай (луга) мәгънәсендә йөртелә. Бу әйтемдә исә ул «як, тараф» һәм хәтта бер-беренә кара-каршы як мәгънәсендә әйтелә. «Болын»ның бу борынгы мәгънәсенә VIII гасырның беренче яртысында куелган Орхон ташларында очрыйбыз. Мәсәлән, **«Төрт булуң коп ягы эрмиш».** (Дүрт як халыкның бар да яу имеш.) Күлтәгиннең тамга хәрефләр белән язылган зур ташъязма һәйкәлендә дүрт болын—дүрт як: көнчыгыш, көнбатыш, көньяк һәм төньяк халыклар бар да дошман имеш. «Төрт булуңдакы будун». (Дүрт яктагы халык. Шул ук мәгънәдә). («Болын-ярын килү» дигәндә дә «болын» сүзе монда хәзерге чабынлык-үләнлек мәгънәсендә түгел, шул борынгы болын (булуң—як) мәгънәсен саклаганга, шул сүз белән бергә бу әйтем үзе дә борынгы чорлардан калып телебездә сакланган дип уйлыйм.

КАРА ТИР ТҮГҮ. Гипербола. Бик каты көч түгеп тырышу. VIII йөз Тоньюкук ташъязмасында: «Кара терим йүгүртти». (Кара тиремне түктерде.) Хәзер дә шул ук мәгънә.

КҮЗ КҮРМӘГӘН, КОЛАК ИШЕТМӘГӘН. Әкият алымынча әйтем. Бик ят, сәер, гаҗәп нәрсә яки хыялга килмәгән бер хәл, яңа бер эшләр димәктән. «Күз күрмәгән, колак ишетмәгән диярлек дәрәҗәдә яхшы чикләвек бирелде». (Г. Тукай.)

734 елда үлгән Билгә каган ташъязмасында: «Көзин көрмәдүк, колакын эшидмәдүк». Ягъни шул ук мәгънәдә, шул ук төп сүзләр белән, шул ук төзелештә әйтелгән, кушымчаларда гына аерма.

КҮК-ҖИР. Кушсүз. Контраст әйтем. Мәсәлән, хәзер без: «Яхшы белән яман арасы—күк-җир арасы», дибез. 731 елда язылган Күлтәгин зур ташында: «Тәңри—йир булгакы». Тәңре—күк түгәрәге мәгънәсендә. Ягъни тәңре—йир дигәне хәзергечә үк күк-җир дигәне. Димәк, күк-җир тәгъбире ул чакта да шул бер үк контраст мәгънәдә хәзергечә кушсүз ясап әйтелгән.

КҮРЕР КҮЗЕМ КҮРМӘСТӘЙ БУЛДЫ, КҮРӘ ТОРЫП КҮРМӘС, ИШЕТӘ ТОРЫП ИШЕТМӘС БУЛУ. Бу әйтемнәр бездә хәзер күрәсе дә, ишетәсе дә килмәү, тую, тәмам гарык булу яки дә күрә торып күрмәгәнгә, ишетмәгәнгә салыну мәгънәләрендә. Мисал: «Күрә торып күрмәс булсак, ишетә торып ишетмәс булсак!» (Р. Фәйзуллин.) VIII гасыр Күлтәгиннең зур ташъязмасында: «Көрүр козим көрмәз тәг, билир билигим билмәз тәг

болты». (Күрер күзем күрмәстәй, белер белегем (акылым) белмәстәй булды). Ягъни шул кадәр авыр кайгы-сагышка төштем.

ТАШКА ТАМГА САЛГАНДАЙ. Гомердә җуелмаслык, нык, анык, законча диган мәгънәләрдә. Мәсәлән, «яшьлектә укыганың ташка тамга салгандай, картлыкта укыганың бозга язгандай», дибез. Яки: «яшь хәтер—ташка язгандай, карт хәтер—бозга язгандай». Янә: «аның гадәте—ташка тамга салгандай, һәр көн тугыздан эш урынында», дибез.

Ташка тамга салу—бу безнең борынгы бабаларыбызның үз ядкяр сүз яки кабер ташларына тамга хәрефләр (рун язуы) белән тукып язган язулары диган сүз. Ягъни безгә ислам дине кергәнче, моннан мең ярым еллар һәм аннан да элек кулланган үз тарихи, милли язмабыз. Һәм шунлыктан «ташка тамга салган» әйтеме дә шул борынгы заманнарда ук телебездә актив булган. Мәсәлән, VIII гасырның 34 нче елында Билгә каган ташъязмасында: «Йәгирми күн олырып, бу ташка бу тамга куп, Йолыг Тегин битидим». (Егерме көн утырып бу ташка бу тамга салып (мин) Юлыг Тәгин яздым). **Битидим**—бөти тукыдым, ягъни ташка тукып яздым димәк. Бездә дә әбиләрнең янга язма бөти яки бөтү—тылсым—талисман тагуларын искә алсак, димәк, яздым мәгънәсендәге борынгы **битидим** сүзенең тамыры да телебездә сакланган икән. **Олырып**—хәзер **утырып** дибез. Әмма кичәге әдәби телебездә һәм башкорт телендә **ултырып** язылуына караганда, бу сүздәге борынгы «л» бездә акыртынлап төшеп «т» белән алмашына бару күренеше. Кыскасы, бу борынгы чыгышлы «ташка тамга салгандай» әйтеме телебездә хәзер дә актив бер тәгъбир.

«ТЕЛ» АЛУ. Хәрби әйтем. Сугышларда дошман кешесен тотып алып, дошман хәлен сөйләтү, дошман серен алу. Сугышта «тел алу», «тел тотып китерү»ләр бик актив кулланылганга, бу әйтем үзе дә безгә соңгы заман сугышларында чыгып таралган сүз кебек булып тоела. Ләкин бу дөрес түгел. Чөнки ул әйтем борынгы төрки каганат гаскәрләрендә үк гамәлдә кулланылган. Мәсәлән, VIII гасырда утыртылган Тоньюкук язма ташында: «Тылыг ала олыр»—«телен» тотып алып утыр. (Ягъни «тел алу» эшен дәвам иттер.) Тагын: «Тылыг кәлтерде» — «тел»не (дошман әсирен) тотып китерде.

ТӨН ОЕМАУ, КӨНДЕЗ УТЫРМАУ... Хәзерге телебездә актив бу әйтем VIII йөз Тоньюкук ташъязмасында: «Тун удзуматы, күндүз улырматы».

УТ ЧӘЧЕП, БУРАН УЙНАТЫП. Хәзерге телебездә актив кулланыштагы бу әйтем VIII гасыр Күлтәгиннең зур ташында кыскарак бер вариантта болай дип әйтеп бирелгән: **«Төркиш каган Болчуда отча, борача кәлти».** (Төркишләр каганы Болчу диган җиргә уттай, бурандай (булып) килде).

ЭШЕН-КӨЧЕН БИРҮ. Кушсүз. Хәзерге телебездә актив бу әйтем VIII гасырдагы Күлтәгиннең зур ташында: **«Әллиг ел ишиг-күчиг бирмеш».** (Илле ел эшен-көчен биргән.) **«Каганлык будун әртим каганым каны! Нә каганка ишиг-күчиг бирүрмән!»** (Каганлы (ханлы) халык идем, каганым (ханым) кайда? Нинди ханга эшемне-көчемне биреп торам?)

ҮЛЕМ-ЖИТЕМ. Кушсүз. Үлем-бетем. VIII йөздәге Күлтәгиннең зур ташында үлү-йитү (җитү) рәвешендә очрый, үлү-бетү, үләр-бетәр хәлгә төшеп диган мәгънәдә: **«Иним Күлтегин бирлә өлү-йитү казгандым».** (Энем Күлтәгин белән үлә-бетә (дәүләт) казандым дигәне.) «Йитү»нең бетү мәгънәсе безнең мәкальләрдә дә саклана: «Юнь юнеңне җетерер» (бетерер) һ. б.

## XI—XIII ЙӨЗЛӘРДӘГЕ ЯЗМАЛАРДА КҮЗГӘ ЧАЛЫНГАН КАЙБЕР ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕМНӘРНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫНА МИСАЛЛАР

ДӘРТ БАР, ДӘРМАН ЮК. Теләк, омтылыш бар, аны эшкә ашырырлык көч, хәл, куәт юк, чара юк димәктән бүгенге әйтем. Моннан мең еллап элек бездә таралган һәм шәрык белән тыгыз культура бәйләнешы булуны күрсәткән борынгы фразеологияләрдән. Кара: «Бу дәрдә һичбер дәрман белүмәзвән». (Бу дәрткә һичбер дәрман белә алмасмын.) Йосыф китабы. Гыйшык дәртенең дәрманы юк. (XVI йөз, 1552 елда Казан өчен сугышта үлгән Колшәриф шигырендә.)

ИКЕ ТӘКӘ БАШЫН БЕР КАЗАНГА СЫЙДЫРУ. Хәзерге телебездә дә бик актив кулланылган бер мәкальдән алып, җөмлә кисәгенә әйләндереп әйтем. Бер тәкәне бер ка-

занга салып пешерү борынгы кучмәлеләр өчен бер табынлык аш саналганга, бу әйтемдә тәкәнең башы хакында сүз бармый, әлбәттә, үзе хакында бара. (Чөнки башы казанда да пешми, учакта өтеп ашалган.) Бу мәкаль һәм әйтем бик борынгы, ул төркиләрдә тимер, бакыр, точ (бронза) казаннар ясала башланган заманнарда ук әйтелгәндер бәлки. Язмаларда да борынгыдан теркәлеп килүе күренә. Мәсәлән, 1068 дә язылган М. Кашгари «Лөгать»ендә: «Ики кучкар башы бир ашичта пишмәз», диелә.

КИРТӘ СИКЕРҮ. 1. Киртә, киртә-кура, киртә эче яки киртәләп алынган ихата — борынгы күчмә тормышта киез өй—тирмә кирәгесе кебек итеп тотылган бер түгәрәк даирә, киртәгә керү—бер даирәгә керү, алыну. «Ноктлар да куймыймын, керсә ярар, дип, киртәгә, Мин үзем сызганны бик яхшы таныйм, дип, иртәгә». (Г. Тукай.)

2. Киртәдән сикерү—буйсынудан, тәртиптән чыгу. Киртәдән сикергән—чыныдан чыккан, баш бирмәс, тыйнаксыз, юньсез кеше. «Бозылды, бөтенләй киртә сикерде!— дип башын чайкап куйды». (Г. Бәширов).

3. Бер диннән икенче дингә «сикереп чыгу», дин алыштыру, чукыну. Бу гасыр башындагы китапларда, мәсәлән, «Каюсы—күрдем, ди, каюсы—ишеттем, ди, каюсы—ул түгелдер, ул инде күптән дөньяда юк, булса да киртәдән сикергән инде, дип төрле сүзләр сөйли башладылар» (Ш. Гуни). Монда—киртәдән сикергән әйтеме—бер диннән икенче дингә күчкән, керәшен булган мәгънәсендә. Киртә сикерүнең бу мәгънәдә әйтелеше дә бездә бик борынгыдан килә. Мәсәлән, 1068 елда язылган Мәхмүт Кашгари «Лөгать»ендә «кол тәңрегә киртекенде» дигән сүз бар. Кол аллага ышанды, ягъни дин кабул итте, үзен дин киртәсенә кертте дип аңлатма бирелгән. Шуның белән киртә сикерү әйтеме диннән чыгу, бер диннән икенче дингә сикереп чыгу мәгънәсендә бездә дә бик борынгы заманнардан ук әйтелә килгәнгә охшый. Чөнки Болгарда 922 нче елда ислам дине рәсми кабул ителгәч һәм аннары монгол яулары басып алганның соңында да, яңадан борынгы төркиләр дине булган мәҗүсилеккә кире кайтулар күп булган. Бигрәк тә мәҗүси кыпчаклар Болгар җирләренә күпләп сырыкканнан соң бу «диннән чыгу» мәгънәсендә «киртә сикерү» тәгъбире актив кулланылган булырга кирәк. Чөнки Казан алынгач, Иван Грозный заманыннан алып, озак гасырлар буена патша хөкүмәте татарларны колонизацияләү һәм көчләп чукындыру белән шөгыльләнгәнлектән, «керәшен булу» мәгънәсендә «киртә сикерү» тәгъбире телебездә икенче дингә күчү мәгънәсен алып һаман да дәвам иткән.

УТНЫ ЯЛКЫН БЕЛӘН СҮНДЕРҮ. Эшне сүрелдерү урынына көчәйтү. М. Кашгари, «Диван лөгать-эт-төрек», XI гасырда: «Отуг үзгич бирлә үчермәс». (Утны ялкын белән үчереп (бетереп, сүндереп) булмый.) Димәк, X гасыр һәм аннан да элек әйтелә килгән әйтем булуы ачык. (Үчү, үчерү—Зөя буе, Лаеш ягында хәзер дә әйтелә. Бетү, бетерү мәгънәсендә.)

## АЛТЫН УРДА ХАНЛЫГЫ ЗАМАННАРЫННАН КАЛГАН ӘЙТЕМНӘРДӘН КАЙБЕР МИСАЛЛАР (XIII—XIV ГАСЫРЛАР)

АВЫЗЫН АЧСА ҮПКӘСЕ КҮРЕНӘ. Киная. Хәзер бездә бу әйтем ач-ялангач, бик фәкыйрь яки дә үтә ябык, арык кеше димәктән әйтелә. Казакъта: «Аузын ашса ишеккарны курингенг». (Авызын ачса эчәге-карыны күренгән).

Шунысы кызык, борынгы кыпчак телендә, Алтын Урда заманнарында бу сүз табышмак итеп тә әйтеп йөртелгән һәм аңа «ишек белән ут» дип мәгънә бирелгән. Ягъни күчмә киез өйнең (тирмәнең) ишеге авызга, эчтә янган учакның ялкыны алсу үпкәгә тиңләштерелгән. Шулай итеп, бер үк уңышлы кинаяле гыйбарә әйтем дә, мәкаль дә, җыр кисәге дә, табышмак та булып китәргә мөмкин. Бу инде тел-фольклорда жанр ара хезмәттәшлек күренеше. Мондый хезмәттәшлек әйтемнең сыгылмалы һәм озак яшәүчән булуын тәэмин итә.

АЗ АЗЫКЛЫ, КҮП ЯЗЫКЛЫ. Изгелек запасы аз, гаебе, гөнаһы күп. «Аз азыклы, күп языклы күдәй галиме». XIX йөз башы язучысы Таҗетдин Ялчыгол әсәре «Сөбател-гаҗизин» китабыннан. Шул ук әйтем XIV йөз башы Рәбгузи әсәрендә: «Аз азыклыг, күп языклыг» рәвешендә бирелә.

АМАЙДАГЫ-МАМАЙДАГЫ. Кушсүз. Касыйм ягы. Бик күптән булган эшләр; әллә кайчангы борын хәлләр, вакыйгалар, Мамай мирза заманында булган хәлләр димәктән калган әйтем.

Мамай мирза—Алтын Урдада нугайлар командиры. 1370—1380 еллар арасында Алтын Урдада үзара тәхет сугышлары китә. Шул 10 ел эчендә 14 хан тәхеттән төшерелә. Шул дау-низаглар эчендә Мамай мирза да 1380 елда Тула өлкәсендә Куликовода сугышта җиңелә. Бу сугышлар татар-мишәрләр яшәгән Саратау, Нурчат, Воронеж, Касыйм, Ука якларын да каплап алганга, ул кызу еллардагы вакыйгалар турында халык авызында соңыннан һәртөрле легенда-хәбәрләр, әлбәттә, бик күп булган. Мамай мирза шулар эчендә актив роль уйнаганга, соңыннан ул вакыйгаларны гомумән «Амайдагы-Мамайдагы эшләр» дип сөйләүдән калган әйтем. «Ул инде, кем, сөйләп китсәң, әллә кай заманнарда булып үткән Амайдагы-Мамайдагы эшләр...»

АНТ-ШАРТ ИТЕП. Патшалык ара эшләрдә ике яктан шарт куешып, ант белән раслап кул куешып яки тамгалап килешү. Бу әйтем рус грамоталарында да ант-шарт рәвешендә очрый. «Ирем яхшы торырга дип ант-шарт итеп, мине яңадан алып кайтты...»

ДИҢГЕЗ ТУБЫКТАН. Аның исе дә китми, кешеләр батып үлә торган һәлакәт — аның өчен барыбер димәктән әйтем. Борынгы Алып гәүдәле Гуҗ хакындагы кыйссадан таралган. Бездә: «Гуҗ Гоныкның угылы ирде, озын буйлыг ирде. Туфан суы енчекендин (тез төбеннән) юкары чыкмады. Тиңизгә илкин сукып, нәһәкләрне тотып, афтапка пешереп ейер ирде». (Диңгезгә кулын сугып, крокодилларны тотып, кояшка пешереп ашар иде.) (XIV йөз башларында ук язылып, татар-болгар арасында бик күп кульязма нөсхәләрдә табылган Рәбгузи китабыннан.)

БАШ ӨСТЕ. Элек хан-солтаннар фәрманын үтәүче кеше хан алдында тезләнеп башын сузып, ханның фәрман кәгазен баш өстенә куйдырып үзенә ала һәм шул вакыт «баш өстә» дип әйтергә тиеш булган. Ягъни фәрманыгыз минем баш өстемдә, аны үтәүгә башым белән җавап бирәчәкмен дигән мәгънәдә символик акт белән беркетеп алу сүзе булган. Ханлыклар беткәннән соң, бу акт онытылып, «баш өстә» дигән сүз үзгәреп, «баш өсте» дигән әйтем булып китә. Бу инде хезмәтегезгә хәзермен димәк. Рус телендә — к вашим услугам.

КИТКӘН БАШ КИТКӘН. Чарасыздан баш иярге, күнәргә риза булу, мәҗбүрлектән яки антыңа тугры булудан һәлакәтле эшкә тәвәккәлләп башыңны тапшыру, ил ташлауга мәҗбүр ителү. Идел-Болгар җирләрен Чыңгыз басып алганнан соң, әсир төшкән болгар-кыпчаклар әтрәгәләм (кол гаскәр) ителеп сатылып, күпләп Мисырга озатылу чорында чыгып таралган әйтем. Петр I заманнарыннан башлап патша хезмәтенә татардан көчләп солдат алу, лашманга куулар башлангач, татарның һәлакәтле эшләргә тәвәккәллек психологиясен чыныктырган бу әйтем никрутлар, лашманнар арасында нык тарала. Мисал: «Электән күнегелгән инде ул. Янәсе, киткән баш киткән, ике үлем булмый» (К. Нәҗми).

КЫР ГАЛӘМӘТ КИЛҮ. Кырга сыеша алмаслык дәрәҗәдә күп гаскәр, бик каты буталыш, кайнашу, сугыш-кырылыш димәктән. Монголлар һөҗүмендә җиңелгән болгар-кыпчакларны аулап күмәртәсе белән гарәпкә коллыкка сатудан калган сүз булса кирәк. Чөнки монда галәмәт сүзе үз мәгънәсендә түгел, бәлки кырда сугышта әсир алынган әләмәтрәк (галәмәтрәк) мәгънәсендә. Мондый зур «кыр галәмәт килү», мондый зур кырылышның тарихта мәгълүм элекке һәм зурысы — Болгар шәһәрләрен Чыңгыз явы басып алганда һәм хәрби ирләрне Кара диңгез буйларына илтеп, генуэзецларга күпләп коллыкка сатканда булган.

## КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫНА КАГЫЛЫШЛЫ ӘЙТЕМНӘРДӘН КАЙБЕР МИСАЛЛАР (XV—XVI ГАСЫРЛАР АРАСЫ)

ИТӘГЕ БӨТЕН, ҖИҢЕ ОЗЫН. Дәүләте киң, хәле иркен кеше димәктән киная. Элек көнчыгыш һәм күчмә мәдәният белән баглы Болгар, Казан заманнарында илдә халык чагыштырмача аз, табигать иркен, көтү маллар, ит-май, сөт-катык, ризык күплеге белән тормыш та, күрәсең, иркен һәм мул булган. Мәсәлән, Казанны алу хакындагы рус елъязмаларында Казан арты җире дөньяда шундый оҗмах кебек байлык-муллык җире итеп тасвир ителә. (Князь Курбский һәм башкалар истәлегендә.) Ул заманнарда табигатьнең иркенлеге билгесенә татарлар гадәттә кием-салымда итәк-җиңне, чабуларны, әлбәттә, киң, мул итеп теккәннәр. Хәзердә дә дәүләтле, хәлле, киң-мул, иркен

тормышлы кеше дип әйтер җирдә «аның итәге бөтен, җиңе озын» дип әйтеп кую шуннан килә. (Шуны да әйтик, фәкыйрьлекнең билгесе—җиң кыскарудан башлана, имеш. Очы тузган саен бөкләп тегә, янәсе.)

КЫРЫМ ЧИРҮЕ КҮК. Кеше күплек, ишле гаилә яки бер урында тупланган гаскәр күплектән киная. (Чирү—гаскәр.) «Петр Федрич Кырым чирүе чаклы халык белән Казанны алмага килә». Яисә: «—Аларның өендә ул кеше, ул бала-чага, мин сиңа әйтим, бөтенләй Кырым чирүе күк!»

Казан ханнары булган Мөхәммәт Әмин һәм Габделлатиф ханнарның анасы Нур Солтан бикә, ире Ибраһим ханнан тол калгач, Кырым ханы Миңлегәрәйгә иргә чыга. 1518 елда Казанда Мөхәммәт Әмин хан үлгәч, Казан бер ара хансыз кала. Касыйм татарларыннан Шаһгали хан Казанга хан булып килсә дә төшерелә. Казанлылар үзләренә династия биреп килүче Нур Солтан бикәнең Кырым ханы Миңлегәрәйдән туган улы Сахибгәрәйне Казанга хан итеп чакырып китерәләр. Аны туганы Мөхәммәт Гәрәй хан күп санлы Кырым чирүе (гаскәре) белән китереп, тәхеткә куйган һәм аларның байтагын сарай гвардиясенә дә куеп, Казанда калдырып киткән була. Сахибгәрәйдән соң Сафагәрәй хан һәм Сөембикә заманында да Казан тәхете янында Кырым чирүе зур роль уйный. Ләкин бу чирүнең Казанда берьюлы искиткеч күп булып күренүе, әлбәттә, Шаһгалине тәхетеннән куып, Сахибгәрәйне мендергән көннәрдә булган, бу хәтле чирүне кунак итү, өйләргә бүлеп кую Казанда нык кына сизелерлек һәм телләргә мисал итеп алырлык зур вакыйга була. Шул заманнардан соң гаскәр һәм күп халык җыйналышын яки бик ишле зур гаиләне күргәндә, күплеккә мисалдан «Кырым чирүе кебек» диган сүз әйтемгә кергән һәм әле дә әйтелүендә дәвам итә. Шунлыктан бу әйтемнең тарихын да 1521 дә, Сахибгәрәйне тәхеткә утырткан көннәрдән калма дип тәгаен әйтеп була.

ҮЗЕН ҮЗЕ БЕЛМӘГӘН, ҮЗЕН МӘМӘТ АТАГАН. Үзенә берәр дәрәҗәле кеше исемен дәгъва кылучы хакында. Мәмәт—Казанның беренче ханы—Олы Мөхәммәт хан. Халык телендә Мәмәт хан, Урмамбит хан исемнәрендә дә йөри. (Урмамбит хан үлгән көн, ун сан нугай бөлгән көн. Мәкаль.) Олы Мөхәммәт ханның исемен, данын, нәсәбен үзенә файдаланып, Казан тәхетен дәгъва кылучылар соңыннан аз булмаган. Югарыгы әйтем шуларга карата. Мәкаль урынында да килә. XV гасырлардан калма.

## КАЗАН АЛЫНГАННАН СОҢ, 1552—1700 ЕЛЛАР АРАСЫН ЧАГЫЛДЫРГАН ӘЙТЕМНӘРДӘН КАЙБЕР МИСАЛЛАР

АК ПАТША. Эпитет. Рус чары, рус патшасы димәк. Великорус дворяннарының Көньяк һәм Идел-Урал, Себер халыкларына патша булып, җир-суын теләгәнчә изеп-талап яшәгәндә һәм Русиянең төп закон чыгару аппаратларында үзләре генә утырып, патшалык итеп торганда, башка халыклар алдында үзләренең аерым шәп ак тәнле, югары затлы расадан яратылган һәм шуңа күрә Россиядән башка төстәге, башка нәселдәге барлык халыкларга ак патша булырга үзләрен генә хаклы дип күрсәтү өчен таккан исемнәре.

АЛПАК ТА КЫСТЫЙ, КАЛПАК ТА КЫСТЫЙ. Ике яктан ике патшалык, икесе дә үз кул астына керергә я үзе яклы булырга кыстый димәктән. XVII—XVIII гасырларда Пугачев явына кадәр төрле-төрле исемдә халыклар күтәрелеше барганда, татар, башкортлар үз ягына, калмык-зангарлар үзенә, рус патшалыгы, казаклар яки поляклар үз ягына кушылырга өндәү алып барган заманнарда чыккан әйтем. Ягъни ике якның кайсына ышанырга, кайсы якта булырга белми торуга мисалдан әйтелә.

КЫРДЫҢ ПЫЧАГЫМНЫ! ПЫЧАК КЫРУ. Татарда пычак кыруга һәм гомумән пычакка бәйләнешле төрле әйтемнәр күп һәм бу сүзнең мондый формаларда кулланышы бик сәер. Мәсәлән:—Я, ни пычагым кырып килдегез анда? Ягъни, ни булдырып килдегез? (Дәресрәге, булдыра алмыйча килдегез мәгънәсендә.) Кырдың пычак! (Булдыра алмадың!) Күрдең пычак! (Пычагымны да күрмәдең! Ягъни бер ни дә күрмәдең!) Мисал: «**Сираҗетдин.** Күрдең пычак! Ул вакытта ул акчалар күптән кладовойда яталар иде». (Г. Камал.)

Кыру—монда бу сүз бер-берсенә каршы ике мәгънәдә: 1) кыру, вату-җимерү; 2) юнып-кырып агачтан, тимердән әйбер ясау. Кырмачы—борын бездә балта остасы

(столяр)—агачтан кырып ясаучы һәм тимер кыручы (токарь). Борынгы болгарда металлургия (тимер, чуен, корыч кою) югары үскәндә, корычны кырып үткен пычак-кылыч ясау зур һөнәр саналып, эш булдыруга мисалдан эш кыру, пычак кыру мәгънәсендә әйтемнәр ясалган. Ягъни, кыру—вату, җимерү мәгънәсендә түгел, киресенчә, эш кырып йөрү—эш булдыру димәк. Урта гасырларда Идел буе болгарларының металлургиядә бу зур мәдәниятләре Европа халыкларына һәм күршеләре русларга тәэсирсез калмый, билгеле. **Кузнец** сүзе болгар-татарча утлы күмер, учак мәгънәсендәге **куз, утлы куз** сүзеннән, шулай ук русчадагы **чугун** сүзенең дә турыдан-туры татарча **чуен** сүзеннән алынган булуын, ягъни шул сүзләр белән бергә металлургия эшләре үзе дә болгарлардан күреп алынган булуын күрсәтә бу мисал.

Әмма хәзерге телдә **«кырдың пычагымны»** әйтеме элеккечә **булмаганны булдыру** түгел, бәлки булганны вату, кыру дигән тискәре һәм ироник мәгънә алып китүенең сәбәбе шул: Казан алынганнан соң татарга пычак-кылыч кебек кораллар йөртү тыела. Булган пычаклары кулларыннан тартып алынып, сындырыла, ватып-кырып ташлана һәм һәр өйгә икмәк кисү өчен бер генә пычак калдырып, ул да стенага чылбыр белән кагып куела, татар икмәген шунда барып кына кисеп алырга хаклы була. Соңыннан патша хөкүмәте тарафыннан бу хөкем бераз йомшартылып, кәсеп өчен балта-пычак тотарга рөхсәт ителсә дә, металлургия татарга тыелган килеш кала. Хәтта ат дагалау кебек иң гади тимерчелек һөнәре дә татар авылларында Октябрь революциясенә кадәр рус кузнецлары кулында булып килде. Шулай итеп, кайчандыр Россиягә металлургия һөнәре кертешкән, чуен-корыч койган болгар-татар балалары патша хөкүмәте кулында колонизацияләнү гасырларында үзләре балта-пычак, кылыч ясау түгел, әзер ясалганны да үз иркенчә тотарлык кодрәтләре дә калдырылмаганда, «пычак кыру» әйтеме дә бездә ироник тискәре мәгънә алып киткән. Пычагымамыни! Пычагыма кирәк! Пычагым калган, тагын анда барып йөрергә! Кырдың пычак! Күрдең пычагымны! һ. б.

ИШЕТМӘСӘҢ ИШЕТ, УРМАН АСТЫ КИШЕТ! Иске Кишет, Яңа Кишет Казанга якын Дөбьяз як авыллары. Кайчандыр бу авыллар патшага баш бирмәгән, чукынмаган өчен җәза отрядлары китерелеп, розгалар суктырылып, төрлечә җәзалангач, татар арасына бу хәбәр һәркайда киң таралып, моңарча нык билгеле булмаган Кишетләр кинәт мәшһүр булудан әйтем булып киткән сүз. Хәзер дә көтелмәгән яңалык булып телләрдә сөйләнгән ят бер хәбәр ишеткәндә: «—Менә, ишетмәсәң ишет, урман асты Кишет!» дип куялар.

ИШТЕҢ ИШЕК БАВЫН! Зур эш кырыр кебек өстенә эш алып тотынып та юк эш эшләп куйган кешегә карата—булдыксыз икәнсең, юкка көчәндең димәктән әйтем. **Ишек бавы:** Казан алынгач һәм татарларга тимерчелек эше һәм корал йөртү бөтенләй тыелгач, кичәге чуен-корыч койган һәм алтын-көмеш акча суккан болгар-татар балалары байтак вакытлар ишекләренә тимер тотка коюдан да мәхрүм ителгәч, тотка урынына ишеккә бер тишек тишеп, шуңа бау ишеп тагып, ике башыннан төенләп куелган. Бер як төенне тотып тартканда икенче як төен белән ишек тартылып ачылган һәм ябылган. Шуннан ишек бавы сүзе таралган. Белеп булмый, мондый баулы ишек бәлки тимерне башлап куллануга кадәр бик борынгы заманнарда да булып, татарлар шул гасырлар хәленә кайтарылганнан соң телдә дә кирегә кайтып яңадан активланган...

Иштең ишек бавын—ягъни шуны да булдыра алмадың, юк эш эшләдең димәктән. «Ишек бавы бер алтын, безнең апай мең алтын» (Г. Тукай). Кияү кергәндә бүләк сорап кертү йоласы.

ПАДИШАҺЫМ СОЛТАНЫМ, ИСКЕ КӘВЕШ ОЛТАНЫМ! Әкиятләрдә патшаларга эндәшү алымы булган әйтем. Легендаларга караганда, Болгар-Казан ханлыгы алынгач һәм бер төркем татар әсирләренә Иван Грозный алдында бүреген салып «падишаһым солтаным» дип баш орып эндәшергә кушылгач, татарлар бүреген салган салуын, әмма ләкин түбәтәен салмаган һәм «падишаһым солтаным» дигәннең артыннан ук бу сүзгә ялгап, тиз генә йөзен аска бер яккарак чәвереп, «иске кәвеш олтаным!» дип әйтеп куйялгап, тиз генә йөзен аска бер яккарак чәвереп, «иске кәвеш олтаным!» дип әйтеп куйган һәм шуны гадәткә керткән булалар. Ягъни моның мәгънәсе: болгар-татарлар үзләре электән үгез күненнән болгарый олтан ясый белә торган халык, безне син тиз генә олтан ясый алмассың дигән сүз, имеш. Шуннан бирле татар әкиятләрендә геройлар патша алдына кереп бүрек салып «падишаһым солтаным» дип эндәшкәндә, бу сүзгә ялгап, «иске кәвеш олтаным» дигәнен дә төшереп калдырмыйча кушып әйтеп сөйләү гадәткә кергән.

АКЧАГА ЧУКЫНУ, АКЧАГА ЧУКЫНГАН. Акчага табыну, акча өчен җанын-иманын сату. «Башкалар бер тиен табалмый яше күздән акса да, Кызганып кылмый иганәт, ул чукынган акчага» (М. Гафури). (Иганәт — ярдәм.)

Иван Грозный Казанны алганнан соң татарны көчләп чукындыру эше җәелдерелә. Шулай да татарның күпчелеген дүндерә алмый. XVII—XVIII гасырларда патша хөкүмәте татарны җаны-тәне белән тәмам кол итеп мескенлеккә төшерү, шул юл белән исемен дә, җисемен дә дөньяда калдырмау өчен, вакытлыча төрле материаль интереслар күрсәтеп ауга төшерергә керешә: һәр чукынган татарга мул гына акчалар түли, аны солдатка алудан, имана түләүләрдән дә азат итә. Чукынмаган татарның җирләрен дә аңа алып бирә һәм башкалар. Шулай да патша бу максатына да ирешә алмый, файдасыннан расходы гына зурракка төшә. XIX йөздә Оренбургка базарга килгән кыргыз-казакъка чиркәүгә кереп тәртенеп чыккан өчен генә берәр сумлык көмеш акча бирелгән. «Ни хәл?» дип хәл сораганга каршы: «Бер тәнкә алып чукынып җөреп җатырмыз» сүзе дә шул заманнардан калган. Әмма соңыннан эзләп тап син ул бер тәнкә алып киткән казакъны даладан. Кыскасы, хәзер инде бу акчага чукыну әйтеме диннән дингә чыгу мәгънәсендә түгел, бәлки акча өчен, мал өчен җан сату дигән мәгънәдә әйтелә. Тукайның «Читен тормыш, капиталга чукынмасаң!» дигәнендә дә шул ук мәгънә.

БАШ КИТӘРЛЕК ЭШЛӘР БАШКАРУ. Патша хөкүмәте татарларга карата аеруча колониаль изү, бетерү сәясәте алып барганда, халыкның дини һәм милли хокуклары төрлечә эзәрләнеп, җир-сулары таланганда һәм төрле җәза отрядлары йөргәндә, бу гаделсезлекләргә каршы баш һәм тел күтәреп чыгу халыкта, әлбәттә, зур кыюлык һәм ирлек саналган. Мондый ирләр, әлбәттә, Себер җибәрелгәннәр һәм шуңа да халык бу зур кыюлыкны «баш китәрлек эш башкару» дип атаган. Бу әйтем халык җырларында да урын алган. Мәсәлән: «Казан калалары таш кала, бик күп калаларга баш кала; Ир башкайларына уйлар төшсә, баш китәрлек эшләр башкара».

БЕЗГӘ БЕЗ БУЛМЫЙ, БЕЗГӘ ШӨШЛЕ БУЛМАС. Сүз уйнату, каламбурга корылган җор сүз. «Без» сүзе монда ике мәгънәдә алынып уйнатылган һәм кинаяле мәгънәдә әйтелгән. Ягъни безгә (безнең халыкка) очлы без булып кадалмыйча, шөшле булып кына тәртелеп калмаслар дигәннән әйтем. Петр I заманнарында һәм аннан соң рус дворяннары үз мәнфәгатьләре өчен татар дворяннарын сыйныф буларак бетереп, җирләрен рус помещиклары кулына өләшеп бирү, татардан гомерлек солдат алу һәм гомумән көчләп чукындыру кебек аеруча каныга һәм кадала торган махсус колонизаторлык законнары чыгарылудан таралган әйтем.

БУШКА ЛАШМАН ТАРТУ. Петр I заманында Казанда хәрби флот салырга, урман эшенә куылган татарлар лашман, лашманчы дип йөртелгәннәр. Аларга бик аз түләнеп, ул акчаны да патша түрәләре басып калырга тырышканнар. Атлысы аты белән, атсызы җәяү, мәҗбүри рәвештә, сукыр бер тиен, ике тиен акча түләмгә Казан артының мәшһүр калын имәннәрен үз куллары белән кисеп, ата-бабадан калган табигый байлыкларын үз атлары белән тарттырып, мең азап белән төрлечә сөйрәп, бик зур михнәтләр чиккәннәр. Шулай ат урынына җигелеп бушка авыр эш эшләп азап чигеп йөрүләр мәгънәсендә бу әйтем хәзер дә телдә калган.

БӘРӘҢГЕ АШЫЙ БЕЛМӘГӘН АВЫЗЫ БЕЛӘН... Бик табигый, җиңел генә эшләнә торган бер эшне булдыра алмаган кеенә ул да сөйләнеп яткан була дигән урында мыскыл белән әйтем.

Бәрәңге ашый белү димәктән, башта ул Америкадан Европага, аннан XVIII йөздә генә Россиягә китертеп утыртыла башлый. Ләкин аны ничек үстерергә булдырсалар да, ничек ашарга икәнен белмичә, чынлап та аптыраганнар. Берләре сабагын, икенчеләре сабагындагы алмасын ашап карап, «тефү» дип төкереп ташлаганнар. Өченчеләре төбендәге бәрәңгене алып, чи кеенчә кабып караганнар яки пешерсә дә тозлап ашый белмәгәннәр һ. б. Ул бары тик XIX йөзнең беренче яртысында гына чынлап утыртыла башлый. Бәрәңге татар өчен дә төп азыкның берсе булып киткәч, аны да ашый белмәү дөньяда иң зур булдыксызлыкның мисалы булган мыскыллы бер әйтемгә әйләнеп китә. «Китче әле шуннан... бәрәңге дә ашый белмәгән авызың белән, син дә бу эшкә тыгылып, сөйләнеп торган буласың тагын!»

**ИСКЕ БИСТӘНЕ КУЗГАТУ.** Тик торганда кирәкмәгән зур гаугалы, авыр мәшәкатьле эшләр кузгату димәктән.

XVIII йөз урталарына табан Казан архимандриты мәшһүр кара йөз Лука Канашевичның Иске Бистәгә монахлар урдасын җыеп алып төшеп, кат-кат крестный ходлар ясатып, ут төрттереп, татарларны үзләре салган Казаннан ул чагындагы чүплек һәм елга аръягы булган Яңа Бистәгә куу хәрәкәтләренә карата чыккан әйтем. Архимандрит хөкүмәт һәм чиркәү сәясәтен үткәрү өчен бу сәфәрләрне кат-кат ясатса да һәм татарларның бер өлешен сөрә алса да, озак һәм каты көрәшләр нәтиҗәсендә аларны Иске Бистәдән бөтенләй куу насыйп булмаган. Хәзер бу сүз халыкка кирәкмәгән авыр мәшәкатьләр тудыруга, авантюра белән маташуга карата әйтелә.

**КОРДЫ БИ АШЫ.** Коры аш, итсез пешерелгән шулпа, кысыр аш, буш аш. Татар-болгар-мишәрләр электә итсез пешкән ашны чын ашка санамаганнар. Бигрәк тә киң җир-су хуҗалары — бәкләр, би-мирзалар. Инде Петр I заманнарында һәм аннан соң да татар би-мирзаларның дворянлыклары бетерелеп, җир-су байлыклары рус дворян-помещиклары кулына бирелгәннән соң, мирзаларның күпчелеге бөлеп-корып, итле шулпа урынына кысыр шулпа—коры аш белән генә киченергә дә туры килә башлый. Шундый табын өстенә килеп кергән, ашарга утырган кеше: «Бу нинди ят аш?» дип, гаҗәпләнеп сорый калса, моңа каршы шаянрак хуҗалар сер бирәсе килмичә, киная белән: «Әйдә, житеш, бу корды би ашы» (ягъни бөлгән, корыган бәк-мирзалар ашы) дип җавап бирүдән калган һәм таралган әйтем. Хәзер аның элекке мәгънәсе онытылып, ит корыганда пешерелә торган аш мәгънәсендә генә әйтелә.

**КЫЗ АВЫРМЫ, ТОЗ АВЫРМЫ?** Өйләнергә авырсынучы кешегә бирелә торган сорау. Кыз алу авыр түгел, мәһәре авыр, аксын да түләр идек, аннан да бигрәк казнага түләү өчен тоз ташу авыр димәктән калган сүз.

Ничәмә төрле салымнар өстенә, һәр өйләнгән кеше казнага тоз салымы түләргә мәҗбүр ителгән. Ул тозны көньяк Тоз түбә һәм Баскынчак күлләреннән арба белән ташыганнар. Татарлар һәм башкортлар өчен бу бик авыр һәм табигатькә ят, начар эш булып тоелган. Чөнки, алар уенча, тоз ул су һәм һава кебек табигатьтә буш һәм түләүсез яткан гомуми бер азык. Өйләнү чыгымнары тоту өстенә хөкүмәткә, никах салымы өчен, меңнәрчә чакрымнан тоз ташып йөрергә мәҗбүр ителүгә каршы бунтлар да күтәрелгән. «—Кайчан кайтыр?—Яз кайтыр. Яз кайтмаса көз кайтыр. Йөге белән тоз кайтыр, тоз артыннан кыз кайтыр». Бу такмазада тозга яз китүченең көз генә өйләнеп кайта алуы әйтелә.



## ИСКЕ ЫШАНУЛАРГА, ГАДӘТ-ЙОЛАЛАРГА, КОРАЛЛАРГА, ХӨКҮМӘТ ҺӘМ ТОРМЫШ ТӘРТИПЛӘРЕНӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ БУЛУ ЯГЫННАН БОРЫНГЫДАН КАЛМА БУЛУЛАРЫ ИСБАТ ИТЕЛӘ АЛГАН КАЙБЕР ӘЙТЕМНӘР

**АВЫЗЫҢА БАЛ ДА МАЙ, АРТЫҢА КОЛЫН ТАЙ!** Сөенечле хәбәр китерүгә каршы теләк-бүләк вәгъдә әйтеме. Борынгы күчмә яки ярым күчмә тормышта зур сөенечле хәбәр китерүгә каршы бүләккә тай вәгъдә итүдән калган. Моны сөенче алу диләр. «—Сиңа бер яңа хәбәр китердем, әйтимме?—Әйт.—Сөенчесенә ни бирәсең?..» Шуңа каршы ни дә булса вәгъдә ителгәч, хәбәрче хәбәрен әйтеп, шуңа каршы сөенче бүләге, әйтик, колын ала. (Элек ат-елкы татар-болгар илендә тулып яткан мал булуы, экспорт товар урынында Һиндстанга меңләгән көтүләр белән озатылулары хакында Ибне Батута сәяхәтнамәсендә әйтелә.)

**АВЫЗЫҢА БАЛЛЫ ҖОФАР ҖАУ!** Теләк. Сөенечле хәбәр китерүчегә әйтелә. Гадәттә бу урында хәзер «авызыңа бал да май!» диләр. Элегрәк «авызыңа бал да яу» диләр иде. К. Насыйри моны халык телендәге «бал яумак» сүзеннән чыгарып, «җау(яу)» шулай ук бал мәгънәсендәдер, ди. Ләкин бу «яу» сүзе борынгыча ягъ—май мәгънәсендә булырга тиеш. Карагыз: «Күзнең явын алып тора» — бик балкып күренгән матур нәрсә турында—«күзнең маен алып тора», димәк. Яу (ягъ) — монда ягылып, сылашып ялтырап торган май.

**Җофар**—тарихчылар күрсәтүенчә, борын Болгар-Казан җирләрендә күлләрдә кыйммәтле һәм хуш исле җофар җәнлеге бик күп булган. (Махсус та асралган булса кирәк.) Монголлар бу җирләрдәге кыйммәтле җофар һәм көтү-көтү коланнарны аулап, бик

каты кырганнар. (Бу хакта Плано Карпини һәм Руброк сәяхәтнамәләрендә әйтелә, 1245, 1253 еллар.) Хәзер фольклорда гына калган. «Күктә-күктә ниләр бар?—Җофар белән шикәр бар. — Җофарыңны бир миңа. — Ник бирәем сиңа». Ф. Халидидә китерелгән **«Авызыңа баллы җофар җау»** әйтеме бездә бу тәр әйтемнәрнең иң борынгысы һәм тулырагы булып аңлашыла.

АГАЧ БАШЫ ТӘСБИХ ӘЙТӘ. Агач башының акрын искән җилгә һаман бер төсле чайкалып, яфракларының лепердәп-медердәп торуын әйтем. Элекке суфыйларның, дәрвишләрнең утырган җирләрендә бер өзлексез тисбе (тәсбих) төймәсе тартып, бер көйгә чайкала-чайкала һаман «алла, алла!» дип медер-медер кабатлап, үзләрен бер ритмик транс хәленә китерүләренә тиңләштерелгән. Ибне Фазлан сәяхәтнамәсеннән күренгәнчә, борынгы болгарларның агачны үзенә бер җанлы, изге кодрәт иясе санап, кирәматкә табынуларына һәм кам (шаман) нарның да шулай ук укынып, шөлдерләрен кагып биеп, үзләрен бер көйгә салып, транс хәленә китерүләренә караганда, татарның җыр башларында еш очраган бу әйтем исламга кадәрле борынгы ышануларга бәйле булуы ачык. Ул бәлки татар кызларының чигеш орнаментларында чигелгәнчә, җир үтә чыгып, өзлексез үсеп тәңрегә (күккә) тоташа торган бик борынгы мәңгелек тереклек агачына (мәңге яшәүгә) ышануларга бәйледер? Бездә «Агач башы» дигән борынгы моңлы озын көйләр дә бар: «Агач башкайлары тәсбих әйтә Акрын гына искән җил белән; Еламачы, сылуым, ник елыйсың, Бер без генә түгел, ил белән...»

АНДА СИН ТҮГЕЛ, СИНЕ АШАГАН КАРГА ДА БАРЫП ҖИТМӘС. Җорланып әйтем. Гипербола. Хәленнән килмәслек әллә кай җирләргә барырга хыялланган кешегә көлеп әйтелә. Элекке заманнарда фәкыйрь генә болгар-татар шәкертләренең дә чын гыйлем табу, галим булу дәртеннән кәрваннарга тагылып, мең җәфалар белән Бохара, Гарәбстан чүлләренә кадәр китеп, гыйлем юлында үлеп калучылар еш булудан әйтемгә кереп калган сүз. Ягъни, син барып җиту түгел, анда син юлда үлеп калгач, мәетеңне ашаган карга да очып барып җитмәс, янәсе.

Бу кыен сәфәрләр хакында тарихта мәгълүмат күп. Мәсәлән, Иран шагыйре Синаи поэмасында X гасырда ничек Болгар ханының улы ялгыз башы Газнә шәһәре мәчетенә кереп, бер кабым алма сорап, кызганыч бер хәлдә үлүе хакында язылa.

АНДЫЙ ГЫНА (гаеп) ХАН КЫЗЫНДА ДА БУЛА. Кеше арасында эшләргә ярамаган кечерәк гаеп эш күрсәң дә аны күрмәгәнгә салын, янәсе. Адәм баласына гомумән хас булган андый гына вак-төяк эшне принципка күтәрергә, аның өчен кешене гаеп итеп эзәрләргә кирәкми дә, ярамый да. Чөнки андый гына эшләр безнең кешеләрдә генә түгел, үзен бик тәкәллефле, нәзакәтле тоткан элита сортлы сайландык класс кешеләрдә дә була дигән мәгънәдә әйтем. Борынгы ханлыклар чорында чыгып таралып, әле дә телебездә әйтелә. Соңыннан «андый гына гаеп мулла кызында да була» дигән төрдәше дә чыккан.

АРТЫННАН ЯУ КУГАН КЕБЕК. Бик каты ашыгып чабып бару. Элекке заманнарда көтелмәгән яктан яу килеп басуларга карата әйтелгән. Хәзер дә: «Кая артыңнан яу куган кебек болай чабасың?» диләр. Яу куу, яу басуның кай борынгы заманнарда башланган булуын атап әйтеп булмаган кебек, бу әйтемнең кай борынгы заманнардан калма булуын әйтеп булмый. Ничек тә ул бик борынгыдыр.

АТЫЛГАН УК КЕБЕК. Охшатым. Бу, әлбәттә, ук атып сугышулардан калган әйтем. Ук сугышы исә бик борынгы вәхши заманнардан килгәнгә бу әйтем дә шул кадәр үк борынгыдыр.

БАЛТА БИРЕП ШӨШЛЕ АЛГАН. Зур бәяле әйберен биреп алмашына кечкенә, бәясез әйбер алган, алданган димәктән. Борынгы болгарда кайбер төньяк тундра халыклары белән товарга товар алмашу сәүдәсе (акчасыз сәүдә) заманнары булганын искә төшерик. Соңрак Идел буендагы ханлыклар бетерелеп, болгарлар үзләре дә татар дип аталу киткәч, угро-фин халыклары белән гадәттәгечә товарга товар алмашуда бу әйтем: «Балта бирдем, шөшле алдым, алдаладым татарны!» дип әйтелә башлый. Ягъни болгар-татарны сәүдәдә алдыйм диюче үзе алданыр, янәсе.

БЕРСЕ АРАПТА, БЕРСЕ ТАРАКТА яки Дөбъязларча: берсе аракта, икенчесе каракта (Тарышна авылы.) Икесе ике яры, икесе аеры юлда, аеры кәсептә димәктән. Бу әйтем башка төрки халыкларда да очрый. (Әйтик, казакъта—«Бери аракта, бери тарапта» h. б.) Шуларга караганда, бу әйтем болгар һәм бигрәк тә Алтын Урда чорында, кыпчак, болгар, казакълар бер территориядә яшәгәндә, асылында «берсе гарәптә, берсе тарафта»

дигән бер уртак әйтемнән таралган булгандыр дип чамалый алабыз. Чөнки Болгар ханлыгы үзе гарәп хәлифәлеге яклавы астында булган. Гарәбстан исә борынгы юллар аша бик еракта. Шулай ук икенче яктан Уйгурстанда утырган Кара ханилар белән дә тыгыз сәүдә мөнәсәбәте. Анысы да бөтенләй икенче «тарапта» (тарафта) бик ерак. Шулай да моннан мең ел элек болгарларның бу илләр белән тыгыз сәүдә һәм культура мөнәсәбәтләре өзелмәгән. Алтын Урда заманнарында да дәвам иткән. Соңыннан бу ерак мөнәсәбәтләр өзелгәч, әлеге әйтем дә үзенең асыл мәгънәсен җуеп, **гарәп** һәм **арап** сүзләре урынына **арак, тараф** урынына **тарак** һәм **карак** дигән очраклы, ләкин шулай булса да элеккегә аваздаш бүтән сүзләр белән алмашынып, әлегечә үзгәрә. Ләкин яшәүчән әйтем шулай да үзе телдә үлми, мәгънәсен саклап яшәвендә дәвам итә.

БУСАГАСЫНА ЙӨЗ СӨРҮ. «Бусагасына барып йөз сөрүдән гарьләнмәм» (М. Фәйзи). Йөз сөрү—кешенең өенә кергәндә бусагасына сәҗдә итү, табыну мәгънәсендәге сүз. Элекке заманнарда дәрәҗә иясе хан-мирзалар, алпавытлар хозурына һәм гомумән дә чит кеше өенә кергәндә, кешеләр ишек бусагасын үбеп табыну сәламе (табуг сәлам) биреп кергәннәр. Бу шул йоладан калган әйтем. Йорт хуҗасының өй эче изге-мөкатдәс җир, ул аның ут-учак даирәсе дип саналган. Анда керү юлы бусага аша булганга, аның аша атлау—шул изге сызыктан атлап узу дип саналган. (Бусага сүзенең тамыры бус; бус итмәк—үпмәк.) Шул ритуал белән бәйләнгән **«бусагасына йөз сөрү»** гамәле коры бер дини мәҗүси акт кына түгел, моның иҗтимагый әхлакый мәгънәсе әлбәттә тирән һәм зур. Чөнки өй, кешенең гаилә оясы буларак, җәмгыятьнең иң беренче төп асыл күзәнәге. Аңа ихтирам саклау—аның бусагасын теләсә кем хуҗа булып, теләсә ничек таптап узарга ярамау, асылда бу адәмчелекнең үзен саклау йоласы булып, шуның мәгънәсе бу әйтемдә саклангандыр, бушка түгелдер.

БӘЛАСЕННӘН БАШАЯК. Бәла-каза килгәндә артык-портык, аны-моны корбан сые итеп биреп, җиңелчә котылу. Әйтик, борынгы заманнарда корбанга чалынган терлекләрнең башын мәҗүси күк иясе булган тәңрегә, аяк-тоякларын җир-су иясенә һәм башкаларга багышлап, үзләренә тереклек эстәгәннәр. (Шундый баш-аяклар бергә күмелгән каберләр болгар җирендә табыла.) Соңрак башын камга (шаман руханиена), аннары ислам кабул иткәч, учакта өтеп пешерелгән тәкә башын мәҗлес түрен тоткан кунакка—түрәләргә һәм башкага сый итеп куелган. (Казакъ һәм башкортларда бу йола хәзергә кадәр диярлек очрый.) Нәтиҗәдә башка берәр мәшәкать килгәндә, «бәласеннән башаяк» дип аны-моны биреп котылу әйтеме дә шуннан килеп чыккан. һәм ул бик актив әйтелә. Мәсәлән: «Бирегез шуңа курортка бер юллама да бәласеннән башаяк, авызы тыгылсын!»

БУКӘЙ КҮРСӘТҮ (букай күрсәтү). Кешене юк белән куркытып, өркетеп маташу, берәр эштән күңелен кайтару өчен бик хәтәр, куркыныч итеп күрсәтү. Әйтик: «Я, я, син миңа букәй күрсәтмә, мин сиңа бала-чага түгел».

Бука, буга, бога, букан, букә, букәй кыргызы, бугъ... һ. б. формаларда барлык төрки телләргә таралган сүз. Башлыча мәгънәләре: үгез, нәсел үгезе, болан үгезе, зубр һәм башкаларның үгезе; үгез куәтле кеше, пәһлеван, баскынчы; букү—сихыр куәтле, күз буар кеше. Букәвел — гаскәрдә интендант, тамгачы (таможник), «Бүре букәвел икән, төлке ясавыл икән» (Әкияттән). Руста **бука** — балаларны куркыткыч әйбер, чырайсыз кеше. Преображенский А. Г. моны — төньяк германча **bokka** — өрәк сүзеннән алынган дип, Даль исә русларга төркиләрдән кергәндер дип уйлый. Французларда төнлә урамда вакытсыз йөргән кешеләрне тотып кыйнаучы өрәк (карачкы монах) мәгънәсендәге сүз дә шул ук сүз белән бәйләнештә дип, һәм шунлыктан бу сүз асылында, Европадан чыгып таралган диючеләр бар. Бу сүзнең төрки телләрдәге тамырларына карагандa, ул, әлбәттә, безгә көнбатыштан килмәгән, киресенчә, IV гасырда төрки халык һуннар Атилла хан җитәгендә Европаны басып, айкап йөргәнгә бу төрки чыгышлы сүзнең анда да барып җитүе бик мөмкин. Чөнки Атилла—Атилла, Атлы хакында эпослар, сагалар Скандинавиягә кадәр таралган булгач, «куркыныч куәт иясе» мәгънәсендәге **бука, бөгә** сүзләре анда да таралган булса, артык гаҗәпләнер урын юк. Мәсәлән, Европа уртасындагы Германиянең исеме күп кенә иске географик карталарда Алмания дип һәм каһарман шагыйрь Муса Җәлил шигырьләрендә дә шулай исемләнеп йөрүе төптә аламан (бандит) һәм бездәге алама сүзе белән бер тамырдан булуын да гаҗәп хәл дип ка-

рамыйбыз. Букәй күрсәтү әйтемендәге букә—бука—бога сүзләре дә үз тума төрки сүз булганга, мәгънәсе дә сүзенә мач килгәнгә, без бу әйтемне үз борынгы малыбыз дип уйлыйбыз.

ИКЕ ТИЕН — БЕР АКЧА. 1. Дөнья малына ваемсыз, гамьсез караш яки тормышны, хуҗалыкта экономияне белмәүче, аны уйламаучы бер төрле тинтәк яки пәрвайсыз кеше хакында әйтем. Мәсәлән: «Аңа нәрсә синең көткән дөньяң! Булса ни дә булмаса ни! Ике тиен—бер акча!»

2. Дөнья малына ис китмәү, мал өчен яшәмәү, акча колы булмау, дөньяга бераз фәлсәфи югарылыктан торып карау һәм шуның белән бар акчасын теләгәнчә туздырырга үзен ирекле дип белүчеләр һәм богемачылар тарафыннан әйтем. Мәсәлән: «Гонорар нәрсә ул? Килә дә китә. Ике тиен—бер акча. Ресторанда бер утыру—кала!»

Искәрмә. Борынгы Идел-Болгарда металл акчаларга кадәр тиен тиресе (һәм башка кайбер күн-тиреләр дә) акча берәмлеге исәбендә саналып йөргән һәм бу сүз русларга да кергән. (Тиен—тәнкә—дәнкә—деньги яки куница (күн, сусар тиресе кисәге, күнчек һ. б.) Ак көмеш акчалар чыккач, «акча» дип аталып, бу сүз базар хакы булган акча берәмлеге мәгънәсендә йөри башлый. Шул чакларда озак кына заман ике тиен тиресе бер көмеш акча хакына тиңләп әйтеп йөртелүдән «ике тиен—бер акча» сүзе телгә кереп, әйтем урынында әйтелеп киткән булса кирәк.

ИРЕННӘН АКТЫ, АВЫЗГА КЕРМӘДЕ яки ТИМӘДЕ. Әкиятчә алым, җор сүз. Кешегә булган сый-хөрмәтне күреп, авыз суын агызып, үзенә дә өлеш тимәсме дип көтеп, коры калучылыктан көлеп әйтелә. Әкиятләр койрыгына очлам сүз булып килгән бу әйтем иске заманның данлы каһарманы Искәндәр Зөлкарнәен (Александр Македонский) белән Хозыр (галәйһессәлам) турындагы бездә таралган мәшһүр легендага бәйләнгән. Алар кешене мәңге яшәтүче тере суын эзләп, борынгы безнең Болгар җиренә киләләр. һәм ул чишмәне эзләп, караңгылык (золмат) иле булган төньяк котып сызыгына керәләр. Анда тере суы чишмәсен тапкач, Искәндәр ашыга-ашыга итеген салып, суны кунычына тутырып, берьюлы тиз-тиз, күп-күп итеп кабып эчмәкче була. Комсызлыгына йотлыгудан бик каты тончыгып, тере суы иренենә тисә дә авызына кермичә читкә ага... Ул эчә алмый, Хозыр баба эчә. Шуның белән тере суын эчү бары тик адәм балаларына яхшылык итүче изге, саф күңелле Хозыргә генә насыйп булып, ул мәңге яшәүгә ирешә. һәм бу легендага бәйле рәвештә бездә **«Иреннән акты, авызга тимәде»** дигән бу тирән мәгънәле әйтем тарала. Аның әкиятләр очламы булуының хикмәте шул: гадәттә әкиятләр батырның бар кыенлыкларны җиңеп, ахырында патша кызын алып, дөньяда булмаган зур сый, туй-тамашалар ясавы белән тәмам була. Бу наз-нигъмәтләргә безнең буын кешесе никадәр генә нәфсен сузса да, болай гына аның авызына керү насыйп булмас. Ул сыйларга лаек булу өчен синең әле дөнья күләм эшләрең һәм яхшылыгың тигән булырга кирәк... һәм, күрәсең, әкиятләр безне дә шуңа чакырып тәмам була.

КАЗАН АСУ. Казанга пешерергә аш салу, аш пешерү. Элек казан чылбыр белән түшәмгә асулы булган, аш пешергәндә аны сиртмә белән учак өстенә китергәннәр, бушатканда һәм бушагач аннан алганнар. Аш пешерү диясе урынга казан асу сүзе әле дә телдә саклануы шуннан. «Тыпый-тыпый карлыгач, кунак килсә казан ас; Кунак ялгыз ашамас. Үземнең карным ач...»

КАЛА СУККАН КЕБЕК. Шәһәр ныгытма курасы (калга) корып куйган кебек. Борынгы кала кору (гарәпчә къәлга) сүзеннән. «Йорты янынннан узуы үзе бер куаныч—кала суккан кебек бит» (Г. Ахунов, «Хәзинә»).

КОТЫ БОТЫНА КИТТЕ. Мыскыллап әйтем. Куркуыннан тәмам шүрләде димәктән. Русларда: «Душа в пятки ушла». Борынгы латинда: «Animus in pedes decidit» — куркуыннан җаны аяк табанына китте димәк. Снегирев моны борынгы римлеләр гректан алганнар, ди (т. 1, 98—99.) һәм дәрестән дә, җанның аяк табанында булуы (Ахиллесева пята) һинде-европалы халыкларда аяк табанын «җан җире» дип ышануга, бу исә аларның тагын да борынгырак мифологияләренә бәйле булуыннан килә. Ләкин моңа карап «коты ботына китте» дигән татар әйтеме дә шуннан алынган дип уйларга туры килми. Чөнки бездә җан җире кешенең ботында дигән ышану булганы юк, бу әйтем тик котбот сүзләренең рифмалашуына корылган булып, ул да булса урынсыз куркуның начар нәтиҗәгә китерүенә ишарә белән мыскыллап әйтем. Шул ук вакыт ул кешенең гәү-

дәсенә кереп-чыгып йөри торган кот дигән нәрсәгә ышануга бәйле булуы белән дә борынгы.

УНИКЕ ТЕЛ БЕЛӘ. Күп телләрдә сөйләшә, укый-яза, эш йөртә белгән утә галим кеше димәктән әйтем. Бу гыйбарәнең таралуына тормышта да реаль һәм тарихи нигезләр бар. Мәсәлән, XV йөздәге «Бабер-намә» китабында язылуынча, Әфганстанның Кабил (Кабул) шәһәрендә 12 телдә сөйләшкәннәр: гарәпчә, фарсыча, төркичә, монголча, һиндчә, әфганча, пшагча, прачича, гибричә, евричә, перкичә, ламганча. Авторы Солтан Бабер: «Бу дәрәҗәдә төрле кавем, төрле теллелек һичбер өлкәдә мәгълүм түгел»,— дип куя. («Бабер-намә», Казан, 1857, 161 бит.) Ләкин безнең Идел буенда Мәкәрҗә ярминкәсе дип йөртелгән мәшһүр базар башта борынгы Болгарда, аннан Казанда булып, шуннан Макарьев һәм Нижныйга күчерелгәнгә һәм ул элек-электән бирле Европа белән Азия ара иң олы базар булып, анда мөмкин булган дөнья халыклары җыелганга күрә, унике телдә сөйләшә белү, бәлки артып та китү күренеше бер заманнар үз җирлегебездә, үз Болгар, Казаныбызда ук булган булуына бер дә шик юк. (Мәсәлән, татар, башкорт, мари, чуваш, ар, мордва, казакъ, кыргыз, рус, әрмән, иранлы, һинд, поляк, немец, финнәрнең бу базарга килүләре мәгълүм эш.) Мондый дөнья базары, сәүдә үзәге булган җирдә күп телләр белүчелек, әлбәттә, зур табыш китергән. Шунлыктан да күп белемлелек билгесе итеп «унике тел белә» әйтеме корыга гына арттырып әйтү яки читтән алып кына әйтелгән сүз булмыйча, үз җиребездә туып әйтелгәндер.

ҮЗ КУЫШЫҢНЫ КОРУ.—«Алып батыр Чулманның Иделгә койган җирендә, яр башына үз куышын корып утырды» (Халык әкиятеннән). «Үз куышыңны корып җибәргәнче катлаулы заманнарның шактый борылмаларын узарга туры килде» (Г. Ахунов, «Хәзинә»).

Куыш кору—әлбәттә, болгарларның борынгы күчмә куыш-тирмә коруларыннан калган сүз һәм ул агач, таштан өеп өй салулар башланганчы ук телдә әйтелгән. Хәзер бу әйтем элекке куыш-тирмә төшенчәсендә түгел, бу заманча өйле-йортлы, гаиләле булып яшәү мәгънәсендә әйтелә.

Борынгы төрки мәдәният белән бәйле булган бу «куыш» һәм аның тамыры булган **«ку»** сүзенең рус теленә төрле сурәттә үтеп керүе дә кызыклы һәм телчеләребез моңа игътибар итәрләр дип уйлыйм. Мәсәлән: кош, ковш, кошелек, кувшин, кобза, кузов... һ. б. Әйтик, бер **кузов** сүзен генә алып карасак, без аны хәзер гүя ки фән-техника революциясе аркасында безгә кергән, әллә ниткән зур культуралы бер яңа сүз кебек, хәрефе хәрефенә туры китереп, бик тырышып «машина кузовында» дип язабыз. Хәлбуки кузов дигәнебез шул ук үзебезнең Казан арты урманнарында үскән карама яки юкә кабыгыннан ясалган җиләк-җимеш, тоз савыты мәгънәсендә үз телебездәге **кузау** дигән сүздән башка бер нәрсә дә түгел. Ул шул ук баягы **ку**, куык, кузак, курай... лар кебек, эче куыш димәктән алып ясалган бер сүз. Шунлыктан аны без хәзер «машина кузовында утырабыз...» дип язуга караганда, туп-туры гына үз телебездә: «машина кузавында» яки хәтта «кузагында утырып барабыз» дип язу шигърирәк һәм дөресрәк булыр иде кебек тия. Чөнки «машина кузовында» дип форма өчен генә язсак та, укыганда аны «кузыфында» дип әйтелгәнгә, бары тик язганны укуыбызны гына авырлаштырабыз.

БҮРЕСЕ УЛАУ.

М и с а л: «Адәм баласының бүресе бер уласа улый икән, әй. Кара инде син: бөтен байлык-дәүләт, бөтен дәрәҗә шул Шаңгәраев кулына үзеннән-үзе агып керә дә тора бит!»

Бүре улавы—кешенең михнәт-мәшәкатьтән яки коллык-изелүдән берьюлы котылуы, якты көнгә чыгуы, шуның сөенечле хәбәре билгесе. Бүре (ак бүре)—төрки халыкларның яклаучысы (патроны, тотемы.) Мәшһүр бер легенда буенча, борынгы төрки халыклар дошманнары тарафыннан Әргинә Кун таулары арасында камауда калып, халык буларак кырылып бетәргә тиешле бер вакытта, Ак Бүре улап, аларга бу камаудан чыгып була торган яшерен юл күрсәткән, үз артыннан ияртеп аларны алып чыккан, коткарган була. Болгар-татар фольклорында, кыпчакларда һәм угызлар (огузлар)да бу бүре культы яши. Монголларда да бүре культы булуы аның хәтта төрек-монгол телләре аерылганга, формалашканга кадәрле бик борынгы заманнарда ук килеп чыкмады микән дип уйларга мөмкинлек бирә. Кыскасы, безнең татарда хәзердә дә кеше авырлыктан

котылган, иркенәйгән, бәхете ачылган, мул яши дигән мәгънәдә «аның бүресе улаган, улый» дибез. Бездәге мәшһүр «Ак бүре» һәм «Ялпы бүре» әкиятләрендә, мәкальләрдә һәм җырларда да бүрегә карата бу хөрмәт саклана. Безнең барлык легенда һәм фольклорыбыз сагында да Ак Бүре тора: «Көндез әкият сөйләгән кешене Ак Бүре ашый».

Мөһим бер искәрмә. Соңгы елларда чыккан кайбер мәкаләләрдә—безнең бабаларыбыз болгарлар эткә табынганнар, башка төркиләрдә бүре культы булганда бездә эт культы гына булган, без эткә табынучы халык дип кызу-кызу язылган сүзләр күренде һәм кабатланды. Шуңа дәлил итеп, 922 нче елда Болгарга килгән Ибне Фазлан сәяхәтнамәсеннән бер җөмлә, тагын атта чабып барган аучы артыннан ияреп чапкан бер эт сурәте, янә бер борынгы аучы каберенә күмелгән эт табылуы кебек берничә материал да китерелде. Ибне Фазланның болгарлар эт улавын яхшыга юрыйлар дип язган булуы дөрес. Ләкин андый яхшыга я яманга юраулар башка хайваннар һәм бөҗәкләр хакында да бездә җитәрлек күп әйтелә һәм мондый сүзләр берсе дә ул хайван-бөҗәкләргә табынуны күрсәтми. Ибне Фазлан да болгарлар эткә табыналар дип язганы юк. Кайбер аучының яраткан эте кабергә күмелсә, ул әле сирәк күренгән эш. Әмма атларны хуҗасы каберенә күмү элек бөтенләй дә еш булган күренеш. Шулай булгач, атка зур хөрмәт хакында сөйләшергә дә булыр иде. Әмма болгар-татарларда эткә гыйбадәт кылырлык хөрмәт булу бер якта торсын, киресенчә, этнең түбәнлеккә төшкән, әрсез, куштан, талашчы һәм тамак ялына бәндәгә бәндә булып, аның ишек төбендә койрык болгап яшәргә калган булуы өчен, хурлык мисалы ителгән татар мәкальләре генә дә бездә ярты меңнән артык. (Мәсәлән, минем җыентыкларда.) Шулардан «Эт каргышы бүрегә җитмәс» һәм «Этнең хуҗасы булса бүренең тәңресе бар» дигән ике генә мәкальне алып карасак та, халкыбыз карашынча, этнең урыны кая да, бүренең дәрәҗәсе кая икәнлеген күрсәтергә җитсә кирәк. Уйлаган кешегә монда, әлбәттә, тирән мәгънәләр җитәрлек һәм билгеле ки: татар бүрене мактаса, бу һич тә аның канэчкеч ерткыч булуы өчен түгел, бәлки бүре ач калса да, бер кемгә дә баш салмавы, табигать биргән үз ирек-азатлыгын бер кемгә дә бирмичә, аны һәр нәрсәдән югары куюы, саклавы өчен һәм үз тамагын үзе куян тотып булса да асрый алганда, аның эт шикелле, хуҗама туры булам имеш, дип, аңа куян тотышып, адәм хуры булып, телләрен салындырып, әлсерәп чапмавы һәм шул хезмәте каршысына хуҗасы кулыннан бер кимерелгән сөяк өмет итеп, койрык болгап куштанлык сатып йөрмичә, үз табигатенә үзе тугрылыклы булып, теш-тырнагы белән үзен-үзе яклап, үзенә үзе баш һәм хуҗа булып, үз иркенчә яшәве, түбәнсенмәве өчен. Димәк ки, борынгы төрки-болгарларда бүре культы һәм татар фольклорында бүрегә хөрмәт саклаткан бердәнбер нәрсә—ул да булса бүренең хөрлегедер. Инде шул ук бүренең кан кардәше булган этне татар карашында нәфрәтле санаткан нәрсәгә килсәк, анысы, әлбәттә, этнең бәндәгә бәндә булучылыгы, аның коллыгы һәм коллыгының хурлыгыдыр. Болгарларның бу карашта тормыйча хәлләре дә юк. Чөнки алар, тарихлардан күрелгәнчә, үзләренә үзләре көсеп белән ризык табарга булдырган, үзләре өчен үзләренә дәүләт корган, ил тоткан, үз җирендә үзе хуҗа, үзләренә үзләре баш бәйсез, мөстәкыйль халык булып яшәгән булгач, этләрчә коллык аларның табигатенә бөтенләй ят, нәфрәтле нәрсә булып тоелмыйча мөмкин дә түгел. Шуның өчен дәдер, тарихларда күрәбез ки, алар үз ил-җирләрен, ирекләрен бирмәс өчен, шәһәрләре кырылып беткәнче сугышканнар. Инде заманына күрә, чагыштырмача шундый данлы тарихлары, дәүләтләре һәм бай мәдәни мираслары булган бер халыкның барлык тарихына һәм тел-фольклор, культура мирасына каршы барып, аны муенына каеш бау тагылган эткә табынучы бер халык булган дип күрсәтергә тырышудан максат ни?

Миңа бу аңлашылмады.

ИР-АТ. Кушсүз. Элек күчмә, ярым күчмә тормышта ирләр гел ат менеп йөргән заманнардан, аларның бер-береннән аерып карап булмастай бергәлекләреннән алып әйтелгән бу. Һәм хәзерге көндә шәһәренә дип әйтмибез, авылына бер ат заты табылмаган очракларда да, ирләр үзара тупланып, «ирләр сүзе» сөйләшеп торган җирне хатын-кызлар «ир-ат арасы» дип әйтеп сөйләшәләр. Мәсәлән: «Мин бер генә хатын-кыз башым белән җыен ир-ат арасында нишләп йөрим, ди? Йөрмим».

ИТӘК КИСЕП ҖИҢ ЯЛГАУ. Бер нәрсәнең берәр кимчелеген шул әйбернең икенче җиреннән кисеп алып шуның белән каплап төзәтәм дип әйберне икеләтә бозып куеп, тагын да шыксызлауга карата әйтем.

Бу мисалга охшаш мәсәлләр Крыловта да (Гришкин кафтан) һәм аңардан күп элекке язучыларда да бар. Шуңа ияреп, татарга бу фразеологизм әзер килеш көнбатыштан килгән импорт кына диючеләр булыр. Ләкин мәкальләр һәм әйтемнәрнең тарихи ягына чынлап игътибар иткәндә, эш алай гына тормавы, бәлки бу әйтем бездә һәм төрки халыкларның үзендә, үз җирлегебездә туып, борынгыдан бирле әйтелеп килгән булуы күренә. Мәсәлән, бездә «Иске дошман дус булмый, итәк кисеп җиң булмый» дигән мәкаль бар. Шулай ук бу сүз казакъ халык дастаннарында да очрый. Бу мәкальдәге «итәк кисеп җиң ялгау» тәгъбиренең дуслык-дошманлыкка бәйләп әйтелүе, әлбәттә, юкка гына түгел, бәлки аның тагын да борынгырак йола хөкеменә бәйле булуын күрсәтә. Ягъни, итәк кисеп җиң ялгау киемнең гаебен каплый алмаган кебек, дошманлык белән кешене үтергәндә аның кан үчен алу, кан каруын кайтару да коры йолым (штраф) түләү белән генә кайтарыла алмый, канлы җинаять бер нинди йолым белән дә каплана алмый, бу бары тик итәк кисеп җиң ялгау гына була дигән сүз. Моңа караганда бу—кан үче кан белән алынган бик борынгы заманнардагы йола хөкеме булып туган мәкаль икәнлеге аңлашыла. Ягъни: кешенең кеше үтерүе кадәр зур канлы җинаять бер нинди түләм белән дә аклана алмый, чөнки бер түләм дә үлгән кешене кайтара алмый һәм аның бәясенә тора алмый, дигән язылмаган борынгы кануннан калма сүз була. Соңыннан, күрәсез ки, мәкальнең соңгы кисәге «итәк кисеп җиң булмый» дигәне — бер гаепне икенче гаеп белән каплап булмый мәгънәсендә әлеге әйтем булып киткән.

КАРАМА КУЫШЫННАН ТӨШКӘН. Ата-анасын—фамилиясен белмәүче табылдык бала димәктән. Элекке заманнарда илне көтелмәгән яулар—сугышлар басканда яки юлларда туган баланың анасы үлеп калса яки яуга әсир төшкәндә баланы үзе дә, кардәшләре дә асрап үстерү мөмкинлеге булмаса, кем күрсә шул алсын дип, агач куышына куеп калдыру йоласы булган. Әйтик, кыпчак ыруының килеп чыгуы хакындагы хәбәр дә купчак — күпшәк, ягъни агач куышыннан табылу риваяте булу яки Карамишовлар фамилиясендә **карамыш**—карап үстерүче һәм карама агачы төшенчәләре булуга игътибар ителсен. Хәзер бу әйтем ата-анасын, фамилиясен, нәсел-нәсәбен яки милләте кем икәнен белмәүче, белергә теләмәүчегә карата әйтелә.

КЕЛӘҮГӘ ТОТАСЫҢМЫ ӘЛЛӘ АНЫ? Келәүгә тоту—борынгы болгар бабаларыбызның моннан мең елдан да элгәрәк, ислам кабул иткәнгә кадәр, тоткан үз мәҗүси диннәре буенча, табигать ияләренә һәм баш тәңрегә дога-теләкләр әйткәндә яки үзләре үлгәннән соңында ияләргә корбанлык өчен хәер-садака итеп бирергә дип, нәзер әйтеп, капчыкка төйнәп асып саклаган кайбер ризык сыман нәрсәләре. Моны саклау келәүгә тоту дип аталып, ислам кабул иткәннең соңында да озак дәвам иткән һәм хәтта бу гасыр башларына кадәр кайбер чормаларда келәү капчыгы эленеп саклануы билгеле.

Инде хәзер аз гына ризык әйберсен ашамыйча саклаучыга, борынгы йола калдыгына ишарә белән, «Келәүгә тотасыңмы әллә аны!» дип көлү катыш суктырып әйтелә.

КОЯШТЫР АЛМАДЫМ, АЙДЫР ӘГӘР, АЛГАН БУЛСАМ КОЯШ ЙӨЗЕН КҮРМИМ, ҖИР ЙОТСЫН. Ант. Сүзеңне раслау өчен кояш, айны таныклык итеп һәм ялган әйтсәң сине йота торган җир иясе белән ант, әлбәттә, исламга кадәрге антлар. Әле дә әйтеләләр.

ТАБЫН ӨСТЕНДӘ ӘЙТӘМ! Табын янында утырганда әйтелгән берәр сүзнең раслыгына табын тулы нигъмәтне таныклык итеп ант орып әйтем. Ягъни, әгәр сүзем рас булмаса, табын тулы аш орсын!

Мондагы **тап, табын** сүзе асылда борынгы ыру-кабиләчелек заманнарында болгар, кыпчак төркиләрендә ыру-кабилә җыены дигән киң мәгънәдәге сүз булып, тап һәм табын исемендә йөргән татар һәм башкорт ырулары булу да шуны күрсәтә. Мәсәлән, XVIII йөз башында Себернең Табул (Тоболь) елгасы буенда **тап** дигән татар җәмәгатенә язма бер нәсихәтнамәдә болай диелә: «Олуг вә кечек **тап** халкы җәмәгатьләренә». Ахырында: «Бу нәсихәтнамәне Хуҗа Шәкер бине Гавыз бай татар башлыгы яздым. Тарих мең дә йөз дә уңдүрттә, елкы елында» (1703 нче елда була.) «Тап халкы Табул елгасының уң тарафында мәгъруф (бик билгеле) бер җәмәгать вә кабиләдер». (Риза Фәхретдин улы, «Асар», 1 том, 30—31 битләр.) Яки башкортларда йомран табын, кәлчер табын һәм башка табын ырулары булу да тап — табын сүзләре шулай ук берберен табышкан төрки кабилә тупламы мәгънәсендә йөргән сүз булуын күрсәтә.

Ихтимал ки, Табул елгасы сүзе дә кайчандыр шулай татар ырулары табышкан елга буе димәктән калган тап, табын сүзләре белән бәйледер? Кыскасы, бу әйтем башта бөтен бер ыру-кабилә җыены һәм аксакаллары киңәшмәсе булган һәм, әлбәттә, төркиләр гадәтенчә, ашы-сые да уртада булган җәмәгатьчел тәгъбир һәм шул табын өстендә ант булган сүз.

Мисал: «Сүзебезнең инә очы кадәресе генә ялган булса, икмәк төсен күрмик. Минә табын өстендә әйтәм!» (А. Шамов.)

УГАТА ҖИБӘРҮ. Сүзне чамасыз арттырып сөйләү. Угата (ук ата)—сүзе ук атымы җир кадәр арттырып, үзеннән кушып ялганлап сөйләү. Борынгы ук атудан. Мисал: «Әй лә, бигрәк угата җибәрәсең инде син!»

ХАН КЫЗЫ ТҮГЕЛСЕҢ. Өй эшен һәм кара эш яратмаучы, мин ул эшне эшли белмим дип җавапланучы иркә,нәзакәтле, нәзберек кызларга карата төртеп әйтәләр. Мисал:— «Шул тавыкны йолкып, тазартып ашка салып пешер.—Мин аны йолка да, тазарта да белмим.—Белмәсәң, менә йолкып тазартканда белерсең. Бик хан кызы түгелсең!»

ЧЫҢРАК ҮТӘ КИТ! Каргыш. Чыңрак (казакъча—чаңрак) күчмә киез өйнең түбә тишеге, түгәрәк агач алкасы, төнлеге (төтенлеге, төтен юлы һәм кирәк чагында яктылык юлы да). «Чыңрак үтә кит»нең мәгънәсе янып, төтен булып чыңрак аша күккә оч димәк. Борынгы күчмәлектән калган, кыпчак һәм көн-көнбатыш як каргышы. Профессор Л. Җәләй тарафыннан бу әйтемгә «җир үтә кит» дип мәгънә бирелгән һәм (мишәрләрдә) чыңрак дигән ниндидер җир асты мифенә ышанулар булган дигән уйларга кителгән. Бу, әлбәттә, хата фикер. Чөнки чыңрак җир астында түгел, түбә өстендә. Ул тирмәнең түбә укларын (үрәчәләрен) тотып торган түгәрәк тә һәм кояш белән төтен юлы да. Шунлыктан эш монда бәлки айга, көнгә, утка табыну кебек мифологияләрсез дә булмас, ләкин ул, һәр нәрсәдән элек, борынгы күчмә төрки кавемнәрнең үз материаль культурасы.

## КАЙБЕР СӨЗЕМТӘЛӘР

Монда китерелгән мисаллардан һәм тарихка ясаган кыска гына экскурсиябездән бер йомгаклау төсендә түбәндәгеләрне әйтергә тиеш табам: димәк ки, әйтемнәребезнең күпчелеге үзләренең чыгышлары буенча ерак тарихи заманнарга кайта. Ләкин, билгеле ки, без аларның тарихын борынгы төрки ташъязмаларга карап кына моннан мең ярым еллардан бирле килә икән дип тә чикли алмыйбыз. Чөнки тамга хәреф, чөй хәрефләрнең моннан 6—7 мең еллар элекке шумирлар культурасы заманнарында да булуы һәм алардан калма ташларда да борынгы төрки сүзләргә охшашлары булуы билгеле. Төрки телле халыкларның үзләре борын заманнарда җир йөзенә кайлардан кайларгача таралган булулары һәм тел тамырларының да ничә мең елларгача бирешмичә саклана алучанлык табигате хакында соңгы заманнарда күп кенә мәкаләләр дә язылды. Бу эзләнүләр һәм гипотезаларга караганда, фән-техниканың хәзерге үсеше алда безнең тел тарихыбызга төрле кампанияләр күзлегеннән генә карамыйча, аны җитдирәк һәм тирәнтенрәк тикшереп өйрәнергә мөмкинлек бирәчәгендә шик юк. Әмма ләкин китерелгән мисаллардан да әлегә безгә шунысы бик ачык күренә: әйтемнәрнең язылып сакланганы да, телдән әйтелеп йөргәннәре дә күпмедер дәрәҗәдә тарихи элементларны һәм мөнәсәбәтләрне үзләрендә югалтмый саклап киләләр икән. (Мин, мәсәлән, үзем тарафымнан җыелган 50 меңнән артык әйтемнең зур күпчелеге, әлбәттә, элекке заманнардан бирле калып әйтелә килгән мирас булырга кирәк дип уйлыйм.) Димәк, тел һәм әйтемнәребез тарихи күзлектән караганда, безнең өчен әлегәчә ачылмаган девон яки каты токым катламы кебек, тирәндә яткан бер хәзинә дип белергә кирәк. Бу мәкаләдә инде беркат искә алынганча, Г. Тукайның: «Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады...» (Г. Тукай. IV том, Казан, 1977, 265 бит) дигәне кебек, безнең өчен хәзер иң мөһиме — ул халык шигыре һәм җырларның да төп тукымасы булган туган телебез, сүзебез һәм шулай ук әйтемнәребезнең меңнәрчә еллар сакланучанлыгы. Дәүләтләр, ханлыклар юк ителсә дә, телебез исән калды, халкыбыз аны шундый кыен изелүләр астында да җаны урынында күреп югалтмый саклаган булса, икенче яктан, бу тарихи культура

хәзинәбез үзе дә халкыбызны төрле җәбер, коллык, хурлыклардан саклап-яклап килде. Яшәү өчен көрәшләргә оештырып рухландырып килүче төп бер коралыбыз да шул ук телебез булды. Шуларның барысы өстенә телебез — тарихлар буена бары тик үз халкыбыз эчендә генә бикләнеп һәм чикләнеп үз күләм мәдәниятебез булып кына калмыйча, халкыбызның кешелек культурасына керткән гаять зур өлеше дә булып тора. Моның шулай икәнен күрше культуралы бүтән янәшә халыкларның телләрен ясашуда да аның нинди мөһим роль уйнавы күрсәтә. Мәсәлән, иран, рус һәм яңа гарәп телләре ясалышы мисалларында бу хакта шул телләрнең сүзлекләренә каралсын. Әгәр дә без бу бай хәзинә булган телебезне, аның тарихын, сүзләребезнең этимологик тарихларын, фразеологик әйтемнәрнең һәм гомумән фольклорыбызның тарихын кардәш төрки халыкларның тел өлкәсендәге эшләре белән мөнәсәбәттә өйрәнә белсәк, ул чагында шул ук тел хәзинәбез безгә халкыбызның ерак үткән заманнарыннан алып иҗтимагый һәм материаль культурабыз тарихын, аның дөньяга карашларын, аның әхлакый, фәлсәфи, рухи, мәгънәви йөзен һәм татар халкының тарихи чыгышы, формалашуы хакында әлегәчә сузылган кайбер бәхәсле мәсьәләләрне дә ачарга, ачкыларга ачкыч булып та хезмәт итәчәк һәм бергә үк башка күп тарихи яңалыклар да ачылачак. Без археологиядә җир казылмалары ясауда нык кына алга китсәк тә, тел археологиясенә тирәнтен керә алганыбыз юк әле. Туган телебезнең тарихчылар өчен үз тарафыннан булышлык күрсәтергә әзер торуы, әлбәттә, мөһим...

Тел, фольклор һәм әдәбият тарихыбыз буенча үземнең эзләнүләрем хакында берничә соңгы сүз: хәзерге фән-техника, машиналар гасырында, көрәк белән кое казып, чиләк белән ком ташып хәзинә эзләү кебек эшләр, ихтимал, кайберәүләр өчен әллә ничек бераз сәер сыман да булып күренер. Ләкин андый машиналар һәм аппаратуралар белән коралланган тел археологларыбызның бу эшләргә куллары җитешмәгәнгәме, ни өчендер, бу көнгә кадәр телебезнең шул тирән катламнарына төшәргә ашыкмауларын күргәч, табигый, мин дә бу хәлгә читтән сәерче булып кына кала алмадым. Кайчандыр Каюм бабайның «Татар телемезгә хезмәтче мин булаем дип утыз биш ел гомер уздырдым» (К. Насыйри. «Ләһҗәи татари» китабына сүз башында) дигәне кебек, мин дә аның хәлендә, ялгыз-ярым булса да, моңарчы булганча һәм кулымнан килгәнчә, бер яктан, бу эшкә булышуны вөҗданым бурычы санадым һәм башка иҗади эшләрем белән бер рәттән, бу тел, сүзлек һәм әдәбият тарихы буенча эшләремә дә 65 еллап гомеремне бирдем. Үкенмим. Халкыбыз өчен эшләвем белән бәхетле булдым.



*Татарстан республикасы Әгерҗе районы Иске Аккуҗа авылында туганмын. Үзем соңга калып туганмын дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә — гаиләдә тугызынчы бала булып, үземнән алда туган абыйдан соң 6 ел узгач, өстәвенә төпчек бала булып туганмын. Монысы әле аның искитәрлек түгел. Әниегез иллене тутыргач туып карагыз әле сез?*

*1973 елда университетны тәмамлаганда яшьтәшләремнең дипломы гына түгел, бала-чагалары да бар иде инде.*

*Соңга калып мин хикәяләр яза башладым. Әшкә соңга калынмаган. 18 еллык стаж булу шул хакта сөйли кебек.*

## Харис Закиров

# ӨЯНКЕЛӘР ШАВЫ

ХИКӘЯ

Бригадир Мирсәяф кергәндә Хаҗәр әби бәрәңге бакчасы түрендәге өянкеләр янында иде. Бакчасына чыккан саен шушы өянкеләргә карап, шуларның шаулавын тыңлап тора ул. Килен булып төшкән елны ире Кадыйр утырткан иде аларны. Утыртканда: «Бакчабызга ямь бирсеннәр, шаулап үссеннәр әле», дигән иде.

Гомер дигәнең сизелми дә үтте. Өянкеләр дә үсте. Кочып кочак җитмәслек булып юанайдылар. Менә әкрен генә искән җилдә бихисап яфраклы ботаклары селкенгәләп ала.

Кадыйрның да якты дөньядан киткәненә күпме вакытлар узды. Бакча түрендә уйнап, яшь өянкеләр тирәсендә кайнашып үскән уллары да төрлесе-төрле җирдә яшәп яталар.

Әллә дөнья мәшәкате, әллә башка нәрсә сәбәп — уллары бик сирәк кайта аның. Әнә быел тагын бәрәңге казыр вакыт җитте. Ник берсе күренсен дә, ник берсе хәбәр бирсен икән.

Ире исән булса бу йорт кешесез торыр идемени? Табигате белән җор, кешеләр белән тиз аралашучан Кадыйрны әллә кайлардан эзләп керерләр иде. Һич уйламаганда, көтмәгәндә бәхетсезлеккә очрады шул мәрхүм.

Кадыйр ул елны плугарь булып эшли иде. Төнге сменага дип эшкә китте. Төн уртасы җиткәндә ярым үлек хәлендә өйгә алып кайттылар. Йөзенә, гәүдәсенә карарлык түгел, кашларына чаклы янып беткән. Соңыннан барысын да белде Хаҗәр. Беренче сменада эшләүче Сәләхи, салам эскертеннән бик ерак китмичә учак ягып, бәрәңге пешермәкче булган икән. Алар сөреләә торган җирнең аргы башына киткәч, учакны җил уйнатып җибәргән дә, эскерткә ут кабынган. Шул вакыт монда килеп җиткән Кадыйр янгынны сүндерергә ташлана. Әмма секунд эчендә ут урап алган эскертне сүндерергә Кадыйрның гына көче җитәме соң? Эскерт тә яна, эскерт белән бергә мазутлы киеменә ут капкан Кадыйр да яна башлый. Сөрелгән туфракта ятып аунау да коткармый аны. Иптәшләре килеп җиткәндә ул инде авыр хәлдә була. Хаҗәр, ат җиккән арбага салып, ирен участок больницасына үзе илтте. Тик савыгып кайтуын гына күрергә насыйп булмады...

Өянкеләргә караган саен Хаҗәр әбинең күңелләре әллә нишләп китә. Гүя ул өянкеләр: «Картың, уллары янында булса, син дә безнең кебек яшәр идең. Без әнә шауласак та бергә, тынып калсак та гел бергә», диләр кебек аңа.

— Хаҗәр әби, монда икәнсең. Үзеңне эзләп каралты-курагызның бар җиреннән карап чыктым. Кунаклар алып килдем. Әйдә, кабул ит!

Көтмәгәндә әйтелгән бу хәбәрдән Хаҗәр әбинең җыерчыкларга күмелгән йөзе яктырып китте. Әллә шатлыктан, әллә каушаудан кызурак сөйләнеп, соравын бирергә ашыкты.

— Улларымның берәрсеме әллә? Кайсысы: Мөдәррисемме, Гайнетдинемме, Гаязыммы?.. Гаязыммы, Мөдәррисемме?..

Бригадир Хаҗәр әбине болай кабалана-ашыга уллары сорар дип уйламаган иде. Шунда ук «кунаклар» дип әйтеп дөрес эшләмәгәнен аңлады. Һәм Хаҗәр әбине тизрәк тынычландырырга ашыкты.

— Бу улларың түгел әле. Студент кызлар алып килдем. Колхозга булышырга җибәргәннәр үзләрен. Синдә торсыннар иде. Сиңа иптәш тә булырлар, бәрәңгеңне казырга да булышырлар, диюем.

Бу хәбәрдән соң Хаҗәр әби бер тын сүзсез торды. Нәрсә әйтсен соң ул Мирсәяфкә. Болай да кузгала башлаган күңелен җилкендерде генә ул аның. Ә студин дигәннәре керсеннәр. Иске булса да бер үзенә болын кадәр өе бар лабаса. Мирсәяф тә юкка кермәгәндер. Көймәсе комга терәлгәндә генә Хаҗәр әбисен борчырга җөрьәт итә ул.

Бик тә өлгер, бик тә тере булып чыктылар ул студент кызлар. Басудан кайталар да, әз генә буш вакытлары булдымы — бакчага чыгалар. Әнә тора башлаганнарына биш-алты көн үтмәде, әбиләренең бәрәңгесен алып, базга салып та куйдылар инде. Өйне дә ялт итеп җыештырдылар. Нәрсәгә генә тотынсалар да булдыралар үзләре.

Араларында Әлфия дигәннәре бик тә ярдәмле булып чыкты. Кулыннан килмәгән эше юк. Нинди генә эшкә булмасын — һәр чак үзе башлап йөри. «Биергә, җырга да чын артист кебек ул Әлфиягез» дип, клуб мөдире Зөләйха кичә генә мактап торды әле үзен. Уллары кайда яшиләр, кемнәр булып эшлиләр дип тә башта ул кызыксынды.

Тик менә шунысы: Хаҗәр әби инде кызларга күнегә, ялгызлыгын оныта гына башлаган иде, тегеләрнең китәр көннәре җитте. Электән килгән гадәт буенча Хаҗәр әби кызларга самавар куйды, юл өстәле әзерләде. Менә кызлар киенә башладылар. Шул вакыт Әлфия: «Әби, истәлек итеп бәйләрсең. Бу бездән күчтәнәч», дип, әбисенә яулык тоттырды. Тагын: «Без китәбез, улларың кайтыр, каршыларга әзерлән», — дип тә өстәде.

Картайгач кеше күңеле йомшак була диләр. Хак икән. Хаҗәр әбинең күз төпләре яшьләнде, тамагына төер утырды.

— Исән йөрегез, игелекле балалар булыгыз, — дигән сүзләрне дә көчкә генә әйтә алды ул.

Киттеләр, үзләре генә түгел, Хаҗәр әбинең тынычлыгын да алып киттеләр алар. Кызлардан соң Хаҗәр әби җанына тынычлык, үзенә урын таба алмый иза чикте. Нәрсәгә генә тотынса да кулы эшкә бармады аның. Тын гына агып яткан елгага пароход кереп зур дулкыннар ясаган кебек, язмышына буйсынып, инде ялгызлыгына күнегә башлаган Хаҗәр әбинең күңел дәрьясында кызлар дулкын чыгаруын дәвам итте. Бигрәк тә Әлфия һаман янында кайнаша, бөтерелә кебек иде аңа. Балаларының берәрсе кыз булса Әлфиягә охшар, Әлфия кебек уңган булыр иде дигән уйлар да башына бер генә кереп чыкмады. Әнә, халыкта: кыз бала — анага, ир бала атага тартым була диләр бит. Хәер, уллары Кадыйрына охшаган дип әйтә аламы соң ул? Юк шул. Кадыйры кешелекле дә, башкаларга игътибарлы да иде. Ә болар... Әнә ничә елга бер кайтып әниләренең хәлен дә белмиләр.

— Тукта әле, улларың кайтыр, каршыларга әзерлән, — дип ник әйтте соң әле Әлфия! Юатыр, карчык кешенең күңелен тынычландырыр өчен генәме, әллә инде ни дә булса сизеп-белепме?

Бүген Хаҗәр әби гадәттәгедән иртәрәк уянды. Уянды да, үзе күргән төшне юрый башлады. Шактый киң елга, имеш. Көймәгә салып Хаҗәр әби шул елга аша сыер алып чыга. Сыеры кымшанмый да. Кайчандыр, шушы йортка нигез салган елларны асраган сыерга охшаган, имеш... Юл төше бу!

Әлфия әйткән сүзләр тыңгы бирмәү өстенә мондый «рас» төштән соң Хаҗәр әби түзмәде, симезлеге белән күзенә байтактан чалынып йөргән тавыгын суйдырды. Бөтен килеш салып казан асты. Киемнәренең дә яңаларын киде. Бу минутларда яшәреп киткәндәй хис итте ул үзен. Гүя ул ишле бер гаиләгә табын әзерли.

Төшкә ашка кадәр байтак иде әле. Әмма сары майлары йөзеп йөргән тавык ашы өстәлгә китереп тә куелды. Борычы-тозы, икмәгекатыгы — барысы да әзер. Тик менә табынга утыручылар гына юк. Хаҗәр әби кичкә кадәр ничә тапкыр тәрәзәдән карап, ничә тапкыр капка алдына чыгып керсә дә, кайтучылар күренмәде. Үч иткәндәй, көн дә кереп хәл белүче Камәр дә сугылмый бүген.

Шулай кич булды. Шулай төн җитте. Хаҗәр әби үзе уйлап чыгарган бу әкәмәтеннән үзен орыша-орыша йокларга ятты. Юләр, төш күрдем, имеш. Юл төше. Шулай юрап кына кайтса икән балаларың. Әлфиясе дә аның: карт кешене юатам дип, көт, кайтмый калмаслар димәсә соң. Хәер, аның ни гаебе бар. Бүген-иртәгә кайтырлар димәде, көтәргә генә кушты бит ул.

Ятты. Ләкин озак йокларга туры килмәде аңа. Капка шакыган тавышка Хаҗәр әбинең болай да сак йокысы бик тиз ачылды. Өенә ут алып, капка ачарга чыкса, үз колагына үзе ышанмый торды. Тавыш бирүче кеше — кече улы — Гаязы бит. Капка ачылуга ук төпчеге:

— Әни, хәлләрең ничек? Авырып торасыңмыни?—дип сүз башлады. Юлда күргән михнәт-газапларын сөйли-сөйли өйгә узды.

Таң атканда ана белән ул чөкердәшеп чәй эчеп, кичә пешкән тавык ашын ашап утыралар иде. Хәл-әхвәл алышып, күргән-белгәннәрне искә төшерә торгач, артык ашыкмаса да үз нәүбәтендә барыбер туа торган көзге көннең җиһанга яктылык сирпүен сизми дә калдылар алар.

Ә төш җиткәндә Хаҗәр әбинең олы улы Мөдәррис, өйлә авышкач уртанчысы Гайнетдин кайтып төште. Ана гаҗәпләнергә дә, гаҗәпләнмәскә дә белмәде. Әмма аңа шунысы ачык иде: болай бергә җыелуда Әлфиянең кулы уйнамый калмагандыр. Шулай булмаса, улларының барысы да бер тирәдә кайтырлар идемени дә, барысы да күрешүгә: «Әни авырып торасыңмыни?» — дип сорарлар идемени?

Хаҗәр әби шулай уйлап ялгышмаган икән. Сүзгә-сүз ияреп уллары хат алуларын, шуннан соң юлга чыгуларын әйттеләр. Гаяз үзенә килгән хатны кесәсеннән үк алып, абыйларына күрсәтте. Сызыксыз ак кәгазь битенә тигез юллар белән язылган хат: «Сезне бәрәңге өмәсенә чакырабыз. Авыру әниегезнең дә хәлен белеп китәрсез. Сезне көтеп, кайтуыгызга ышанып калучы әниегез һәм сезгә таныш булмаган студент кыз Әлфия», — дип тәмамланган иде.

Балаларны юлга чыгарган хатларны тагын бер кат искә алудан бер мәлгә тынлык урнашты. Туганнар ирексездән бер-берсенә, аннан кыяр-кыймас кына әниләренә карап алдылар. Ул карашларда уңайсызлану да, борчылу да, ваемсызлыктан кичергән вөҗдан газабы да бар иде...

Ә Хаҗәр әби улларын сыйлауны дәвам итте. Озак көткән йөрәк җимешләре үз янында булудан дөньясы түгәрәк, җаны ял итә иде ананың.

Гали Халит

# ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫНДА ДӨНЬЯ ҺӘМ ТАРИХ КОНЦЕПЦИЯСЕ

1

XX йөз башы татар поэзиясендә Дәрдмәнд (Закир Рәмиев) үзенең иҗат юнәлеше белән дә, иҗтимагый хәле белән дә үзенчәлекле шагыйрьләрнең берсе Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Н. Думави, З. Бәшириләр кебек, яңа гасыр башында азатлык өчен барган көрәшләргә таң калып һәм шуңа булган шатлыкларын шау-гөр килеп җырларга ашкынган әдипләрдән ул нык аерылып торды. Аның үз шигъри кушаматын Дәрдмәнд—«Хәсрәт чигеп яшәүче» дип алуы ук шундый давыллы чорда шактый сәер тоела иде.

Ул алтын прискалары тоткан Рәмиевләрнең берсе булып, алар «яхшы йортлар салдырганнар, яхшы атлар җиккәнәр, байлыкка, рәхәткә чумганнар»[1]. Шуңа күрә шагыйрь үз сыйнфый дәрәҗәсен һәм зур материаль көчкә ия булуын шактый тирән аңлап, аны шигырь белән бик төгәл итеп әйтүдән һич тә тартынмаган:

**Әгәрче дәүләтем юктыр җитәрлек,**
**Ишәктәй һәм йөк астында түгелмен.**
**Үзем башмын, үзем түш һәр эшемдә,**
**Тынычлыкта торамын, хуш күңелмен**[2].

Үзен әнә шундый югарылыкта торучы асыл зат дип хис иткән һәм яшәвеннән тәмам канәгать шагыйрьнең сәнгатькә карата да беренче таләбе — «Матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәт багына сакчы» («Шагыйрьгә», 1907) рәвешендә булды һәм бик ачык төстә «түбән чынбарлык» белән бәйле поэзиягә каршы куелды. XIX йөзнең икенче яртысы рус поэзиясендәге шикелле (монда Тютчев, Фет һәм Некрасов иҗатлары күздә тотыла), XX йөз башы татар поэзиясендә дә «матурлык поэзиясе» (яки «саф» поэзия) һәм «тормыш (яки гражданлык) поэзиясе» концепцияләре мәйданга чыкты. Шагыйрьнең тормышка һәм халыкка мөнәсәбәте мәсьәләсе төп критерий булып әверелде.

Дәрдмәнд тормыш ваклыгыннан, аның көндәлек бурычларыннан саф һәм югары булган сәнгатьне күпме генә якламасын, — тарихка, үз заманына, тормышка һәм кешегә мөнәсәбәт күрсәтүдән читтә кала алмады. Чөнки ул да, бик күпләр шикелле үк, үз чорының гаять катлаулы, каршылыклы тарихи-иҗтимагый шартларында яшәгән һәм үз язмышы өчен көрәшкән конкрет бер сыйныф идеологы булудан ваз кичә алмый иде. Шулай итеп, татар поэзиясенә өстен сыйныфлар, аеруча

[1] Ф. Кәрими истәлегеннән. — Дәрдмәнд әсәрләре, 1928 ел, II бит.
[2] Дәрдмәнд. Сайланма әсәрләр. Казан, 1959 ел, 89 бит.

буржуаз даирәләр белән турыдан-туры һәм тыгыз бәйләнештә торган шагыйрь килде.

Нинди яңалык алып килде соң ул безнең поэзиягә? Бу сорауга җавап бирү юлында татар әдәбият белеме кайбер уңышлы тәҗрибәләр ясап карады инде. Шулай да Дәрдмәнд поэзиясенең «серләре» тулысынча ачылган һәм аларның төз системасы табылган дип булмый әле. Бу «серләрне» беренче мәртәбә күпмедер күләмдә кыю итеп ачарга теләгән тәнкыйтьче Г. Ибраһимов булды. Аның 1913 елда басылган «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Тукай, С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд кебек өч зур шагыйрьнең үзенчәлекләрен күрсәтү нияте белән кызыклы гына фикерләр әйтелгән иде. Бу әсәрнең Дәрдмәндкә караган өлешендә:

«Аның тасвиратында бәндә, — ди тәнкыйтьче, — хәят юлында үз теләгәнençә бара торган падишаһ түгел, бәлки язмыш агышының кызганыч колы...». «Дәрдмәнд хәятка авыр карый. Вакыйгъдә үлем белән хәятның һәр икесен дә эченә алган җиһан аңа бигрәк үлем ягы белән күренә, күбрәк каберстанны аңдыра»[1].

Шагыйрьнең дөньяга карашын тулысынча өметсезлек караңгылыгында калган итебрәк сурәтләү белән килешү, бәлки мөмкин дә түгелдер, әмма китерелгән өзектә Г. Ибраһимовның Дәрдмәнд поэзиясе үзәгеннән үткән фәлсәфи караш һәм лирик настроениене шактый төгәл формалаштыруы бәхәссез. Бу настроение, үзенең төп юнәлеше белән, дөнья әдәбиятларында булып үткән романтизмны искә төшерә. Чыннан да, шагыйрьнең иң беренче әсәрләреннән саналган «Үткән көннәрдә» шигырендә әнә шундый настроение бар. Монда, үткәннең матурлыгын сагынып, аны бүгенгегә каршы куеп үкенү шикелле элегик мотивлар өстенлек итә. Шуңа күрә бу шигырьне романтик поэзиягә бик характерлы элегиянең бер үрнәге дип атарга мөмкин. Дәрдмәнд лирикасында элегиянең фәлсәфи һәм идиллик төрләре зур урын тота. Аның да лирик герое дөнья, тормыш, тарихи барыш һәм кеше турындагы тирән сагыш, хәсрәт тойгыларына дучар.

Заман яшәргәндә, яңарганда һәм күп әдипләр шуңа сөенгәндә, чынбарлыкны тамырыннан үзгәртүгә ышанып иҗат иткәндә, Дәрдмәнд бөтенләй киресен җырлады:

> **Нә алтын, бәлки балчык бу замана,**
> **Белалмим, кемгә тансык бу замана.**
> **Уенчык, яшь иде яшьлек көнемдә,**
> **Бүген карт, бәлки карчык бу замана[2].**
> **[«Замана», 1906].**

Шулай итеп, үткән заманнарның матурлыгын сагынып, яңа, яшь заманны картайган санап, шагыйрь революцион чынбарлык белән каршылыкка керде. Мондый хәлнең нигезендә, барыннан да элек, тарихи пессимизм ята иде.

Дәрдмәнд — үзенең иҗтимагый хәле белән зур тарихи катастрофалар кичергән шагыйрь. Ләкин ул үз сыйныфының сукыр колы гына түгел, ә күпмедер дәрәҗәдә аңардан югары торган һәм тарихи катастрофалардан үз сыйныфының да котылгысыз икәнлеген аңлаган художник-идеолог буларак, тарихи трагедияне һәм зур чынбарлыкны аңларга теләүдә активлык күрсәтүче дә иде.

XX йөз башы татар поэзиясен кеше һәм дөнья проблемасы биләп алды. Бу проблеманы инде хәзер тарих, ил һәм халык мәсьәләләреннән читтә күз алдына китерү һич тә мөмкин түгел иде. Шул проблема һәм мәсьәләләр Дәрдмәнд иҗатының да үзәгендә. Әмма шагыйрь аларны бик үзенчәлекле һәм үтә каршылыклы хәл итте.

Иң әүвәл аның 1908 елда, ил тарихындагы һәм халык тормышындагы бик авыр бер чорда — Столыпин реакциясе котырынган вакытларда язылган «Кораб» һәм «Без» кебек шигырьләрен искә төшерик. Бу шигырьләрне кайсы гына якка борып карасаң да, аларның үзәгеннән үтә торган бер фикер — тарихны, заманны ничек аңлау, бәяләү шактый ачык. Дөрес, бигрәк тә «Кораб» шигыренә карата әдәбият белгечләре арасында төрлечәрәк фикерләр күренгәләде; ихтимал, тагын да күренер әле. Хәтта кайберәүләр аннан Россия өстенә «якынлашып килә торган яшен-

[1] Г. Ибраһимов. Әсәрләр, сигез томда, 5 т. Казан, 1978 ел, 103, 105 битләр.
[2] «Вакыт», 1906 ел, 13 апрель.

ле кукрәү» тавышын ишетергә һәм Горькийның «Давыл хәбәрчесе» белән тыңлаштерергә дә теләгәннәр иде (мәс. П. Коган мәкаләләре). Әмма шагыйрь үзе үк нәкъ 1908 елда «Бузләрем маналмадым» шигырендә:

**Мин өмиднең сул кулыннан**
**Бер сынык нан[1] алмадым...**

дип икърар иткән иде. Димәк, Россия эченнән узган революцион җил-давыллардан ул өметләнмәгән дә, ләззәтләнмәгән дә икән. Әйе, Дәрдмәнд Россияне тетрәткән иҗтимагый үзгәрешләр турында сөйли һәм революцион давылларның дәһшәтле көч икәнен бик яхшы аңлый. Әмма шуннан чыга торган нәтиҗә нидән гыйбарәт? Бу сорауга: «Ил корабын җил сөрә!.. Нинди упкын тарта безне җан сорап?!» — дигән аптыраулы җавап бирелә «Кораб» шигырендә. Җил, давыл, дулкынланган диңгез, әлбәттә, тарих стихиясен гәүдәләндергән һәм бигрәк тә романтик әдәбиятларда күп кулланылган шартлы-традицион сурәтләр. Алар романтик поэтиканың аерылмас атрибутлары булып килде. Дәрдмәнд тә аны шундый сыйфаты белән файдалана.

Дәрдмәнд фәлсәфәсенең сурәтле формасы — табигать символикасында. Дөнья, тарих, тормыш — бер дәрья, океан, диңгез ул. Шуның шикелле, дөнья да котырына, дулкынлана. Тарих диңгезе дә мәрхәмәтсез — беркемне дә, бернәрсәне дә кызганмый.

Әнә шул котырынган стихия корабны, илне, гомумән тарихны кая алып бара?— шагыйрьне шундый сорау борчый, «Без» шигыренә тагын да конкретрак итеп:

**Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...**
**Дәригъ, мәхзүн[2] күңел, без дә бетәбез,**

— диелә. Шулай итеп, искә алынган шигырьләрдән чыга торган төп идея — тарих барышы илләр, халыклар һәм кешеләр язмышын рәхимсезлек белән хәл итә — мәңгелек комы белән күмә диюдән гыйбарәт. Мондый караш, әлбәттә, тарихи барышка өметсезлек белдерә, язмышка каршы тору мөмкин түгеллеген раслый. Анда фатализм, язмыш, тәкъдир фәлсәфәсе өстенлек итә.

Әлбәттә, Дәрдмәнд пессимизмының аеруча кискен булып чагылышында Беренче рус революциясеннән соңгы реакция чынбарлыгының ролен дә истә тотарга кирәк. Аның әнә шулай артык куе төстә гәүдәләнешенә Россияне буйдан-буйга баскан, буган, аскан-кискән Столыпин вәхшәте үзенең билгеле тәэсирен ясамый калмагандыр. Шуңа күрә Дәрдмәнд фәлсәфәсендәге, аның тарихка мөнәсәбәтендәге өметсезлек гомумән реакция елларындагы татар әдәбиятында сизелгән төшенкелек настроениеләре белән уртак күренеш иде. Әмма Дәрдмәнд пессимизмының эчтәлеген реакция елларына мөнәсәбәт белән генә, шул җирлеккә кайтарып калдыру белән генә чикләп булмый. Тулаем алганда, бу фәлсәфәнең асыл мәгънәсе — аерым милләт, кеше, ил язмышы гына түгел, ә бөтен кешелек язмышы тарихның мәрхәмәтсез стихиясе алдында көчсез булуын күрсәтергә теләгән космик пессимизмга кайтып кала. Бу пессимизмның төп мәгънәсе — бөтен дөньяның һәм шуның белән бергә җәмгыятьнең бер һәлакәттән икенчесенә котылгысыз рәвештә барырга тиешлеге хак дип өметсезлеккә бирелүдә. Дәрдмәндкә карата үз вакытында Г. Сәгъди бу фикерне түбәндәгечә формалаштырган иде: «... Ул фикерхисләренә, моң-зарларына гомумилек, җиһанилек сыйфатын бирергә тырыша. Гүя ул үзе өчен түгел, «милләт», «ил» һәм аннан да аша китеп, гүя ул бөтен кешелек хәяты өчен, бөтен илләрнең, бөтен кешелекнең юк булып китүе өчен әрнүче булып күренә. Аның өмидсезлеге дә — гүя бөтен җиһанның, бөтен «илнең» өмидсезлеге»[3]. Шуңа күрә дә шагыйрь үзенең бүгенге тыныч, матур тормышыннан, рәхәтеннән күпме генә канәгать һәм материаль өстенлегеннән никадәр генә риза булмасын, ахыр чиктә ул үзе дә, бөтен дөнья, галәм, тарихның фаҗигале барышы белән чагыштырганда, бик мескен, кызганыч җан иясе булып калуын икърар итәргә мәҗбүр:

[1] Нан — икмәк, ризык.
[2] Дәригъ, мәхзүн — аяныч, кайгылы.
[3] Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926 ел, 232 бит.

Зэгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан,
Түгел бал корты мин чагып елаткан.

Галәмгә традицион-фаталистик фәлсәфә ноктасыннан караучылар гадәттә кешене бик кечерәйтеп күрсәтәләр. Көнчыгыш әдәбиятында да бу караш гасырлардан гасырларгача кабатлана килде. Дәрдмәнднең дә кешене кырмыскага чагыштыруында шул рухтагы космизм бар: кешенең шундый дәрәҗәгә төшерелүе, әлбәттә, галәмнең зурлыгына, очсыз-кырыйсызлыгына һәм һичбер көчкә буйсынмас булуына нисбәтән күз алдына китерелә. «Галәм һәм кеше» фәлсәфәсе бер Дәрдмәнднеке генә түгел, башка татар әдипләренең дә игътибарын биләде. Мәсәлән, М. Гафуриның: «Чиге юк бу галәмнән бер кисәкмен», — дию ендә шул фәлсәфә чагылды («Кояш баеганда», 1909). Шул рәвешчә, татар поэзиясендә космик лиризм урын алды.

Дәрдмәнднең әле генә искә алынган шигырендә шагыйрь шәхесенең реаль тормыштагы хәле белән аның рухи дөньясы кичерешләре, фәлсәфәсе арасында гаять тирән чоңгыл, аралык барлыкка килә. Әнә шул чоңгылда инде котылгысыз бер каршылык та ятса кирәк. Тукай, Гафури, Рәмиевләрнең лирик геройлары белән чагыштырганда, Дәрдмәнд героеның тавышы һәм горурлыгы шактый тонык булып калачак. Беренче төркем шагыйрьләр тудырган лирик геройларның барысына да:

Баш имә, зур син, — бу әдна[1] җанлылар дөньясына:
Падишаһ син! бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа,

(Г. Тукай. «... гә (ядкяр)», 1908)

— кебек горурлык, ягъни кешенең явыз чынбарлыкка баш имичә яшәү һәм иҗат итү хисе уртак. Димәк, алар кеше горурлыгын һәм язмышын яклап көрәшкә күтәрелгән трагик герой образын пьедесталга бастырдылар. Мәсәлән, С. Рәмиев герое ләгънәтләнгән дөнья белән котылгысыз конфликтка керә, әмма ул үзен һич тә язмыш колы итеп санамый, кечкенә бер җан иясе дәрәҗәсенә дә төшми, ә үзендә һичбер явызлыкка буйсынмас демонизм сизә. Ул кызганыч түгел, ә үз идеалы, үз азатлыгы өчен көрәш юлында һәлак булудан курыкмаган актив трагик герой. Беренчел романтик сыйфаты да аның менә шунда. Ә Дәрдмәнд лирик герое — мелодраматик герой. Аңарда явызлык белән бәрелештә туган трагизм юк. Ул пассив, ягъни язмыш каршында баш ияргә өнди. Шуңа күрә дә шәхес трагедиясенә шагыйрьнең югары бәя бирүе хакында сөйләү өчен Дәрдмәнд поэзиясеннән җирлек табу шактый читен. Тукай яки С. Рәмиев лирикасында аерым шәхес трагедиясе турында сөйләргә мөмкин. Аларның икесендә дә трагик настроение Беренче рус революциясе җиңелгәннән соңгы авыр иҗтимагый-политик шартларны газаплы кичерү белән бәйләнгән иде. Бу яктан алар икесе дә билгеле тарихи чор трагедиясен кичергән конкрет шәхес буларак алга басалар, шул яктан бер-берсенә якын торалар. Чор трагедиясен поэтик шәхес, лирик герой нинди позициядән аңлады һәм кичерде? — дигән сорауны куйганда инде, Тукай белән Рәмиев арасындагы аерма турында сөйләү таләп ителәчәк, әлбәттә. Кыскача гына әйткәндә, беренче шагыйрьдә чынбарлыкны аңлау һәм хис итүнең тарихи-объектив колачы киң, иҗтимагый пафосы көчле булса, икенчесендә исә чынбарлыкка субъектив мөнәсәбәт өстенлек ала. Әмма ике очракта да, әйтелгәнчә, шәхес трагизмының конкрет тарихи шартлар һәм сәбәпләр белән бәйләнеше ачык иде. Ә Дәрдмәндкә карата мондый фикер бик абстракт һәм дәлилсез булып кына калачак. Әйе, кешелек кичергән һәм кичерәчәк тарихи процессның котылгысыз икәнлеген ул аңлый. Әмма аны тоташ фаҗига һәм кешедә аңа каршы торырлык көч юк дип карый.

## 2

Тормыш һәм тарих серләренең фатальлеге, халыктан, кешедән өстен һәм көчле булуы турындагы фәлсәфәнең тамырлары бик борынгы заманнарга китә. Дәрдмәнд,

[1] Әдна — түбән.

бер яктан, Көнчыгыш әдәбиятларында күп гасырлар буе кабатланып килгән традицион фәлсәфәгә теләктәшлек итә:

> **Галәм өчен, әйтче, кеше, син кем генә!**
> **Синең яшәү — барлы-юклы төтен генә.**
> **Үлем һаман упкын әле, төпсез упкын,**
> **Төштең киттең һәм мәңгегә беттең генә[1],**
>
> **(Х. Туфан тәрҗемәсе)**

— дигән Урта гасыр Көнчыгышының даһи шагыйре Гөмәр Хәйям (1048—1132), һәм мондый фәлсәфә бөтен дөнья әдәбиятларында урын алган. XVIII йөз рус поэзиясе вәкиле Херасков кына түгел, аннан соң, ягъни XIX йөздә, инде Герцен, Белинский, Чернышевский кебек сугышчан материалист әдипләрнең, философларның эшчәнлекләре киң колач алган заманда, Фет һәм Тютчев кебек күренекле шагыйрьләр шул рухтагы фатализмны, язмыш фәлсәфәсен тагын да нечкәртелгән төстә җырладылар. Алар кешенең табигать һәм тарих законнары каршында көчсезлеген әйтергә теләде. Гомумән романтик әдәбиятта һәм аның геройлары тормышында язмыш зур роль уйный торган серле көч итеп каралды. Язмыш образы Лермонтов поэзиясенә дә чит түгел. XX йөз башы татар поэзиясендә дә аның тирән эзләре калган.

Мондый фактларны истә тотканда, Дәрдмәнд җырлаган традицион-фәлсәфи идеяләр аны Көнбатыш әдәбияты, бу очракта, конкретрак алганда, Фет һәм Тютчев белән билгеле күләмдә якын куеп, чагыштырып фикер йөртергә дә мөмкинлек бирә. Дәрдмәнд белән, мәсәлән, Тютчев арасында дөньяны һәм тарихны аңлау ноктасыннан зур якынлык бар. Тютчев иҗатында «гүяки тарихи акланышы булмаган котылгысызлык, язмыш, илаһи кодрәт төшенчәләре беренче планга этәрелде»[2].

Тарихи фатализм концепциясе — XX йөз башында да шактый таралган күренешләрнең берсе. Шуңа күрә Дәрдмәндтә аның чагылышын тик борынгы, традицион бер идеяне кабат тергезү, яңарту дип кенә карау тулы булмас. Тарихи язмышның котылгысызлыгына ышану, әйтелгәнчә, романтизм әдәбиятында еш очрый. Бу идеяне символистлар да үзләренчә дәвам иттерделәр, аңа үз фәлсәфәләрен салдылар. Мәсәлән, Вл. Соловьев бөтен дөнья тарихының соңы турындагы теорияне тәкъдим итте. Бу төр пессимизм астында тарихны яңарта торган революцион көчләрнең килүен аңламау яки күрмәү генә түгел, бәлки инкяр итү ята иде. Символизм идеологлары трактовкасында тарихи язмыш фатализм концепциясе мистик, реакцион эчтәлек алды.

Шул ук вакытта символизмның А. Блок шикелле вәкилләре, тарихи катастрофа, һәлакәт теориясен һәм пессимизмын кабул итмичә, кешелек тарихының яңадан корылачагына, моны түбәннән күтәрелүче көчләр тормышка ашырачагына һәм дөнья тарихи процессының гармониясе булуына өмет белдерделәр. Блок фикеренчә, «тарих көчләрендә фаталь характер бар. Тарихны тыеп булмый. Тарих кешелекне яңа эпохага китереп җиткерде. Кеше инде аңа каршы торырлык хәлдә түгел...»[3].

Дәрдмәнднең дә тарихи котылгысызлык концепциясендә Блок белән билгеле төстә аваздашлык, якынлык шиксез кебек. Аңарда да тарихның барышын, үзгәрешен, яңарышын инкяр итү түгел, ә зарури, котылгысыз дип ышану сизелә. Аның бигрәк тә табигать лирикасыннан шундый тойгы тибеп тора. Блоктагы кебек ук, Дәрдмәндтә дә табигать дөньясындагы гармонияне табарга омтылыш бар. Бу тенденция исә шагыйрьнең чынбарлыкка мөнәсәбәтендә оптимистик башлангычка да юл калдыра.

Чыннан да, егерменче еллар азагында ук инде Г. Нигъмәти кебек тәнкыйтьчеләр Дәрдмәндкә гел өметсезлек кенә хас булмавын, аңарда үзенчәлекле оптимизм барлыгын да күрсәтеп киткәннәр иде: «Өмитсезлек дөньяга карашы Дәрдмәнд иҗатында беренче урынны алган мотив түгел»[4], — дип расларга батырчылык итте

---

[1] «Көнчыгыш шагыйрьләре», җыентык. Казан, 1959 ел, 171—172 битләр.
[2] Л. К. Долгополов Тютчев и Блок. — «Русская литература», 1967, № 2, с. 66.
[3] Л. К. Долгополов. Поэмы Блока и русская поэма конца XIX — начала XX веков. М.-Л., 1964, ст. 110.
[4] Дәрдмәнд әсәрләре. Казан, 1929 ел, 22 бит.

Г. Нигъмәти һәм шушы фикеренә дәлил итеп «Хәят» шигырен китерде. Тәнкыйтьче бу мисалда шагыйрьнең тормышка «зур мактаулар яудыруын, аны мактавын» һәм «тибеп, ашкынып торган оптимизмын» күрде. Әмма озак еллар өстенлек иткән фикер Дәрдмәнд поэзиясен тоташ пессимизм итеп бәяләргә тырышудан гыйбарәт булды. Соңгы елларда исә Дәрдмәнд дөньяга карашының ике ягын — аның пессимизмын да, оптимизмын да күрергә, боларның нидән гыйбарәт икәнлеген аерып аңлатырга омтылыш алга чыкты[1].

Дәрдмәнднең дөньяга карашында урын алган ике капма-каршы башлангычның — пессимизм һәм оптимизмның барлыгына, аларның янәшә, бергә яшәвенә игътибар итү нигезсез булмаса кирәк. Әмма бу ике башлангычның, идея-философик тенденцияләрнең бер-берсе белән сыешуын ничек аңларга? Әйе, Дәрдмәнд— тарихи барышка фәлсәфи карашы белән пессимист, әмма шагыйрь-художник буларак, чынбарлыкка мөнәсәбәтендә, аны хис итүендә шул фәлсәфә кысаларында гына бикләнеп кала алмый. Аның реаль чынбарлыкка эстетик, сәнгатьчә мөнәсәбәте субъектив-сыйнфый аңыннан көчлерәк һәм киңрәк.

Дәрдмәнд пессимистик фәлсәфәсенең бик борынгыдан килүен һәм бөтен дөньяга билгеле икәнлеген әйткән идек инде. Тагын да борынгыны искә төшереп, башлыча оптимист, көр күңелле шагыйрь буларак дан казанган һәм шул ук вакытта дөньяның фанилыгын, язмышның мәрхәмәтсезлеген җырлаган Гомәр Хәйямга мөрәҗәгать итик:

**От стрел, что мечет смерть, нам не найти щита:**
**И с нищими и с царем она равно крута.**
**Чтоб с наслажденьем жить, живи для наслажденья,**
**Все прочее — поверь! — одна лишь суета**[2]**.**

**(О. Румер тәрҗемәсе.)**

Әйе, Дәрдмәнд поэзиясендә дә әнә шундый ике яклы фәлсәфә — язмыш алдында барысы да көчсез, әмма шулай да яшәүнең тәмен, рәхәтен татып дөньядан китәргә кирәк дигән фәлсәфә әледән-әле лейтмотив булып сызылып бара.

**Ни гамь — бөлсәм, әгәр үлсәм — ни ваем,**
**Эчеп дуслык шәрабыннан исерсәм,**
**Булып дуслар белән берлектә даим**[3]**,**
**Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм,**

**(«Ни гамь бөлсәм...»)**

— ди шагыйрь һәм аңа икенче бер шигырендә («Нәсихәт») дөнья атын йөгәнләп, аңа атланып яшәү һөнәрен белергә, тапталып яшәмәскә чакыра. Әлбәттә, Г. Хәйям фәлсәфәсе белән Дәрдмәнд фәлсәфәсе арасына туры сызык куеп кына сүз алып барырга ярамый. Чөнки Дәрдмәнд фәлсәфәсенең иҗтимагый-тарихи сәбәпләре һәм идея-эстетик йөге, ихтыяҗы башка инде. Шагыйрь үз заманыннан аерылган хәлдә күктә асылынып тормый яки ал гөлләр, сөмбелләр арасында гына яшәми. Мәхәббәткә ул күпме генә мөкиббән китмәсен, мәҗнүннәр шикелле баш имәсен, барыбер аның да җирдән аерылгысыз булуын раслый һәм шуның белән традицион-идеаль мәхәббәтнең иллюзия, хыял икәнлеген күрсәтә:

**Йөреп, бер-бер карап чык һәр каберне,**
**Алып туфракны учка, иснә җирне:**
**Ни җирдә гыйшык вә сәүдәләр**[4] **исе бар,**
**Аның шул җирдә кабре... шунда ул яр!..**

**(«Хикаяи гыйшык», 1908)**

Дәрдмәнд оптимизмын гомумән яшәешкә, көндәлек тормышка мөнәсәбәт яки интим хисләр кысасында гына калдыру бу мәсьәләгә берьяклы карау булыр иде. Шагыйрьнең дөньяны танып-белүдәге фәлсәфи һәм эстетик концепциясе буларак, оптимизм идеясе аның киң мәгънәсендәге дөньяга һәм тарихка мөнәсәбәтен дә

---

[1] Нуруллин И. З. Путь к зрелости. Казань, 1971, с. 172.
[2] Омар Хайям. Четверостишия. Библиотека журнала «Азия и Африка сегодня», Вып. II, 1971, с. 6.
[3] Д а и м — һәр вакыт.
[4] С ә ү д ә — мәхәббәт, сөешү

сугара барды. Менә шул урында Дәрдмәнд борынгы Көнчыгыш поэзиясеннән килгән бик билгеле бер караштан — мәхәббәт һәм шәраб (мәй) дөньясында онытылып, кәеф-сафа чигеп яшәүне мактаудан югары күтәрелде дә инде. Нәкъ шул урында аның оптимизмы заманга, тарихка мөнәсәбәт шикелле әһәмиятле, актуаль, зур идеягә якын килде. Моның үзәгендә заманның тарихи логикасын, үткәннең һәм киләчәкнең табигый гәүдәләнеше булуын инкяр итүдән бигрәк, аны кабул итү тойгысы өскә чыкты.

Дәрдмәнд иҗатының традицияләр белән бәйләнешен һәм бигрәк тә оптимизмын карагандa, Көнчыгыш поэзиясендә шактый таралган пантеизм идеяләренең заман рухында яңартылып кабатлануын, дәвам иттерелүен дә истә тотарга кирәк. Пантеистик концепция XIX йөз ахырындагы рус әдәбиятында да урын алган иде. Түләем бу концепция «дөнья серен» сизәргә, ачарга, табигать белән кеше арасындагы бәйләнешне аңларга омтылды. Шушы мәгънәсендә ул Дәрдмәнд карашларында да үзенең эзен калдырды. Әгәр дә С. Рәмиевтә пантенизм кешене аллалаштырудан, шәхесне шул рухта идеаллаштырудан гыйбарәт булса, Дәрдмәндтә исә тарих белән табигать һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләр фатальләштерелде, серле итеп каралды. Аларның икесендә дә пантеистик идеяләр «югары көч — табигать — кеше» мөнәсәбәтләре яктылыгында төрле аспектта хәл ителде. Дәрдмәндтәге пантеизмның характерлы бер ягы табигатьне идеаллаштыруга, табигать культына барып тоташа: «Куй, табигать хөкмен итсен — шул тәкамел[1], шунда ямь»,— ди шагыйрь («И мөхәррир», 1908). Нәкъ шушы караштa инде аның тарихка, тормышка һәм кешегә оптимистик мөнәсәбәтенең сере дә яшеренгән шикелле. Монда сүз барысы да табигать законнарына таянып, шулар яктылыгында хөкем итәлергә тиешлеге хакында бара, һәм бу идея, ышаныч — романтизмның асылташларыннан берсе булып, антропологик концепция нигезендә ята. Чыннан да, Дәрдмәнд фәлсәфи карашларының сәнгатьчә конкрет эчтәлеге бигрәк тә табигать белән бәйләнештә үзенең нечкә лирик психологик сыйфатларын күрсәтте. Татар поэзиясендә гаять үзенчәлекле булып, аның иҗатында табигать лирикасы формалашты.

Табигать пейзажына шактый игътибар иткән шагыйрьләрнең күренеклесе тагын Тукай булды. Дәрдмәнд тә, Тукай да милли лириканың бу тематикасында бик характерлы ике тенденцияне — реалистик һәм романтик тенденцияләрне башлап җибәрделәр һәм нигезләделәр.

Дәрдмәнд табигать лирикасында күзгә ташланган нәрсә — аның дөньяга карашы үзәген билгеләгән фәлсәфәсе, бигрәк тә пантеистик идеяләре белән бәйләнешнең калку булуы. Аның лирик герое табигатьнең ниндидер серле көчкә ия булуы, табигать стихиясенең магик, могҗиз кодрәте турында сөйли. Шагыйрь игътибарын барыннан да бигрәк әнә шул тарта:

**Ятам кайчакларың моңлап,**
**Һаваның тынлыгын тыңлап,**
*Киләә өннәр колак чыңлап.*
**Диямен:**
**— Ни бу! Нидәндер бу!**
**Җавап урнында гөрлҙи су,**
**Тирәклек тирбәнә, шаулый[2].**

Тагын бер мисал:

**Исәрме җил тугай буйлап,**
**Елармы кыз моңын сөйләп,**
**Көләрме шатланып көйләп,**
**Агач, таш эчләре шаңрап,**
*Киләдер бер нида яңрап [2]!*

[1] **Тәкамел** — камилләшкән, җитлеккән, өлгергән.
[2] Дәрдмәнд. Сайланма әсәрләр. 1959 ел, 82 бит. Курсив безнеке. — Авт.
[3] Дәрдмәнд әсәрләре, 1929 ел, 96 бит. Курсив безнеке. — Авт.

Бу шигырьләрдә табигать аша гомумән дөнья һәм яшәү серен аңларга, хәтта ул сернең тавышын (өнен, нидасын) ишетергә теләү бар. Шагыйрь иҗатында әледән-әле яңгырап торган шундый мотивларның ачыграк чагылышына мисал итеп тагын да, мәсәлән, аның бер нәсереннән өзек китерик: «Үлән өстенә сузылып яттым. Җил шаулый, колак чыңлый иде. Бу искән җилләрдә кичкән елларның моңлы агышы беленә, үткән гомерләрнең хәсрәтле сагышы тоела иде. **Алда киләчәк адәмнәрнең тупарлашып баскан аяк тавышлары ишетелгәндәй була иде»**[1].

Китерелгән мисаллар Дәрдмәнднең фәлсәфи карашларына икенче бер мотивны өстиләр: шагыйрь табигать стихиясе эченнән икенче хакыйкать тавышын ишетә. Аннан «кичкән елларның моңлы агышы», «үткән гомерләрнең хәсрәтле сагышы» гына килми, ә алдагы тарихның да, киләчәк буыннарның да хәбәре, аяк тавышы яңгырагандай. Димәк, шагыйрь кешелек җәмгыятенең күчемлелек, дәвам итү зарурлыгын раслый, һәм бу раслауны аның пантеистик оптимизмыннан аерып булмый. Мондый оптимизм исә кешелек барышының закончалыгына, тарихның дәвамлылыгына, гомумән табигый үсешкә һәм яшәеш матурлыгына ышанычны Дәрдмәнднең тарихи пессимизмы һич тә кире какмавы турында сөйли. Менә шуннан инде аның поэзиясендә табигатьнең эчке рухи рәхәтен, ләззәтен һәм гүзәллеген сурәтләү осталыгы үсеп чыкты. Нәкъ шушы моментта шагыйрь романтик идеалының тагын бер сыйфаты ачылып китсә кирәк. Ул сыйфат романтизмның табигать культына һәм дөнья гармониясен белдергән музыкаль концепциягә барып тоташа.

Аеруча унынчы елларда, татар әдәбиятында романтизм шактый куәт алгач һәм үзенең милли үзәненә төшкәч, күп кенә әдипләр музыка, мәхәббәт һәм табигать культы белән мавыгу шаукымын кичерделәр. Гомумән алганда, бу культта яшәүнең рухи гармониясен эзләү сизелеп торды. Әмма Дәрдмәнд поэзиясендәге музыка культын туры мәгънәсендә музыканы илаһилаштырудан, аны дөньяның рухы, җаны итеп аңлаудан гыйбарәт дип карарга кирәкми. Аңарда ул, беренчедән, поэзияне, шигырь сәнгатен идеаллаштыруда һәм шуңа нисбәтән шигъри сүзнең нечкәлеген, нәфислеген, гүзәллеген табарга тырышуда күренә; икенчедән, дөнья, табигать гармониясен, аның фәлсәфи, рухи һәм шигъри серен ачарга теләү рәвешендә гәүдәләнә. Шулай итеп, музыка культы Дәрдмәндтә тотрыклы идея-эстетик концепциягә әверелде. Бу яктан ул рус романтик поэзиясендә шактый зур урын алган музыка культына якынайды.

«Музыка дөньяны иҗат итә» дигән Блок һәм моның белән «дөнья гармониясе» концепциясенең мәгънәсен әйтергә теләгән. Тютчевның табигатькә мөнәсәбәтендә музыка культы аерата көчле булуын күрсәтәләр. Аның поэзиясендә табигать күренешләре хәтта «җырлый» итеп сурәтләнә[2]. Табигать, мәхәббәт һәм җыр — өчесе бергә бер-берсеннән аерылмас, гармоник, шигъри, музыкаль дөнья тудыра дип караган Фет. Шагыйрь исә шул гармонияне, музыканы аңлау сәләтенә ия булырга тиеш. Болар һәммәсе романтик концепциядән гыйбарәт. һәм Дәрдмәнднең дә музыка культын шул мәгънәдәрәк аңлау дөрес булыр.

Аның поэзиядән башка җанрларга игътибар итмәве дә очраклы түгел, ягъни ул барыннан да бигрәк шигырь дөньясында үзенә тирән канәгатьлек, ләззәт һәм матурлык таба. Монда ул сайланма тема һәм мотивларны җырлавы белән дә аерылып тора, ягъни теләсә нинди тема һәм мотивлар белән эш итми. Тютчев һәм Фет шикелле үк, ул да поэзиягә лаек булган һәм лаек булмаган объектлар бар дип карый. Бу караш шулай ук романтизмга хас. Ә реализм әдәбияты барлык күренешләр дә поэзиядә чагылырга мөмкин дип раслый.

Романтизм пейзажга күбесенчә эмоциональ һәм психологик буяуларны салырга омтылды. Табигать күренешләренә «җан пейзажы» («Пейзаж души»), рухи тональлек итеп карады. Әйтик, табигатьтәге давыл рухи давыл белән янәшә куелды, күк күкрәүдә, диңгез дулкыннарында һ. б. шундый күренешләрдә эчкә яшерен көч бар дип саналды. Дәрдмәндтә дә табигать лирикасын «җан пейзажы» итеп сурәтләү шактый сизелә. Һичшиксез, аның иҗатында табигать культы һәм дөнья гармониясе кебек идеяләр күп очракта психологик аспектта булып, шагыйрьнең тарихка, дөньяга,

---

[1] Шунда ук, 86 бит. Курсив безнеке. — Авт.
[2] Сб. «Мастерство русских классиков». М., 1964, с. 226.

кешегә булган төп фәлсәфи карашыннан аерылгысыз моң, сагыш, элегик настроениеләр белән сугарыла:

**Агышың, и агым су, туп-тулы зар,**
**Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар!..**

— дип эндәшә шагыйрь агым суга һәм үзенең моң-зарлары белән уртаклаша.

Туган-үскән җирне, аның табигатен сөю, аннан аерылып яшәүнең газабы, аны сагынуның ләззәте, анда гомер итүнең чын бәхет булуы кебек мотивлар Дәрдмәнд лирикасына бик характерлы. Ул мотивлар күп кенә очракларда туган ил табигатенең җил-яңгырларын, гөл-чәчәкләрен һәм гомумән аның җанга ягымлы бизәкләрен сурәтләү белән үрелә:

**Чыкты кояш, кызарып нурлар очты,**
**Бизәнде тау, бизәнде кыр, гөлләр үсте.**
**Һава тымык, шылт итми... үләннәр чык,**
**Җым-җымылдап уйныйдыр җирнең өсте.**

Менә шул дүртьюллыкта табигать сурәтләренең гаять бай бизәкләре һәм төрле күренешләре күз алдына бастырылган, аларның күп сыйдырышлы панорамасы тасвир ителгән. Г. Нигъмәти әйткәнчә, шагыйрь «аз сүз, кыска җөмләләр белән бай картина бирергә тырыша».[1] Дәрдмәнд лирик стилендә импрессионистик элементлар да шактый гына. Аның табигать лирикасында да шул рухтагы, эмоциональ-психологик күтәренкелек белән әйтелгән, бик үзенчәлекле, субъектив экспрессивлык белән өретүле сурәтләү еш очрый:

**Бу — ул матур, бу — ул күркәм,**
**Бу — ул,**
**Бу — ул хуш исле яз!**
**Бу — ул хуш исле таң җиле...**

Дәрдмәнд туры мәгънәсендә гражданлык поэзиясе вәкиле түгел, ә фәлсәфи-әхлакый поэзия традицияләрен дәвам иттерүче һәм яңартучы. Шушы яктан ул гаять дәрәҗәдә эзлеклелек һәм үзенчәлек күрсәтте. Дәрдмәнд поэзиясенең фәлсәфи-әхлакый характеры аңарда хикмәт традицияләренең тотрыклы булуын да таләп итте. Шул сәбәпле ул безнең поэзиядә традицион-афористик стильне дә нык саклаучылардан һәм үстерүчеләрдән булды.

Татар поэзиясендәге хикмәт традицияләренең ике чыганагын истә тотарга кирәк: аның берсе бик борынгы язма әдәби традицияләргә барып тоташа, икенчесе халык авыз иҗатыннан азыклана. Соңгысына мисал — бигрәк тә ике гасыр аралыгында Акмулла һәм Гафури кебек шагыйрьләр иҗатында казакъ фольклорыннан килә торган традицияләрнең мул чагылышы. Бу факт хикмәт жанрында шактый гына үзгәреш барлыкка килүе хакында да сөйләргә мөмкин. Әлбәттә, хикмәт традицияләренең ике чыганагы да бер-берсе белән теге яки бу төстә үзара бәйләнештә булды.

Дәрдмәндтәге хикмәт лирикасы исә югарыда күрсәтелгән тенденциядән шактый аерыла. Аңарда Көнчыгыш поэзиясенә хас хикмәт традицияләре тотрыклырак һәм рациональ башлангыч көчлерәк. Брюсов шикелле, Дәрдмәнд «акыл-хирыс» («мысль-страсть») концепциясенә күбрәк басым ясый. Аның шигырьләрендәге эмоциональлек, хисси башлангыч сурәтләрнең шигъри нечкәлеге, пөхтәлеге, символик, аллегорик һәм афористик рәсемлелек белән тудырыла. Шагыйрь үз фәлсәфи һәм әхлакый карашларын шул рухтагы үгет-нәсихәтләрен гаять нечкәртелгән сурәтләргә, символ-кинаяләргә, афоризмнарга яшереп бирү юлын сайлый. Аңарда хикмәтле сүз, акыл, әхлак үгете шәрә дидактик шигырь булып түгел, ә «ишарә пафосы» һәм «яшерелгән лирика» кебек традицион алымнар ярдәмендә бирелә. Бу алымнарның төрләре һәм диапазоннары Дәрдмәнд поэзиясендә байтак. Шул сәбәпле андагы хикмәт мотивлары да сурәтләрнең төрле структурасында гәүдәләнә. Аларны иң гади, туры формаларыннан алып бик тирән яшеренгән символик формаларына кадәр очратырга мөмкин:

[1] Дәрдмәнд әсәрләре, 32 бит.

Югарыга ташны аткан юләрләр
Үз аңкау башларын тишеп үләрләр.
Тишек тапсаң сиңа япкан ишеткән,
Үзеңнең ертык авызыңнан көләрләр.

(«Беренче апрельдә зыярәт портретын җибәргән дустыма», 1910)

Шагыйрь үзе үк, бу шигырен «Аталар сүзе» дип искәртүе белән, аның халык телендәге гыйбрәтле, хикмәтле сүзләрдән — афоризмнардан торуын әйткән. Бу мисалда билгеле мәкаль-әйтемнәрне нигез итеп алган һәм үгет-нәсихәтен бик туры итеп чагылдырган хикмәт поэзиясе үрнәген күрәбез. Шул рухта шагыйрь гаять дәрәҗәдә кыска, үткен, тәгәл һәм халыкчан булган шигъри афоризмнар-хикмәтләр иҗат итте:

Күңлемнең әзрәк кенә кинәсе бар,
Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.

Дәрдмәнд поэзиясендә бик тирәнгә, эчкә яшерелгән, ягъни символик, шартлы сурәтләр артында торган хикмәтле, гыйбрәтле фикер-киңәшләр аз түгел. Хәтта аларның кайберләрендәге символиканың нәрсәгә ишарә икәнлеген тәгәл белүе дә читенләшә (мәсәлән, «Яз чәчәге», «Җәй үтте» һ. б.). Мондый очракларда шагыйрь еш кына табигать сурәтләренә мөрәҗәгать итә һәм аларга яшерелгән символикага артык субъектив төсмер бирә.

* * *

Дәрдмәнднең шәхси һәм иҗади язмышында социалистик революциягә мөнәсәбәт — җитди мәсьәләләрнең берсе. Бу мөнәсәбәт шактый катлаулы һәм каршылыклы булды. Чөнки шагыйрьнең өстен сыйныфлар белән нык бәйләнештә булуы һәм халыктан ераклыгы Россия чынбарлыгын тамырыннан үзгәрткән тарихи борылышны аңа тиз арада гына аңларга мөмкинлек бирмәде. Революциягә аның беренче мөнәсәбәтен белдергән әсәрләреннән «Куанды ил...» дип башланган шигыре — әнә шул гаять каршылыклы һәм катлаулы настроениенең бер күрсәткече.

Шагыйрь, бер яктан, революциянең ил, халык өчен куаныч һәм тормыш түе икәнлеген күрә, — димәк, аның тарихи зарури хәл булуын икърар итә; әмма, икенче яктан, үзе яңа «тормыш туеның кияве» була алмавына, урыны кирәксез кешеләр арасында калганга үкенәчәген белдерә һәм шигырьнең азагын «йөз аклыгың өчен авызың йозаклы булсын» дип тәмамлый. Димәк, Дәрдмәнд, революциянең ил, халык куанычы кебек зур тарихи үзгәреш икәнлеген аңлаган хәлдә, үзенең аңа турыдан-туры хезмәт итәргә кыюлыгы, көче җитмәвен һәм шул сәбәпле битарафлык позициясендә калуын әйтергә тели. Шуңа күрә дә бу — революциягә дошманлык түгел, ә яңа тарихи шартларның мәгънәсен аңламауның бер драматик чагылышы иде. Шулай ук шагыйрьнең революцияне тарихи зарурлык, котылгысызлык дип аңлавы да көтелмәгән нәрсә булмады. Аның бу карашы — дөнья барышындагы, җәмгыять үсешендәге тарихи яңарышны, искенең юкка чыгып, үлеп, аңа алмашка яңаның килүен котылгысыз дип санаган фәлсәфи ышанычларының бер реаль гәүдәләнеше иде. Бу очракта да Дәрдмәнднең Блокка билгеле бер охшашлыгы бар шикелле: Блок дөнья музыкаль концепциясе аша революциянең тарихи зарурлык һәм пычрак чынбарлыкны сафландыра торган көч икәнлеген аңлауга килде һәм революция музыкасын тыңларга чакырды. Дәрдмәнднең дә пантеистик карашы дөнья гармониясен эзләүдән аерылгысыз иде. Ул да дөнья гармониясе тарихи катаклизм һәм һәлакәтләрдән азат була алмый дигән карашны алга сөрде. Шуның нәтиҗәсе буларак, аерым кешеләр һәм сыйныфлар теләсә-теләмәсә дә, үзгәрешләрнең революциянең котылгысыз икәнен аңлау мәҗбүрияте, ихтыяҗы икърар ителде. Дәрдмәнднең социалистик революциягә мөнәсәбәтендә әнә шундый мәҗбүрият, ихтыяҗ, һичшиксез өстенлек алды. Бу инде аның үз сыйныфыннан аерылу юлына басуы дигән сүз иде. Шуңа күрә Дәрдмәнд үз шәхси язмышын да үзенчә хәл итте. Ул революциядән качмады. Милли буржуазиянең күп кенә идеологлары совет

дошманнары белән бер лагерьга кереп, илен, халкын ташлаганда, шагыйрь үзенең туган-үскән җирендә калды һәм аңа мәхәббәтен җырлады:

**Әй, туган илнең һавасы,**
**Рәнҗемә, зинһар кутәр!**
**Рәнҗемә, зинһар кутәр!**

— дип гафу үтенүе бик тә гыйбрәтле иде.

Дәрдмәнд поэзиясендә туган ил тойгысы тирән драматизм белән сугарылып, үзенең лирик нечкәлеге, сагышлы моңы белән гәүдәләнеп калды. Бу нечкәлек халык поэзиясеннән килгән мотив һәм сурәтләрне искә төшерә:

**Тәгәрәп, уйнап**
**Буй үскән**
**Туган илем, исән бул!**
**Чәч кузгатып,**
**Җай искән**
**Таңгы җилем, исән бул!**

— шикелле юллар үзләре генә дә халык җырларына тоташкан аһәң һәм сурәтләрнең гаять тирәнгә үтеп керүләре, шагыйрь кичерешләренең тибешенә тәңгәл килүләре турында сөйләрлек дәлил, үрнәк булырлар. Шундый аһәң һәм сурәтләр арасында нечкә билле сөйгән кыз образының басып торуы туган илгә мәхәббәтне тагын да күркәмрәк итә, аның халыкчан гүзәллеген һәм җылылыгын көчәйтеп җибәрә.

Революциягә һәм ватанга мөнәсәбәт — яңа тарихи шартларда Дәрдмәнд иҗатының бик әһәмиятле мотивы булды. Бигрәк тә туган ил темасы аша шагыйрьнең яңа чынбарлыкны аңларга омтылышындагы кискен тирбәлешләр, каршылыклы уй-тойгылар шактый сизелеп калды:

**Ни газизрәк, бу Ватанмы!**
**Аһ, туган каумем[1] газиз...**
**(«Төрләнгән сулар...»)**

дигән сорау һәм аңа җавап шагыйрьне бик борчыды. Бәлки бу хәл Дәрдмәнднең драматик кичерешләрендә, тарихи барышка мөнәсәбәтендә һәм үзенең шәхси язмышына карата да кечкенә роль уйнамагандыр. «Ләкин, шагыйрьнең бәхетенә каршы, ватан һәм милләт рәвешендәге каршылык тирәнәюгә, трагик чишелешкә таба бармый».[2]

Чыннан да, Дәрдмәнд иҗатында ватан белән милләт арасындагы каршылыклы мөнәсәбәт мотивы буйдан-буйга сузылып килә диярлек. Октябрьдан соң да билгеле дәрәҗәдә аның шул рухтарак дәвам итүен кире кагып булмас. Әмма, шуның белән бергә, аның бу чорда инде тирәнәюен түгел, ә ватан, милләт һәм шагыйрь арасындагы уртаклык, якынлык, тугандашлык тойгыларының бер ноктагарак килүе, өскә чыгуы турында кыюрак итеп әйтергә мөмкин.

**Илдә бер дуст булмаса гәр,**
**Ил бөтен дошман түгел,**

— диде шагыйрь һәм үзе белән ил арасындагы якынлыкның һич тә өзелмәс изге тойгы булуын җырлады. Тагын да:

**Атам-анам йорты өчен**
**Булса мең җаным фида;**
**Туган-үскән җирем өчен**
**Соң тамчы каным фида,**

— дигән юлларын революциядән соң язылган дип санасак, Дәрдмәнднең яңа ватанга мөнәсәбәте никадәр тирән үзгәреш алуын күрербез, гуманистик һәм халыкчан эчтәлеге киң колач белән яңгыравын ишетербез.

---

[1] Кавем — халык, милләт мәгънәсендә.
[2] Н. Хисамов. Дәрдмәнд поэзиясендә туган ил мотивы. «Совет мәктәбе», 1969 ел, 2 сан, 28 бит.

# ГАБДУЛЛА ШАМУКОВКА 70 ЯШЬ



*РСФСРның һәм Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты, СССР Язучылар союзы члены, язучы, тәрҗемәче Габдулла Рухулла улы Шамуковка 70 яшь тулды.*

*Ул 1909 елның 11 декабрендә хәзерге Ульяновск өлкәсе Кече Кандал районы Әсән авылында туган.*

*Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрында зур, җаваплы рольләр башкарып, онытылмас характерлар тудырган (Н. Погодинның «Мылтыклы кеше» әсәрендә—В. И. Ленин, Ә. Фәйзинең «Тукай» драмасында — Тукай, Гогольнең «Ревизор»ында — Хлестаков кебек үзенчәлекле образларны гына искә төшерик!) Г. Шамуков әдәби иҗат белән дә күптәннән шөгыльләнә. Иң яратып язган жанры — мәсәлләр, балалар өчен әкият-пьесалар. Шулай ук аның театр сәнгате һәм әдәбият, шигырь төзелеше һәм тел мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре дә укучыга яхшы таныш. Арада өлкән әдип Нәкый Исәнбәт турындагы очеркы аеруча игьтибарга лаек.*

*Г. Шамуковның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә киң билгеле. Ул А. Островскийның «Котырган акчалар», Эсхилның «Богауланган Прометей», В. Шекспирның «Отелло», «Ромео һәм Джульетта», «Чамасына күрә чарасы» әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, милли театрыбыз репертуарын баетты. Бай сәхнә иҗаты тәҗрибәсен уртаклашып, Г. Шамуков озак еллар буе Казан театр училищесында һәм педагогия институтында лекцияләр укып, практик дәресләр алып барды.*

*Хөрмәтле әдипне һәм артистны зур бәйрәме белән укучыларыбыз исеменнән кайнар котлап, бу санда аның быел басылып чыккан сайланма китабына кергән яңа мәсәлләрен тәкъдим итәбез.*

## Габдулла Шамуков

# МӘСӘЛЛӘР

### Керпе белән Куян

— Чү, аппагым,
Шәм колагым!
Кая киттең чабып болай җан-фәрманга? —
Дип эндәшә Керпе дусты Ак Куянга.
Кая киттең чабып болай җан-фәрманга? —
— Ни бар анда?
— Бездә расход кыскартырга керештеләр:
Тикшерәләр юкны-барны;
Бөтен артык-портыкларны
Ыргытабыз кисеп диләр.
— Киссәләр соң?
Менә җүләр!
Син нигә дип пошынасың?
Нинди артык-портыгың бар,
Әйтче, зинһар?
Койрыгың да юк бит хәтта!
Юкка чапма,
Шом таратып тирә-якка.
— Кисәрләр дим тәпиләрне.
— Акыллымы син, җүләрме?
Гади исәп-хисапка да
Башың җитми мәллә, кода?
Артык тәпи юк ич синдә,
Дүртәү генә!
— Менә!
Санап торамыни алар?
Кисеп алгач, эзлә син, бар!

### Елан кырмыска оясында

Елан, һич көтмәгән җирдән,
Кырмыскалар оясына бәреп кергән.
Ә Кырмыска халкы бердәм:
Чакырылмаган бу кунакны күрү белән,
Кайный башлый бөтен иләү, зур казандай;
Елан, янган утка китереп ташлагандай
Әрнүенә чыдый алмый,
Боргалана,
Сыргалана,
Үрле-кырлы сикерә, ауный;
Ары омтыла, бире омтыла,
Җәһәннәмнән чыгып ычкынмакчы була;
Әмма ләкин булдыралмый,
Кырмыскалар һөҗүменнән арыналмый.

Зәһәрләнеп чагуы да,
Һәләкәтле агуы да
Бу сугышта ярдәм итми аңа һич тә.
Ахыр чиктә
Кычкыра ул сорап ярдәм
Урмандагы җәнлекләрдән:
— Коткарыгыз!.. Аһ!.. Каравыл!..
Зинһар өчен куймагыз юл
Җинаятькә, хаксызлыкка!
Бер дә юкка
Күрәм җәбер!..
— Хаклык кирәкмени хәзер? —
Ди Бал корты. — Ләкин син бел:
Җүләрләр юк, алданмаслар. Хаклык монда
Кем ягында —
Сизеп тора һәрбер күңел.
Күрәләр ич: Кырмыскалар синдә түгел,
Син Кырмыска оясында.

## Тәэсирле хат

Имеш, бер чак
Капыл гына
Калын урман башлыгына —
Аю картка килеп төшкән шундый бер хат:
«Сәлам сезгә, дигән, яшел киң тугайдан,
Күк томанга төренгән Ялантаудан.
Җәелеп яткан бүз яланнан...»
Аннан
Тагын шундый сүзләр язган:
«...Карурманның Сандугачы —
Бар галәмгә мәгълүм җырчы,
Безнең якка килеп чыгып әллә кайдан,
Киң тугайны, Ялантауны, елга, күлне
Бар җәнлекләр, кош-кортларны — бөтен илне
Гаҗәеп җыры белән итте хәйран,
Сихерләде һәр күңелне.
Җырының тәэсире шундый көчле,
Тыңлагач та сихри моңын,
Бу дөньяда яшәүнең бар матурлыгын
Тирән итеп аңлагандай булдык төсле.
Рәхмәт сезгә,
Шундый җырчы биргән өчен илебезгә!..»
Шундый җылы хат укыгач,
Аю—түрә тирән уйга батты чынлап:
— Кара син, ә! Болай булгач,
Чакыртып үзем дә бер карыйм тыңлап.

*Вәли ага Хангилдин — татар тел белеменең күренекле галиме иде. Аның «Татар теле грамматикасы» тел фәне өлкәсендә фундаменталь хезмәт булып тора. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр армый-талмый эшләп килде. Түбәндә тәкъдим ителгән мәкалә аның соңгы хезмәтләреннән берсе.*

*РЕДАКЦИЯДӘН.*

**Вәли Хангилдин**

# ӘДӘБИ ТЕЛЕБЕЗНЕ ТАГЫН ДА КАМИЛЛӘШТЕРИК

Тел үзенең иҗтимагый функциясе белән кешеләрнең аңлашу, аралашу коралы булып танылган. Ләкин ул гади аңлашу коралы гына түгел, бәлки бер үк вакытта кешеләрнең рухи эшчәнлекләрен — эчке тойгыларын, хисләрен, кичерешләрен һәм аң-белемнәрен тәгъбирле торган иҗат коралы да. Һәрбер аерым телдә тудырылган халык әдәбияты, язма әдәбият һ. б. әнә шул коралның эшчәнлек җимеше бит.

Язма әдәбият һәм телнең шуны барлыкка китерә торган нык эшкәртелгән төре — әдәби тел җәмгыять тормышында аеруча әһәмиятле роль уйный. Аның төзелеше дә гади сөйләмнекенә караганда күп бай һәм катлаулы. Җәмгыять бер халдә генә тормый, үзгәрә. Шул процесста әдәби тел дә, әлбәттә, үсә, камилләшә барырга тиеш. Моның өчен әдәби телнең өзлексез актив кулланылуы зарур.

Татар әдәби теленең дә илебездәге бүтән әдәби телләр шикелле үсәргә, яхшырырга һәм көчәергә омтылышы һәм эчке мөмкинлекләре бар. Әмма моны тормышка ашыру өчен кулланучыларның шул кадерле коралга сак, кайгыртучан мөнәсәбәттә булуы кирәк.

Әдәби телнең кулланылу колачы да, төзелеше дә бер халдә генә тормый, даими үзгәреш кичерә, бу — тарихи күренеш. Үзгәрешләр үзләренең күләм һәм темплары ягыннан бик төрле. Алар милли телнең хуҗасы, иҗатчысы булган тел коллективы яшәгән һәм яши торган җәмгыятьтә социаль-политик алмашынулар булганда шактый зураялар, күзгә аеруча кискен һәм ачык ташланалар. Озынрак гомерле әдәби телләрнең тарихында моңа да мисаллар байтак.

Татар әдәби теле дә — озын гомерле телләрнең берсе. Аның хуҗасының, соңгы өч-дүрт гасыр буена «татар» исеме белән аталып йөртелә торган халыкның, милли-мәдәни яшәеше, культурасы тарихка мең елга якын вакыт буена билгеле.

Татар әдәби теле дә үз гомерендә бик күп үзгәрешләргә дучар булган. Шул нигездә ул иң элек ике зур дәвергә аерыла: борынгы татар әдәби теле, хәзерге татар әдәби теле. Хәзерге татар әдәби теленең үзенең дә ике варианты формалашкан: октябрьгача һәм совет чорындагы хәзерге татар әдәби теле.

Хәзерге татар әдәби теленең ике варианты арасында күп кенә уртаклыклар бар. Ләкин практик көчләре буенча болар бер-береннән шактый аерыла. Октябрьга чаклы яшәгән вариантының практик көче зур түгел. Чөнки ул чакта бу вариант әле төзелеше буенча формалашу дәверен — балалык һәм үсмер елларын гына кичерә иде. Кулланылу, гамәлгә ашырылу колачы ягыннан да ул чакта әле моңа киң җәелерлек экономик һәм социаль-политик шартлар юк иде. Шунлыктан бу вариант татар халкының бер өлешенә генә хезмәт күрсәтте, нигездә өстен

катламның дин, мәгариф, әдәбият, матбугат һәм культура өлкәләрендәге ихтыяҗларын аз-маз канәгатьләндерү белән чикләнергә мәҗбүр булды. Бу елларда әле татар халкының зур күпчелеге әдәби телебездә уку-язу мөмкинлегеннән шактый дәрәҗәдә мәхрүм иде.

Хәзерге татар әдәби теленең практик көче аның икенче варианты йөзендә генә җитлекте, чөнки бу вариант совет чорында формалашты, шунда үсте. Моңа кирәкле уңай экономик һәм социаль-политик шартларны Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм совет власте тудырды.

Татар әдәби теле практикасы совет чорында өзлексез киңәйде, ләкин ул процесс бер төрле үк колачта һәм тизлектә бармады, үзенең көче буенча ике зур чорга — 1921—1941 еллар һәм шуннан соңгы дәвергә бүленде.

Беренче чор Татарстан АССР төзелгәннән соң республикада татар телен гамәлгә ашыру турында Татарстан хөкүмәтенең 1921 елдагы махсус декреты игълан ителү көненнән башлана. Бу — татар телен республика күләмендә киң колач белән җәелдерүне законлаштырган беренче зур тарихи документ була. Шуннан соң республикадагы барлык учреждениеләрдә, оешмаларда һәм көнкүрештә, рус теле белән бер үк хокукта, татар теле дә кулланышка кереп китте. Бу — искиткеч зур тарихи вакыйга булды.

Карарны үтәүгә җитәкчелек итү өчен махсус оешма — «Татар телен гамәлгә ашыру» комиссиясе төзелде һәм республика тормышының барлык тармакларында: совет төзелеше, мәгариф, әдәбият, вакытлы матбугат, культура, фән, һ. б. өлкәләрдә егерме ел буена гаять олы, җитди һәм нәтиҗәле эшләр башкарылды.

Билгеле булганча, патша Россиясендә татар халкы дәүләт төзелеше эшләренә үз теле белән бөтенләй катнаштырылмады. Ул чорда дәүләт аппаратындагы һәм җәмәгать оешмаларындагы рәсми эшләр, гомумән, рус телендә генә йөртелде, эш кәгазьләре русча гына язылып торган иде. Шуңа күрә ул чорда дәүләт төзелешендәге рәсми эшләрне татар телендә йөртү осталыгына ия, эш кәгазьләрен татарча яза алырлык кешеләр бөтенләй хәзерләнмәгән иде. Укый-яза белмәүчеләр дә анда әле бик зур процент тәшкил итте.

Шунлыктан, ТАССР төзелеп, республикабызда татар телен гамәлгә ашыру мәсьәләсе планга куелу белән алга иң элек гаять зур ике проблема килеп басты: 1) татарларның укый-яза белмәүләрен бетерү, 2) татар телен киң күләмдә гамәлгә ашырырлык кадрлар булдыру.

Татар халкын укырга-язарга өйрәтү иң элек гарәп язуында, аннары латин графикасы нигезендә — яңалифчә, өченче тапкыр рус графикасы нигезендәге язуда үткәрелде. Татар телен киң күләмдә гамәлгә ашыру өчен исә, хөкүмәт, шул эшкә яраклы булган хәтле хезмәткәрләрне файдалану өстенә, төрле курслар һәм мәктәпләр оештыру юллары белән, берничә ел буена яңа кадрлар әзерләде. Шул кадрларның эшчәнлеге белән, күп тә үтмәстән, учреждениеләребездә, җәмәгать оешмаларында һәртөрле рәсми эшләр һәм сөйләшү-аңлашулар татар телендә дә практикага керде, эш кәгазьләрен һәр ике телдә — русча һәм татарча язу эше киң җәелде, берничә ел үтүгә, ул хәтта гадәти күренешкә әверелде. Вывеска, реклама, игълан, афиша һ. б. ике телдә языла башлады, татар телендә баса торган язу машинкалары чыгарылды, татар машинистканары әзерләнде. Кыскасы, татар теле республикабызның барлык төбәк һәм почмакларында рус теле белән чын-чыннан бертигез дәрәҗәдә кулланылды.

Татар халкының мәктәпкәчә тәрбия учакларында һәм мәктәпләрендә барлык оештыру, җитәкчелек һәм укыту эшләре гел татар телендә барды. Шул ук вакытта аларда рус теле укытуга зур урын бирелгән иде. Татар мәктәпләре өчен программалар, дәреслек һәм ярдәмлекләр һәрбер предметтан татар телендә төзеделәр, язылдылар һәм рус теленнән татарчага тәрҗемә ителделәр. Рус теле буенча исә татар мәктәпләренә яраклаштырылган дәреслекләр әзерләнде.

Шулай итеп, патша Россиясе шартларында кимсетелгән, кыерсытылган татар теле совет власте шартларында мәгариф системасының барлык баскычларында төрле фәннәр буенча киң белем алу коралына әверелде. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның «...дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы» дигән сүзләре дә нәкъ менә шушы чорда гына тулысынча раслану тапты.

Октябрьга чаклы культура тармагында татар әдәби теленең кулланылуы бик чикле булды. Ул чакта без аны сәхнә әдәбиятын уку һәм кайбер зур шәһәрләрдә генә булгалаган төрле театр һәм әдәбият кичәләрен, концертларын тамаша иткәләү юлы белән генә ишеткәли идек. Татар теленең бу юнәлештә киң колач белән гамәлгә ашырылуын да без фәкать совет власте чорында, аеруча Татарстан республикасы төзелгәннән соң гына күрдек.

Бу чорда ана телебез сәнгатьнең барлык тармакларына үтеп керде. Республикабызда дәүләт театрлары һәм филармония ачылып, сәхнә кадрлары әзерләү тәртипкә салынды. Район үзәкләрендә үзешчән театрлар, авылларыбызда исә драмтүгәрәкләр оештырылып, сәхнә эшләре җәелдерелде. Радио тапшырулары һәм китапханәләр аркылы да күп кенә эшләр башкарылды. Татар телендә матбугат бастыру, спектакльләр кую, ана телен укыту, дәүләт аппаратында куллану һ. б. халкыбыз күпләп республика һәм өлкәләрдә да гадәти күренешкә әйләнде.

Латин һәм рус графикаларындагы алфавитларны төзү, шуларның орфографияләрен кагыйдәләштерү барышында татар теленең эчке төзелеше дә байтак тикшерелде: аның фонетик, лексик һәм мор-

фологик үзенчәлекләре тагын да ачыкланды. Әдәби тел практикабыз төзелешен аерым өйрәнү эшләре дә көчәйде: норматив әдәбият — дәреслекләр, һәртөрле сүзлекләр, кагыйдәлек һәм белешмәлекләр күпләп нәшер ителде. Татар әдәби теле практикасының теоретик нигезләрен яктырткан хезмәтләр дә пәйда булды. Мәсәлән, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Нугайбәк, Ф. Сәйфи, Г. Сәйфиләрнең язу, орфография, лексикография мәсьәләләре турындагы әсәрләре; Җ. Вәлидинең фәнни нигездәге грамматикасы, аңлатмалы сүзлеге, Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» исемле фәнни хезмәте һ. б. басылып таралды. Әдәби тел күп кенә практик һәм фәнни ярдәмлекләр белән тәэмин ителде.

Шул рәвешчә, бөтен колачы белән киң күләмдә кулланылу, гамәлгә ашырылу процессында бу аралыкта әдәби тел практикабызның төзелеше бик нык эшләнде, нигездә яңача нормалашты; нәтиҗәдә аның мөмкинлекләре артты, практик көче зурайды.

Бөек Ватан сугышыннан соң татар әдәби теленең төзелешен теоретик өйрәнү эше тагы да көчәйде. СССР Фәннәр академиясе сафына кергәннән соң Татарстан тел, әдәбият һәм тарих институты татар телен фәнни өйрәнүне шактый киңәйтте һәм тирәнәйтте. Әдәби телебезнең лексик, фонетик, грамматик, стилистик һәм график-орфографик төзелешен фәнни-тарихи нигездә яктырткан әдәбият булдырды. Әдәби тел төзелешенең күп мәсьәләләре яңача ачыкланды, анықланды, кайбер проблемалар да чишелде. Шулар арасында әдәби тел практикабызны яхшыртуга турыдан-туры юнәлтелгәннәре дә аз булмады. Мәсәлән, фәннең берничә төрле тармагы буенча атама сүзлекләре төзелеп нәшер ителде, фәнни-практик ярдәмлекләр чыгарылды.

Телнең әдәби төре зур игътибарга һәм аңлы тәрбиягә аеруча мохтаҗ, чөнки куллапылу процессында ул, бер яктан, стихия юлы белән бара торган сөйләү теле һәм иске әдәби тел чолганышында яшәсә; икенче яктан, ул чит телләр белән дә азмы-күпме даими бәйләнештә яши. Шуңа күрә телнең әдәби төре ике яктан уңай һәм тискәре йогынтылар кичерә. Аннары әдәби тел тормыш таләбе буенча өзлексез үсә; лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик төзелеш якларыннан һәртөрле яңалыклар белән тулылана, катлаулана, һәм шул ук вакытта, ул искергән тел элементларыннан арына да бара.

Әдәби телнең төзелү процессында бик нык күздә тотылырга тиешле тагын бер төп нәрсә — аны тәзүче һәм тәрбияләүче кешеләрнең, кадрларның һәрьяктан төрлелеге. Алар арасында бер үк телнең төрле диалектлары, сөйләшләре һәм башка телләр, хәтта чит телләр белән тыгыз бәйләнештәге кешеләр: тел төзелеше буенча практик һәм теоретик хәзерлекләре төрле дәрәҗәдә булган, социаль һәм профессиональ төркемнәре ягыннан аерыла торган кешеләр һ. б. бар. Әдәби тел төзелеше боларның да уңай һәм тискәре йогынтыларыннан корыч стеналар белән коймаланып куелмаган бит!

Югарыда әйткәннәребез яшәештәге һәрбер әдәби телнең төзелү һәм үсү процесслары һәр вакыт уңыш белән бергә уңышсызлык куркынычлары арасында баруын ачык күрсәтә. Шуңа күрә туган теленә мәхәббәте суынмаган һәрбер коллектив һәм шуның аерым члены, белгечләр, сүз осталары ярдәмендә туган телнең әдәби төрен, аның төзелешен һәр вакыт үзенең игътибар үзәгендә тоткан һәм тота: аны саклау, көчәйтү, яхшырту юлында кирәкле барлык чараларны өзмәстән дәвам иттерә, аны чын-чынлап үз баласы итеп тәрбияли. Безнең күп милләтле илебездә шуны раслый торган фактлар бик күп.

Советлар Союзында күп кенә аерым милләтләрнең төп культуралары буенча ел саен әллә ни хәтле әдәбият чыгарыла, һәртөрле практик эшләр башкарыла. Кайбер республикалардагы тел һәм әдәбият институтларында хәтта махсус тел культурасы секторы бар.

Фактлар илебездәге аерым халыкларның үз әдәби телләренә олы ихтирам белән карауларын ачык күрсәтә. Яхшы аңлашыла, чөнки тел, аеруча аның әдәби төре — зур иҗат коралы бит. Материаль җитештерү эшләрендә корал, гомумән, иң төп һәм иң зур функцияне үти торган булса, тел-корал да рухи продукция җитештерүдә шундый ук функцияне үти. Шул рәвешчә, һәр ике тармакта продукциянең сан һәм сыйфат яклары, нигездә, коралга бәйле: «Корал эшли, ир мактана» дигән әйтем шуны ук раслый. Шуңа күрә дә, продукцияне үрчетү һәм яхшырту эшен, гадәттә, коралны көчәйтү һәм яхшыртудан башлыйлар. Рухи продукция өлкәсендә дә ул шулай булырга тиеш, чөнки эшкәртелмәгән чи тел белән югары сыйфатлы продукция тудырып булмый. Безнең чорда телнең әдәбилеген иң югары баскычка күтәрү эше тагын да актуальрәк.

Татар халкы үз телен шулай ук бик яратә, туган теленә аның мәхәббәте һәм ихтирамы гаять зур. Халкыбызның иң зур күпчелеге аны һәр вакыт сөеп кулланган, бүген дә шулай ук куллана. Шул кайнар тойгыларын ул үз шагыйрьләренең, әдип һәм галимнәренең иҗатларында да чагылдыра килгән: Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Дәрдмәнд, Һади Такташ, Хәсән Туфан һәм башкаларның татар теле турындагы шигырьләре; К. Насыйри, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Җ. Вәлиди, Г. Камал, Ф. Әмирхан, А. Ф. Богородицкий, Г. Шәрәф, Г. Бәширов, Ф. Сәйфи-Казанлыларның татар телен эшкәртү буенча практик һәм теоретик эшчәнлеге — һәммәсе дә әйтелгән фикерне раслаучы дәлилләр. Г. Тукайның «Туган тел» шигыре — халык телендә, халык авызында...

Билгеле, үзенең алга барышында әдәби тел практикабыз халыкка хезмәт күрсәтүен көчәйтү белән бергә, эчке төзелешен дә

нык үстерде һәм яхшырта барды. Бу процесс та төрле чолганышларда һәм күп төрле тел кадрларының катнашы һәм эшчәнлекләре белән дәвам итте. Бүген дә ул шулай бара. Шул шартларда уңышлар белән бергә кимчелекләрнең дә булгалап торулары бер дә гаҗәп түгел. Безнең әдәби телебез һәр вакыт тел коллективыбызның, аеруча тел-әдәбият, матбугат һәм нәшрият кадрларыбызның игътибар үзәгендә торырга тиеш иде. Бездә дә аның уңышларына кинәнү, соклану белән бергә, андагы җитешсезлек һәм кимчелекләрне — гомумән, авыруларны азайту, хәтта бетерү юлындагы чаралар өзлексез дәвам итәргә тиеш.

Кызганычка каршы, әдәби телебезнең кулланылу колачын, аның гамәлдәге төзелешен тагын да яхшырту, камилләштерү юлында, сөйләм культурабыз өлкәсендә без бу елларда бик аз һәм гаять әкрен эшлибез. Соңгы вакытларда татар тел культурасы темасына язылган мәкаләләрнең газета-журналларыбызда гадәттән тыш сирәк чыгарылулары, китап нәшриятыбыз тарафыннан чыгарылган продукция арасында татар тел культурасы мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләрнең аз очравы да шуны дәлилләп килә.

Танылган татар тел галиме Шиһаб Рамазанов: «Бездә телебезгә сизгер мөнәсәбәт, тел нечкәлекләрен сиземләү тойгылары тәрбияләнмәгән, үстерелмәгән, — дип язган иде. — Ачык әйтергә кирәк: тел белеме, тел культурасы, телебезгә мәхәббәт, практикабызда тел дисциплиналылыгы җитенкерәми бездә... Гомуми культура дәрәҗәбезне үстерү белән бергә, лингвистик белемебезне, төп культурабызны да үстерергә, телебезгә мәхәббәт һәм сизгер мөнәсәбәт тойгылары тәрбияләргә тиешбез». Дөрес һәм хаклы бәяләү, файдалы киңәш бу. Бу өлкәдә җиң сызганып эшләрлек өлгергән тел кадрлары да инде бездә җитәрлек.

Яшәргә һәм үсәргә сәләте булган һәрбер әдәби тел дөрес һәм җитди ясалган аңлы йогынтылар ярдәмендә төрле биеклеккә күтәрелә ала. Совет чорында татар әдәби теле үзенең эчке төзелеше буенча чорга лаеклы рәвештә шактый нормалашты. Тел төзелешенең барлык берәмлекләре (аваз, сүз, җөмлә һ. б.) һәм категорияләре (сүз төркемнәре, төркемчә һәм төрләре, җөмлә кисәкләре, синтаксик бәйләнеш һ. б.) буенча аның әдәби нормалары ачык билгеләнде, график-орфографик төзелеше бу чорда шулай ук яңа эзгә утырды. Шул әдәби нормаларның төп кагыйдәләре башлангыч һәм урта типлардагы татар мәктәпләре өчен языла һәм нәшер ителә торган татар теле дәреслекләрендә, ярдәмлек һәм кулланмаларда бирелгәннәр. Татар телендәге әдәбият, вакытлы матбугат — гомумән, нәшрият продукциясе, әнә шул әдәби нормалар нигезендә тудырылып, дөньяга чыгарыла. Шуңа күрә татар әдәби телендә каләм хезмәте белән шөгыльләнүче кешеләр ул нормаларны тулысынча һәм төгәл үзләштерергә мәҗбүрләр. Әдәби телебезне сөйләмдә кулланучы кешеләр дә (укытучы, лектор, оратор, режиссер, пропагандист, актер һ. б.) шул ук әдәби нормаларны нык өйрәнү, үзләштерү нигезендә генә бүгенге таләпләр дәрәҗәсенә күтәрелә алалар. Татар әдәби теленә теләсә кем бары тик шул нормаларны өйрәнү юлы белән генә ия була ала. Ул нормалар мәктәпләребездә һәм мәктәптән тыш дәреслекләрне, норматив кулланмаларны (кагыйдәләр, сүзлекләр һ. б.) һәм гомумән, әдәбиятны уку, тел-әдәбият өлкәсендәге культура чараларына актив катнашу процессларында гына тиешенчә үзләшәләр.

Шулар өстенә тагын, әдәби нормаларны аңлап үзләштерергә, татар әдәби теле төзелешенең практикадагы барышын һәм бүгенге торышын күзәтү, өйрәнүгә нигезләнеп язылган тәнкыйди әдәбиятны, тел культурасы темаларына язылган әсәрләрне уку бик файдалы.

Ләкин, бик кызганыч, татар әдәби теленең гамәлдәге төзелеше һәм нормалары турындагы кагыйдәлекләр бездә аз. Мәктәп дәреслекләреннән башка, татар әдәби теленең гамәлдәге норматив төзелешен тулырак, җентеклерәк яктырткан әдәбият безнең китап базарыбызда юк диярлек. Кайбер кагыйдәлекләр бөтенләй төзелми. Мәсәлән, татар теленең әдәби әйтелеш вариантларын кагыйдәләштергән китап барлыкка китерелмәгән. Хәтта көн саен, сәгать саен татар әдәби телен файдалана торган кадрларыбыз да (укытучы, лектор, актер, диктор һ. б.) әле татар теленең әдәби әйтелеш кагыйдәләрен (орфоэпиябезне) өйрәтә торган кулланмаларны күрү бәхетенә ирешә алганнары юк. Хәлбуки, инде безнең китап шкафларыбызда «Татар теленең орфоэпия кагыйдәләре», «Татар теленең орфоэпия сүзлеге» кебек исемнәрдәге китаплар булырга бик вакыт.

Татар әдәби теленең язу төзелешен кагыйдәләштергән ярдәмлекләребез шулай ук сан һәм сыйфат ягыннан канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә түгел. Бу өлкәдә һәрбер грамоталы кешенең өстәлендә торырга тиешле ике китапның «Орфография кагыйдәләре» белән «Орфография сүзлеге»нең инде исемнәре генә күз алдында. Болар үзләре исә китапханәләрдә һәм китап белән бик сак эш итә торган кайбер кешеләрнең кулларында гына сакланса саклана торгандыр, чөнки аларның төзелүенә һәм беренче тапкыр басылып таралуларына гына да инде утыз елдан артык вакыт узды. Яңа басмалары чыгарылганы юк.

Татар теленең гамәлдәге орфография кагыйдәләрендә күп кенә кимчелекләр бар. Бу фактны төзүчеләр үзләре дә икърар иткәннәр. Ш. Рамазанов бер мәкаләсендә: «...күп кенә очракларда орфография кагыйдәләренең үзендә дә кирәк хәтле ачыклык һәм төгәллек юк». «...Орфография кагыйдәләре»ндә (1941 елгы басма) һәм «Орфография сүзлеге»ндә (1941 ел) эшләнеп бетмәгән, ачыкланып җитмәгән моментларны тиешенчә ачыкландырып,

төгәлләндереп бирергә кирәк. Бу өлкәдә үз белгәнеңчәрәк эшләргә, орфографик трюклар ясарга урын калдырмаска кирәк», — дип язган.

Аңлашыла ки, шул ике ярдәмлекне төзүдә төпкә җигелеп эшләгән Ш. Рамазанов, аларның җитешсезлекләрен ачыктан-ачык әйтеп кенә калмаган, кимчелекләрне бетерергә кирәклекне искәрткән.

Совет чорында татар әдәби теленең сүзлек хәзинәсен тәртипкә китерү, баету һәм кагыйдәләштерү юлында күп кенә эшләр башкарылды: татар теленең тәрҗемәле гомуми сүзлекләре, төрле фәннәр һәм хуҗалык тармаклары буенча хосусый сүзлекләр нәшер ителде. Татар теленең диалектологик сүзлеге дә булдырылды. Бу сүзлек әдәби телнең сүз байлыгын диалекталь сүзләрдән сакларга һәм аны алардан арындырырга, шулай ук аларны, ягъни диалекталь сүзләрне стилистик максат белән әдәби тел төзелешендә аңлап файдаланырга ярдәм итә.

Ләкин әдәби телнең сүзлек хәзинәсен үстерүдә, төзекләндереп нормалаштыруда аңлатмалы сүзлекләр иң зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә әдәби тел практикабыз белән актив файдалана һәм шуның төзелеше өстендә эшли торган һәрбер кешенең китап шүрлегендә алар булырга тиеш[1].

Әдәби тел үсешенә атама сүзлекләр дә зур ярдәм итә. Болар бүген дә әле безгә кирәк. Шунлыктан аларны тулыландыру һәм яхшырту эше өзлексез дәвам иттерелергә тиеш. Бу — бер яктан. Икенчедән, шунысы да бар: атама сүзлекләрен эчләренә алган китап һәм китапчыклар бездә байтак, ләкин алар бик таркау, сыйфат ягыннан да бик төрле. Аларны тел төзелеше өчен игелеклерәк, куллану өчен уңайлырак хәлгә хәлгә китерергә кирәк. Моның өчен алар, тагын бер тапкыр җентекле тикшерелеп, төзәтелеп, тулы һәм бөтен бер сүзлек-белешмәлек рәвешенә куелырга тиеш.

Татар әдәби теленең уңышлы үсүе өчен, аның төзелешендәге төрлелекләрне һәм катлаулылыкларны җентекле рәвештә өйрәнү, иҗади нык үзләштерүебез шарт. Ләкин нәкъ менә шушы таләпне без тиешенчә эшкә ашыра алмыйбыз, әдәби телебезнең гамәлдәге гомуми төзелешен аның урнашкан, урнашу процессында торган һәм урнашырга лаеклы әдәби нормаларын еш кына аера белмибез, буташтырабыз. Шуның өстенә, бездә кайбер очракларда, урнашкан һәм урнашырга хаклы әдәби нормаларга игътибарлы, хәтта ихтирамлы мөнәсәбәт җитенкерәми. Әдәби нормаларыбыздан зарурятсыз тайпылу, хәтта аларны бозу фактлары шактый күп бездә.

Миңа татар телендәге нәшрият продукциясенең байтак төрләрен күздән кичерергә, радио, телевидение тапшыруларын еш кына тыңларга һәм шуларның тел төзелешләрен нечкәләп күзәтергә туры килде. Күз алдыма әдәби телебездәге күп кенә типик кимчелекләр — чатаклык һәм ялгышлар да килеп бастылар.

Очраган кимчелекле фактларның зур күпчелеге сүз һәм сүз төрләре сайлаудагы ялгышларны, уңышсызлык һәм төгәлсезлекләрне чагылдыра. Фонетик һәм грамматик төрләрдәге ялгышлар, төгәлсезлекләр дә байтак, әлбәттә.

Соңгы бер-ике ел аралыгында «төгәлләү», «төгәлләнү» сүзен тәмамлау, тәмамлану, утәү, утәлү, бетү, бетерелү, тулу, тутырылу мәгънәсендә кулланулар бик ешаеп китте: план төгәлләнде, шуның белән эшне төгәлләдек, ярыш договоры төгәлләнде, уку елы төгәлләнде кебек төзелмәләр күп очрый. Андыйларга радио тапшырулары аеруча юмарт. Андый төзелмәләрне укыгач һәм тыңлагач, «төгәлләү», «төгәлләнү» сүзенең мәгънә эчтәлеге гадәттәгедән күп киңәйтелгәнлек аңлашыла.

Бер үк сүзнең еш кабатлануы сөйләмнең күркен дә, ягымлылыгын да киметә. Безнең публицистик һәм фәнни стильләрдәге сөйләмнәребездә бигрәк тә «буенча», «биредә» сүзләрен куллану белән мавыгу арта барганлык сизелә. Кайберәүләр аларны бер үк җөмләдә ике-өч тапкыр кабатлый. Мәсәлән, менә бу сөйләмдә «биредә» сүзе ике тапкыр кулланылган. «Бехтерев исемендәге колхозда 500 савым сыер бар. Биредә көнгә 500—600 килограмм гына сөт алалар... Биредә дә азыкны парлап, эшкәртеп ашатмыйлар». Хәлбуки, телебездә шул ук сүзнең гаять киң кулланыла торган «монда» дигән мәгънәдәше бар. Автор нилектәндер моны читләткән.

Сүз һәм сүз төре сайлаудагы төгәлсезлекләр күбесенчә шул мәгънәдәш сүзләргә (синонимнарга) туры килә. Менә тагын берничә мисал: «Кар бөртекләре зурайганнан-зурая бара» (татар теле дәреслеге) «...эреләнгәннән-эреләнә бара» диелергә тиеш. «Бу турыда мин җитәкчеләрдән сорашып бактым»... «сорашып карадым» кирәк.

Искергән һәм алынма сүзләрне урынсыз куллану очраклары да байтак: «Бер мәкаләдә... педагогик системаны **бәян итү** мөмкин түгел», «Син тактаны тотып тор дип **әмер** итте». «Бу уен Казанда традицион булып китте» һ. б. Диалекталь сүзләрне урынсыз яки кирәксезгә кулланулар да еш очрый.

Сүзләрнең төрләрен сайлау, куллану буенча ялгышлар, төгәлсезлекләр дә күп: «а» авазына башланган сүзләр фразасы урынына «а» авазы белән башланган» диелергә тиеш. «Чөгендер кайда китә?» түгел, «кая китә» булырга тиеш. «Хәят **апасы белән** нәрсә булганлыгына ул игътибар итмәде». Монда «апасына» дип әйтү генә татарча була.

Сүз тезмәләре һәм җөмлә төзелешләрендәге кытыршылык һәм ялгышлар да аз түгел. Менә берничә мисал: «Укытучыны

---

[1] Редакциядән: «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең беренче томы инде дөнья күрде, калган ике томы басылырга әзерләнә.

һәм җәмәгать эшлеклесен хөрмәтләү» (мәкалә исеме). Монда «һәм» теркәгече куе дөрес түгел, чөнки текстта сүз бер үк кеше турында бара. Дөресе: «Укытучыны — җәмәгать эшлеклесен хөрмәтләү» булырга тиеш. «Бездә алты штаттан тыш активист бар» (радио). Дөресе: ...«Штаттан тыш алты активист», «Соңгы елларда безнең әдәбият турында бик пошына башладым». «Безнең» сүзе артык, «әдәбиятыбыз турында»... булырга тиеш.

Күрсәтелеп үтелгән фактлар гамәлдәге әдәби телебезнең төзелешен күзәтү уңаенда тупланган материалның бер кисәге генә. Татар әдәби теле төзелешендәге кимчелекләрне төзәтү өзлексез дәвам иттерелергә тиеш. Шулай иткәндә, андый материалның тулырак табылачагына мин шикләнмим, чөнки әдәби тел төзелешебез бу алым белән бик аз тикшерелгән. Ләкин, тупланган күзәтү материалы бик зур булмаса да, күзәтүләремнең барышында һәм нәтиҗәсендә мин әдәби тел төзелешебезнең хәленә, ихтыяҗларына карата кайбер фикерләр әйтерлек мәгълүмат алдым һәм ул фикерләремне шушы мәкаләмдә чагылдырырга тырыштым.

Телебезне теоретик яктан өйрәнү эше өзлексез дәвам итә. Әдәби тел төзелешебез өстендәге практик эш исә алай өзлексез бармый. Моны да өзлексез итәргә иде. Тел теориясенең төп бурычы әнә шул практиканы яхшыртырга, камилләндерергә булышлык күрсәтүдән гыйбарәт бит. Татар теленә карата да ул шулай. Бүгенге көндә әдәби тел практикабызны гомумән һәм аның эчке төзелешен камилләндерү юлында эшләү, безнеңчә, тагын да актуальрәк. Культура хезмәтчеләребез (актер, режиссер, диктор, җырчы, декламатор һ. б.) һәм каләм ияләребез (язучы, редактор, лектор, журналист һ. б.) татар әдәби теле төзелешен кагыйдәләштергән төрле кулланмалар өстенә, тел культурабыз темаларына язылган әдәбият белән дә тәэмин ителергә тиешләр.

Ләкин зур үкенеч, безнең бүгенге китап базарыбызда андый әдәбият, бигрәк тә татар тел культурасы темаларына язылып нәшер ителгән китаплар бик аз. Булган хәтлесе дә, күбесенчә, яшәештәге әдәби телебезнең уңай якларын, уңышларын гына күрү, күрсәтү белән чикләнә. Уңышлар зур, әлбәттә. Шуның белән бергә, андагы җитешсезлекләргә, нормальсезлекләргә дә күз йоммаска, боларны да яшермәскә иде: шунсыз әдәби телнең сыйфатын яхшыртып, камилләндереп булмый. Халык телендәге: «Байлыгын яшергән бөләр, чирен яшергән үләр» дигән мәкальнең икенче кисәге безнең чорда да бит әле чынбарлыкны дөрес чагылдыра. Моны истә тотарга кирәк.

# МИРАСКА ИХТИРАМ

Соңгы егерме биш-утыз ел эчендә халкыбызның культура тарихы, әдәбияты белән шөгыльләнгән, кызыксынган һәр кешенең Мөхәммәт ага Гайнуллин китапларына мөрәҗәгать итмичә калганы юктыр, шаять. Алай гына да түгел, татар филологларының инде ничәнче буыны Мөхәммәт ага дәреслекләре буенча белем алдылар һәм ала киләләр. XIX һәм XX йөз башы татар әдәбияты буенча нинди генә сораулар туса да, аларга җавап эзләп, без шул галимебез китапларына мөрәҗәгать итәбез һәм шактый мәсьәләләр буенча алардан үзебезгә кирәкле белешмәләрне табабыз. Чөнки әдип хезмәтләренең төп сыйфатын аның һәрбер эзләнү, һәрбер күзәтү, хәтта аерым фикерләренең дә фактик материалга, кире каккысыз документларга нигезләнгән булуы характерлый.

Галимнең XIX йөз һәм XX гасыр башы татар әдипләре эшчәнлегенә багышланган яңа китабы[1] Нил Юзиевның «Игелекле хезмәт белән узган гомер» дип исемләнгән кереш мәкаләсе белән ачыла. Анда 75 яшен тутырган аксакал әдибебезнең тормыш юлына, төп эшчәнлегенә әтрафлы бәя бирелеп, мәгълүм бер йомгак ясалгандай, аның педагог һәм остаз буларак нәрсәләр эшләве дә тәфсилле күрсәтелә.

Китаптагы беренче мәкалә тәүге татар романын тудыручы **Муса Акъегет** (1864—1923) иҗатына багышланган. Галим, үз гадәтенчә, иң элек укучыны язучының тормыш юлы, ул язган китапның эчтәлеге белән таныштырып чыга. Шуннан соң әсәр иҗат ителгән чорны, шул чакта актуаль булган мәсьәләләрне яктыртып, «Хисаметдин менла» романының хосусиятларын анализлый, анда куелган, чишелгән мәсьәләләрнең социаль-иҗтимагый әһәмияте ача. Әсәргә характерлы каршылыклар — «үсеп барган буржуаз тәртипләрне идеаллаштырып» гәүдәләндерү — гомумән, андагы мәсьәләләрнең куелышы һәм чишелеше, автор дөрес күрсәткәнчә, «реалистик сәнгатьнең бер этабы» булган мәгърифәтчелек реализмына хас сыйфат ул.

Муса Акъегет башлап җибәргән эшләрне ары таба үстерүче **Заһир Бигиев** (1870—1902) татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган. «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» романыннан алып, көчле публицистик рух белән сугарылган «Мавәраэннәһергә сәяхәт» исемле китабына килгәнче узылган юлны күзәтсәк, әдипнең аз вакыт эчендә дә гаять нык үсүен, тормышны читтән күзәтүче, аның тискәре якларын әдәби образлар аша гына фаш итүче художниктан халкын, илен агартырга өчен практик эшләргә тотынган актив җәмәгать эшлеклесе үсеп чыгуын күрәбез.

Күренекле әдип, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе **Фатих Кәрими** (1870—1937) хакындагы мәкалә аерата игътибарга лаек. Аерата дип басым ясап әйтүнең сәбәбе шунда, бу — иҗаты бай, язмышы катлаулы әдип хакында беренче системалы һәм күләмле хезмәт. Сер түгел, соңгы елларга кадәр Ф. Кәрими эшчәнлеге хакында махсус язылмый иде. Моның азмыкүпме дәрәҗәдә мәгълүм сәбәпләре дә бар, әлбәттә. Беренчедән, Ф. Кәрими иң күренекле буржуаз-либераль «Вакыт» газетасының даими мөхәррире, икенчедән, ул узган юл гаҗәп катлаулы, каршылыклы иде. Хәтта аның кайбер фикерләре, әгәр аларны гомум фоннан, үзләрен тудырган сәбәпләрдән аерып алганда, гаять «шөбһәле» дә иде.

Мөхәммәт ага Гайнуллин исә, мәсьәләгә төрле яклап килеп, әдип эшчәнлеген хәрәкәттә, үсештә, ягъни чын тарихилык планында анализлый. Гадәти мәгърифәтче платформасыннан чыгып иҗат итә башлаган әдип эшчәнлегендә кайчакларын ныграк руен, тулаем алганда уңай якка таба үсә баруын галим бик дәлилләп күрсәтә.

Шул ук вакытта Мөхәммәт ага Ф. Кәрими эшчәнлегендә кайчакларын ныграк чагылгалап алган фикри буталчыклар, ялгышлар һәм тарихи чикләнгәнлекләрне читләтеп узмый, бәлки Г. Тукай, Ф. Әмирхан иҗатлары фонында аларның табигатен ачып, сәбәпләрен күрсәтеп, гадел хөкем дә чыгара.

Автор Ф. Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» исемле мәкаләләр (репортажлар) җыентыгына карата да кызыклы фикерләр әйтә, үз нәтиҗәләрен мәгълүм төркиолог В. А. Гордлевский тарафыннан әйтелгән объектив бәя белән ныгытып куя.

Мөстәкыйль фикер иясе, гражданин буларак Ф. Кәриминең яхшыга таба үзгәрә

[1] Мөхәммәт Гайнуллин. Татар әдипләре. 1978.

баруын әлеге «Истанбул мәктүпләре» аерата ачык күрсәтә. Балкан сугышы башлангач, ул Төркиягә «Вакыт» газетасы тарафыннан җибәрелгән «битараф» мөхбир — корреспондент сыйфатында гына түгел, бәлки яшьли алган тәгълим-тәрбиясе тәэсирендә Төрек империясенең «бердәмлеге», элекке шөһрәте саклануны ихлас күңелдән теләгән, мәгәр Балкан илләре халыкларының азатлыкка хаклы булуларын аңлый алмаган гаять каршылыклы позициядәге журналист буларак килә.

Әмма ул, Төркиядә беркадәр яшәгәч, иске Госманлы империясенең генә түгел, яңа «Яшь төрекләр» хәрәкәте башында да мәсләксез-максатсыз авантюристлар торуын, аларның бөтен политикасы үз халкын алдауга, башкаларны изүгә юнәлтелгән политика икәнлеген аңлый башлый. Шуңа күрә беренче «мәктүпләрдә» авторның «төрек иле» бердәмлеген яклавы ярылып ятса, ахырда язылган корреспонденцияләрдә аның иске империя җимерелүе закончалыклы икәнлеген тануы икърар ителә. Мондый эволюцияне кыска вакыт эчендә, әлбәттә, намуслы фикер иясе һәм гражданлык хисе көчле эшлекле генә кичерә ала.

Җыеп әйткәндә, «Истанбул мәктүпләре» бер Фатих Кәрими иҗатында гына түгел, бәлки бөтен татар журналистикасы тарихында да аерым урын билап торган мөһим күренеш. Шуның өчен дә, Мөхәммәт ага махсус күрсәтеп узганча, Г. Тукай аны «җан азыгы» дип олылаган.

Язучы, журналист, педагог, тарихчы **РИЗА ФӘХРЕТДИНОВ** (1858—1936) иҗатына багышланган очеркны да шул шәхес эшчәнлегенә караган беренче эзлекле хезмәт дип бәяләргә кирәк. Автор бу каршылыклы, мәгәр бай иҗатны нигездә өч планда — мәгърифәтчелек, язучылык һәм журналистлык яссылыгында характерлый. Әйтергә кирәк, ул үз алдына куелган шушы конкрет бурычка — кечкенә күләмле популяр хезмәттә Р. Фәхретдинов эшчәнлегенең уңай һәм катлаулы якларын объектив бәяләүгә тулысынча диярлек ирешә алган.

Әлбәттә, Фәхретдинов — тарихчы, Фәхретдинов — ориенталист дигән темалар буенча да әтрафлы итеп язып булыр иде. Мәсәлән, галим төзегән «Асар» исемле био-библиографик җыелманың әдәбият тарихына материаллар туплау өчен әһәмияте, һичшиксез, зур. Шәмсетдин Зәки, Әбелмәних Каргалы, Акмулла кебек шагыйрьләребезнең тормыш юлларына, Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Фәезхановлар мирасына мөрәҗәгать итсәк тә, юл башында әлеге «Асар» торачак. Мәгәр, узганга икенчерәк максат белән карап, мәсәлән, мәктәп-мәдрәсәләребез челтәрен, педагогик әдәбиятыбыз репертуарын барларга теләсәк тә, шул ук «Асар»дан бай мәгълүмат туплар идек.

Дөрес, Р. Фәхретдинов бу мәсьәләләрне махсус тикшереп тормый, бәлки теге яки бу биографиягә караган материалларны тәртипкә салганда тәрҗемәи хәл иясенең кайда, кемнәрдән сабак алуы, үзенең кемнәрне тәрбияләве, нинди әсәрләр язуы яисә күчерүе хакында эзлекле рәвештә теркәп бара. Менә шундый мәгълүматларны «Асар»дан «сөзеп алып», бер тәртипкә салсак, XVII—XIX йөздәге мәгърифәт учаклары хакында шактый колачлы бер картина хасил булыр иде. Шушы күзлектән караганда, без Р. Фәхретдинов мирасына тиешле төгәл бәяне бирә алмадык әле.

Фәхретдинов — ориенталист дигән тема буенча да махсус монография язып булыр иде, һәм без андый хезмәттә гадәти популяризаторны гына түгел, бәлки шәрык телләрен, шәрык халыклары культурасын нечкәләп белгән, махсус әдәбияттан да тирән хәбәрдәр булган төпле, киң колачлы галимне, катлаулы фикер иясен күрер идек.

Әмма Р. Фәхретдинов эшчәнлеге буенча мондый ачылып җитмәгән мәсьәләләргә тукталуым белән мин рецензияләнә торган китап авторы алдына махсус дәгъва куярга теләмим. Мин бары Мөхәммәт ага әйткән бер фикерне — Фәхретдинов иҗаты гаять бай һәм катлаулы дигән тезисны көчәйтергә, әтрафлырак нигезләргә телим.

**ШАКИР МӨХӘММӘДОВ** (1865—1923) эшчәнлегенә багышланган күләмле хезмәт тә игътибарга лаек. Ул дәвамлы эзләнүләр җимеше. Әгәр бүген XX йөз башы татар әдәби процессының демократик канатында үзенчәлекле сатирик язучы, ялкынлы журналист Шакир Мөхәммәдовның күрәбез, аның иҗади мирасыннан актив рәвештә файдаланабыз икән, без моңа, һичшиксез, рецензияләнә торган китап авторына бурычлы.

«Әлегә кадәр биографиясе дә һәм иҗаты да тиешенчә өйрәнелмәгән, хәтта күп вакытта исеме дә телгә алынмый торган» **ГАЛИӘСГАР ГАФУРОВ — ЧЫГТАЙ** (1867—1942) хакындагы мәкалә дә, һичшиксез, кирәкле һәм урынлы публикация. Югарыда махсус киңрәк анализланган ике мәкалә кебек үк бу хезмәт тә өр-яңа материалларга нигезләнгән. Автор анда Г. Чыгтайның катлаулы, бик каршылыклы тормыш юлын, үзенчәлекле иҗатын төрле яклап тикшерә, объектив бәя бирергә омтыла. Бездәге мәгърифәтчелек реализмы тарихын өйрәнгән чакта, шөбһәсез, Г. Чыгтайның «Тутам рисаләсе» повесте дә үз урынын алырга тиеш.

Г. Чыгтай, мәгълүм булганча, атеистик фикеребез үсеше тарихында да сизелерлек эз калдырган шәхес. Бу өлкәдә аның як-якка ташлануы, үзара көрәшүче һәр ике тараф күзлегеннән караганда да, «мөртәтлекләр» эшләп алгалавы, гадәти генә бер шәхси трагедия түгел, бәлки гасырлар буе хөкем сөргән традиция тәэсиреннән аерылу яисә арыну дигән катлаулы процессның чагылуы иде. Шушы күзлектән караганда да, Г. Чыгтайның гыйбрәтле эшчәнлеге игътибарга лаек, әлбәттә.

XX йөз башы татар шагыйрьләреннән

**СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ** (1880—1926) һәм **ДӘРДМӘНД**, ягъни **ЗАКИР РӘМИЕВ** (1859—1921) иҗатлары да Мөхәммәт ага Гайнуллинның күптәнге күзәтү объектлары. Китапта басылган мәкаләләрнең язылу тарихы сыйфатында 1947—1962 еллар дип куелуы да күп нәрсә турында сөйли. Әмма бу мәкаләләрне элгәрге хезмәтләрнең кабат басылуы гына дип карарга ярамас иде. Чөнки алар яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган. Мисалга Шакир Рәмиев хаты китерелүен күрсәтергә мөмкин. Ул документ, минемчә, бертуган Рәмиевләрнең матбагачылык өлкәсендәге эшчәнлеген элеккегә караганда тирәнрәк һәм гаделрәк бәяләргә ярдәм итә.

XX гасыр башы поэзиясе Габрулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдмәнд һәм Мәҗит Гафури кебек «ай-йолдызлардан» яисә беренче дәрәҗә зурлыктагы йолдызлардан гына тормаган, әлбәттә. Башкачарак итеп әйткәндә, гасырыбыз башындагы татар шигърияте күгендә икенче, өченче дәрәҗәдәге йолдызлар да җемелдәгән. Әдәбиятыбыз тарихын төгәлрәк иңләп, тулырак яктыртыр өчен менә шундый иҗатларга да игътибар итү зарури. Мөхәммәт ага Гайнуллин моны онытмый. Ул, мәсәлән, вакытында ук **МИРГАЗИЗ УКМАСИ** (1884—1946), **ЗЫЯ ЯРМӘКИ** (1887—1965), **ЗАРИФ БӘШИРИ** (1888—1962) кебек шагыйрьләр хакында язып чыкты, аларның сайланма әсәрләрен бастыру эшенә актив катнашты.

Безнең алдагы җыентыкта да әлеге өч шагыйрьнең иҗатларына караган мәкаләләр урнаштырылган. Алар, күләм ягыннан шактый җыйнак булсалар да, шагыйрьләрнең иҗаты, эшчәнлеге хакында ярыйсы гына төгәл төшенчә алырга, хәтта аларның үзләрен дә яратып калырга ярдәм итәләр.

Китапка кергән материалларның бер циклын хатын-кыз шагыйрәләр һәм язучыларга багышланган мәкаләләр тәшкил итә. Цикл «1905 ел революциясе һәм татар хатын-кыз язучылары» дигән очерк белән башлана. Анда хатын-кыз язучыларның активлашуын тәэмин иткән социаль-иҗтимагый сәбәпләр яктыртылгач, **МАҺРУЙ МОЗАФФАРИЯ** (1873—1945) иҗатына тукталына.

Заманында **«ГЫЙФФӘТ ТУТАШ»** псевдонимы белән киң танылган **ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВА** (1895—1977), шулай ук **ЗӘЙНӘП СӘГЫЙДӘ** (1897), **МӘХҮПҖАМАЛ АКЧУРИНА** (1869—1948) иҗатларына багышланган очерклардан да бай мәгълүмат алып була. Болардан Мәһүпҗамал Акчурина иҗатына килсәк, татарларда педагогик белем үсүгә, этнография һәм әдәбият тарихы өчен материал туплауга, шулай ук хатын-кыз язучылар арасында публицистик жанр үсүгә зур өлеш керткән бу әдибәнең мирасы махсус өйрәнүгә мохтаҗ. Китап авторының М. Акчурина «мәкаләләрен җыеп, бер җыентык чыгарып», яшь буынны шулар белән якыннан таныштырасы иде дигән тәкъдиме бик урынлы яңгырый. Гомумән, Мөхәммәт ага дөрес әйткәнчә, «хатын-кыз язучыларның әдәби эшчәнлекләре төпле тикшеренүләрне, тагын да тулырак анализ ясауны сорый» (216 б.).

**ФАТИХ ӘМИРХАН** (1886—1926) эшчәнлегенә багышланган «Әдип-гражданин» исемле күләмле мәкаләнең эчтәлеге белән укучылар элек тә таныш иделәр. Автор бу тема өстендә 1947 елдан бирле эшли, әдип мирасын барлауга, аны пропагандалауга лаеклы өлеш кертә килә. Әгәр бүген Ф. Әмирхан иҗаты безнең өчен чагыштырмача яхшы таныш икән, монда да Мөхәммәт ага Гайнуллинның өлеше шактый.

Татар совет язучысы, публицист **МӨХӘММӘТ ГАЛИ** (1893—1952) һәм күренекле галим, тәнкыйтьче **ГАБДРАХМАН СӘГЪДИ** (1889—1956) иҗатларына караган мәкаләләр дә кызыксыну белән укылалар. Чөнки болар да әдипләр хакындагы беренче системалы хезмәтләр. 30 нчы еллар Г. Сәгъди иҗатының үзенчәлекләре дә, минемчә дөрес яктыртылган. Мәкалә ахырына истәлек материаллары кертелү дә шулай ук бик файдалы булган.

«Дөньяви әсәрләр эзеннән» дигән мәкалә дә, һичшиксез, кызыклы һәм материалга бай. Әмма нигездә аноним яисә иске традициядәге поэзия әсәрләре хакында хәбәр итә торган бу мәкалә, минемчә, рецензияләнә торган китап өчен «ак карга» сыманрак килеп чыккан: калган очерк-мәкаләләрдән ул объекты белән дә, жанр үзенчәлеге ягыннан да аерымланып тора. Әгәр бу мәкаләгә бирелгән урын, әйтик, Закир Һади иҗатына багышланган булса, китап тагы да отар иде. Күрсәтелгән мәкалә исә Мөхәммәт аганың башка бер китабында лаеклырак урынын табар иде шикелле.

Татарларда балалар әдәбияты аерым төр буларак формалашкан дәвердә зур эшчәнлек күрсәткән, мәгълүм «Ак юл» журналын чыгару белән татар журналистикасы тарихында үз урынын яулаган **ФӘХРЕЛИСЛАМ АГИЕВКА** (1887—1938) багышланган кечкенә язма да, беренче белешмә сыйфатында, игътибарга лаек. Кызыклы әдип хакында киләчәктә дә эзләнүләр язылыр, әлбәттә, чөнки китап ахырындагы әлеге соңгы мәкалә шуның файдасына сөйли.

Шулай итеп, күзәтүдән күренгәнчә, «Татар әдипләре» исемле китапка күренекле галимебез Мөхәммәт ага Гайнуллинның 1947—1977 еллар дәвамында язылган 20 очерк һәм мәкаләсе урнашкан икән. Икенчерәк итеп әйткәндә, бу китапта әдип эшчәнлегенең төп юнәлешен чагылдырган 30 еллык хезмәт җимешләренең бер өлеше тупланган. Бер өлеше дип әйтүнең сәбәбе шунда, китап ахырында бирелгән әһәмиятле, бик урынлы библиографик белешмәдән күренгәнчә (төзүчесе Ә. Кәримуллин), без күзәтеп чыккан мәкаләләр Мөхәммәт ага хезмәтләренең нибары уннан бер өлешен генә тәшкил итәләр

икән (библиографиядә 280 нән артык хезмәт теркәлгән).

Ләкин «өлешнең» дә төрләре була. Китапка кергән мәкаләләр дә, күзәтүдән күренгәнчә татар әдәбияты белеменең мөһим фронтларының берсенә карый икән. Шуңа күрә бу җыентык дөньяга чыгуны әдипнең генә бәйрәме дип түгел, бәлки татар әдәбияты тарихының әһәмиятле казанышы дип бәяләргә кирәк.

«Татар әдипләре» китабында бирелгән фоторәсемнәр, әдәби истәлекләрдән китерелгән иллюстратив материаллар да, һичшиксез, китапның эчтәлеген ачуга, аның документаль нигезен көчәйтүгә хезмәт итәләр. Кайбер фоторәсемнәрнең беренче мәртәбә басылган булуын да күрсәтергә кирәк.

Китапта аерым төгәлсезлекләр, эрелеваклы кимчелекләр дә очрый. Һәм мондыйлар, беренче чиратта, китапның редакцияләнү сыйфатына карый. Сүзебез буш дәгъва булып калмасын өчен берничә мисал китерик.

Беренчедән, мәкаләләрдә төрле әсәрләрдән китерелә торган өзекләр автор текстыннан ээлекле рәвештә аерымланып бирелмәгән (мәсәлән, куштырнаклар, икенчерәк төрле шрифт ярдәмендә). Шуңа күрә еш кына кайда цитата тәмамлануы, кайда автор тексты башлануын аңлар өчен махсус уйланып утырырга кирәк.

Икенчедән, китапны редакцияләү процессында махсус атамалар, ялгызлык исемнәре бозылган. Мәсәлән, төрек галиме Кятиб Чәләби исемен татарчалаштырып «Катип Чиләби», дөньякүләм мәгълүм философ Ибне Хәлдунны исә «Ибне Хәлидун» дип бозу (92 б.), ул редактор «төзәтүләре» аркасында туган буталчыклар гына. Мөхәммәт аганың элекке хезмәтләрендә Ибне Фадлан дип түгел, бәлки, татар әдәби телендә кабул ителгәнчә, Ибне Фазлан рәвешендә дөрес язылган иде, чөнки ул безнең телгә кергән Фазыл, Фазыйлалар белән бер үк тамырдан. Гомумән, рус-европа телләрендә «д» аркылы бирелә торган гарәпчә тел арты «зъ» авазы татарларда гадәти «з» булып яңгырый (казый, риза, рамазан кебек).

Монгол империясе башкаласы Каракорумны «Кара ком»га әверелдерүдә дә (97 б.) редактор каләме сизелгәндәй итә.

Күрсәтелгән хаталарның редакцияләү процессында туган күңелсезлекләр икәнлеген түбәндәге факт артыгы белән раслый. Мәсәлән, галимнең моңарчы чыккан башка китапларында (җөмләдән: «Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан. 1968) Россиядәге мөселманнарның мәгълүм дини учреждениесе исеме «Диния назараты» рәвешендә дөрес язылган. Чөнки биредә «назарат» башкарма, инспекция дигән мәгънәне белдерә. Редакцияләнә торган китапта исә ул ээлекле рәвештә «Дини назарият» дип бозып бирелгән (80, 82, 94, 134 бб.). Нәтиҗәдә «Дини эшләр буенча башкарма» диясе урынга «дини теория» килеп чыккан.

Һәрхәлдә, халыкара культура мөнәсәбәтләре, идеологик фронт өлкәләренә карый торган мондый исемнәр һәм атамаларның бозылып бирелүе китап файдасына хезмәт итми, әлбәттә. Бу хакта сүзне шуның белән тәмамлыйсы килә: беренчедән, фәнни китапларны чыгаруда катнашучы редакторлар да тыйльми җаваплылык хисен югалтмасыннар иде; икенчедән, яшь редакторлар өчен махсус атамалар буенча сүзлек-белешмә булдыру хакында да уйланырга вакыттыр инде.

Дөрес, китапта авторның үзеннән килә торган төгәлсезлекләр дә бар. Ул, мәсәлән, ни өчендер иске телебезгә кергән фарсы изафәсен ээлекле рәвештә чагылдырмый. Әйтик, «тәскин калеб» түгел (157 б.), ә «тәскине калеб» рәвешендә язылырга тиеш иде. Мондый язылышны саклау гаруз вәзендәге шигырьләр өчен бик тә зарур.

Дөньяви эчтәлекле бер поэманың авторы сыйфатында Мулькай дигән кеше атала (294 б.), мәкаләнең журнал вариантында да ул шулай бик сәер язылган иде. Чынлыкта ул Мәуләмбирде дигән исемнән кыскартылып ясалган булып, Мәүлекәй рәвешендә яңгырый. Андый исемле кешеләрне Көньяк Себер һәм Казагыстан татарларында берничә мәртәбә очратканым бар. Шуңа күрә укучылар массасы игътибарына галим тәкъдим иткән кызыклы поэманың авторы Мәүлекәй Юмачиковның тулы исеме Мәүләмбирде булса, гаҗәп түгел.

Әлбәттә, китапның чын йөзен мондый сирәк очрый торган төгәлсезлекләр түгел, ә югарыда тәфсилләп язганыбызча, эчтәлекле мәкаләләр, ягъни нәтиҗәле эзләнүләр һәм отышлы күзәтүләр тәшкил итә.

Җыеп әйткәндә, «Татар әдипләре» китабын чыгарып, Татарстан китап нәшрияты, аксакал әдибебезнең хезмәтенә хөрмәт күрсәтүдән тыш, татар әдәбияты тарихы белеменә дә лаеклы өлеш өстәргә булышкан. Китапта гәүдәләнгән мираска ихтирам хисе укучыларда да яхшы сыйфатлар тәрбияләүгә хезмәт итәчәк. Узган буыннар хезмәтенә хөрмәт белән карый алу үзе үк культура һәм олы җанлылык галәмәте.

Ниһаять, «Татар әдипләре» китабы тәҗрибәсе, укучыны узганның кайбер сәхифәләре белән таныштырудан тыш, безне алдагы бурычларыбыз хакында да уйланырга мәҗбүр итә. Чөнки, китапны ябуга, иҗат портретлары әле популяр рәвештә халыкка җиткерелмәгән башка бик күп язучыларыбыз, шагыйрьләребез хакында уйланырга тиеш буласың.

Мәсьәләгә бу яктан карaганда да Мөхәммәт ага Гайнуллин эшчәнлеге аерата тәкъдир итүгә лаек.

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ.**

# ЯКТЫЛЫККА — НУРГА ИЛТӘ

Сакланып калган игъланнарны, вакытлар узу белән саргайган газеталарны карап утырганда, ирексездән, татар театр сәнгате узган көрәш һәм җиңүләр юлын күз алдыннан кичерәсең. Яңалык өчен, яктылык өчен көрәш юлы бу.

Билгеле булганча, яңа гасыр таңында уянып килүче татар халкының үсәннән-үсә барган культура ихтыяҗын бер «Сәйяр» труппасы гына канәгатьләндерә алмый иде. Ирекә омтылган көннәрдә революцион рух көннән-көн күбрәк мәйдан ала барган бер чорда С. Гыйззәтуллина-Волжская тарафыннан оештырылган икенче татар театр труппасы — «Нур» сәхнәгә күтәрелә. Үзенең истәлекләрендә С. Гыйззәтуллина-Волжская бу хакта болай дип яза:

«1912 елны мин Уфада «Нур» труппасы оештыру дәрте белән янып йөри идем. Шул елны мин, Зөләйха Богданова, Фәхриниса Сәмитова — өч артистка «Сәйяр»дан чыктык та Уфага киттек. Булачак труппага кешеләр табарга кирәк иде. Шул чакта атаклы җырчы Фәттах Латыйпов миңа Пермь шәһәрендә һәвәскәрләр арасында театрны бик яратучы, бик сәләтле Шакир Вахитов дигән бер егет барлыгын әйтте. Егет үзе Агафуров дигән байларда приказчик булып эшли икән... Озак та үтми, Шакир, үзенең Нуретдин Хәнҗәров дигән тагын бер яшь һәвәскәр иптәшен ияртеп, Уфага килеп тә җитә. һәм «Шамилский» дигән сәхнә фамилиясе алып, ул «Нур»ның беренче спектаклендә үк уйный башлады.

Уфадагы татар яшьләре «Нур» труппасы төзелгәнче үк инде театр эше белән бик кызыксыналар. Алар яңа труппа төзү максаты белән килгән артистларга оештыру һәм сәхнә эшләрендә актив ярдәм күрсәтәләр. Яшьләр әледән-әле әдәби-музыкаль кичәләр һәм спектакльләр куеп торалар. Мәсәлән, Хәбибулла Әхтәмев «Бездә беренче театр» исемле мәкаләсендә: «Мәдрәсәи Госмания»дә беренче спектакль 1901 елның 27 гыйнварында булды. Без бу эшебезне «Галия» мәдрәсәсенә күчкәч тә дәвам иттердек», — дип яза («Яңа юл» журналының 1923 елгы апрель саны.)

Сәрур Сүнчәләй[1] үзенең истәлекләрендә 1907—1908 елларда рус-татар училищесында укучы кызларның «Кызлар шулай кызык итәләр», «Беренче театр» кебек пьесаларны куюлары турында сөйли.

Карт коммунист Нәҗип Габдрәшитовның[2] Уфада татар яшьләре тарафыннан оештырылган спектакльләр турындагы истәлеге аеруча игътибарга лаек. «Без 1908-1909 елларны фәкать татар эшче, приказчик һәм укучы яшьләрдән торган һәвәскәрләр оешмасы төзеп эшкә башлыйбыз, спектакльләр куябыз»,— дип яза ул.

Ленинград Дәүләт архивында Н. Габдрәшитовның матбугат эше буенча баш идарәгә язган үтенеч кәгазьләре бар. Ул аерым пьесаларны сәхнәгә кую өчен рөхсәт сораган. Әмма патша цензурасы күп вакытта аның үтенечләрен кире каккан.

«Нур» труппасы төзелгәч, Н. Габдрәшитов спектакльләрдә катнаша. Гражданнар сугышы чорында, 5 нче Армиянең полит бүлеге тарафыннан мөселман секциясенең мөдире итеп куелгач, ул Кызыл гаскәрләр өчен труппалар төзү эшендә актив булышлык күрсәтә, татар артистларына төрлечә ярдәм итә.

1911-1916 елларда Уфада эшләп килгән мөселман ханымнар җәмгыяте дә спектакльләр куюга зур әһәмият бирә һәм елына берничә әсәр күрсәтә. Уфа яшьләре бу җәмгыять файдасына 1911 елның февралендә русчадан тәрҗемә ителгән «Хатыннар эше», Г. Камалның «Беренче театр», 1913 елны Гариф Богдановның «Хуҗа һәм приказчик» исемле комедияләрен куя. Җамали Моратов, соңыннан «Нур» труппасы артисты булган Гыйләҗ Казанский, Габдрахман Мангушев, Мөхтәр Мутин һәм башка яшьләр әлеге спектакльләрдә бик теләп катнашалар.

С. Гыйззәтуллина-Волжская труппасы исә, үзенең тәүге чыгышлары белән үк шәһәр халкы арасында зур популярлык казана. Ул бу чорда татар-башкорт хатын-кызларының аяныч тормышын тасвирларга омтыла һәм русчадан ирекле тәрҗемә

[1] В. И. Ленин исемендәге Үзәк китапханәнең гыйльми хезмәткәре. Хәзер пенсиядә. Мәскәүдә яши.

[2] Хәзер Уфада яши.

ителгән «Җиңел хезмәт» исемле пьесаны куя.

С. Гыйззәтуллина Гайшә ролендә нык кимсетелгән, авыр тормыш газизлегеннән котылу теләге белән яшәгән, ләкин байлар тырнагына эләгеп мәсхәрәләнгән кызганыч образны реалистик осталык белән башкара.

Бу постановка тамашачыны үз язмышы турында да тирән уйландыра.

Моннан тыш Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмасын куйганнан соң, труппа гастрольгә китә. Чиләбедә 20 апрельдә «Народный дом» залында «Җиңел хезмәт» драмасы куела. Һәр вакыттагы шикелле Чиләбе һәвәскәрләре ярдәмче составта актив катнашып, труппаның эшен шактый җиңеләйтәләр. Труппага төрле яклап ярдәм итүче һәвәскәр артист Гариф Борнаев була. Монда да «Җиңел хезмәт» тамашачыларда тирән тәэсир калдыра: «...кайбер абыстайлар күзләрен сөртә-сөртә, менә гыйбрәт, менә театрда нинди гыйбрәтләр күрсәтәләр икән дип сөйләшәләр. Кат-кат кул чабып алкышладылар. Безнең дә башка милләтләрдәге шикелле театрыбыз, яхшы уйнаучы артистларыбыз бар икән дип куаныша-куаныша таралдылар[1]», — дип яза «Тормыш» газетасы хәбәрчесе.

Чиләбе гастроленнән соң «Нур» труппасы Петропавловскига барып, шул спектакльләрне куя, аннары 1914—1915 еллар сезонын уздыру максаты белән Оренбургка кайта. Алты ай эчендә 16 спектакль куя. Ул спектакльләр арасында Г. Камалның «Уйнаш», «Банкрот», «Бүләк өчен», «Беренче театр», «Бәхетсез егет», «Каениш» исемле әсәрләре, С. Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», Я. Вәлинең «Ачлык кушты» һәм башка әсәрләр була.

1915 елның икенче яртысында «Нур» труппасы, «Сәйяр» дан килгән берничә артист белән берләшеп, Оренбургта «Татар драм артистлары труппасы» дигән исем белән йөри башлый. Чөнки беренче бөтендөнья сугышы башланып, труппадагы артистларның берничәсе солдатка алынгач (Ш. Шамилский һ. б.), «Нур» труппасының үз составы ярлылана төшә. «Татар драм артистлары труппасы» коллективы Мольерның «Саран»ын, Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен, Г. Кариевның «Артист»ын һ. б. пьесларны куя.

«Хаҗи әфәнде өйләнә» постановкасыннан соң, ноябрь аенда С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм аның иптәшләре «Татар драм артистлары труппасы»ннан кире аерылалар.

«Нур» труппасы 1915—1916 еллар сезонын үткәрү өчен Оренбургта калса да, башка шәһәрләргә дә гастрольгә чыгып йөри. Орск шәһәрендә ул Г. Камалның «Каениш» исемле комедиясен, В. Иманскийның «Качкыннар»ын куя. Труппаны Орскида эшләп килгән театр һәвәскәрләре шатланып каршы алалар. Алар арасында Мирхәйдәр Фәйзи, Бәдәр Йосыпова (соңыннан РСФСРның атказанган артисткасы), Мөхәммәт Сәлимҗанов һ. б. була.

[1] «Тормыш», 1914, 27 апрель.

Труппа Оренбургта бераз эшләгәннән соң, 1916 елның җәендә Уфага килеп житә. Ләкин биредә эшне башлап җибәргәнче, С. Гыйззәтуллина-Волжская, коллектив эшчәнлегендә моңа кадәр булган ялгышларны һәм кимчелекләрне исәпкә алып, труппаны ныгыту максаты белән житди чаралар үткәрә. Уфа шәһәрендә алдынгы яшьләр белән тыгыз элемтәләр урнаштыра. Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Н. Нариманов әсәрләре һәм дөнья классиклары әсәрләренең тәрҗемәләре хисабына труппаның репертуарын яңарта. Труппага сәләтле яшьләр Әмин Зөбәиров, Исхак Әпмәшов, Локман Аитов, Маһирә Мирвәлиева, Нәҗип Әбдрәшитов, Гата Исхаков һ. б. килә.

Сәхибҗамал ханым репетицияләрне үзе алып бара, артистларны өйрәтә һәм үзенең уены белән үрнәк күрсәтә. Кыскасы, режиссерлык эшен дә алып барганга, артистлар С. Гыйззәтуллина-Волжская белән нык хисаплашалар һәм аңа зур хөрмәт күрсәтәләр.

Ш. Шамилский үзенең остазы Сәхибҗамал ханымның эше турында: «Репетиция вакытлары-да без уйный торган рольләрне үзе уйнап күрсәтә. Фантазиягә бай булуы аңа без күрми калган моментларны да чагылдырырга мөмкинлек бирә, уенына җанлылык, театральность кертә иде», — дип яза («Совет әдәбияты», 1941 ел, 1—2 саннар, 82—84 битләр).

Әлбәттә, С. Гыйззәтуллина-Волжская тудырган образларның барысына да тукталу мөмкин түгел. «Уйнаш»та ул Сәрбиҗамал ролен башкара. Аның «финалда ире Әхмәтҗанга тилмереп караулары йөрәкне әрнетеп, бу бичара хатынның тәкъдире өчен күздән яшь агызырга һәм дулкынланырга мәҗбүр итә»[1].

1916 елның көзен «Нур» труппасы Иж заводыннан гастрольдә йөреп кайткач, киләсе ел сезоннарында да «Нур»ны Уфада калдыру мәсьәләсе матбугат битләрендә күтәрелә. Чөнки «Нур»га мәхәббәтен баглаган Уфа тамашачысы труппа кышкы сезонны биредә үткәрер дип өмет итә. Шул уңай белән «Тормыш» газетасы: «Сәхибҗамал ханым вә иптәшләре Уфада калсалар, Уфа халкы шаять аларга ачык йөз күрсәтер», — дип яза[2]. Һәм чыннан да, «Нур» труппасы үзенең Уфада калу теләген белдерү белән, труппага ярдәм итү өчен махсус театр комиссиясе төзелә. Комиссияда шагыйрь һәм язучылардан Сәгыйть Сүнчәләй, Шәриф Сүнчәләй һ. б. була. Ярдәмче составта Әмин (Габдулла) Зөбәиров, Гәрәй Әминов, Нәҗип Әбдрәшитов, Шәйхзадә Бабич һәм башкалар катнаша. Театр комиссиясе «Нур» труппасының көндәлек эшендә зур ярдәм күрсәтә.

«Нур» Уфадагы сезонын (1916—1917) М. Фәйзинең «Кызганыч» драмасы белән 26 сентябрьдә ача[3]. М. Фәйзи Сөләйман бай йөзендә либераль татар сәүдә буржуа-

[1] «Совет әдәбияты», 1941 ел, 1—2 саннар.
[2] «Тормыш», 1916 ел, 14 август.
[3] «Тормыш», 1916 ел, 29 сентябрь.

сының түбәнлегән, анық байлык артыннан куу һәм үз нәфесләрен канәгатьләндерү өчен һәр пычраклыкны эшләргә әзер торуын чагылдыра. Драматург бу әсәрендә шулай ук бөтен омтылышын, бөтен сәләтен гади халык балаларын тәрбияләү эшенә биргән укытучы Гәүһәр образын сурәтли. Спектакльдә С. Гыйззәтуллина-Волжская — Гәүһәр, Г. Казанский Заһит рольләрен башкаралар. Гәүһәр белән Заһитның мәхәббәт драмасы тамашачыда көчле тәэсир калдыра.

1916 елны татар театрының тууына ун ел тула. Бу уңай белән кайбер шәһәрләрдә юбилей кичәләре уздырыла. Казанда юбилей тантанасы оештырылмаса да, Ф. Әмирхан «Аң» журналында «Сәхнәбезнең ун яшьлек мөнәсәбәте белән»[1] исемле мәкалә язып чыга. Уфада да юбилей хәзерлек һәм оешканлык белән үтә. Лекцияләр укыла, бенефислар оештырыла. Шул уңайдан бирелә С. Гыйззәтуллина-Волжская бенефисы үткәрелә. Бенефиска «Уйнаш» һәм «Бәхетсез егет» драмалары куела. С. Гыйззәтуллина-Волжская үзенең яраткан рольләрен — Сәрбиҗамал белән Гайнине башкара.

«Нур» труппасы февраль революциясе көннәрендә Г. Колахметовның «Яшь гомер» исемле драмасын беренче кат сәхнәгә куя. «Ирек» газетасы: «Бу әсәр 1905 елда хөррият хәрәкәтенә катнашкан яшь вә татар эшчеләре хаятеннән алынып язылганга, сәхнәгә куюы өчен элек рөхсәт ителми иде»[2],— дигән хәбәр урнаштыра.

Бөек Октябрь социалистик революциясен татар артистлары зур иҗади күтәренкелек белән каршы алалар. Шул көннәрдә «Нур» труппасы сәхнәгә «Яшь гомер» драмасын икенче кат куя. Әнә шулай, «Нур» труппасының реалистик юнәлештәге эшчәнлеге татар пролетар әдәбиятына нигез салган Г. Колахметовның «Яшь гомер» драмасын мәгънәви бөтенлеге белән тамашачыга җиткерү дәрәҗәсенә кадәр үсә. Труппа кыска вакыт эчендә идея-эстетик яктан да, актерлык осталыгы ягыннан да күтәрелә бара. «Яшь гомер» постановкасы үзенең идея эчтәлеге белән шул вакыттагы Уфа тамашачыларының иҗтимагый зәвыгына бик туры килә.

Алдынгы рус пролетариаты һәм рус әдәбияты татар хезмәт ияләренең фикер офыкларын киңәюгә ярдәм итә һәм аларны революцион яңарыш хәрәкәтенә тарта. Татар халкының прогрессив интеллигенциясе исә бу хәрәкәтне әйдәп баручы була. 1917—1918 еллар сезонында «Нур» Уфа сәхнәсендә А. Островскийның «Гроза»сын куя. Бу спектакльдә С. Гыйззәтуллина-Волжская кешенең рухын басып, горурлыгын аяк астына салып таптаган патриархаль семьяда яшәгән нечкә һәм бай тойгылы, ирекка омтылучы, эчкерсез саф күңелле хатын — Катерина образын иҗат итә. «Тоткынлыкта изелүче вә шул сәбәпле дөнья белән бәхилләшергә мәҗбүр булучы мәзлумә яшь килен Катя ролен Волжская берәүне чынлап сөюдән башка гөнаһсы булмаган вә шул ук горефтән азап күрүче гашыйк Борис ролен Казанский чыннан да үз рольләренең рухына кереп уйнадылар»[1],— дип яза рецензент.

С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның изге эшендә аның талантлы шәкертләре һәм иптәшләре Ш. Шамилский, Г. Казанский, З. Богданова, Ә. Зөбәиров, И. Әлмәшов, һ. б. артистлар бөтен көч һәм талантлары белән ярдәм итәләр. Гомумән, татар театрының реалистик юнәлештә үсүендә бу артистларның өлеше зур була.

Ш. Шамилскийның, мәсәлән, никадәр киң диапазонлы артист булуын күз алдына китерер өчен ул тудырган төрле характердагы образларның берничәсен генә санап үтик: Закир («Бәхетсез егет»), Миңлегали («Зәңгәр шәл»), Хәйретдин («Яшь йөрәкләр»), революцион матрослар җитәкчесе Годун («Разлом»), партоешма секретаре Кузнецов («Томан арты»), Хлестаков («Ревизор»), Кент («Король Лир»)... һәркайсы — татар сәхнәсендә тирән эз калдырган образлар. Мәсәлән, Камалның «Ут» драмасы сәхнәгә куелгач язган рецензиясендә Г. Кутуй Рәүф ролен башкаручы Шамилскийга туктальп: «Дөресен генә әйткәндә, Шакир Шамилский спектакльнең «уты» булды»,— дип язды. Бу сүзләрдә, әлбәттә, дөреслек зур. Чөнки Ш. Шамилский сәхнәдә үзе янып уйнаган шикелле партнерларга да яну дәртен бирә иде. Ул һәр образ өстендә ювелир осталыгы белән эшли, аның тирән хасиятен аңларга һәм сәхнәдә гәүдәләндерергә тырыша. Гомумән, Ш. Шамилский тормыш агымын, чор сулышын тиз сиземләп, тирәнтен аңлаган иҗат кешесе булырак, совет сәхнәсендә замандашларыбызның кызыклы образларын иҗат иткән артист.

Мин «Нур» артистларын бала чактан күреп үстем, моның белән үземне бәхетле саныйм. Гыйләҗ Казанский берничә ел бездә фатирда торды. Ул урта буйлы, саргылт чәчле, зәңгәр күзле, кызу йөрүчән чандыррак кеше иде. Аның тавышы көр, матур, дикциясе ачык. Драма артисты буларак та, музыкаль әсәрләрдә дә ул тирән реалистик сәхнә образлары иҗат итте.

Г. Казанский нинди генә труппаларда эшләмәде дә, нинди генә шәһәргә татар театр культурасын алып бармады икән! Уфада «Үрнәк» исемле труппа төзү дисеңме (1922 ел), Омск, Красноярск, Төмән, Семипалат һ. б. шәһәрләрдә труппалар оештыру дисеңме... Ул матур мәгънәсендә артист-гастролер иде.

«Нур» труппасында баштан ук катнашкан Зөләйха Богданова (Болгарская) да 1905 елгы Беренче рус революциясе елларыннан соң сәхнәгә килгән талантлы артистқаларның берсе.

14 яшеннән Крестовников заводында эшләгән Зөләйха 1909—1910 елгы сезонда «Сәйяр» труппасы спектакльләренә актив катнаша башлый. Тагы бер елдан «Сәйяр» труппасы Мәкәрҗә ярминкәсенә барганда үз составына Зөләйха Богданованы да

---

[1] «Аң», 1916 ел, № 16—17.
[2] «Ирек», 1917 ел, 30 март.

[1] «Тормыш», 1918 ел, 28 февраль.

ала. З. Богданова «Нур» труппасы белән дә төрле шәһәрләрдә гастрольләрдә йөри.

Хәзер Татарстанның халык артисткасы Мәрзия Миңлебаеваның да сәхнәгә килүе С. Гыйззәтуллина-Волжская эшчәнлеге белән бәйле.

«Нур»ның төрле җәмгыятьләр файдасына әледән-әле спектакльләр куеп ярдәм итеп торуын да әйтергә кирәк. Шундыйларның берсе итеп, 1918 елның 2 апрелендә Уфаның «Яңа клуб» залында татар халык шагыйре Г. Тукай хөрмәтенә Татар эшчеләре шурасы хозурындагы «Музыка вә драм җәмгыяте» тарафыннан оештырылган кичәдә труппа артистлары да катнашуын күрсәтергә була.

Беренче бүлектә «Нур» труппасы С. Сүнчәләйнең «Музыкант» исемле бер пәрдәле драмасын куя. Икенче бүлектә Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй, Зәки Баязитскийлар Тукайның тәрҗемәи хәленә караган хатирәләрне, аның хатларын һәм шигырьләрен укыйлар. Өченче бүлектә исә яшь җырчы Әминә Бәхтизина тарафыннан милли көйләр җырланып, музыка мөгаллиме немец Вильгельм Клименц җитәкчелегендә «Саз» төркеме тарафыннан милли көйләр һәм «Тукай маршы» башкарыла.

Уфада эшләү дәверендә «Нур» труппасы, шәһәр тамашачыларын театр сәнгатен яратырга һәм аңларга өйрәтеп кенә калмыйча, демократик тәрбия бирү буенча да зур роль уйный. «Нур» труппасы башкорт халкы тормышын чагылдырган пьесалар куярга омтыла. Шуңа да яшь драматург Сөләйманов (Тарский) тарафыннан язылган «Ашказар» исемле драманы артистлар шатланып каршы алалар һәм сәхнәгә кую чарасына керешәләр. «Яңа клуб» залында «Нур» труппасы тарафыннан мәшһүр «Ашказар» көенең вакыйгасыннан алынып язылган «Ашказар» исемле дүрт пәрдәле драма уйнала. Кызганычка каршы, «Ашказар» пьесасы басылмаган, кульъязмасы да сакланмаган. Кыскача рецензия һәм башка чыганакларга караганда, бу спектакль этнографик планда куелган була.

Башкорт дәүләт Академия театры коллективы, Башкортстанның күренекле драматурглары, артистлары һәм җәмәгать эшлеклеләре татар сәнгать осталарының аларга күрсәткән зур ярдәмен хөрмәт белән искә алалар. Мәсәлән, РСФСР һәм Башкортстанның халык артисты Әмин Зөбәиров С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның һәм аның иптәшләренең Уфа сәхнәсендәге хезмәтләренә бәя биреп: «Татар сәхнәсенең кадерле әнисе Гыйззәтуллина-Волжская, Шакир Шамилский, Маһирә Мирвәлиева, Фатыйма Ильская, Локман Антовларның башкорт сәхнәсендә тудырган образлары безнең һәркайсыбызга иҗат үрнәкләре булып торалар...» [1],— дип язды. Шагыйребез Г. Тукайның «Театр яктылыкка — нурга илтә»... дигән сүзләрен истә тоткан хәлдә, без бүген татар сәхнә сәнгатен оештыруда башлап йөргән, шул юлда фидакарьлек күрсәткән иҗат әһелләренең исемен чын күңелдән ихтирам белән телгә алабыз.

**ХӘСӘН ГОБӘЙДУЛЛИН,**
**сәнгать фәннәре кандидаты.**

---

[1] «Совет Башкортстаны», 1957 ел, 24 май, № 120.

# ТӨСЛӘРДӘ — КҮҢЕЛ ЯКТЫСЫ

*Харис Якуповка — 60 яшь*



Харис Якупов иcеме сәнгать сөючеләрнең һәр вакыт игътибар үзәгендә. Бу бик табигый хәл. Җыр-музыканы яратасыңмы, яки әдәбиятка гашыйкмы син — Харис Якупов әсәрләрендә сәнгатьнең бу төрләре һәммәсе дә чагылыш таба. Һәрхәлдә, рәссам шуңа омтыла. Халкыбыз җырларындагы тирән моң да, мәкаль-әйтемнәргә тупланган зирәклек тә бар...

РСФСР халык художнигы, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты Харис Якуповка быел алтмыш яшь тулды. Күпме вакыйгалар шушы гомергә сыйган, күпме эш эшләнгән. Казанда үткән бала чак еллары, Казан сәнгать училищесында укыган чаклар... Иҗат итәргә тулы мөмкинлекләр ачылгач кына, кинәт Бөек Ватан сугышы башлана. Һәм Харис Якупов сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә. Ләкин рәссам кәгазь-каләмен, буяу-пумалаларын бервакытта да үзеннән калдырмый. Фронт газеталары өчен сатирик рәсемнәр ясый, көндәлекләр алып бара. 1942 елны Харис Якупов КПСС сафларына баса. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Харис аганың күкрәген Ленин ордены, Кызыл йолдыз ордены, II дәрәҗә Дан орденнары бизи.

Алтмыш яшь. Рәссам белән очрашканнан соң мин моңа ышанмыйчарак тордым. Самими күз карашы, балаларча елмаюы аңа алтмыш яшьтер дип уйларга һич кенә дә ирек бирми. Мәктәп укучысыдай, «Пионер каләме»нә (хәзерге «Ялкын» журналы), «Яшь ленинчы» газетасына рәсемнәр ясар кебек ул. Менә ничә еллар узса да, Харис ага «Пионер каләме» уздырган конкурсларны бүгенгедәй хәтерли. Шул журналда алган иң ул беренче чыныгуларны. Аннары Казан Пионерлар сараендагы рәсем түгәрәгенә йөргән. Сәнгать училищесында укыганда исә, талантлы рәссам Нәбиулла Вәлиуллин яшь Хариска нәкыш сәнгатенең серләрен ача, олы сәнгать дөньясына алып чыга торган юлны күрсәтә ул аңа.

Сугыштан соңгы чорларда Харис Якупов тарихи темаларга мөрәҗәгать итә. Әле сәнгать училищесында укыган елларында ук диплом эше итеп ул милли азатлык көрәшенә багышланган «Бунт» картинасын яза, 40 нчы елларның икенче яртысында халкыбызның үткәндәге тормышын яктырту нияте белән күп кенә тарихи портретлар ясый. Алар арасында бөек шагыйребез Габдулла Тукай, атаклы язучы Шәриф Камал, Максим Горькийның яшь вакытын — Алексей Пешковларны очратабыз. «А. С. Пушкин Казан юлында», «Горький Марусовкада», «Тукай крестьяннар арасында» кебек картиналар совет нәкыш сәнгатендә лаеклы урын алдылар.

Харис Якуповның Бөек Ватан сугышы чорларын чагылдырган картиналары байтак: «Туган илдә», «Төп көчләр өзеклеккә керә», «Азатлыкка очу (Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев батырлыгы)», «Хөкем алдыннан (Советлар Союзы Герое Муса Җәлил)». Соңгысына аерым тукталып үтәсе килә. Муса Җәлилнең немец-фашистлар концлагерендагы батырлыкларына багышланган «Хөкем алдыннан» картинасын караганнан соң совет кешесенең корыч ихтыярына кем генә сокланмады икән?! Дошманнар коммунист йөрәген бернинди җәзалау алымнары белән дә буйсындыра алмыйлар. Герой-шагыйрьнең йөзендә совет халкының җиңүгә ышанычы балкый.

Харис Якупов 50 нче елларда Лотфулла Фәттахов белән бергә эшли. Аларның зур хезмәте — «В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» картинасы СССР Дәүләт премиясенә лаек булды. Картинада 20 нче еллардагы татар интеллигенциясенең гомумиләштерелгән образлары урын алган. Бөек юлбашчыбыз татар делегатлары белән сөйләшә. Владимир Ильич — гади, һәм бер үк вакытта аның бөтен дөнья турында кайгыртучан уйлар белән яшәүче даһи икәнлеген тоясың.

Рәссам зур полотнолы әсәрләр язу белән берррәттән графикага да мөрәҗәгать итә. 60 нчы елларга кадәр ул Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан бик күп китапларны рәсем белән бизи. Классиклардан А. С. Пушкин, В. Г. Короленко, Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ә. Фәйзи китапларына һәм «Татар халык әкиятләре» җыентыгына иллюстрацияләр ясый. Шушы хезмәтләрен югары бәяләп, аңа Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Харис Якупов — реалистик сәнгать вәкиле, совет нәкыш сәнгатенә зур өлеш керткән рәссам. Абстракционистларга һәм футуристларга аның үз мөнәсәбәте бар. Мәсәлән, «Уйлану. Тереләр һәм үлеләр» картинасын гына алып карыйк. Әлеге картина капиталистик илләрдә шактый киң таралган ялган сәнгатькә протест булып яңгырый. Яшь кенә кыз һәм өлкән генә агай чынбарлыкны бозып күрсәткән сыннар, рәсемнәр янында уйланып торалар. Бу сыннар кешеләрнең күңелен төшерә, аларның теләкләрен һәм өмет чаткыларын сүндерә. Әлбәттә, бераү дә сәнгать әсәрләреннән андый хис, фикер алырга теләми. Рәссам үзенең картинасында шуны раслый.

Рәссам бик еш кына хезмәт халкы тормышын, алар башкарган күркәм эшләрне сурәтли. Менә шундый картиналар сериясе 60 нчы елларда языла. Авыл эшчәннәренең тормышын өйрәнә ул, Питрәч районының Вахитов исемендәге колхозында колхозчылар белән бергә яши һәм иҗат итә. «Дуңгыз караучы М. Галиуллина портреты», «Көчле кешеләр (сыер савучылар Ф. Гәрәева, М. Исламова, С. Сәгъдиева)», «Алдынгы терлекчеләр — көтүчеләр Н. Җиһаншин, Ш. һәм Г. Шакировлар» һ. б. картиналар нәкъ менә шул чорда языла.

1976 елны Харис Якуповның «Чаллы сылулары» һәм «Алдынгы терлекчеләр — көтүчеләр Н. Җиһаншин, Ш. һәм Г. Шакировлар» дигән картиналары РСФСРның И. Е. Репин исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Харис Якупов иҗатында лениниана аеруча күркәм урын алып тора. Бөек юлбашчының яшьлеген чагылдырган «Пролог (В. И. Ульянов Казан университеты студентлары сходкасында. 1887)» әсәрен барыбыз да яхшы беләбез. Үзәктә — студент Ульянов. Аның күзләрендә — ышаныч, чөнки аның фикерен меңләгән студентлар хуплый, бу хәрәкәт бөтен Россиягә җәелер, эшчеләр, крестьяннар аның сүзен ишетер һәм Ульянов йөзендә үзенең яклаучысын табар.

Әле шушы көннәрдә генә рәссам «Пролог» картинасының дәвамын тәгәлләде. Картина «Зур Идел» күргәзмәсенә куелачак. Рәссам ару-талуны белми, һаман да илһамланып иҗат итә. Күп санлы истәлекләре, хезмәттәшләренең иҗатына күзәтүләр нәкъ шул турыда сөйли. Әмма аның төп хезмәте — нәкыш. Киндерләргә салыначак төсләргә күңел яктысын бирергә тырыша Харис Якупов.

**ХӘЙДӘР ГАЙНЕТДИНОВ.**

# КИҢЛЕК ҺӘМ КЫЮЛЫК ЮЛЫННАН

*Философия фәннәре докторы Яхъя Абдуллинга — 60 яшь*



Гыйлем мәйданы — көрәш мәйданы да. Һәр гыйлем иясе — шул көрәшнең сугышчысы. Кешелек тарихы һәр яңа сүз, һәр үзенчәлекле фикернең көрәшсез пәйда булганын белми. Алдынгы караш, алга әйдәгән фикер өчен сөрелгәннәр, башлар киселгән. Кеше аңы борын-борында кан белән бәйле. Биологиясе белән генә түгел, идеологиясе белән дә.

Бүген бу көрәшне иң югары ноктасында тора дию хата булмас. Идеология көрәшенең импульслары атом-төш коралларын җибәрә торган кара яисә кызыл төймәләрне тибрәндереп тора. Халыкның ук та үтерә, сүз дә үтерә дигәненең бүгенгедән дә ачыграк аңлашылганы булмагандыр. Сүзнең, фикернең җаваплылыгы гадәттән тыш артты.

Яхъя Абдуллинның гыйльми эшчәнлеге дә чорның, халыкның шушындый таләбе белән үлчәнә ала. Эшчәнлеге генә дә түгел. Тормышы, гомере дә. Мөхәммәдъяр, Курсави, Мәрҗани, Насыйри, Күлтәси, Тукай, Ямашев, Ф. Әмирхан, Җәлил һәм башка бик күпләр кебек асыл затларның сүзен, эшен, тормышын өйрәнеп, аң-белем мирасларын җиткерүгә ул чын мәгънәсендә галим-көрәшче булып керешкәннәрдән берсе. Бу гыйлем ияләренең һәркайсы милләтебез һәм илебез халыкларының күңел бакчасындагы олы фикер агачлары сурәтендә күзаллана. Яхъя Абдуллин менә шул агачларны (һәркайсын!) карап-тәрбияләп торучыны хәтерләтә. Шулай булмый икән, халыкның рухи дөньясы кайдадыр китек күренәчәк, сүзе өзек калачак. Ул аларның һәркайсы өчен, һәр сүзе өчен көрәшергә әзер. Коммунист буларак, Яхъя Абдуллинның шушыңа иманы камил. В. И. Ленинның, гомумән коммунист яки революционер булу гына җитеп бетми, һәр моментта чылбырның үзенчәлекле бер бүлемтеген таба белергә кирәк,—аны бар көч белән эләктереп, бөтен чылбырны тотарлык һәм алдагы бүлемтекләргә күчәрлек булсын, дигән фикере бар. Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Ш. Күлтәсидәй гыйлем ияләренең һәркайсы — әнә шундый тоташ чылбырның аерым бүлемтекләре. Һәм аларның алдынгы фикерләре татар халкының рухи дөньясы күгендә тагын да яктырак нур чәчә башлауга ул җитәкләгән иҗтимагый фикер тарихы секторы һәм Г. Ибраһимов исемендәге тарих, тел һәм әдәбият институты (СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы) зур өлеш кертте. Бу нисбәттән Яхъя Абдуллинның «Татар мәгърифәтчелеге фикере» дигән китабы (1976) һәм докторлык диссертациясе Татарстанның фән, культура җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну уятты, олы бәягә лаек булды.

Галимнең гомерендәге иң олы хезмәте булган бу китапның үзенчәлекле яклары нидән гыйбарәт?

Ул XIX гасыр татар мәгърифәтчелегенең бөтен фәлсәфи мирасын беренче тапкыр фәнни системалап, марксизм-ленинизм тәгълиматы яктылыгында аларның фәлсәфи-социологик карашларын тикшерә. Мәгърифәтчеләрнең татар иҗтимагый фикерендәге урынын билгели. Күренекле гыйлем ияләренең мирасына яңача якын килә, яңа исемнәрне яңача күтәреп чыга.

Бу хезмәт — аның күп еллык фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсе. Философия фәннәре докторы профессор К. Фасеев белән берлектә язылган «Чернышевский һәм татар иҗтимагый фикере» (1978) дигән брошюрасы, фәнни җыентыкларда, республика һәм үзәк матбугатында басылган күп санлы хезмәтләре Я. Абдуллинны киң эрудицияле галим, кыю фикерле кеше итеп танытты.

Әлеге киңлек һәм кыюлык—аның хезмәт сөючән, тормышта үз урынын һәр вакыт таба белгән, кешеләргә игелек кылырга омтылган холык-фигыленең көзгедәгечә чагылышы.

Уналты яшеннән район газетасы хезмәткәре, комсомол активисты, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре—аның ихтирамга лаек хезмәт биографиясе юлы. Испания республикасын яклар өчен интернационал бригадага алуларын үтенеп, Советлар Союзы Маршалы К. Е. Ворошиловка язган үтенеч, ак финнар белән булган сугышка җибәрүләрен сорау һәм Бөек Ватан сугышында Сталинград, Ленинград, Беренче Белоруссия фронтларында батарея комиссары, рота командиры урынбасары, дивизион парторгы сыйфатында Эстония, Польша аша үтеп, Берлинны штурмлауда катнашу — аның хөрмәткә лаек сугышчан юлы. Яралангач, аны 1942 елда ук сугышта катнашудан азат итәргә телиләр. Ләкин ул—«Коммунистлар, алга!» дигән бөек боерыкны үзенең намус теләге сыйфатында кабул иткән партия сугышчысы—ирекле төстә тагын фронтка җибәрүләрен үтенә. КПСС Үзәк Комитетының Иҗтимагый фәннәр академиясенә аспирантурага укырга керүдән башлап, философия фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу — аның олылауга лаек фәнни юлы.

Ул—Татарстан язучыларының күптәнге якын дусты: ничә ел дәвамында инде ТАССР Язучылары союзының философия семинарын алып бара, журналыбызның һәр чак көтеп алына торган авторы.

Калган вакытларда ул—театрда, концерт залларында, якташлары—Саба район хезмәт ияләре арасында. Танышасыгыз килсә, сез аны тиз танып алырсыз: бәйрәмнәрдә ул ике «Кызыл йолдыз» орденын, бер дистә медален таккан булыр; күренмәсәләр дә, фронт яралары белән бөтен тәне тулганлыгы да сизелеп куяр; күзгә иң ташланган сыйфаты—тыйнак, көләч, игътибарлы, ярдәмчел булыр.

**Ә. РАХМАН**

## Сабир (Мирза Алекпер Таирзадә),

Әзербәйҗан шагыйре

1862—1911

*Сәүдәгәр семьясында туа, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнеп мәдрәсәдә, аннары шагыйрь Сәид Ширвани мәктәбендә укый. Яшьлек елларында лирик шигырьләр яза, фарсы классик шагыйрьләрен тәрҗемә итә. 1906 елда Бакуда «Мелла Насретдин» исемле сатирик журнал чыга башлагач, «Һөдһөд» дигән кушамат белән дини фанатизм һәм борынгы йолаларга каршы, халыкны мәгърифәткә һәм азатлыкка чакырып сатирик шигырьләр яза башлый.*

### Буйвол

Буйволы була берәүнең. Сөт эчеп ята.
Бүтәннәргә шул сөтне ул су кушып сата.

Бер җәйне яңгыр башланып ишә дә ишә.
Килере кимегән хуҗа кайгыга төшә.

Кала шул зур су астында кырлар һәм болын
Шушы су агызып китә аның буйволын.

Елый хуҗа: «Беттем... Беттем»... Бүтән сүз әйтми,
Ә улы әйтә аңарга: «Кичер! Түз, әти!

Сөтенә күпме су куштың, син беләсеңме?
Һәм менә бәлагә тардың—күр күрәсеңне.

Бел, сөткә кушкан су басты бар тирә-якны,
Акты каралты-куралар, буйволың акты.

Язмышны каргама, әти, бу кайгың өчен—
Бәхетсез көнне китерде үз көчең, эшең!»

## Врач һәм сырхау кеше

Елап килә берәү: «Ярдәм итче, доктор!
Нидер булды... һич тә түзәр хәлем юктыр.
Борып-борып эч авырта. Ай, ай, үләм!..
Исән калсам иде синең ярдәм беләң!»
Доктор аның пульсын тыңлый, эчен капшый.
«Иртән нәрсә ашадың?» дип сорый катгый.
Әйтә сырхау: «Тәңре шаһит—алдау юктыр,
Нәни телем көйгән икмәк каптым, доктор...
Шуннан артык ашамадым бер нәрсә дә...»
Доктор өчен ачыклана бер мәсьәлә
Һәм... ала ул күз даруы—үз-үзенә
Бик ышанып, «хәзер салам, ди, күзеңә».
Әйтә аннан: «Әгәр яхшы күрсә күзең,
Яман ризык капмас идең... Син бит үзең
Тинтәк җансың... Синдәй затлар булсын сирәк.
Әйдә, эшне күздән башлыйк—шулай кирәк!»

# Кристионас Донелайтис,

Литва шагыйре

1714—1780

*Көнчыгыш Пруссиядә крестьян семьясында туа. Кенигсбергта ярлылар өчен мәктәп һәм университет тәмамлый. Башта укытучы, соңыннан пастор була. Литва матур әдәбиятын башлап җибәрүчеләрнең иң күренеклесе. «Ел фасыллары» дигән зур поэмасы күп телләргә тәрҗемә ителгән. Үткен мәсәлләре, матур шигъри хикәя фрагментларының кулъязмалары сакланган. Үзе исән чакта бер генә әсәре дә басылмаган.*

## Мактанчык Имән

Бер капкорсак Имән булган,
Мактанган: Җил егалмый!» — дип,
Масайган: «Миңа куна,—дип,—
    Кыю бөркет, җитез тилгән...»
Чыршы, Нарат, Юкә, Талны
Танымаган, санламаган—
Ул аларның барчасына
    Өстән карап, ачы көлгән.

Бер читтә, кысан канауда,
Хәтта җиңел җилдән куркып,
Тирбәлгән ялгыз Камышны
    Күргән дә капкорсак Имән

Аны мәсхәрәләп көлгән:
«Дуга булып бөгеләсең!
Беләсеңме, син көчсез бит
Бик күп миллион тапкыр миннән!»

Ә көлә башлагач, Күкнең
Үзенә үк тел тидереп,
Җыелып килеп бөтен яктан
Җилләр аңа һөҗүм башлый.
Һәм тәкәббер мактанчыкны
Җир өстенә егып давыл,
Йолкып ата тамырларын,
Ябалдашын өзеп ташлый.

Камыш әле һаман исән—
Җилләр белән сәламләшә.
Үсә ул һаман чайкалып
Үзенең тар канауында.
Ә имән дөрес дөмекте!
Сәбәбе—көн кебек ачык!—
Фәкыйрь, көчсезләрдән көлеп,
Үзен өстен санавында.

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Сәлим Шәйдуллин

## МӘСӘЛЛӘР

### Читкә кагылган Чәчәк

«Кортларга бал, еланнарга агу бирә.
Икейөзле, яратмыйбыз шуңа күрә!» —
Дип, бер төркем
Бөҗәкләр бер көн
Чәчәктә ышанычсызлык күргәннәр
Һәм аңардан йөз чөергәннәр.
Моны үзенчәрәк аңлаган күрше Үлән
Чәчәктән болай дип көлгән:
— Ай-һа-ай, күрше,
Нинди көлке хәлгә калганыңны күрче!
Сиңа хәзер ни диясе?
Икейөзле булгач, күпме җан иясе

Үзеңне бит эһ тә итми ташлап китте!
Ялгызлыкка дучар итте!
Хурлыгыңнан булмыйсың син ничек харап??
— Ник хурланыйм? Ташласыннар!—дигән Чәчәк,—
Мин шуны беләм: моңа карап
Минем бәһам төшмәячәк.
Чөнки сафлыкка юк минем һичбер үчем—
Яшим тик яхшыга хезмәт итү өчен!
Ә миндәге матурлык матдәләреннән
Кем дә кем файдалана икән
Яман эштә,
Монысына инде, иркәм,
Мин гаепле түгел һич тә!

## Әһлиулла һәм Барабан

«Житте! Тыел! Интектермә безнең жанны!
Тавышыңнан инде тәмам колак тонды!»—
Дип, әй кыйнады Әһлиулла Барабанны...
Ә Барабан... аның саен тавышланды!

Котылыйм дисәң Барабан тавышыннан,—димәк,
Аны кыйнаудан туктарга кирәк!

## Марат

Нәни Марат яшел тышлы Карандашны
Төсле карандашлар тартмасына салды,
Фәкать тышкы билгесенә карап кына.
Ә карандашның үзәге яшел түгел, гади иде.

Бәлки эшләмимдер мин әллә ни зур эш
Язып монда бала ялгышуы хакында?
Әмма шундый хәл очрый еш... олыраклар арасында.

## Туры сүз

Мәжлестә утырган чакта бергә күшәп,
Чалыш авызлы Маэмайга әйтте Ишәк:
— Кыек авыздан туры сүз чыгарга мөмкинме, туган?
Маэмай жавап бирде исе китмичә бик:
— Ниндирәк колак белән тыңлыйсың бит?!

# 1979 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

*«1979 ел өчен Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында» КПСС өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары. № 6.*

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Хәсәнов М. Х. **Социалистик реализм һәм татар совет әдәбияты мәсьәләләре. № 4.**
**Бүгенге поэзия турында сөйләшүгә йомгак. № 5.**
**«Замандаш» конкурсы йомгаклары. № 5.**

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Ахунов Г. **КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында Татарстан әдәбияты проблемалары. № 11.**
Вәлиев М. Ф. **Иҗатка — таләпчәнлек. № 11.**
Галиев Ш. **Балалар — тормыш чәчәкләре, җимешләре нинди булыр! № 11.**
Зарипов М. **Заман һәм традицияләр бәйләнеше. № 11.**
Маликов Ә. **Һәр вакыт юлда. № 11.**
Михалков С. **Эшлекле сөйләшү. № 11.**
Мәһдиев М. **Ике съезд арасында әдәби тәнкыйтьнең үсеше. № 11.**
Нури З. **Тагын да кыюрак адымнар белән. № 11.**
Паушкин Г. **Алга барырга кирәк. № 11.**
Расих А. **Прозабыз турында. № 11.**
Юзеев И. **Шәҗәрәнең очы кемнәрдә! № 11.**
Юзиев Н. **Хәзерге татар совет поэзиясенең үсеш тенденцияләре. № 11.**
Әхмәдуллин А. **Татар драматургиясенең хәзерге хәле. № 11.**
**Съезд кабул иткән карар. № 11.**

1979 ЕЛ — ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР ЕЛЫ

Миңнуллин Р. **Качышлы уйнаганда.** Шигырьләр. **№ 10.**
Мәхмүтов М. **Сабыйларның бәхете хакына. № 10.**
Нури З. **Зурлар турында... нәниләр.** Шигырьләр. **№ 10.**
Шәфигуллин Ф. **Ерактамы, якындамы!** Хикәя. **№ 10.**
**«Ялкын» журналы битләреннән. № 10.**
**«Яшь ленинчы» газетасы битләреннән. № 10.**

ПРОЗА

Батулла. **Яшенле яңгыр койганда.** Хикәя. **№ 12.**
Баянов Ә. **Аязучан болытлы һава...** Повесть. **№ 2.**
Вергазов А. **Нәзер.** Повесть. **№ 6.**
Галиев М. **Ул чакта...** Повесть. **№ 1.**
Гаффар Ә. **Бер йотым су.** Хикәя. **№ 12.**
Еники Ә. **Тынычлану.** Хикәя. **№ 3.**
Касыймов Э. **«Ахири» дуслар.** Әкият. **№ 4.**
Маликова М. **Янартаулар яктысында.** Повесть. **№ 11.**
Маннапов Ш. **Чехолдагы ракеталар.** Хикәя. **№ 5.**
Минский Г. **Хикәяләр. № 10.**
Мирхәйдәров Р. **Көтеп алынган сәфәр.** Повесть. **№ 4.**
Мәһдиев М. **Таңы ерак төндә.** Хикәя. **№ 6.**
Нуруллин В. **Аккан су юлын табар.** Повесть. **№ 4, 5.**
Побережный Р. **Зәңгәр конверт.** Хикәя. **№ 2.**
Расих А. **Сынау.** Роман. **№ 7, 8, 9.**
Сөләйманова С. **Гөлбадран.** Повесть. **№ 2, 3.**
Хуҗин М. **Керәшче.** Хикәя. **№ 7.**
Хәбибуллин М. **Хәтер ярлары.** Повесть. **№ 10, 11.**

Шәмин Ә. **Яңа язлар.** Повесть. № 12.
Шәмси С. **Сагыну.** Хикәя. № 6.
Юныс М. **Табу һәм югалту.** Повесть. № 7.
Әмир М. **Үсә төшкәч.** Автобиографик повесть. № 1.

## ПОЭЗИЯ

Арсланов Н. Яшә, илем! Шигырьләр. № 5.
Афзал Г. **Канәгатьсезлек хисе.** Шигырьләр. № 4.
Булатова К. **Апрель керде җиргә.** Шигырьләр. № 3.
Гатауллин Р. **Яңа шигырьләр.** № 8.
Дәүли Н. **Хатлар килә миңа...** Шигырьләр. № 8.
Закиев Р. **Кояш иңгән аяз алан.** Шигырьләр. № 12.
Игәнәй Я. **И гүзәл гамь.** Шигырьләр. № 2.
Латыйп Г. **Апрель бирде безгә Ленинны.** Шигырь. № 4.
Латыйп Г. **Күңелдә — яз.** Шигырьләр. № 11.
Латыйпов К. **Яктылык тизлеге.** Шигырьләр. № 12.
Маликов Ә. **Медальләр.** Шигырьләр. № 2.
Мансуров З. **Вакыт агышы.** Шигырьләр. № 11.
Миңнуллин Р. **Мәңгелек сәфәр.** Шигырьләр. № 5.
Мәхмүдов Ә. **Хезмәт яме.** Шигырьләр. № 12.
Низамиев Р. **Идел.** Шигырьләр. № 4.
Нури З. **Яз дәфтәреннән.** Шигырьләр. № 5.
Рәхим Г. **Кара әле, Тукай, Казаныңа.** Шигырьләр. № 4.
Рәшитов Ә. **Талпыну.** Шигырьләр. № 12.
Садә Г. **Бүләккә атәч.** Шигырьләр. № 10.
Сафин Ф. **Алма бакчасында.** Шигырьләр. № 8.
Сөләйманов Б. **Казаннан китәр алдыннан.** Шигырьләр. № 10.
Сөләйманова С. **Сабыр канатларым.** Шигырьләр. № 12.
Төхфи Х. **Робагыйлар.** № 5.
Фәйзуллин Р. **Яңа шигырьләр.** № 1, № 10.
Харис Р. **Тынычлык таләп итәм.** Шигырьләр. № 6.
Хәким С. **Яңа шигырьләр.** № 2, № 9.
Шакирҗанова Л. **Без — хатын-кызлар ич.** Шигырьләр. № 3.
Юнысов Р. **Элемтәчеләр.** Шигырьләр. № 1.
Әгъләмов М. **Кайдадыр күктә кояш...** Шигырьләр. № 6.
Әминева Н. **Иң кирәклесе.** Шигырьләр. № 12.
Әхмәтҗанов Роберт. **Интернационал.** Шигырьләр. № 1.
Әхмәтҗанов Рәшит. **Кыска шигырьләр.** № 5.
Әюпов Х. **Тик без генә.** Шигырьләр. № 8.
Яруллин Ф. **Юл сайлау.** Шигырьләр. № 6.

## КЛАССИК ПОЭЗИЯДӘН ҮРНӘКЛӘР

**Һенрих Һейне шигырьләре.** № 10.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Бәширова Ф. **Кояшым.** Шигырьләр. № 4.
Гадел Ә. **Кызыма.** Шигырьләр. № 7.
Галиев М. **Атлантида.** Шигырьләр. № 7.
Закиров Х. **Өянкеләр шавы.** Хикәя. № 12.
Зәйдуллин Р. **Алмагач.** Шигырьләр. № 7.
Зөлкарнәев Л. **Бәй өченмени ат — бәйге өчен.** Шигырьләр. № 7.
Рәкыйпов Р. **Диңгезче дәфтәреннән.** Шигырьләр. № 7.
Рәхимова Б. **Идел өсте күк томан.** Шигырьләр. № 4.
Садриев Ф. **Гадәти иртә.** Хикәя. № 5.
Шаһимәрданов М. **Югалган кыз.** Хикәя. № 5.
Әхмәдиев Н. **Мин — Җирнеке!** Шигырьләр. № 7.

## ДУСЛАР ИҖАТЫ

Дәүләтов Г. **Туган моңнар.** Шигырь. № 7.
Мамбет Б. **Ана һәм Ватан.** Шигырь. № 8.
Тимеркыя Ю. **Вәгъдәсе бар икән.** Шигырь. № 8.
Фазыл Р. **Низамига.** Шигырь. № 8.

Хәлим А. Гарсиа Лорка авазы. Шигырь. № 7.
Черкез-Али. Мин октябрь баласы. Шигырьләр. № 8.
Шәми-Задә Ә. Бер тамчы су. Шигырьләр. № 8.
Әмин С. Җивана. Шигырь. № 8.
Әхмәтхуҗин Ә. Алсу кош турында. Шигырь. № 7.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Гыйләҗев А. Без уникe кыз идек... Драма. № 9.
Миңнуллин Т. Яшьлегем — юләрлегем... Пьеса. № 6.

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Латыйп Г. Безнең сыер. Шигырьләр. № 2.
Миңнуллин Р. Мияулый торган ишек. Шигырьләр. № 3.

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Басыйров Х. Больницага эләктем. № 7.
Галиев Ш. Хикмәтле сүзләр. № 3.
Кальметов С. Дустымның фәрештәсе. № 5.
Кашфелзадә. Йокысыз төн. № 4.
Миңнуллин Т. Вәхшиләр. № 4.
Монасыйпов В. Исеме булсын сәүдәгәр. № 7.
Нури З. Иң яхшы сый. Шигырьләр. № 9.
Сабиров Ф. Тапшыру. № 7.
Садыйкова А. Уйнап әйтсәң дә, уйлап әйт. № 6.
Туктар И. Егет белән кыз. № 4.
Тәрҗеманов Җ. Мин язуны ничек ташладым. № 8.
Шаһгалиев Р. Дүртьюллыклар. № 5.
Шәйдуллин С. Мәсәлләр. № 12.

## МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Кристионас Донелайтис. Мактанчык имән. № 12.
Лафонтен мәсәлләре. № 3.
Лессинг. № 5.
Сабир (Мирза Алекпер Таирзадә). Буйвол... № 12.
Украин халкы һәм әдипләре иҗатыннан. № 8.

## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Абдуллин М. Татар эшчеләр хәрәкәте һәм «советология». № 10.
Байтимеров Р. Туган як җылысы. Шигырьләр. № 11.
Биктимерова Т. Егерменче елларда хатын-кызлар хәрәкәте. № 10.
Бәширов Г. Кара төндә нур чәчеп... Хикәя. № 8.
Каюмов М. Юлда. Шигырь. № 11.
Максудов Р. Камада ак пароход. Очерк. № 9.
Маннапов Ш. Син шундый җир. Шигырьләр. № 11.
Мөхәррәмов М. Ленин декреты белән. № 7.
Сибгатуллин К. Кешеләрнең барын танып йөрим. Шигырьләр. № 9.
Хамматов Ш. Сугышта сыналган әдәбият. № 8.
Хәлиуллина Р. Бәби мунчасы. Шигырь. № 9.
Әхмәтҗанов Роберт. Республикам шагыйрьләре. Шигырьләр. № 10.

## ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Атнабаев Ә. Горурлык. Шигырь. № 3.
Бикбаев Р. Башкортстан монда башлана. Шигырь. № 3.
Биккол Ш. Озата кил. Шигырь. № 3.
Гали М. Ышанам. Шигырь. № 3.
Гыйләҗев Х. Әҗәл белән айкашканда. Шигырь. № 3.
Исәнголов Ф. Агыйделнең аръягында... Хикәя. № 3.
Кудаш С. Гомер сөрәсем килә. Шигырь. № 3.
Кәрим М. Туган илем! Шигырь. № 3.
Мирзаһитов Ә. Бөек Октябрь һәм Башкортстан әдәбияты. № 3.

Назаров Р. Башкорт. Шигырь. № 3.
Нәҗми Н. Башкортстан. Шигырь. № 3.
Рамазанов Г. Дурт мәхәббәт. Шигырь. № 3.
Хисаметдинова Р. Буранбай. Шигырь. № 3.

ӘДӘБИ БӘЙРӘМНӘР



## Габдерәхим Утыз Имәнинең тууына 225 ел

Шәрипов Ә. Кереш сүз. № 10.
Габдерәхим Утыз Имәнинең тапкырлыгы, үткенлеге, зирәклеге турында риваятьләр. № 10,

## Дәрдмәнднең тууына 120 ел

Халит Г, Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе. № 12

## Г. Камалның тууына 100 ел

Мәһдиев М. Г. Камал «Йолдыз»да. № 1.
Хамматов Ш., Мөбәрәкшин Ф. Әдип һәм татар матбугаты. № 1,
Ханзафаров Н. Гаризалар ни сөйли! № 1.
Хәсәнов М. Х. Татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы. № 1,
Еникеев Ш. Ягымлы тавышы әле дә яңгырый кебек... № 1,
Ишморат Р. Таланты алдында баш иеп. № 1.
Камалова Р. Әтиемне мин ничек хәтерлим. № 1.
Әмири К. Әдип тормышыннан берничә сәхифә. № 1.

## Г. Сәгъдинең тууына 90 ел

Бариева Э. Галим һәм тәнкыйтьче. № 3.

## Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына 90 ел

Мөхәммәт М. Тукайның садә дусты. № 8.

## Нәкый Исәнбәткә 80 яшь

Редакцион мәкалә. № 12.
Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик әйтемнәрендә тарихилык һәм үткән белән хәзергенең чагылышы. № 12.

## Ф. Кәримнең тууына 70 ел

Кәрим Ф. Сөйләр сүзләр бик күп алар... Шигырьләр. № 1,
Минский Г. Шагыйрьнең яшьлеге. № 1.
Юзеев И, Озын гомерле шагыйрь. № 1.

## Әмирхан Еникигә 70 яшь

Сафиуллина Ф. Рухи матурлык җырчысы. № 3.

## Габдулла Шамуковка 70 яшь

Редакцион мәкалә. № 12.
Шамуков Г, Мәсәлләр. № 12.

## Шәрәф Мөдәрриснең тууына 60 ел

Госман Х, Шагыйрь үткән юллар. № 11.

## Мостай Кәримгә 60 яшь

Баянов Ә. **Мәкалә. № 10.**
Кәрим М. **Ашыкма килергә, картлыгым.** Шигырьләр. **№ 10.**

## Ә. Давыдовның тууына 60 ел

Баянов Ә. **Вакыт сурәтләре. № 3.**

## Шәриф Хөсәеновка 50 яшь

Миңнуллин Т. **Драматург. № 11.**

## Шамил Рәкыйповка 50 яшь

Редакцион мәкалә. **№ 9.**
Рәкыйпов Ш. **Кайдан син, Жан!** Повесть. **№ 9.**

## И. Кәлимуллинга 50 яшь

Редакцион мәкалә. **№ 3**
Кәлимуллин И. **Бунтарь портреты янында.** Поэмадан өзек. **№ 3.**

### ОЧЕРКЛАР

Гәрәев М. **Академик. № 1.**
Зарипов М. **Ут бригадиры. № 4.**
Зарипов М. **Яңа эш — киң колач. № 7.**
Зарипов И. **Хыяллар остасы. № 6.**
Зарипов И. **Уренгойның ак боланы. № 12.**
Ихсанова Л. **Стелла — йолдыз дигән сүз. № 3.**
Насыйбуллин М. **Чакырылган кунак. № 10.**
Рафиков М. **Суда балык йөздер. № 12.**
Сирай Д. **«Элемтәгә чыгам». № 5.**
Тимбикова К. **Казан кызлары. № 2.**
Шакир С. **Утлы еллар әле дә хәтердә. № 2.**
Шакир С. **Чемпион кыз Галимә. № 5.**
Юсупова Р. **Чәчәкләр бәйләме. № 11.**
Әйди Т. **Атомны йөгәнләүче. № 8.**

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. **Кешелеклелек өчен көрәшү. № 10.**
Залесская Л. **Чорлар аша үтеп киләчәккә. № 6.**
Ивлев Г. **Рөстәм Кутуйның лирик прозасы. № 10.**
Кедрина З. **Социалистик реализм күп милләтле совет әдәбиятының уртак казанышы. № 6.**
Мостафин Р. **Каләм очында — КамАЗ. № 7.**
Мусин Ф. **Тарихилык юлыннан. № 6.**
Муханов Г. **Әдәби процесс һәм социалистик яшәү рәвеше. № 10.**
Нәгъмәтуллина Й. **Әдәбият галимнәренең Бөтенсоюз киңәшмәсе. № 6.**
Низамов И. **Публицистикага кыюлык һәм осталык. № 7.**
Хангилдин В. **Әдәби телебезне тагын да камилләштерик. № 12.**

### БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Мансуров З. **Йөрәк уйлый да белсен. № 3.**
Низамиев Р. **Шагыйрьләргә заман текәлгән. № 2.**
Сөләйманова С. **Шагыйрь — заман баласы. № 2.**
Хәким Сибгат. **Җәлилләр ачкан юлдан. № 4.**

Хәйдәрова Л. **Кем соң син, замандаш. № 4.**
Әхмәтҗанов Роберт. **Төп юнәлеш — кешене саклау. № 4.**
**Укучылардан хатлар. № 3.**

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Булатов Ф. **Батырларга дан җырлап. № 6.**
Бәшәров Р. **Күңелемә алам яктылык. № 4**
Вәлиев М. **Тынгысызлык уты. № 5.**
Вәлиев Мөдәррис. **Дөньяның гамьнән башка яме юк. № 2.**
Галимуллин Ф. **Әдәбият фәне үсеше турында. № 8.**
Госманов М. **Мираска ихтирам. № 12.**
Зарипов Х. **Бу — безнең туган халкыбыз. № 3.**
Миңнул Г. **Беренче карлыгач. № 1.**
Мостафин Р. **Аналарның чәче ник агара! № 10.**
Мөхәммәдиев Р. **Якутлар табыладыр вакыт белән. № 3.**
Мәхмүтов Х. **Бурнаш белән яңадан очрашу. № 1.**
Нәбиев Р. **Матбугатыбызның үсеш юллары. № 4.**
Поварисов С. **Яшерен касса. № 7.**
Хисамов Н. **Яңарыш чишмәләре. № 10.**
Хәйретдинов Р. **Җитди хезмәт. № 2.**
Әгъзәмов Ф. **Сүздән һәйкәл. № 7.**



## СӘНГАТЬ

Монасыйпов Ш. **Татар скрипка сәнгате. № 2.**
Фәйзуллаева М. **Халык музыкасы һәм композитор. № 6.**
Харис Р. **Татарстан артистлары Италиядә һәм Мальтада. № 8.**
Әйди Т. **Тылсымлы сурәтче. № 3.**

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Булатов Ә. **«Нужа калач ашата». № 2.**
Гобәйдуллин Х. **Яктылыкка — нурга илтә. № 12.**
Гәрәй И. **Чөйгәне шоңкар булган. № 2.**
Кадыйров И. **Себер татарлары музыкасы. № 4.**
Кудашев Г. **Камиллек һәм нәфислек юлыннан. № 2.**
Яфаров Л. **Тукайча тәгәллеккә. № 2.**
Җамалетдинов Л. **Тукай һәм әдәби әкият. № 4.**

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Булатов Ә. **Мәгърифәтче язучы Гариф Чыкалый. № 5.**
Гайнетдинов М. **Дастаннар китабы. № 10.**
Клипиницер М. **Муса Җәлил «Орлес» заводында. № 9.**
Мәхмудов Ә. **«Моабит дәфтәрләре»ндә эстетик идеал гәүдәләнеше. № 9.**
Хамматов Ш. **«Миллионнарның бәйлә йөрәген...» № 4.**
Хәкимов Р. **Әдәбиятыбызда интернационализм идеяләре. № 7.**
Шәрипов Р. **Мөхәммәдьяр иҗатында бәхет мәсьәләсе. № 3.**
Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М. **Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссасының татарча варианты. № 6.**

## ӘДӘБИ ОСТАЛЫК ТУРЫНДА

Хөсни Ф. **Орлыкпар кая төшә...** Этюдлар. **№ 5, № 8.**

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Гайнетдинов Х. **Төсләрдә — күңел яктысы. (Х. Якуповка 60 яшь.) № 12.**
Насыйров Т. **Ямашевның туганы, Тукайның дусты. № 5.**
Рамазанов Т. **Якты эз. (Б. Әлменовның якты истәлегенә) № 8.**
Рахман Ә. **Киңлек һәм кыюлык юлыннан. (Я. Абдуллинга 60 яшь.) № 12.**
Фәттах. **Эшчән һәм турылыклы дустыбыз. № 3.**
Шакирова-Таһирова О. **Профессор Таһиров. № 6.**

Ш и р и я з д а н о в Р. **Яхъя Халитовка 50 яшь. № 10.**
Ә й д и Т. **Тылмач кына түгел. № 10.**
Редакцион мәкалә. **Кыям Миңлебаевка 50 яшь. № 6.**
М и ң л е б а е в К. **Тәрҗемә үрләре. № 6.**
Редакцион мәкалә. **Юл дәвам итә.** (Тәнкыйтьче Роберт **Бикмөхәммәтовка 50 яшь.) № 1.**

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Г а д е л Ә. **Керәшен татарларында көн-ай атамалары. № 6.**
Г а л и е в А., М а к с и м е н к о В. **Шагыйрьнең абыйсы. № 5.**
З ә б и р о в И. **Җәлилнең сабакташы. № 5.**
С а т т а р о в Г. **Исемнәребез бакчасында. № 6.**
С ә й ф е т д и н о в А. **Керәштә балкыган гомер. № 10.**
Җ ә л ә л о в Х. **Ерак араларны якын итеп. № 5.**

Безнең сафка. № 4, 10.

Укучылар сүзе. № 2, № 7, № 9.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—10, № 12.

## ҖЫРЛАР

Ә г ъ з а м Ф ә т т а х музыкасы, С и б г а т Х ә к и м сүзләре. **Әй, Казан. № 3.**
Р и н а т Е н и к е е в музыкасы, Җ ә у д ә т Д ә р з а м а н о в сүзләре. **Солдат булдым. № 10.**
Ф е р д и н а н д Г а л ә м и е в музыкасы, Р ә ш и т Ә х м ә т җ а н о в сүзләре. **Ерак юлга чыгасың, егет. № 12.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Шушы елның август аенда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең һәлак булуына 35 ел тулды. Шул уңай белән Казанның Яшьләр үзәгендә укучылар конференциясе уздырылды. Казан китап сөючеләр җәмгыяте оештырган бу кичәдә драматург Риза Ишморат үзенең Җәлил белән очрашулары турында, язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин «Герой шагыйрь эзләре буйлап» исемле китабын ничек язуы турында сөйләде. Татарстанның атказанган артисткасы Хәдичә Гыйниятова белән М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры җырчысы Зилә Сөнгатуллина Җәлил сүзләренә язылган җырларны башкарды.

Конференциядә катнашучылар патриот-шагыйрь турында фильм карадылар.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ОТЧЕТЫ

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышында язучы Фаил Шәфигуллинның иҗат отчеты тыңланды. Язучылардан Мирсәй Әмир, Роберт Миңнуллин һәм Зөлфәт Ф. Шәфигуллинның прозасына, балаларга атап язган әсәрләренә, шулай ук шигырьләренә һәрьяклап анализ ясадылар.

Фикер алышуларда Фатих Хөсни, Нури Арсланов, Рәйсә Ишморатова, Мөдәррис Әгъләмов һәм Саимә Ибраһимова иптәшләр катнашты. Алар язучының иҗатына нигездә уңай бәя бирделәр, теләк-фикерләрен әйттеләр, уңышлар теләделәр.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — АВЫЛДА

КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары уңае белән, «Казан утлары» журналы Питрәч районының Мулланур Вахитов исемендәге колхозын шефлыкка алган иде. Сентябрь аенда колхозның Культура йортында журнал редакциясе хезмәткәрләре һәм авторлары белән кызыклы очрашу булды. Журнал турында, бүгенге татар әдәбияты турында барган бу сөйләшүдә журналның әдәби тәнкыйть бүлеге редакторы, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев хәзерге әдәби процесста журналның тоткан урыны хакында әйтеп китте, журналның авторлары белән, киләсе елда басылып чыгачак яңа әсәрләр белән таныштырып үтте. Журналның җаваплы секретаре, язучы Кояш Тимбикова укучыларга журналның ничек чыгуы турында, журналга язылу тәртипләре турында сөйләде, үзенең яңа хикәясен укыды. Поэзия бүлеге редакторы Рәдиф Гатауллин, хатлар бүлеге редакторы Роберт Миңнуллин, проза бүлеге редакторы Марсель Галиев кичәгә җыелган авыл эшчәннәренә шигырьләрен, хикәяләрен укып күрсәттеләр.

Кичәдә Татарстан китап нәшриятының баш редакторы, язучы Вакыйф Нуруллин да катнашты. Ул моннан берничә ел элек «Күпер чыкканда» исемле повесте өчен М. Вахитов исемендәге колхоз премиясенә лаек булган иде. Язучы әлеге кичәдә үзен премия белән бүләкләгән колхозчылар алдында иҗат отчеты ясады, үзенең соңгы вакытта язган әсәрләре белән таныштырды, авыл эшчәннәренә уңышлар теләде.

Кичәнең соңгы өлешендә Татарстанның атказанган артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина чыгыш ясады. Аның җырлавын тамашачылар яратып тыңладылар.

Соңыннан М. Вахитов исемендәге колхоз председателе Фәйзерахман Сафин кичәдә катнашучыларга рәхмәт белдерде. Ул сүзен: «Безнең колхозчыларыбыз әдәбият-сәнгать белән кызыксыналар, китапларны, газета-журналларны яратып укыйлар. «Казан утлары»н аеруча кызыксынып укып баралар. Быел «Казан утлары»н колхозның һәр хуҗалыгы алдырыр дип ышандырабыз!» — дип тәмамлады.

Журнал хезмәткәрләре моннан соң да шушындый кичәләрне ешрак уздырырга булдылар.

## «ЯЛКЫН»ГА БАГЫШЛАНГАН КОНФЕРЕНЦИЯ

Арча педагогия училищесында «Ялкын» журналына багышланган укучылар конференциясе булды. Училище студентлары журнал битләрендә дөнья күргән әсәрләрдән өзекләр укыдылар, Госман Бакир, Мәхмүт Хәсәнов, Роза Хафизова, Җәмит Рәхимов повестьларын яратып укуларын әйттеләр. Булачак педагоглар шулай ук журнал күтәргән проблемалар хакында да фикер алыштылар, уй-теләкләре белән уртаклаштылар.

Конференциядә журналның баш редакторы Р. Хафизова, җаваплы секретарь Р. Вәлиев, бүлек редакторлары Ф. Сафин, Х. Гайнетдинов катнашты.

## ОЧРАШУЛАР

КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарын тормышка ашыруга өлеш кертү нияте белән бер төркем язучылар Алексеевск районында булып кайттылар. Анда шагыйрьләр Рәшит Гәрәй, Хәкимҗан Халиков, Разил Вәлиев, Фәнвур Сафин һәм Әхмәт Гадел катнашты. Шагыйрьләр районның уилап хуҗалыгында булдылар, авыл хезмәтчәннәрен үз иҗатлары белән таныштырдылар, колхозчыларның хезмәте һәм тормышы белән кызыксындылар.

* * *

Язучылар Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев, Әхмәт Сәйфетдинов һәм җырчы Миңгол Галиев Кукмара районының фабрика цехларында, тулай торакларында эшчеләр белән очрашулар үткәрделәр, колхозларда әдәби-музыкаль кичәләр уздырдылар, авыл хезмәтчәннәре алдында әсәрләрен укыдылар, әдәбиятыбызның бүгенге торышы белән таныштырдылар.

* * *

Шагыйрьләр Мәхмүт Хөсәен, Рәдиф Гатауллин, прозаик Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм Татарстанның атказанган артисты Шамил Әхмәтҗанов Зеленодольск районының «Искра», «Совет», Ленин исемендәге, Вахитов исемендәге, Ильич исемендәге колхозларында булдылар. Алар кыр станнарында, җәйләүләрдә, культура сарайларында игенчеләр, терлекчеләр белән очрашулар уздырдылар.

* * *

Язучылар Риза Ишморат һәм Рәйсә Ишморатова Чистай районының «Дружба», Киров исемендәге колхозларында, Бахта һәм Мөслим авылында колхозчылар белән очрашу кичәләре уздырдылар, үзләренең иҗатлары белән таныштырдылар, авыл тормышы белән кызыксындылар.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫНА БАГЫШЛАП

Татарстан Язучылар союзы каршындагы шагыйрьләр секциясенең бюро утырышы булды. Бюро членнары яшь шагыйрь Хәйдәр Гайнетдиновның шигырьләрен укып тикшерделәр. Чыгыш ясаучылардан Нури Арсланов, Әхсән Баян, Рәдиф Гатауллин, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов яшь шагыйрь иҗатындагы уңай һәм кимчелекле якларны билгеләп үттеләр, киңәшләр бирделәр. Бюро утырышы, Х. Гайнетдиновның кулъязма җыентыгын, нигездә, китап нәшриятына тәкъдим итәргә мөмкин, дигән карарга килде.

## ИҖАТ ЯШЬЛӘРЕ ЮГОСЛАВИЯДӘ

Татарстанның бер төркем яшь язучылары, шагыйрьләре, артистлары, журналистлары Югославиядә булып кайттылар. Алар Белград, Сараево, Байна Башта, Дубровник шәһәрләре белән таныштылар, «Бечиче» халыкара яшьләр лагерында булдылар. Иҗат яшьләре арасында шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Җәүдәт Дәрзаманов һәм язучы Әхәт Гаффар да бар иде.

## ЯЗУЧЫ БАМ ТӨЗҮЧЕЛӘРЕ ЯНЫНДА

Язучы Самат Шакир җәй айларында БАМ төзүчеләр белән бергә Якутия АССРның Беркатит поселогында инженер-төзүче булып эшләде, очрашуларда катнашты. Биредә 1977 елда Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемен алу өчен көрәшүче бригада төзелгән иде. С. Шакир бригада членнарына Казан бүләкләре тапшырды. Комсомол-яшьләрне коммунистик рухта тәрбияләүдәге хезмәтләре һәм төзелештә турыдан-туры катнашуы өчен «Якутия яшьләре» исемендәге төзү-монтаж поезды идарәсе язучы Самат Шакирны «Почетлы төзүче» итеп алды, Мактау грамотасы тапшырды.

## «СИВАШЛЫЛАР КӨРӘШТӘ һӘМ ХЕЗМӘТТӘ»

Әрмәнстанның башкаласы Ереванда «Айастан» нәшрияты кызыклы китап бастырып чыгарды. Ул, 1918 елда Идел буенда оешып, гражданнар сугышы елларында һәм Бөек Ватан сугышы фронтында дан казанган мәшһүр Сиваш дивизиясенең 60 еллык көрәш юлын яктыртуга багышланган. Китапта егерменче елларда дивизия газетасының редакторы булган күренекле язучы Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Леонид Леоновның котлау хаты бирелгән. Сиваш дивизиясенең элекке сугышчысы күренекле язучы Гомәр Бәширов та әлеге китапта полкташ иптәшләренең кадерле истәлегенә багышланган очерк белән катнаша.

## ЯШЬЛӘР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Киевтагы «Днепро» нәфис әдәбият нәшриятында «Сузирчя» («Йолдызлык») дип аталган җыентыкның чираттагы китабы (украин телендә) басылып чыкты. Анда тугандаш республикалардагы яшь шагыйрьләрнең һәм язучыларның иң яхшы әсәрләре урнаштырылган.

Җыентыкта татар әдипләреннән Әхәт Гаффарның «Рәхмәт, җир» исемле хикәясе, Равил Фәйзуллин шигыре бар.

Китапны бизәү өчен яшь рәссамнарның картиналарыннан күчермәләр файдаланылган. Алар арасында Татарстанның яшь рәссамы Ф. Якуповның «Җылы җил» картинасы да урын алган.

## ТАТАР ШАГЫЙРЕ — ГАСКӘРИЛӘР ГАЗЕТАСЫНДА

Кызыл Байраклы Урал хәрби округ газетасы «Красный боец»та фронтовик шагыйрь Мөхәммәт Садриның шигырьләре басылып чыкты. Аларны русчага Владимир Савельев тәрҗемә иткән.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА БАГЫШЛАП

РСФСР Язучылар союзы һәм Саратов язучылары оешмасы органы булган «Волга» журналының 6 нчы саны тулысынча Татарстанга багышланып чыкты.

Журнал КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиевнең «Бөек туганлык хисе» исемле мәкаләсе белән ачыла. Биредә Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Михаил Скороходов кебек өлкән шагыйрьләр белән беррәттән, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Равил Бохараев, Шамил Маннапов кебек урта һәм яшь буын шагыйрьләр дә сүз алган.

Прозаиклардан Аяз Гыйләҗев һәм Җәмит Рәхимов повестьлары, Мәҗит Рафиков хикәясе, Марсель Зариповның Казан шәһәре турындагы, Геннадий Паушкинның КамАЗ төзелешенә багышланган очерклары да тәкъдим ителгән.

Журналның «Әдәби тәнкыйть» бүлегендә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахуновның «Татар әдәбияты офыклары» дигән күләмле мәкаләсе урнаштырылган. Сәнгать бүлегендә Ильтани Илялова «Сәхнә остасы» исемле мәкаләсендә СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров иҗатына анализ ясый.

Болардан тыш Гәрәй Рәхим һәм Шәүкәт Галиевнең балалар өчен язган әсәрләре, «Чаян» журналы бездә кунакта» рубрикасы белән журнал авторларының юмористик шигырьләре һәм парчалары бирелгән.

## 1980 ЕЛ КИТАПЛАРЫ

Татарстан китап нәшрияты 1980 елга тематик план бастырып чыгарды. Киләсе елда укучыларыбыз кулына бик күп кызыклы китаплар килеп керәчәк. Түбәндә шул китапларның кайберләре тәкъдим ителә.

Проза китаплары:

Гариф Ахунов. «Йолдызлар калка». Повесть; Әхәт Гаффар. «Бер йотым су». Хикәяләр; Марсель Галиев. «Ул чакта» Повестьлар, хикәяләр; Батулла. «Ташламам, җан кисәгем!». Хикәяләр; Рәйсә Ишморатова. «Чәчәкләр». Повесть, хикәяләр; Шәйхи Маннур. «Чын сөю бармы?» Повесть; Мөхәммәт Мәһдиев «Ут чәчәге». Роман, повесть; Мәдинә Маликова. «Янар таулар яктысында». Повесть; Сажидә Сөләйманова. «Гөлбадран». Повесть; Азат Вергазов. «Гозер». Повесть; Рафкат Кәрами. «Очар кошлар белән янәшә». Повесть; Адлер Тимергалин. «Таш алиһә». Повесть; Барлас Камалов. «Йөрәк давыллары». Повестьлар, хикәяләр; Хәсән Сарьян. «Егет язмышы». Повестьлар; Мәгъсүм Хуҗин. «Урманлы үр». Хикәяләр; Диләрә Зөбәерова. «Яшьләр күңеле». Повестьлар, хикәяләр.

Поэзия әсәрләре:

Рәшит Әхмәтҗанов. «Җан җылысы»; Рәдиф Гатауллин, «Чакыру»; Роберт Әхмәтҗанов. «Хәтер елгасы», Нәби Дәүли. «Мин җирдә калам»; Шәрәф Мөдәррис. «Дуслар күңеле», Зәки Нури. «Шигырьләр, поэмалар»; Хәсән Туфан. «Шигырьләр»; Сәгыйть Рәмиев .«Таң вакыты»; Утыз Имәни. «Шигырьләр, поэмалар»; Гали Хуҗиев. «Шигырьләр, поэмалар»; «Салих Баттал. «Тылсымлы балдак»; «Фәнинур Сафин. «Сез кемнәр?»; Харрас Әюпов. «Ышаныч»; Рашат Низамиев. «Йолдыз яңгыры»; Булат Сөләйманов. «Таңнар фонтаны»; Хисам Камалов. «Аһәң», Мөнир Мазунов. «Ихлас күңелдән», Фәнис Яруллин. «Танышлар арасында».

Балалар өчен шигырь китаплары:

Мәрзия Фәйзуллина. «Болытсыз яңгыр»; Мөдәррис Әгъләмов. «Без, без, без идек»; Заһирә Гомәрова. «Әнис алмасы»; Роберт Миңнуллин. «Җиде абый тай җигә»; Җәүдәт Дәрзаманов. «Төнге маҗара»; Хәкимҗан Халиков. «Уйныйсың киләме?»; Равил Фәйзуллин. «Паласны кем кагар».

Тәнкыйть китаплары:

Азат Әхмәдуллин. «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш»; Миләүшә Маннурова. «Батырлар җыры»; Мансур Хәсәнов. «Интернационализмның җанлы традицияләре»; Ринат Мөхәммәдиев. «Әгәр без язмасак».

Болардан тыш нәшрият планында Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан» исемле пьесалар җыентыгы, Нәкый Исәнбәтнең «Кырлай егете» дигән пьесалар китабы, «Салих Сәйдәшев турында истәлекләр», «Такташ турында истәлекләр», «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән Габдрахман Әпсәләмовның «Болытлар агыла», Фатих Хөснинең «Утызынчы ел», Аяз Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» романнары, Эдуард Касыймовның «Повестьлар»ы кертелгән.

Әлеге китапларны укучылар Казандагы һәм районнардагы китап кибетләреннән сатып ала алалар. Читт өлкәләрдә яшәүче иптәшләргә теләгән китапларын түбәндәге адрес буенча соратып алдырырга була.

420000
**Татарская АССР**
**г. Казань,**
**ул. Октябрьская, д. 18**
**книжный магазин № 14**
**«Книга — почтой»**

## «ЧАЯН»ГА — ДИПЛОМ

«Сатира тынычлык өчен көрәштә» исемле III Халыкара күргәзмә йомгаклары буенча «Чаян» журналы СССР Художество академиясе президиумының дипломы белән бүләкләнде. Күргәзмәдә «Чаян» рәссамнары И. Әхмәдиев, И. Бобровицкий, Л. Бочкова, Ю. Денисов, Л. Елькович, В. Игнатьев, Л. Насыйров, С. Насыйрова һәм И. Хантимеров катнашты.

## СӘНГАТЬ УЧИЛИЩЕСЫ

Кама автомобиль төзүчеләре шәһәре Чаллыда сәнгать училищесы ачылды. Аның музыка, хореография, рәсем ясау бүлекләрендә музыка мәктәпләре укытучылары, бию ансамбле артистлары, дизайнерлар — торак һәм промышленность предприятиеләрен бизәүчеләр әзерләнәчәк.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАНДЫ

ТАССР Эчке эшләр министрлыгы, Язучылар союзы, Композиторлар союзы совет милициясенә багышланган иң яхшы җырларга, марш һәм шигъри әсәрләргә конкурс үткәрделәр.

Җюри җыр жанры буенча композитор Рафаэль Биляловның шагыйрь Рөстәм Кутуй сүзләренә язган «Батырлык җыры»н беренче премиягә лаек дип тапты. Бу җыр батырларча һәлак булган сугышчан комсомол дружинасы члены Артем Айдинов истәлегенә багышлана.


Икенче һәм өченче премияне шагыйрь Мәхмүт Хөсәен («Тоз турында баллада») һәм композитор Рөстәм Яхин белән («Тыныч көрәштә» җыры) Рамазан Байтимеров алды.


Совет милициясенә багышланган маршлар арасында композитор Хәлимә Таҗетдинованың шагыйрә Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язган «Милиционер җыры»на икенче урын бирелде. Конкурс җюрие Илдус Якубовның балаларга багышлап язылган «Шинель» исемле җырына кызыксындыру премиясен бирде.

# ЕРАК ЮЛГА ЧЫГАСЫҢ, ЕГЕТ

ФЕРДИНАНД ГАЛӘМИЕВ
музыкасы

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ
шигыре






Ерак юлга чыгасың, егет,
Давылларммы алда, буранмы?—
Күрсен илең давыллар аша
Синең исән-имин узганны.
Кушымта: Кыю җаның, чая башкаең
Әзер ерак юллар узарга.
Үлемсез дошман бул дошманга,
Үлемсез дус бул син дусларга.
Мәхәббәтең белән юлларда
Бергә барсын нәфрәтең-көчең.
Яратмаслар сине дошманнар,
Үз илеңне яраткан өчен.

Кушымта.

Халык йөрәгеннән көч алып,
Көрәшләрдә өйрән җиңәргә.
Күз алмаңдай сакла илеңне,
Юлдаш булып батыр ирләргә.

Кушымта.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Ак карлары, бәхет-куанычлары белән Яңа ел килде. Бу ел безнең журналны меңнәрчә яңа укучыларга баетты. Январь аеннан башлап алар өенә дә журнал тапшырырлар. 1980 елның беренче аенда чыккан сан укучыларны ни белән шатландырыр соң?

Монда һәр әдәби жанрдан әсәрләр мул итеп бирелгән. Соңгы елларда сирәк чыга башлаган поэма да, роман да, повесть та бар, хикәяләр һәм шигырьләр дә күп.

Күренекле шагыйрь Илдар Юзеевның журналны башлап җибәргән «Мәхәббәт китабы» исемле поэмасы укучы күңеленә, әлбәттә, хуш килер. Чөнки монда һәркемне дулкынландырган, борчып торган әхлак мәсьәләләре күтәрелә. Шагыйрь аларга үзенчә бәя бирә, үзенчә чишелеш эзли.

Мәхмүт Хәсәновның «Шөгеровлар» романы — нефтьчеләр тормышына, ә Барлас Камаловның «Актуган Габсаттары» повесте авыл кешеләре язмышына багышланган. Язучы Б. Камалов үзенең бу повестен 50 яшьлеге көннәрендә тәмамлаган.

Проза әсәрләреннән тагын Г. Әпсәләмовның «Карт мукшы», Х. Камаловның «Куян күзе нигә кызыл?», А. П. Чеховның «Ата», Ф. Яруллинның «Мыштым Гайсә», Н. Акмаловның «Әгәр ышансагыз» хикәяләрен күрсәтергә мөмкин.

Журнал даһи юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга һәм Татарстан төзелүенең 60 еллыгына багышланган әсәрләрне бирүне дәвам иттерә. Бу санда язучы Самат Шакирның БАМ төзүчеләр турындагы очеркы һәм М. Гәрәевнең «Шамил батыр» исемле әсәре басылып чыгачак.

Әдәби тәнкыйть бүлеге дә беренче санда тирән эчтәлекле язмаларга бай. Монда тәнкыйтьче Ф. Миңнуллинның «Яшьлекне сагыну» исемле мәкаләсе, Р. Кукушкинның балалар әдәбиятына багышланган язмасы һәм башка материаллар бар.

Гадәттәгечә, журналда «Сәнгать», «Китап күзәтү», «Безнең календарь», «Безнең сафка», «Мәсәлчеләр мәҗлесе», «Төрлесеннән», «Елмаеп та, көлеп тә...» рубрикалары бар.

Журналның 1980 елгы 1 нче санын әдәбият-сәнгать яңалыклары турындагы кыска хәбәрләр йомгаклап куя.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210